

# КАЗАН УТЛАРЫ

8
АВГУСТ
1981

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

**8**
АВГУСТ
1981

## *Бу санда*

Ә. МАЛИКОВ. Күтәрелеп буразнадан... «Якташлар» циклыннан . . . 3
А. ГЫЙЛӘҖЕВ. Әтәч менгән читәнгә. Повесть . . . 9
Ф. ЯРУЛЛИН. Өйрәт, тормыш. Шигырьләр . . . 88
Р. КУТУЙ. Сөенче. Хикәя . . . 93
Р. ФӘЙЗУЛЛИН. Авыл дәфтәре. Шигырьләр . . . 98

КПССның XXVI СЪЕЗДЫ КАРАРЛАРЫН — ТОРМЫШКА!

Ш. ХӘБИБУЛЛИН, Ф. ӘГЪЗАМОВ. Максатлар бердәмлеге . . . 103

ПУБЛИЦИСТИКА

А. НАГНОЙНЫХ. Братск каһарманы . . . 112

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Р. МӨХӘММӘДИЕВ. Шигъри хәрәкәт һәм аның кайбер тенденцияләре . . . 122
Г. ХАНТИМЕРОВА. Төсләр балкышы . . . 133

КИТАП КҮЗӘТҮ

Р. ӘХМӘТҖАНОВ, Н. ХАНЗАФАРОВ. Тәнкыйть сүзе — кадерле сүз . . . 139
Ф. ГАЛИМУЛЛИН. Яшьләр юлга чыга . . . 140

КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

М. ГОСМАНОВ. Эзләр дастанга илтә . . . 143
Р. ИЛЬЯСОВ. Остаз . . . 148

ТӨРЛЕСЕННӘН

С. ШАКИР. Кызыл чәчәкләр үсәр . . . 151
Р. МӨХӘММӘТҖАНОВ. Кояш белән ай микән . . . 155
М. ШИҺАПОВ. Җанлы курчаклар . . . 159
Н. ИКСАНОВ. Давыл кардәше . . . 167

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

## ӘДИП МАЛИКОВКА 60 ЯШЬ

**Ш. БИКЧУРИН. Озын юллар, ерак еллар арасы** . 172

## БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

**Н. АРСЛАНОВ. Ибраһим Салаховка 70 яшь** . . . 177
**Константин Лебедевка 60 яшь** . . . . . . . 179
**Г. ВАЙДА-СӘЙДӘШЕВА. Рөстәм Яхинга 60 яшь** . 180

## ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

**Н. АРСЛАНОВ. Юмарт дуслар.** Шигырь . . . . 183
**Г. РӘХИМ. Битараф бәндәгә.** Шигырь . . . . . 183
**Ф. ШӘФИГУЛЛИН. Чират.** Хикәяләр . . . . . 184

**Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары** . . . . . . 188

**Баш редактор: ЗӘКИ НУРИ**

Редколлегия: **ШАМИЛ БИКЧУРИН, РАЗИЛ ВӘЛИЕВ, АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ, МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ, ЗӨЛФӘТ, ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН, ТУФАН МИҢНУЛЛИН, РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ** (баш редактор урынбасары), **РӘФЫЙК НӘФИКОВ, АТИЛЛА РАСИХ, КОЯШ ТИМБИКОВА** (җаваплы секретарь), **СИБГАТ ХӘКИМ, ФАИЛ ШӘФИГУЛЛИН, НИЛ ЮЗИЕВ**

---

Техник редакторы *Р. Сөләйманова*
Корректорлары *Ф. Кадыйрова, Т. Шакирҗанова*

---

**Редакциянең адресы:** Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.
**Телефоннар:** баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-61, поэзия бүлеге — 3-07-61, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-63, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Производствога бирелде 27/IV-1981 ел. Басарга кул куелды 16/VII-1981 ел. ПФ 09039. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,2). Тираж 102944 экз. Заказ Д-171. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1981 ел.

Әдип Маликов

# КҮТӘРЕЛЕП БУРАЗНАДАН

«ЯКТАШЛАР» ЦИКЛЫННАН

*Атаклы нефть табу остасы Социалистик Хезмәт Герое Корбан Вәлиев истәлегенә.*

I

Ул чаганнар Чупай-тауда —
Тамырлары таш яра.
Таянып тау иңнәренә,
Үсә Әлмәт — яшь кала.

«Мәскәвский» биек йортлар
Тора күккә тезәлеп.
Монда көн-төн үз ритмына
Тибә Девон йөрәге.

Сары чәчле сәрбиләрне
Ияртеп артларыннан,
Атлый миләш, алмагачлар
Урамның як-ягыннан.

... Урыйм Әлмәт урамнарын,
Тынгы тапмый җаныма.
Барып чыгам искәрмәстән
Иске Әлмәт ягына.

Аеру кыен хәзер бездә
«Иске» белән яңаны.—
Тоташтыра шул ук урам
Авыл белән каланы.

Уты-суы — барсы уртак,
Өйләрендә газ дөрли,
Бер уйласаң, безнең якта
Мондый авыл азмыни?!

Исемен саклап киләчәккә,
Шәһәр синнән аралды.
Тыеп булмый үсү көчен
Таза булса яралгы.

Читтән килгән күпме «яу»ны
Сыендырдың куеныңа.
Хезмәт иттең ул чагында
Кунак өе урнына.

Бу тирәкләр мәңгелектән
Үсеп чыккан диярсең.
Кичергәннәр ут-давылны,
Күргән алар күрәсен.

Әлмәтнең бар үз тарихы,
Елъязмасы — ташларда.
Әлмөхәммәт[1], сине монда
Нинди җилләр ташлаган?

Почта ачкан, нигез корган,
Олы җанлы ир булган.
Ач-ялангач качакларга
Җан башыннан җир бүлгән.

Киң Россия үзәгеннән,
Түзми изү-талауга,
Киткән күпләр оя эзләп,
Чиксез сахра, далага.

---

[1] «Әлмәт» шул исемнән кыскартып алынган.

Уза авыл уртасыннан
Ак каенлы олы юл.
Бер өяздән — бер өязгә
Юк аннан да туры юл.

Спас җиткәч, күңелле чак —
Ярминкәләр башлана.
Тальян гармун өздергәндә
Күзләреңнән яшь тама.

Биеп тора баскан җирдә
Сембер аргамаклары.
Әлмәт урманнары аша,
Яшерен юллар салып узган
Мәшһүр ат караклары.
Елык-елык камзуллары,
Казан кәләпүшләре.
Тынгы бирми сабыйларга
Сары хөрмә төшләре.

Миңлебай[1]лар үр меңәләр,
Тәягәннәр чабата.
Аркан ишеп, чыпта сугып,
Кич була да таң ата.

Аллы-гөлле, юкә чуклы —
Бигәш эшлияләре...
Хакына күрә — товары,
Табыла иярәре.

Тимерчеләр бизмән ясый,
Төртке-төртке сaплары.

Бизмәндә үлчәп тапканын,
Яши Әлмәт яклары,

Язмышы Иске Әлмәтнең
Булмаган бик җиңелдән.
Ничә кабат үкереп янган,
Ничә кабат терелгән.

Илдә чыпчык үлми диләр,
Дәртең булсын яшәргә.
Һөнәрчеләр чана тартып,
Чыккан ерак сәфәргә.

Җылытыйм дип башкаларны,
Сөендереп аларны.
Тегүчеләр келтер-келтер
Аттыралар таңнарны.

«Юлларыңда алтын алма
Өзсәң иде үрелеп».
...Җиде кат җир асларында
Ята алтын күмелеп.

Таптап йөри бай-ярлысы,
Буйлар җитми тирәнгә.
Әкияттәге Алып-батыр
Килмәгән бу тирәгә.

Һөнәре ата-бабаның
Таләпчән еллар аша,
Сайланып та, чарланып та
Бүгенгегә тоташа.

2

Табылмаса миллион еллар
Посып яткан җир мае,
Әлмәтең дә, КамАЗың да
Тумас иде, мөгаен.

Тумасын ләкин ни генә,
Башлана ул хыялдан.
Безнең бу көннәр турында
Ленин куптән уйланган.

Геологлар адым саен
Тоеп Ильич карашын,
Айкап йөри үҗәтләнеп,
Идел-Урал арасын.

Кремльгә килә Губкин,
Ә кулында — ком ташы.

Күзен кысып, иснәп, капшап,
Карый ташны юлбашчы.

Дегет исе... димәк, нефть!
Мең мәртәбә без хаклы!
Наркомфинга чаба галим,
Ычкындырмый форсатны.

Безнең буын мич янында
Күмер ашап йөргәндә,
Фән дөньясы, тиргә батып,
Девон серен өйрәнә.

Аклады бөек өметне
Идел-Урал буйлары.
...Ир-егетләр, торып-торып
Сезгә кайта уйларым.

---

[1] Миңлебай — авыл.

Мотаһарлар, Михаиллар,
Гобәйдуллин Әхәтләр [1] —
Сез килгәнсез бу дөньяга
Иң хәерле сәгатьтә.

Чияле тау итәгендә
Юл ачканда Девонга,
Соңгы борау — соңгы өмет
Була Әхәт кулында.

Ялгый аны, эчтән генә
Кабатлап бисмилласын.
Белгәннәр гүя Әхәтнең
Кулы җиңел буласын.

Дулый тере кара фонтан —
Ул үзен раслый, димәк.
Дөрли факел — бу якларга
Бәхетле язмыш теләп.

Чөяләр күккә чиратлап
Әхәтне, Степан [2]ны,
Гөнаһ түгел күтәрсәң дә
Тутырып стаканны.

Беренче Девон фонтаны
Зиһеннәрне чуалтты.
Беренче Девон фонтаны
Күзен ачты бу якның.

Очрашканда Әхәт белән
Берәр олы табында,
Яки газет чиратында —
Киоскылар янында,

Кыска гына бер арада
Сорашабыз хәл-әхвәл.
Корбан ага Вәлиевне [3]
Искә алабыз иң әвәл.

Дуслар идек. Утырганнар
Күз алдымда хәзер дә.
Елады ул бер кичәдә,
Үткәннәрне хәтерләп.

Тормыш кичү — уен түгел,
Белә үзе татыган.
Савапларың, гөнаһларың
Калмый йөри артыңнан.

Чын исеме Ногман булган
Киткән чакта авылдан.
Ә соңыннан ил телендә
Корбан булып танылган.

И, бормалы-бормалы
Иске Чаллы юллары.
Язмыш Кама ярларына
Алып килә Ногманны.

Әти-әни, туганнары —
Төялгәннәр бер атка.
Аргы якка паром көтеп,
Баса алар чиратка.

Ат ите пешә учакта.
Күктә — кошлар гаугасы...
Сары комда, моңаешып,
Кала камыт, арбасы.

Арбадан төшүгә сине
Алган тормыш суырып.
Йөрткән кайнар табасында
Борчак кебек куырып.

Җаннарыңны айкап ала
Пароход тавышлары.
Кала Шишкин урманнары,
Таңда сайрар кошлары,

Даны чыккан ачлык ел бу,
Халык тифтән кырыла.
Ленин ничек борчылмасын
Якташлары турында?!

Икмәк бара баржаларда,
Үтә аның әмерен.
Ага Идел, белеп кенә
Изгелекнең кадерен...

Әчтерханда — «оҗмах», имеш,
Тамак туяр ничек тә.
... Үзенекен итми калмый
Язмыш сиңа үчексә.

Котырына ваба чире.
Әти-әни, туганнар
Төшерелә бер кабергә...
Ногман — ялгыз. Урамда

Ниләр кылсын ятим бала,
Эчтә бүре уласа?
Башкаеңны кукрәгенә
Куяр кеше булмаса?

Йөри торгач «әлеп-чәлеп»,
Эш табыла алай да,—
Яллана тамак хакына
Бистәдәге бер байга.

---

[1] Девон нефтен ачучы, Бөтенсоюз рекордлары куючы бораулау осталары Мотаһар Нургалиев, Михаил Белоглазов, Социалистик Хезмәт Герое Әхәт Гобәйдуллиннар.
[2] Кузьмин Степан — шул чактагы бораулау мастеры.
[3] Атаклы нефть табу остасы, Социалистик Хезмәт Герое.

Ишетмичә бер җылы сүз,
Көн үтсен дә ай үтсен.
Уйнамасын, көлмәсен дә,—
Эшләп байны баетсын,

Уч төбедәй кәгазь алып
(Никтер «Корбан» диелгән),
Китә малай типке астыннан,
Рәнҗү саклап күңелдә.

Ногманмы син, Корбанмы син,—
Талаучыга барыбер.
Килер бер көн, әле шулар
Ялчыларга ялыныр.

Кушыла да үз ишенә,
Тая таулар иленә,
Грозныйда йөри Корбан,
Калып сөяк-тирегә.

Кемдер сала иңбашына
Авыр итеп уң кулын.
— Качу турында уйлама,
Атлавыңны бел, улым..

Картузында йолдыз яна,
Әллә күктән атылган?
Чекист дигән абыйларны
Күрә шунда якыннан.

Яшә, диләр, коммунада,—
Бөтенесе гел бушка,
Каян килгән мондый хөрлек,
Кем боерган, кем кушкан?

Ленин үзе кушты, диләр,
Күрсәтәләр рәсемен.
«Чәлеп» йөрү һөнәр түгел,
Долой иске кәсебең!

Алга икмәк куйсалар да —
Күз алдында шул рәсем...
(Сөяк куллы ачлык-патша
Җанга үткән, күрәсең).

«Әти сыман, сөеп карый,
Йөзе шундый мөлаем.
Минем ятим икәнемне
Белгәндер ул, мөгаен».

Торба ташый промыселга;
— Аткайларым, на-на-на!
Уен гына кебек бу эш
Нужа күргән малайга.

Ут уйната Али-оста,
Мактауга ул бик саран.
Ә шулай да Корбан исеме
Төшми кызыл тактадан.

— Оператор итәм сине,
Синдә гайрәт җитәрлек,
Өйрәтермен, булсаң гына
Мине узып китәрлек!

Сатылмый алтын-көмешкә
Намус дигән төшенчә.
Җаны чиста булса гына
Яши кеше кешечә!

Корбан инде үзе оста,
Эстафета — яшьләргә,
Искә төшсә үткәннәре,
Күзе һаман яшьләнә.

Аталарча, шелтәләп тә,
Мактап кирәк урында,
Кайгырта ул башкаларны,
Онытып үзе турында.

Иле йокы күрмәгәндә,
Йокы алмый аны да.
Илне сөю — сүздә түгел,
Яши аның канында.

Мылтык тотып илен саклый
Йөзен куя ялкынга.
Үтә сират күперләрен,
Тугры калып антына.

Табылмаса миллион еллар
Посып яткан җир мае,
Әлмәтең дә, КамАЗың да
Тумас иде, мөгаен?!

Кайтып төшәр иде микән
Корбан ага Майкоптан?
Хәйран калып йөри оста
Девондагы байлыкка.

Барып чыга авылларга,
Тарантаска утырып.
Булмый ялгыз башың гына
Мондый эшкә тотынып.

— Я, кем кели бригадама?!
— Сәер кеше син, абзый,—
Ышандырып кара әвәл
Председатель Минһаҗны!

Колхоз өчен җаны фида,
Чукын дисәң — чукыныр.
— Китү уен сизсә мәгәр —
Йодрыклап тотыныр.

— Кырда эшләр бетеп торса —
Юл тушәргә чыгабыз.
Кышкылыкка утынга дип,
Чаж-чож урман егабыз...

Тыңлый Корбан, уйлый Корбан:
«Нәкъ шундый бит үзем дә,—
Ялгамыйча очын-очка,
Йокы керми күземә».

— Нефте бармы — бар да булыр,—
Ышаныгыз Корбанга.
Газ җылытса авылларны,
Исән калыр урман да.

Ярамый, дуслар, тормышны
Гел бер җайга сөрәргә.
Байлык өстенә утырып,
Мөмкин ачтан үләргә.

Академик Губкин кушты,
Ленин кушты, иптәшләр.
Белмәсәгез — өйрәтербез,
Сезне гаеп итмәсләр...

Онытмый яхшы хуҗалар
Алачык — бирәчәкне.
Минһаҗның да баш йомыры,
Уйлый ул киләчәкне.

Астыңнан алтын тапсалар —
Булмас та кысылмыйча...
Янәшә аккан елгалар
Калмый ул кушылмыйча.

Ил тотынса — әйе, булыр,
Җәйрәп ятыр юллар да.
Туачак яңа гигантлар
Мохтаҗ безнең кулларга...

Егетләре сөлек кебек:
Кызлар — һушың алырлык,—
Нәфес колы булмыйм дисәң —
Кирәк кырыс сабырлык.

Тау буенда культбудкасы,
Йөри Корбан шатланып:
Ашкындырып тирә-юньне,
Ата девон фонтаны!

Кайда кыен — урыны шунда,—
Бар булганын калдырып,
Күчә яңа мәйданнарга,
Яңа юллар салдырып.

Үтәр еллар, кемдер әйтер:
Хәл ителгән дип сана,—
Корбан будка куйган саен
Туа тора яшь кала.

Берни түгел исбатлавы,
Кирәк икән дәлилләр:
Ил каршында балкый Әлмәт,
Азнакайлар, Җәлилләр!

Ә хәзергә тар сукмаклар,
Сөт һәм ипи сумкада...
Җылыта матур хыяллар
Ачык кырда кунсаң да.

Өлгермәгән салырга да
Яшел гимнастеркасын.
Мондый гына авырлыкка
Чыдар солдат җилкәсе.

Аксап куя тешен кысып,
Сырлы таяк кулында.
Чәрдәкләнгән тез капкачы
Даулы Берлин юлында.

Усаллансаң көч тә арта,
Батырлык чикләнмәгән.
Сынатмадык, өстебездән
Танклар үткәндә дә.

Үзми калмый тоткан җирдән,
Алынса әгәр Корбан.
Йөрәгеңне аямаска —
Калышмыйм дисәң чордан!

Дус-ишләр килә өмәгә
Идел, Кавказ, Уралдан.
Кайта илен, җырын сагынып
Читтә йөргән туганнар.

Ана сөте белән иңгән,
Кан кайнаткан җыр бит ул.
Туган якны сагыну хисе —
Барсыннан да зур бит ул.

Бәхет эзләп киткәнсез дип
Кем гаепләр аларны?!
Кем төзегән Уралмашны
Данлы Магнит — каланы?!

Баш калкытып буразнадан,
Җиргә гашыйк кешеләр
Күтәрә нефть чирәмен,
Таянып ил көченә.

Тарта алар заман йөген,
Тарта төпкә җигелеп.
Чын хуҗасы булса гына
Күрсәтә җир игелек.

Сары чәчле сәрбиләрне
Ияртеп артларыннан,
Атлый миләш, алмагачлар
Урамның як-ягыннан.

Дәшә мине, колач җәеп,
Геройлар аллеясы,
Зурлап батыр якташларны,
Килә башны иясе.

— Саумы, Әхәт! Галстукның
Иң «модныен» таккансың,
Сайлый-сайлый ачкычларын,
Ачтың Девон капкасын.

Син ялгаган теге борау
Инде күптән музейда.
Укыйсың исемең тарихтан,
Ышанмыйча үзең дә.

Йөзендә Корбан аганың
Җыерчыклар дулкыны.
Башка булмас икәү генә
Сайрашыплар утырып.

...Туктап тордык Яр Чаллыда,
Узышлый, төнлә генә.
Уйга калдың яр башында,
Таянып иягеңә.

Алда КамГЭС балкый дөрләп,
Сулда КамАЗ ухылдый.
Калкып чыкты үткәннәрең,
Теләгеңә буйсынмый.

Министрдан алган бүләк —
Яныбызда «газигың».
Әйттең кинәт: «Ярда калган
Шул арбаны тап идең»...

Сигнал бирде шунда «КамАЗ»,
Узган чакта яныңнан.
Корбан ага, синең кулдан
Күпме гигант кабынган!

Совет миллионеры диеп
Әйтә идек үзенә.
Ташып торды, елга сыман,
Ул тудырган хәзинә.

Яши белде ул мавыгып,
Мавыгып бала сыман.
Күтәрелде парламентка
Гадиләр арасыннан.

Инде болар ил агасы,
Инде барсы титуллы.
Килә көчле дулкын булып
Комсомоллар токымы.

Корбан ага кебекләрнең
Ялкынлы варислары.
Үзебезнең каннан күчкән
Уңыш һәм ялгышлары.

Яшь бер чибәр автобуста
Урын бирсә елмаеп,
Күңел рәнҗи: «Мин картмыни?»
Куям кинәт тураеп:

Ә ул чибәр эш урнында
Шундый җитди... усал да.
Я инженер, яки техник...
Урнын бирмәс кусаң да.

«Дуслык юлы»на да хуҗа
Чәчәк сыман шул кызлар.
Алларында, күз кысышып,
Җем-җем итә йолдызлар.

Шаулый һаман ат бурлары
Качып йөргән урманнар.
Җир байлыгы ташый бүген
Алар йөргән юллардан.

Якташларның бу бүләге —
Ватаныма тугрылык:
Төзи, бизи, киендерә,
Җанга күчә җыр булып.

Ашыктыра моторларны,
Калаларны җылыта.
Төяп дуслык экипажын,
Йолдызларга юл тота.

Тапканын хәзер бизмәндә
Үлчәми безнең яклар.
Нинди үлчәүләргә сыйсын
КамАЗ кебек гигантлар!

Чикләнмәде республикам
Миллиардлар яулап кына,—
Нур өсти Девон сулышы
Халкымның талантына!

Җир байлыгы — Ил байлыгы
Эзләмәгән — югалтыр.
Илең көчле булса гына
Сиңа сан бар. Син — батыр!

*Әлмәт, 1980*

***Производствода һәм көнкүрештә кешеләрнең үзара мөнәсәбәте, шәхеснең катлаулы эчке дөньясы, тынгысыз планетабызда аның урыны — болар һәммәсе художество эзләнүләре өчен бетмәс-төкәнмәс өлкә.***

**Партиянең XXVI съездына КПСС Үзәк Комитетының Отчет докладыннан.**

Аяз Гыйләҗев

# ӘТӘЧ МЕНГӘН ЧИТӘНГӘ...

ПОВЕСТЬ

I

Һай, биек тә соң Сәләхетдиннәрнең читәне! Бер иш юанлыктагы, гел бер буй чикләвек чыбыкларыннан җил үтмәслек тыгыз итеп үрелгән, исең китәр! Әнә, житез генә күтәрелеп килгән кояшның кылыч нурлары, читәннең тар ярыклары аша көчкә-көчкә кысылып үтеп, җиргә зәгыйфь кенә ак шадралар сузганнар. Түшен киереп, тамак асты алкаларын селкетеп йөргән кызгылт гаярь әтәч бүген әллә ничә мәртәбә шушы читән янына килеп карады, әмма очып кунарга йөрәге житмәде. Келәт алдындагы буш ялгашны чукып маташкан тавыклар ишегалдына таралыштылар, җим эзләгән күзләре читән тирәсендә уралган әтәчкә төште. «Әһә!» диделәр алар, бер-берсенә горур хуҗаларын күрсәтеп, «әтәчебезнең болдыр култыксасына басып кычкырганы бар, лапас өрлегеннән аваз салып таңны уята, өй кыегына сөялгән биек баскычны бар дип тә белми... Инде бу читән башына менеп тә бер тавыш бирсә, бөтен дөнья әтәчләренең котын алачак!»

Әтәч тә юләр түгел, тәҗрибәсе һәм куәте бар, ишле кәнизәкләренең ни көткәнен күз карашларыннан сизде, тавыклар аның дәрт-дәрманын көчәйтеп, кырлый-кырлый, читән күләгәсендә сырпаландылар. Ниһаять, әтәч тәвәккәлләде — ишегалдын иңләп канатларын җилпеде, мәгъруР башын кыйгайтып күккә карады, һәм, мә сиңа, читән казыгына очып та кунды. Өстән караганда дөнья бик киң һәм тавыклар бик вак булып күренделәр...

Муен йоннары күпереп тырпайды, муен бер карышка озынайды, канатлары җил-давыл чыгарды һәм ... чү! Ни булды?!

Киң җиһанга дәһшәтле аваз салырга җыенган кызгылт әтәч читәннән егылып төште.

Егылган җиреннән — кычыткannар арасыннан уктай атылып чыкты да озын, таза ботларын яхшы юртак кебек ян-якка ташлап, яңгырдан-

кардан каралып беткән, юан-юан бүрәнәләрдән салынган келәт астына кереп тә качты...

Дөньякүләм чуалышлар күзлегеннән түгел, шушы авыл төбәгендәге хәлләрдән генә чыгып караганда да бу вакыйгада әллә ни искитәрлек нәрсә юк та кебек, әмма ул без алдарак танышачак кешеләр язмышына турыдан-туры һәм бик тыгыз бәйләнгән булганга, без бу гади йорт кошының шул иртәдә егылып төшү фактын зурлап әйтеп китүне кирәк санадык. Кайчагында тормыштагы бик нәни вакыйгалар да һич көтелмәгән зур нәтиҗәләр китереп чыгара, «ихтималның арты киң!», ди безнең тапкыр халык! Бу юлы да шулайга китте эш, кызгылт әтәчнең егылуы байтак мажаралар тудырды, шуңа күрә сүзебезне, белә торып, нәкъ әнә шул кеп-кечкенә вакыйгадан башлап киттек.

Ни хәл итмәк кирәк, егылды да төште әтәч!

Бөек хөкемдарларының җиргә мәтәлүен күргәч, тавык-кәнизәкләр төрлесе төрле якка сибелде, шомланып кырлый һәм кытаклый башлады. Иң куштан симез сары тавык әтәч артыннан келәт астына кереп йомылды, ябыграк кара тавык, кысыла-кысыла, капка астыннан урамга ук чыгып китте һәм егылган әтәчнең иң явыз дошманы булган өшегән кикрикле ак әтәч тирәсендә сырпалана, юргаларга тотынды.

Мунча түбәсендә, тузанлы каен себеркеләр арасында бөтен дөньядан качып, унбер йомырка өстендә шыпырт кына чырлап утырган бүрекле чуар тавык та чыдамады, өтек канатларын җилпи-җилпи, корыган яфракларны тузгытып лапас эченә очып төште.

Китте кытаклау, купты тавыш, кузгалды ыгы-зыгы, әкәмәт. Моңа күрше-тирә әтәчләре дә игътибар иттеләр: муеннарын сузып күкне күзәттеләр — тилгәннәр эскадрильясы очып килгәнме әллә?! Тауның карурманга якын кыяларында актык көннәрен уздыручы түш йоны коелган карт бөркет адашып авыл өстенә килеп чыкканмы? Өерләре белән карчыгалар күченеп барамы әллә? Һич югында, тавык ите сагынган кызыл төлке су буендагы куе таллар арасыннан ындырларны, тавыкчебеш тибенгән тиреслекләрне күзәтеп ятамы?.. Әллә мур-кыргыры бүре-явыз ук бармы?!

Юк, күк чалт аяз һәм буп-буш иде. Әнә, әллә кайда гына бер разведчик тилгән оча, аның бу көтелмәгән сәер тавыш-гаугага һичбер мөнәсәбәте юк икәнлеге күренеп тора, тавыш Югары очта, ә ул Түбән оч буасы ярларына таралышкан гамьсез каз бәбиләрен күзли булыр. Бөркет күләгәсе дә тирбәлми, төлке дә тал яфракларын селкетми...

Алайса нигә купты соң әле мондый гауга? Югары оч әтәчләренә тынгы бирмәгән, очның бөтен тавыкларының кайнар мәхәббәтен үзенә яулаган кушйодрык кикрикле, дистә ярым урак койрыклы, иң озын ботлы, иң кыдрач, иң көчле сугыш чукмары Гәрәй-хан кушаматына лаек булган кызгылт йонлы, киң күкрәкле әтәчнең муенын «кых-х» иттеләрме әллә?

«Әһә!» диештеләр Гәрәй-ханнан байтак җәбер-җәфа татыган, йолкынган каурыйлы, кутырлы кикрикле бик күп әтәчләр, «якынрак барырга да, җайлы чакта катырак кычкырып, гайрәтне күрсәтеп куярга кирәк! Тавышны тавыклар да ишетеп калсын!»

Уңнан да, сулдан да йомылып әтәчләр чабыша башлады. «Югары очта бүгеннән беренчелек миндә!» дип шауладылар алар.

Китте шикләнү, китте юраулар, фараз кылулар, күрәзәлек-табышмак чишүләр, шулар һәммәсе күршедән-күршегә, йорттан-йортка күчеп, бөтен авыл кош-кортлары пыр туздыі. Ишегалларында җим сосып, бодай тулы тагарак белән сулы ялгашлар арасында тыпыр-тыпыр килеп сарып йөргән йомры үрдәкләр бакылдады, су буйларына сибелгән каз көтүләре каңгылдады, ияк асларындагы катлы-катлы борынгы алкаларын дерелдәтеп, күләгәдән кояшка голдыр-голдыр күркәләр кабарып чыкты... Чыктылар да, койрыкларын җилкәннәр күк киереп: «кайда? ни

бар?» дип хәтәр генә йөренә башладылар. Йорт кошларына ияреп чыпчыклар чыркылдашты, күгәрченнәр пыр-пыр кыеклап очып уздылар, песнәкләр ботактан-ботакка сикереште. Кыскасы, бөтен ишегалларында тоташтан тавыш купты, хәвефле кошлар хоры авылның кап уртасындагы пожар каланчасына менеп йоклаган Хәйретдин агайны да уятты. Ул йокы аралаш иреннәрен тәмле чапылдатып чаңның бавын тартып куйды. Бау тукмак телне хәрәкәткә китерде һәм чыңлаган көмеш тавыш Язкилде урамнарын иңләп талгын гына таралды. Бер минуттан идарәдән каланчага шалтыраттылар.

— Ни булды? Нигә чаң кагасың?

— Ишетмисезмени?

— Нәрсәне?

— Вәт чукраклар, — дип сукранды Хәйретдин агай. — Колакларына чүбек тутырганнар! Кош-корт котырына бит!

— Котырса ни? Җәй башы бит, беренче июнь, кычыткан җирләре бардыр.

— Кош-корт юкка котырмый ул! Бер-бер хәл бар монда! Тау астына бүре килмәгәнме?

— Былтыргы унбер бүреме?? — Идарәдәгеләрнең шаулап көлүе Хәйретдин агайга да килеп ишетелде.

— Көлегез, көл, — диде ул җәберсенмичә генә. — Кош-кортны акылсыз дип уйламагыз сез! Бер дә юкка түгел. Түгел!

— Их, Хәйретдин агай, Хәйретдин агай!..

— Хәйретдингә ни булган? Әлү, әлү! Нигә эндәшмисез?

Хәйретдингә асылда берни дә булмаган, ята әнә рәхәтләнеп җиләстә, «авылда ни бар? нинди хәвеф-хәтәр килгән безгә? нигә кычкырышалар?» дип җентекләп сорарга иде аның исәбе. Тыңламадылар, әх, өлкәннәрнең җанын аңлыймыни хәзерге яшьләр!..

Әйе, кош-кортлар пыр тузышты Язкилдедә, ә аларның хуҗалары кайда соң? Нигә йортта күренмиләр? Нигә тынычландырмыйлар? Нигә бер Хәйретдин агай гына тавышка игътибар итте? Җитмәсә ул да кызу эш өстендә каланчада йокы симертә? Йоклар чак мыни?.. Чәчүләр бетеп, печәнгә төшәргә өлгермәгән тын ара булса да авыл халкы кырылып эштә: печән оны тартучы машина иртәдән-кичкә кадәр тынмый диярлек, чокыр-чакырлардан, ермак-таучыклардан чабылган сусыл кычытканны, витаминлы чүп үләннәрне т..лыклы онга әйләндереп утыра. Тәмле, хуш исле яшькелт онны өч катлы капчыкларга тутырып ферма янындагы складка ташып та торалар. Яшьме син, картмы, пенсионермы-түгелме, барыбер — әгәр аз-маз җегәрең бар икән, рәхим итеп шушы көннәрдә колхозга алты центнер яшел массаны илтеп тапшыр! Идарәнең карары шулай! Ә Язкилдедә идарәнең карары нык, гомуми эштән, өмәдән беркем дә читтә калмасын! Бала-чага, үсмерләр, кызкыркын урманда. Язкилденең урманнары исә әкияттәге Кырлай урманнары кебек матур, бай, ул пот-пот бал бирә торган юкәлекләр дисеңме, ул гөрежләләр чәчелеп үсә торган каенлы аланнар дисеңме, ул шомыртлы, баланлы урыннарны әйтәсеңме, һәммәсе — муллык-саулык чыганагы! Яшьрәк юкәләрнең иң аскы ботакларын кыркып укучы балалар себерке бәйли. Язын бәрәннәргә, бозауларга күчтәнәч! Болыннарда, көтүлекләрдә, сугарулы плантацияләрдә дә эш кайнап тора, мең салават күпере ясап төрле-төрле хикмәтле машиналар туктаусыз су сиптерә. Чапкычлар әзер, печән җыйгычлар әзер, лафетлар тезек, муеннарын сузып рәт-рәт комбайннар арыш кырларына текәлгәннәр — бүгеннән чыгалар, боерык кына бир! Биек-биек шома башлы сенаж башняларында җылы җил уйный, алар да Язкилде болыннарының печәнен, кырларының люцернасын, кукурузын, борчак саламын көтеп дүртәүләшеп балкып утыралар.

Кыскасы, һәркем эштә, һәркем файдалы хезмәттә! Запчастьлар бар, ягулык ташылган, агитбригада планы төзелгән, «кош-корт котырына» дип идарәдәгеләрнең нигә әле эче пошсын?! Кабул ителгән карар катгый: чүп-чарны тоташтан ташып торалар, машина туктаусыз дөпелди, капчыклар арта тора...

Шулаен шулай да, әлегә без күргәне, Хәйретдин агай җиләстә иркенләп йоклап ята... Бардыр, койрыкны сыртка салган башкалар да бардыр. «Күктә ни булмас дисең, очсыз-кырыйсыз күк бит ул!» Күктә генә түгел, җирдә дә әллә ниләр бардыр!

Хәйретдин агай да, Гәрәй-хан кушаматлы әтәч кебек, безнең алдагы әңгәмәләрдә мәгълүм бер урын тотканга, аның турында да аз-маз сөйләмичә узып китеп булмас. Гадәттәгечә, иң әүвәл туган елына туктальйк... Менә син әй! «Хәйретдин агайга ничә яшь?» дип уйладым да, җавапсыз тотлыгып калдым...

Була бит шундый кешеләр, аларга ничә яшь икәнен тәгаен әйтү дә кыен. Кыен гынамы сиңа, мөмкин түгел! Язкилде кешесе Хәйретдин агай да әнә шуларның берсе иде. Яхшы ата-ана баласы, кендек әбисе, артына берне чәпелдәткәч, акырып җылап җибәргән, көне килгәч аңа да «кызыл ыштан» үлчәгәннәр, үскән-үрмәләгән, йөгереп киткән. Барысы да кешечә, һәммәсе дә күз күргәнчә гадәти. Бер ягы сәер — аңа туган көненнән башлап бүгенгәчә бар халык, олысы-кечесе, «Хәйретдин агай» дип кенә дәшә. Башкаларга «абый», «абзый» диләр, яши-яши «бабай» дәрәҗәсенә күтәрәләр, «җизни» бар, «кайнеш» бар, «кода»лар күпме, «яшьтәш», «адаш», «чордаш» — тагын әллә кемнәр, әллә нихәтле матур исемнәр авыл-күршене бергә укмаштырып яшәтте, ә аңа гомергомергә бары тик «Хәйретдин агай» дип кенә мөрәҗәгать итәләр. Хәйретдин агайның үсеп җитеп кайчан өйләнгәнен дә, башка чыгып авыр гына тормыш итә башлавын да, кызларын кияүгә биреп берәм-берәм читкә таратуын да, төпчек малае Мидхәтнең ата-анасының җанын көйдереп читтә — Чиләбедә төпләнүен дә, олы кызы Майбәдәрнең өченче бәбәйдән вафат булуын да, газиз карчыгы Сабираның шул хәсрәттән урын өстендә бик озак авырып ятып, Хәйретдин агайның ничәмә-ничә еллар карчыгын җилкәсенә кочтырып мунчага алып барып йөрүен дә, ниһаять, Сабираны җирләвен, карчыгы кабере өстенә биниһая олы ак таштан һәйкәл куюын да беләләр, хәтерлиләр... Чәчләре көмешләнүен, сакал-мыекларының агаруын күреп торалар, һәммәсе күз алдында, картайды Хәйретдин агай, тәбәнәкләнде, биле бөкерәйде, әмма аңа мөнәсәбәт тә, эндәшү дә шул килеш калды, үзгәрмәде. Үзе дә кайгы-шатлыгын уртак итәргә бер чакта да ашыкмады, сагышы үзәгенә сеңде, аз сүзле, сабыр холыклы була калды. Кызын җирләгәч тә тилмереп җыламады, Язкилдегә кайтты да атна буе кулларын корсагы өстенә кушырып, кояш баешына текәлеп, бер ялгызы капка төбендәге бүкәндә утырды. Майбәдәр кияүгә китеп, үлеп калган Түбән авыл кояш баешында иде. Атна утырды, тирән итеп бер көрсенде дә, берни булмагандай балтасын биленә асып эшкә чыгып китте. Кызының вафаты турында беркем белән берни сөйләшмәде. Карчыгын җиргә тапшырып кайткач та атна буе ялгызы булды, бу юлы кеше арасына да чыкмады. Өчесен дә, җидесен дә уздырмады. Урамда күренмәде, ишек шакыганнарга ачмады. Күрше-колан, «кайгысыннан эчеп ятамы әллә бичаракай?» дип борчылды. Кибетче Фәсхетдин, бөкересен җилкәсендә сикертеп, өч бөртек сакалын учлап, «Хәйретдин агайның бер чакта да чүллидән ары аракы алганы булмады», дип ышандырып торгач, авылдашлары ул уйдан кире кайттылар. Үлеп ятамы әллә дисәң, һәр көн өйлә вакытында морҗасыннан төтен күтәрелеп, эчтә җан иясе барлыгын хәбәр итеп торды. Атна узгач Хәйретдин агай урамга чыгып тирән генә бер көрсенде дә, эшләпәсен басып киеп, балтасын билбавына кыстырып эшенә юнәлде.

Балта остасы, пыялачы, итек төзәтүче, такта ячучы, калайчы, тегермән ташы тешәүче, дуга, тәртә бөгүче, тагын бик күп, авыл халкы өчен бик кирәк һөнәрләрнең иясе иде ул! Әткәсе атаклы оста иде, улы аннан да уздырды! Бала-чагага күпме уенчык кына ясады ул, балчыктан сызгы әвәләде, талдан кәрҗин үрде, кыз-кыркынга җиләккә йөрергә каен тузыннан тырыс текте. Ул кайнаткан каен сагызын бөтен авыл бик яратып чәйни торган иде! Чиләк төпләүче дә ул, кисмәк-чапчак чабучы да ул, иләк кысасы бөгүче дә ул! Язкилде кешеләре аның җанына үтеп кереп якыная алмасалар да, Хәйретдин агайның кадерен белеп тордылар, олылап йөрттеләр. Бәлки шул, һәркемгә, һәр җәһәттә кирәге чыгып торганга, йорты сукмагыннан кеше өзелмәгәнгә, бик яшьләй әткәсенең кул арасына кереп тирә-юньдә дан алганы өчен яше-карты аны «агай» дип олылап атап йөрткәндер дә?

Инде картая төшкәч, карчыгы тәмам урын өстенә егылганда, «ике кулыңа бер эш булыр, йөрергә дә якын» дип, аны мәктәпкә завхоз итеп куйдылар. Кинәнде укытучылар, рәхәтләнде директор, сөенде укучылар! Мәктәп ишекләре очып кына ачылды, лыялалар һәрвакыт бөтен, парталар төзек (рәт-рәт тезелешеп ялтырап торалар), күргәзмә әсбаплар барысы ремонтланган, утын ташылган, киселгән, вакланган, мичләр акшарлы, йозаклар төзек, хезмәт кабинетында балта-өтергеләр үткер, струклар иң пеше каен такталар өстеннән йөгереп кенә йөри, ак йомычкалар куштан кеше мыегы төсле алкаланып-алкаланып идәнгә сибеләләр, кайсы яктан килеп карасаң да хуҗалыкта тәртип, нык куллы хуҗа барлыгын раслап торучы иплелек иде. Шуның өстенә Хәйретдин агай укытучыларның өенә дә барып йөри, вак-төяк ремонт ясый, мич чыгара, утын кисешә, токмач кунасы ышкып бирә, пыяла белән уклау шомарта, тагарак-ялгаш чаба, кисмәк төпли, мичкә кыршаулый, кыяр тозлаша, бәрәнге алыша, кирәк икән, менә дигән бәбәй арбасы ясап бирә, бер дә, бер дә тик тора белми иде.

Тагын бер мөһим якны әйтми китәргә ярамый, Хәйретдин агай бер чакта да акчага кызыкмады, бирсәләр бик читенсенеп кенә, азын гына, кат-кат рәхмәтләр укып, «Сабира апагызга тәм-томга тотсам гына инде», дип өстәмә аңлатып кына алды.

Шул завхоз булып эшләгәндә карчыгын җирләде, өендә ялгыз калып, ике ел дисәм аз, өч ел дисәм күп, шактый изаланган иде, Чиләбедән улы Мидхәт белән килене Начтук (Зәй ягыннан Сәрәпәле керәшене кызы) кайтып төштеләр. Бер-ике көн каш астыннан гына күзәтеп йөрде дә, Мидхәт мәсьәләне бик каты куйды: «Эшләтеп үтерәләр монда сине, әткәй, юаш дип сигез камыт кигерткәннәр... Хватит!» дип өстәл сукты. «Үзебезгә алып китәм, покранимир адәм төсле торырсың. Бер башыңа бер кумныт булыр! Тор әйдә, иркенлә! Әнә, алмаш-тилмәш өч вынугың калкынып килә, малайлар, кулың кычытса аларга аз-маз һөнәр үрәтерсең. Давай!»

Карышты Хәйретдин агай, бармас өчен әллә нинди юк сәбәпләр уйлап чыгарды, «өйләнәм, сөйләшенгән карчыгым бар!» дип карады, «сихәтлегем какшады», дип ялварды. Мидхәт тә кире беткән эт икән (әллә бала карап җыгы чыккан Начтук боргычладымы малайны?), айваена карамастан, әткәсен җиде ят җирләргә алып китте. Иң кызганычы, Хәйретдин агай, улыннан бигрәк килене коткысына бирелеп (хатын-кызны гомере буе олылады ул!), йорт-җирләрен сатты, өй җиһазларын күрше-коланга исталекка таратып бетерде. Агач кыру станогын «төсем итеп сакларсыз» дип күрше колга Миннәхмәтләргә биреп калдырган иде, ул киту белән Миннәхмәтләр олы улларын өйләндереп башка чыгардылар, аның нигезенә яңа өй бастырып куйдылар. Мәшәкать арасында уралып станок юкка чыкты. Балалар «мәктәп музеена кирәк» дип инәлеп эзләп килсәләр, татарныкы төштән соң, станоктан шомарган каеш кына калган! Миннәхмәт килене анысы белән качкын кәҗә-

ләрен арканлап йөртә икән, «тигез җирдә түмгәк эзләп, кадимдәге чүп-чарны таптырып йөрмәгез», дип, станок каешы белән балаларны өтеләп ук чыгарган.

Әйе, өч ел дисәм күп, ике генә ел үтте дисәм азрак булыр, мәгәр көннәрдән бер көнне, калку җирләр кардан ачылып елтыр сукмаклар төшкәндә, бик җыйнак кына чемодан тотып, як-ягына ялт-йолт каранакарана, Язкилдегә бер өлкән кеше килеп керде. Аягында үкчәләре нык кына ашалган озын куныччлы күнитек, өстендә терсәкләре кыршылган бостон костюм... Юлчы бөкерәя төшеп бераз барды-барды да чемоданын корырак җиргә куеп, кулъяулыгы белән кайнар тирен сөртә-сөртә, яңа йортларга, яктырып-балкып утырган шифер түбәләргә, җилкенеп-җилкенеп сайрашкан сыерчыкларга карап торды да бер көрсенде. Шунда гына таныдылар, юлаучыбыз үзебезнең Хәйретдин агай, имеш...

Йорты-өе юк, нигезендә Миннәхмәт малаеның тәрәзәләр белән мул чуарланган верандалы, алты почмаклы нарат йорты шәбәеп утыра, нихәл итсеннәр, Миннәхмәтнекеләр кыстый-кыстый картны үзләренә алып керделәр. Күбрәк Чиләбе турында сөйләшергә тырыштылар. Хәйретдин агай туп-турыдан ярып салды: «Һәйбәт, анда да бик һәйбәт! Урамнары таш кына! Яңгыр-мазар нипачум!» (Кайчандыр солдат буткасын ашаган кешеләр, хәзер, берәр яры барып кайтсалар, телләренә рус сүзләре кушып сөйләшүгә күчәләр!) «Керәшен булса да килен дә ничава, татар токмачын кетердәтеп баса. Примергә, кыстыбыен да наять пешерә! Ну воздух начар икән анда, безнеңчә түгел, чыдайт нельзя, әмәл юк, күкрәкне кыса да тора, түзсәң түз, түзмәсәң ятып җыла. Иртә таңнан урамнарда зәһәр төтен тудыйм-судыйм бөтерелә башлый, кая ул, безнең Язкилдегә җитәме соң?!»

Миннәхмәтләрнең сәфәрчегә кушылып Язкилдене бик мактасылары килә, күзләре улларының юан-юан бүрәнәләрдән салынган йортына төшә дә, телләрен тешлиләр.

Сүзе аз булса да чишмә суы белән куелган самовар чәен туктаусыз эчте Хәйретдин агай, чемоданыннан бер савыт бөртек чәй чыгарып Миннәхмәт хатынына тоттырды.

Элекке күрше Сабирҗаннар да аны кунакка дәштеләр. (Алар Хәйретдин агайның мунчасын бушлай гына үз ындыр түрләренә күчереп утырткан нар иде). Алар да бик озаклап килене, оныклары турында сораштылар. «Теләгең булса, ни, үзебездә тор. Өй арасында эш бетмәс! Беләбез, тиктормас җан бит син! Кыштырдарсың, сүз әйтмәбез. Аерым казан сорама, без ашаган булыр, хәзер туклык», диделәр алар.

Кемдә, кайда тору җәһәтеннән Хәйретдин агай алай өзеп әйтергә ашыкмады, кыенсынып кына чыгып китте, өйрәледә бер кич, буткалыда ике кич кунгалап, атна чамасы үз нигезе тирәсендәгеләрдә вакыт кыскартып йөрде дә, авыл уртасында диярлек ялгызы гына диярлек тереклек итеп яткан Миннисa карчыкка йортка барып керде. Миннисаның ире куянчы Әфләтүн сугыштан кайтмады, балалары исә берәм-берәм КамАЗга күчеп беткәннәр иде.

«Рәнҗемисеңме безгә», дип сорады Миннәхмәт. Хәйретдин агай башын гына чайкады. «Мунчаңны күчереп салып бирәм», диде Сабирҗан. «Кирәкми», диде Хәйретдин агай.

Миннәхмәт тә, Сабирҗан да шул сүзне ишетәселәрен алдан ук белеп килгәннәр иде.

«Хәйретдин агай да Хәйретдин агай!»

Ул язда авылга шул тансык сүз кайтты.

Дуга бөгүләрнең кирәге калмаган иде инде — атлар бетеп бара. Миччә утын ягучылар да бармак белән генә санарлык калган, һәркемнең патша сарае кебек дәү өен ташкүмер кайнарлаган су җылыта. Нәүрәп өсләрен ныгытасы, такталарын алыштырасы юк — кар базларын то-

таштан кумгәннәр, аларны дәү-дәү ак аюлар — холодильниклар алыштырган. Чиләк тәпләүләр, казан ямаулар, аяк киеме төзәтүләр шулай ук иске бер сүз булып кына телдә калган, тишелде исә чыгарып ташлыйлар, ватылды исә чүплеккә ыргыталар. Үзгәрешләрне киткәнче дә сизенә иде Хәйретдин агай, әмма байтакка сузылган сәфәреннән соң ул Язкилдегә бөтенләй яңа күз белән карады. Шиксез, Хәйретдин агайның абруен югары күтәргән һөнәрләрнең авылда кирәге калмаган иде, алай да ул тына белмәде, күрше-коланның койма-капкаларын тикшереп, кадаклап, иплән-сипләп чыкты. Бушаган араларда су буеннан талчыбыгы ташып, эссе мунчада пешеләп кәрҗин үрде, сыбызгы ясап малай-шалайны сөендерде, карчык-корчыкны көендерде. «Сыбызгы сызгыртып җил чыгаралар!» дип сукранды әби-сәбиләр. Минниса карчык Хәйретдин агай ни кыланса да канәгать иде, өй арасына күптән көттергән ир-ат керде, булышчы табылды. «Актык көннәргәчә бергә булырга язсын!» дип карчык һәр иртәне хак тәгаләдән яхшылык сорады. Яхшы юлдаш иде Хәйретдин агай!

Ел дисәм аз, ике ел узды дисәм күбрәк булыр, көннәрдән бер көнне, атна кич иде бугай, Хәйретдин агай Минниса карчыкның чите кителгән түгәрәк көзгесе каршында хәйран озак маташты. Кайчы белән мыегын кыскартты, чалгы плитва белән җыерчыклы ияк астын, югарган колак тирәләрен чистартты. Борын тишегеннән әрсезләнеп тырпайган төкләрнең башына эскәк җитте. Чишбедән кайтканнан бирле ял иткән күнитеккә дә май тиде, пинжәген дә кат-кат кагып киде Хәйретдин агай. «Әллә миннән китәргәме исәбе?» дип коты чыгып уйласа да, Минниса карчык аны-моны сорарга базмады. Кулын артына куеп салмак басып чыгып киткән картны күз белән бик еракка кадәр озатып калды. Хәйретдин агай туп-туры идарәгә барып керде һәм гомерендә иң озын сүзне шушы кичтә әйтте.

— Кул бит ул, кул! Бер дә тик торганны өнәми... Үзем дә белмим, гел эш сорап тора! Инде генә ял итәргә утырам, я бер эш күзгә күренә, я икенче эш. Кулны әйтәм, зарыга! Кул зарыгуын белгәнегез бармы икән, харап икән ул! Кайтканнан бирле күңел урынында түгел, борсалана көн-төн. Чөнки димен, ике кулга бер эш юк. Эш юк, каһәр суккыры! Эше юкның җаны тыныч түгел, ял итеп булмый. Даваегыз, егетләр, бер эш табыгыз миңа!

Идарәдәгеләр көлемсерәп бер-берсенә караштылар.

— Эшләп торасың ич, Хәйретдин агай, — диде бригадир.

— Күнегелгән колхоз эшенә чыгасым килә.

— Син, Хәйретдин агай, Ватан сугышы инвалиды. Ике мәртәбә авыр яра алган, кан койган кеше. Колхозыбызның хөрмәтле ветераны. Пенсия аласың. Алай да гел диярлек булышасың. Сине ныклап эшләтергә хакыбыз юк, — диде парторг Мәймүнә.

— Эшләмичә ятырга минем права бармы?

Уйладылар, уйладылар да, Хәйретдин агайны, сугыштан бер кулы имгәнеп кайткан Шәмси Кирамы белән икесен яңгын сараена дежур итеп куйдылар. Икесенә ике ат, бер ат сарае, каравыл өе һәм башка кирәк-яраклары — балта-багурлар, насослар, чиләкләр, һәммәсе акт белән тапшырылды. Бер тәүлек постта Кирам тора, икенче тәүлектә дежурга Хәйретдин агай килә.

Ике ай дисәм күп, бер ай шулай эшләгәч тә, дисәм әзрәк булыр, кичләрнең берсендә, тагын килде Хәйретдин агай председатель янына. Килде дә читенсенеп кенә сүз катты:

— Бер гозер бар иде бит әле минем, кем...

— Тыңлыйм, — диде председатель бер дә сәерсенмичә генә.

— Соң, шул инде һаман!.. Элек авылларда мәчет манарасы була иде. Каравыл өе янында дүрт аякланып каланча кукраеп басар иде. Авылга төс биреп торалар иде алар, ямь таратып.

— Хәзерге авыл төссезме?

— Алай түгел, хәзерге авыллар да бик ямьле. Мәгәр каланчасыз нинди авыл ди инде ул?

Председатель, Хәйретдин агайның гадәт-холкын тирәнтен белмәсә, бәлки карулашып та маташыр иде, белгәнгә күрә, озын сүзсез ризалашты, «мәчет манарасын көтмә, аларының кайтачагы юк», дип көлеп куйды. Язкилделәр каланчалы да булдылар. Сенаж башнялары кайтмаган иде әле ул чакта. Каланча юкта аны-моны абайламыйча йөргәннәр икән, торгызып куйгач тел шартлаттылар: «Үзенә күрә түгел, матурлыгы бар икәнич монын!» диештеләр.

Күгәрә башлаган чаң кыңгыравын Хәйретдин агай мәктәп музееннан барып алды. «Хезмәткә кирәктә музейда интектермәгез, менә мин үлгәннән соң алып китәрсез!» диде ул.

Хәйретдин агайның ярты гомере каланча тирәсендә уза башлады. Моңа Миннниса карчык эчкерсез куанды: «Көн аралаш кына күрешеп торгач, ифрат ару була икән ул, көмәйләр! Сагынышып күрешәсең!» дип кое янында эч серен сөйләде.

Ат сараен ындыр табагы төсле чиста тотты Хәйретдин агай, атны кыргычлап, ялтыратып, коендырырга Олы суга алып төште, алдыннан ризык өзмәде, вакытында эчертте.

Сүз җаеннан Хәйретдин агайның тагын бер күркәм сыйфатын — үтә пөхтәлеген, җаны-тәне белән чисталык яратуын әйтми китеп булмый. Чөнки каланчага менеп черем итүенең сәбәбе дә әнә шул чисталык яратуыннан гына килеп чыкты! Картның дөньядагы иң олы дошманнары чебен-черки, таракан кебек өй хәшәрәтләре иде. Өендә чебенне тотмый да тотмый инде ул, әмма мәгәр каравыл өендә һәрвакыт бердәй чисталыкны саклау читенрәк иде. Җитмәсә наянрак кешеләр Хәйретдин агайның чебен-черкиләргә каршы сугыш ачканын белеп, картның бу холкын мәзәк иткәлиләр иде. Шырпы кабына чебен тутырып киләләр дә, берәү дә күрмәгәндә, каравыл өенә очыртып җибәрәләр. Менә башлана алар өчен тамаша, Хәйретдин агай «мур кыргырлары, тагын кереп тулдыгызмы, затсызлар!» дип берәмтекләп аларны куып йөри, ашау-эчүен, эшен оныта! Мүкәләп өстәл астына кереп китә, какшаган аяклы агач диванга сикереп менә, тотып бетермичә тынмый иде. Бөкере җилкәле кешенең ярсып өстәл астына кереп китүе дә мәзәк кайберәүләр өчен, диван өстендә селтәнеп маташуы да көлке! Бар бит агач авызлы бүкәннәр!

Эш шуңа барып житә ки, ярсыган Хәйретдин агай урамга да галуш олтанын таякка кадаклап ясаган «чебен әҗәле»н тотып чыга, ат коендырырга төшкәндә дә кулында шул була иде. Беркөн хәтта печәнгә аргы болынга барганда да камчы урынына шуны тоткан, үшән биясен шуның белән каулаган, имеш. Инде ул йоклый торган җиргә черки явыз үтеп керсә, бетте баш, Хәйретдин агай ул төнне керфек тә какмыйча уздыра.

Бүген нәкъ шундый көн булды. Хәйретдин агай черкиләр белән төн буе сугышып чыкты. Төн үтә җылы, җилсез иде, черкиләр әллә кай җирләрдән ярык табып каравыл өенә һөҗүмнәрен туктатмадылар. Таңга таба черкиләргә чебеннәр отряды да кушылгач, картның кәефе тагын да ныграк кырылды...

Кулалмашы Кирам болай ару гына кеше иде үзе, басынкы да, карышусыз да, авызы да тик тора белә, тик соңгы елларда аны бала-чага бик басты, олы килене белән хатыны былтыр көздә икесе бер атнада бәбәй алып кайттылар. Мәшәкате артты Кирамның, мәшәкатькә аркаланып бөтен эшне Хәйретдин агайга өеп тапшырды. Хәзер тота да аңа салына: «Әллә димен, Хәйретдин агай, бүгенгә генә минем урынга да калып торасыңмы? Балаларның берсенә ютәл төшкән, икенчесендә томау. Карарга кеше юк, карчыкның үз бәбәе... (бу урында Кирам кирәк тешләрен ыржайтып хи-хи-хи дип көлеп куя), килен сыер сава!..»

Кала Хәйретдин агай, бер көн кала, ике көн дә. Кирамга үпкәләп тормый, рәнҗеми, ашарга карчыгы Минниса ташып тора, аңа да бер эш, ак тастымалга төрелгән шулпалы чүлмәген ике кулы белән тотып, танавын чөеп, керт-керт кенә басып килеп житә, каравыл өе буш чакта, чебен-черки жанга тимәсә, кара-каршы гына утырып аш ашыйлар, озаклап чәй эчәләр. Бәхетләре тигез, хәвеф-хәтәр булганы юк. Язкилде кешеләре ут ягына килгәндә бик саклар, байлыкның кадерен беләләр, шулай да былтыр, жәй уртасында чак кына көлкегә калмады Хәйретдин агай. Әлеге дә баягы шул унбер бүре аркасында инде...

Идарәдәгеләр бая шуңа ишарә ясап көлештеләр.

Эш болай булды. Йокыдан ук кәефсезләнеп уянды Хәйретдин агай, төшендә Чиләбене күрде. Житмәсә мунча көне дә иде. Каравыл өе янында малайлар уйнамый түгел, берәүсен жибәреп кайтарды, икенче малай юртып кына барып килде — Кирам эштә күренмәде. Хатыны: «чирләп ята абзагыз», дип әйткән: «Әй, исереп йоклый ла ул, гырлаган тавышы бөтен очка ишетелә!» диештеләр малайлар. Кирамның андый гадәте бар, бар гынамы, ярата салырга, кулыннан килсә жырлый-жырлый шешәсенә кереп утырыр иде... Кыскасы, Хәйретдин агайның ак мыегы үргә карады: «Кәкже алай, — диде ул, — мунча көнем икәнне белеп тә соңга кала?!»

Кирамнарга үзенә барырга туры килде.

Хәйретдин агайны мунчага озатып эштә каласы кеше чоланнарының как идәнендә, бер кырыйга авышкан буй-буй тышлы түшәгенә көпшәк кызыл танавын терәп, трактор тавышы чыгарып гырлый-гырлый йөзә үбән ята иде. Яланаягының сары тырнаклы озын бармаклары гына кыймыл-кыймыл киләләр. Төрткәләп уятып карадылар, башына чүмеч тутырып суык су сиптеләр, куш-йодрык сыярлык борын тишекләренә нашатырь спирте бөркеделәр, жилпуч хәтле колакларын удылар, уянмады Кирам, дөнья яңгыратып өч төчкерде дә, башмак иреннәрен кыйшайтып: «Әйдә, тутырып сал!», дип мөгрәде. Хәйретдин агайның кәеф тәмам кырылды, күкрәгенә ачу килеп бөялде. «Тьфу, нәләт!» диде ул жан ачуы белән. Кирам хатыны Гөлниса ике кулына ике бәбәй кыстырып аны урамга чаклы озатты: «Ачулан, Хәйретдин агай, бик нык ачулан! Дежурга үзем барыр ием, күрәсең ич... Кияүләрең күп булмасын икән лә, килгәне бере ярты кыстырып килә!» диде ул. Аз да түгел, ким дә түгел, Кирамның жиде кияве генә бар иде.

. «Мунча булды, бәлеш мичтә, нигә күренмисең, карт?» дип битенә мул гына кершән ягып, чуклы шәлен иң өстенә чөеп юргалап Минниса да килеп житте. Хәйретдин агай беренче мәртәбә карчыгына жикеренде: «Бар ди монда мунча кайгысы!» Һәм тузынып каланчага менеп китте. Алтмыш жиде арātаны менеп житкәнче дүрт мәртәбә туктап тын алды. Бер туктый иде элек, ике туктаганы бар иде, бүген дүрт рәт туктады, менгәч тә тиз генә исен жыя алмады, тез буыннары калтырады, күл алдында яшелле-кызыллы төрткеләр биешеп торды. Һәм, кирәк бит! Язкилденең иң Югары очында яшәп яткан Сәләхетдиннәр ягына карады. Ни дип карады инде ул якка, белмәссең!.. Сәләхетдиннәрнең биек-биек читәне тирәсендә кара шәүләләр абайлап алды. Сарыкка да охшамаган, сыер малы да түгел, кыймыл-кыймыл киләләр, жан иярә! Ни булыр икән бу шәүләләр? Нәкъ унбер баш! Һәм ул күзләре яшьләнгәнче күзәтеп торды да: «унбер бүре килгән» дип идарәгә шалтыратты.

Аучыларга «бүре бар!» дип әйт кенә син, бер-берсен уздырып, күгәргән көпшәле мылтыкларын эре ядрәләр белән корып авыл читенә барып та життеләр. Хуш, ни күрәләр инде болар?.. Шуны күрәләр ки, көлә-көлә чак эчләре ярылмый боларның, әле ярый билләрен киң каешлар белән бугаң булалар! Сәләхетдин хатыны Гөлбикә биек читәнгә

җиллэтергә туннар элгән икән. Нәкъ унбер тун! Тун итәкләре җилфердәп Хәйретдин агайның талган күзенә бүре булып күренгәннәр. (Ачулы күзгә тун да бүре булып күренә, онытмагыз!)

Хурлыгыннан каравыл өен ташлап китәргә дә талпынды Хәйретдин агай, председатель үгетләп калдырды. «Синең хакка каланча куйдырдык, тагын кулың кычытып киләсең бар, китмә!» диде.

Бер килсә килә бит ул, былтыр Сәләхетдиннең унбер туны иләсмиләс ясаган иде, быел әтәчләре Хәйретдин агайны хафага төшерде — тавыш Югары очтан, шулар ягыннан башланды ич!..

Хәйретдин агайга болай төпченеп тукталуыбызның сәбәбе шул, безнең əңгəмәләрдә ул төп урынны алмаса да, алдарак шактый кирәкле кеше булып чыгачак. Хәзер Хәйретдин агай белән әйбәтләп танышкач, сүзебезнең башына, баярак кына егылып төшеп ботын сындыра язган Гәрәй-хан кушаматлы гайрәтле кызыл әтәч янына кайтсак та була. Без әлеге әтәч хуҗасының исемен атамадык. Сәләхетдиннең бирге як күршесе Мирфатыйх дигән кеше. Читән Сәләхетдиннеке булса, әтәч әнә шул Мирфатыйх атлы кешенеке. Хәзер иплэп кенә, кош-кортларны өркетмәскә тырышып шул якларга әйләнеп кайтыйк әле, хөрмәтле укучы! Алга!

2

Каз-үрдәкләр акрынлап тынычланды, тавышлары басылды, Гәрәйхан келәт астыннан чыгып берни дә булмаган төсле гаярьләнеп канатын кагып куйды, җиңелмәвен күрсәтер өчен янындагы куштан сары тавыкка мәхәббәтле караш ташлады. Башын югары чөеп, кикриген калтыратып, күкрәк йоннарын тырпайтып бая егылып төшкән урынына карады һәм янлап-янлап чигенергә тотынды. Читәннең теге ягында, Сәләхетдиннәрнең куе карлыган куаклары арасыннан иң элек тырпаеп торган чәч күренде, чәч артыннан туфракка буялган тар маңгай, маңгайга ияреп яфраклар арасыннан ике мут күз елтырады.

Сәләхетдин малае Зәйтүн иде бу. Ул кулындагы шома саплы рогаткасының кызыл резинкасына үткер кырлы чуер таш кыстырып маташа иде. Әтәчнең келәт астыннан чыгуын күрүгә малай читәнгә якынрак тартылды, ике чыбыкны аралап арага рогаткалы кулын тыкты һәм тагын атып җибәрде; бу юлы тидерә алмады, әтәч кушаяклап бер якка сикереп куйды, муенын сузып-сузып сугышчы малайга карады. Их, арада биек читән булмаса, дип уйлады бугай ул. Дәһшәтле кош иде Гәрәй-хан, бала-чаганы куркыту гына түгел, корычтай томшыгы белән чукый-чукый олыларны да пыркытып куа торган явыз зат иде!

Ул арада булмады, Мирфатыйхлар өйалдыннан озын саплы бакыр чүмеч күтәреп, Зәйтүннең яшьтәше, әтәчнең яшь хуҗасы Әнәс атылып чыкты, һөҗүм белән мавыккан рогаткалы юлбасар аны-моны абайлаганчы читән кырына барып җитеп:

— Нигә атасың безнең әтәчкә, бүксә? — дип чәрелдәде.

Елгыр Зәйтүн карлыган яфрагы исе килеп торган ике кулын да югары күтәрде һәм әле учын, әле кул сыртын әйләндереп күрсәтте.

— Мә, кара! Менәтерәк! Бармы әйберем, бармы!

— Син аттың аңа, бүксә.

— Атмадым. Сезнең карт әтәчегез үзе егылып төште.

Зәйтүннең мыскыллы сүзеннән гарьләнеп җыларга житешкән Әнәс, чүмечен җиргә атып, ике куллап читән чыбыкларына ябышты.

— Безнең әтәч картмы? Безнең әтәчме?

— Карт, карт,— дип үртәште Зәйтүннең тиктормас авызы.— Безнең әтәч сезнең йолкышны борып кына сала! — Зәйтүн хата җибәргәнен аңлады, әтәч турында ярыш сүзен артык озынга җибәрергә ярамый

иде. Чынлыкта, Энәсләрнең Гәрәй-ханы аларның былтыргы салкыннарда өшегән ак әтәчләренә көн күрсәтми иде. Ялгышын төзәтергә ашыгып малай сүзне бик тиз борды. — Ә безнең ата каз сезнең ата казның жанын ала!

— Ала! Җанынмы? Һе, килеп кенә карасын. Сезнең ул арык каздан бәбкә дә булмый әле.

Кызганычка каршы, бу сүздә дә Энәс өстен чыкты: аларның бүрекле ата казлары метр ярымлы юан муенын сузып Зәйтүннәрнең казларын шыр җибәртеп куа иде.

— Ә, — дип һаман бирешмәскә тырышты ул. — Безнең куа сыер ике бозау китерде. Икене, икене!

— Һе, икене! Белдең! Берсен фермадан урлап кайткач ике булды!

Әтәчне бер атуда бәреп төшерсә дә сүздә тагын ялгыш җибәрде Зәйтүн, авыл арасында «урланган!» дип телгә кергән игезәк бозаулар турында искә төшермәскә иде! Кош-кортларны онытып өй эченә керергә, ялтыравыклы шкафлар, пианино, келәмнәр, телевизор, радиоалгычлар, бәллүр вазалар, ишегалдындагы «Москвич», лапастагы «Иж-Планета» белән мактанырга, тагын әллә нинди дәлилләр китерергә дә Энәсне егып салырга иде... Юк бит, кирәк чагында иң кирәге телгә килми кала! Нишлисең, беренче классны өчле-тугызлыга быел гына бетергән малай өй, эче байлыгы белән мактана белми иде әле, әткәсенең «берәүгә дә баш фирмә, җиңелгәнне җиңгә тагалар, бирешмә!» дигән көндәлек катгый боерыгын хәтерендә тотып кына Энәс белән әрепләшеп маташа иде. Телгә тагын әтәч килде, чөнки төз атып бәреп төшереп, малайның борын шактый күтәрелгән иде.

— Гарьлек, гарьлек! Карт әтәчләре читәнгә менгән иде, мәтәлеп төште. Гарьлек! Карт булмаса тавыкларыгыз безнең әтәч янына кереп йөрмәс иде! — Болары Зәйтүн әнкәсенең сүзләре булса да Энәскә бик авыр ишетелделәр, ул кызарынып-бүртенеп ызгышны олыларга күчерде.

Бәхәс бары тик әтәч аркасында гына чыкты дип уйлый күрмәгез тагын, тирәндәрәк аның сәбәбе, эчтәрәк!

Энәс беренчене гел яхшы билгеләренә генә бетерде, Зәйтүннең язмадан һәм арифметикадан өчле чыкты, аны икенчегә авырлык белән генә күчерделәр. Яхшы билгеләренә генә укыган Энәскә кичә бүләк — өр-яңа чуар кепка элакте. Кибеттән әтисе алып кайтып бирде. Энә ул кепка, аның кичә генә бритва белән кырылган озынчарак башын мул кояш нурларыннан саклап кукыраеп утыра. Козырегы тырпайган, сигезгә бүленгән түбәсендә шаһзадәләрнең алтын тажы сыман тумпак төймәсе дә бар. Бүген иртән Энәснең анасы кепканы кулына алып карады да көлеп җибәрде:

— Күрше Зәйтүннең борыны төсле икән бу төймә, — диде.

Энәс урамга йөгереп чыгуга Зәйтүнне күрде дә:

— Синең танауны минем кепка өстенә текканнәр! — дип сөрән салды.

Яңа кепкага кызыгып карап торган малайлар бердән Зәйтүнгә борылдылар:

— Төймә борын, төймә борын! — дип дәррәү такмакларга тотындылар.

Уку бетүгә яңа кепка гына түгел, велосипед белән ботинка да вәгъдә иткәннәр иде Зәйтүнгә, берсе дә эләкмәде. Арифметикадан «өчле» сөйрәп кайткан төпчегенә Сәләхетдин абзыйның җен ачуы чыкты. Ул дөньяда «санау фәнен» генә «кирәкле һәм бик файдалы» дип исәпли иде. «Башкаларын мәктәптә укыта алмыйлар аның, башка кирәкләрен мин сезгә үзем өйрәтәм», дип кабатларга ярата иде ул еш кына.

Ул ат кылы кебек эре төкле кашын җыерды да:

— Ә теге Мирфатыйх бүлтерәгә ничәле алган? — дип сорады.

Әнәснең яхшы укуын, математикадан «бишле» үк алуын ишеткәч, малайны җилтерәтеп алды:

— Санауны да үрәнмәгәч, тамагыңны ничек туйдырырсың? Кеше арасына ничек керерсең? Дөньяда яшәүне бик җиңел дип беләсеңме әллә? Авызыңнан тартып алырга гына торалар!..

Малайны тагын да гарьләндереп ул Зәйтүннең борынына чиртте.

Болай да сызлап торган борынны «төймә, төймә» дип тамгалап, малайлар Зәйтүнне бөтенләй гарьләндерделәр. Ул уенга катнашмады, кырт борылды да ишегалларына кереп китте. Байтак эзләнде, ниһаять, эзләгәнен — иске кызыл камераны тапты, ике каеш телеп алды һәм бик шәп рогатка ясады. Карлыган куагы арасында Әнәсләр ишегалды тирәсен сагалап утырганда кичәге хурлыклы әңгәмә тагын бер мәртәбә аның хәтеренә төште.

Әтисенә ияреп аны әнисе дә нык орышты. «Нинди өчлегә уку булды бу?» дип сукранды ул. «Тамагы тук, өсте бөтен, шул Камаловлар тәресеннән дә калышып торгач...»

Быел сигезенчене тәмамлап йөргән Фирүзә апасы да әнкәсен җүпләп сүзгә катышты: «Нигә өчле куймасыннар ди аңа! Яза башласа, селәгәе дәфтәренә тия! Юеш танау!» диде.

Һаман шул танауга бәйләнәләр!

Малайның күңелендә үч алу тойгысы кайнады, үч тойгысы тышка бәреп чыкты һәм аның беренче ударын Гәрәй-хан татыды...

Читән-баррикада аша малайлар шактый әрепләштеләр, алай гына бушана алмадылар, читән чыбыгының беренчесен Әнәс суырып чыгарды.

— Нигә безнең читәнне сүтәсең, таз? — дисә дә, икенче чыбык Зәйтүн кулында иде. Малайларның кайсы җитезрәк дисәк, Әнәс монда да алдынгылыкны алды, читән арасына баш сыярлык булгач, ул бакыр чүмечен тотып теге якка үтеп керде. Керүе булды чүмеч белән Зәйтүннең башына берне тондырды.

Әле йодрык белән сугарга мөмкин, терсәк белән төрткәләгәннәре бар Зәйтүнне, артына тибеп калганнары бар, мәгәр моңа кадәр, шушы хурлыклы көнгә кадәр әле беркем дә аның башына бакыр чүмеч белән кундырмаган иде! Менә кайда ул гарьлек. Аның кара күзләреннән ут очкыннары коелды, нәзек муены тырпайды, беләк мускуллары каз күкәе хәтле булып кабардылар, ул күлмәк итәге астыннан, чалбар каешына кыстырган рогаткасын тартып чыгарды да агач сабы белән Әнәснең чыгынкы, киңчә маңгаена берне китереп төртте. Хурланды Әнәс, Зәйтүнгә таба ыргылды, шул чагында алмагачлар, карлыган куаклары белән шыпланган бакча яктырып китте: аның кепкасы, бөтен оч малайларының күзен кызыктырган сигез бүлкәле, төймә түбәле чуар кепка очып төште һәм малайның шәп-шәрә ап-ак башы ачылды...

— Кабак баш, — диде Зәйтүн.

— Чуен маңгай, — диде Әнәс кепкага иелеп.

Һәм Зәйтүн — түз, Әнәскәй, түз! — фабрика ярлыгы да алынмаган өр-яңа кепкага китереп басты. Валлаһи! Тырнагы өч ай киселмәгән, өч атна су тамчысы күрмәгән кап-кара пычрак аягы белән кепка өстенә менде! Әнәс күзләрен чытырдатып йомды, ачканда аның мактанычы, өр-яңа, күз явын алырлык кепка, Сәләхетдин бозавының кайракланган табаны астында калып, чиле-пешле тәбикмәккә әйләнгән иде. Һәм ул, гомерендә беренче мәртәбә җан ачуы белән чинап, бакыр чүмечкә тотынды, шап иттереп Зәйтүннең маңгаена тагын берне кундырды. Зәйтүн коралсызланды, рогаткасы җиргә төште, җитез Әнәс аны аяк очы белән эләктереп, әллә кайларга, бәрәңге ызаннары арасына ук ыргытты. (Күпме эзләсәләр дә рогатканың табылмавын, бары тик көзен, бәрәңге алганда гына, бер сабакка уралган, кояшта янып өзелер дәрә-

җәгә житкән резинка чыкканын гына әйтеп узыйк. Ни хикмәттер, ул гөптә бер генә юньле бәрәңге дә юк — бөтенесе чатлы да ботлы, кәкере дә бөкере була!)

Рогатка югалса да ул башлаган гауганың шактыйга сузылачагын зирәк укучы сизенгәндер дә инде! Дөрес сизенәсез!

Малайлар әүмәкләшә торгач ике карлыган куагын изделәр, байтак кура җиләге сабагын сындырдылар. Ниһаять, Әнәс өскә чыкты, Зәйтүннең өстенә менеп утырды, ике бармагы белән тегенең почык борынын кысты.

— Булдымы? Ашадыңмы? Туйдыңмы, бүксә? Безнең әтәчкә яңадан тимәссеңме?

— Җибббәрр! — дип тырпылдады тынкыш Зәйтүн, яткан җиреннән аркасын дугаландырырга һәм Әнәсне чөеп ыргытырга тырышып. Тик Әнәс аны нык иярләгән иде, ике яктан касыгына үкчәләре белән тибеп Зәйтүнне бик тиз ипкә китерде.

— Яңадан атмам, — диярга мәҗбүр булды Зәйтүн.

Малайлар кепканың аста калганын абайламаганнар, берзаман калкынсалар, җирдә үлән суына манчылып төсе үзгәргән бер чүпрәк кисәге күрделәр. Бу... әлеге дә баягы өр-яңа кепка иде! Зәйтүннең дә эш шәптән түгел, маңгай ике урыннан күгәреп шешкән, күз тепләре тырналган, яңак сыдырылган, чалбар төбе умырылган, күлмәк сәдәфләре коелган. Әнәс кепкасын тезенә каккалап торды да сиздермичә генә Зәйтүнгә берне китереп төртте.

Моңарчы җыламыйча түзгән иде Зәйтүн, хәзер авызын түгәрәкләп, урт тешләрен күрсәтеп, бакча тутырып акырырга керешә. Шул чакта Зәйтүннәрнең болдыр яныннан усал, коры тавыш яңгырады.

— Әй, сугыш чукмарлары! Икегез дә атлагыз әле монда!

Зәйтүннең сигезенчедә укып йөрүче апасы Фирүзә тавышы иде бу.

Малайлар сискәнеп куйдылар.

## 3

Соңгы бер-ике елда Фирүзә сүзгә саранланды, аның тавышын урамда түгел, өйдә дә бик сирәк ишетә иделәр. Бер нәрсә сөйләшми диярлек, чыга, кайта, урамда очраганнарга сәлам бирми, төнтекләнеп башын иеп читкә карап уза, өйдә чакта күбрәк вакытын көзге каршысында үткәрә.

— Кит, затсызланып көзге алдында бөргаланма! — дип, әнкәсе кырыкмаса-кырык тапкыр кисәткәндер инде. Фирүзә анда да җавап кайтармый, шулай да кырыгынчы тапкыр кисәткәч, түзми:

— Әллә бизәнеп утырган кеше бармы? Дәрес укыйм ич мин! — дип усалланып каш астыннан гына карап ала.

Хак, өйдә кеше барда Фирүзәнең күзе күбрәк китап битләрендә була, яшен тизлеге белән көзгегә карап алуын ул берәүгә дә сиздерми, э инде кеше юкта...

Соңгы кеше артыннан ишек шапылдап ябыла. Фирүзә җиңел сулап китабын бер якка этәреп куя, идәнгә төшсә дә иелеп алмый, кулларына таяна һәм күзләрен түгәрәкләндереп көзгегә йотыла. Ул бик озаклап, бик җентекләп үзенең йөз әгъзаларын өйрәнә: тел очы белән иреннәрен ялый, очлы колаклары янында бөдеркәләнеп торган йомшак чәч бөртекләрен төкереклэп чылата, тагын да ныграк бөдрәли. Күлмәгең ике күкрәк турыннан да чеметеп алга калкытып куя. «Түшләр акрын үсә!» Аннан, сул кулының имән бармагын иреннәренә аркылы куя да тырнагын чәйни-чәйни керфекләрен, кашын, муенын, маңгаен, җентекләп, бөрәмтекләп күздән кичерә башлый.

Күзәткән саен гаепне күбрәк таба.

Муены нәзегрәк тоела аңа, ияк тә очлырак, яңаклар да югарак, бо-

рын да җәенкерәк. («Әле ярый Зәйтүн борыны булмаган, нишләр идең!»)

Чынлыкта исә Фирүзә бер дә ямьсез кыз түгел: очлы ияк тә килешә аңа, муены да нәзек түгел, килешле биек муен, яңаклары исә алланып, янып тора! Тик ул берсеннән дә риза түгел, борынын да, ияген дә яратмый, көзге каршына килдеме, чырае караңгылана. Ташлап та китә алмый көзгене, аннан башка да яши алмый! Ярата иде элек үзен Фирүзә, каш-керфекләреннән дә бик канәгать иде, күзләренә дә исе китеп сокланып карый иде. Авылда бер чибәр дип саный иде моннан ике ел элек кенә. Менә ике ел инде кыз белән көзгедәге шәүлә арасында кискен көрәш бара...

Ул язда аның бит очларына вак-вак кына кызыл төрткеләр килеп чыкты. Калкып-төртеп тә чыктылар, Фирүзәнең йокысын да качырдылар. Ә йокысызлык һәммә кешенең, шул исәптән үсмер кызларның да холыкларын тамырдан үзгәртә торган була. Күзгә күренеп үзгәрде Сәләхетдин кызы!

Арага шуны да кыстырып куйыйк, кызның әнкәсе Гөлбикә апа үзе дә кешеләрнең тышкы кыяфәтенә бик нык игътибар бирә иде. Гөлбикә, медицинага һичбер мөнәсәбәте булмаса да, Язкилде авыл халкының ябыклыгын яки симезлеген тикшереп кенә яши иде дисәк тә хаталанмабыз. Яман иде аның ул холкы! Мәсәлән, һәр көн кичен, эштән яки биләмнән кайткач, көндез очрашкан кешеләренә бәя бирә башлый, яңалыкларны, ишеткән гайбәтләрне сөйли, «Фәлән апа белән ашта янәшә утырдык әле. Ул ябыклыгын күрсәң, бармаклары үтә күренмәле, янбаш сөякләре тырпайган! Аяклары сәнәк сабы юанлыгы гына... Ире ничек тора микән аның белән?!» дип башлап китә дә, урамда очраган, эштә күрешкән, юлда сөйләшкән авылдашларының таза-симезлегенә тулы бер отчет бирә. Авыл хатыннарының кайсысының балтыры юан, кайсысының биле нәзек, кайсысының түше тулы, кайсысының арты бик юка, һәммәсен бәйнә-бәйнә, үтергеч мыскыллау белән сөйләргә ярата Гөлбикә. Берсен дә мактамый, һәммәсенә ачы сүзе, зәһәр теле кагылып уза. Берәүләрне озын итеп, җан биздергеч ваклыклар белән тасвирласа, икенчеләргә бәһасе кыска, әмма кыскасы да үтергеч зәһәр була аның: «Карачкы. Ач бет. Ач әрвах. Үлемнән калган. Зираттан җәяү качкан. Сөйкемсез. Шыр сөяк. Котсыз»... Тагын әллә ниләр, тагын әллә ниләр!

Симез кешеләргә тагын да аяусызрак эләгә! «Ит бүкәне. Кышлау умарта. Сыра мичкәсе. Юылмаган күәс. Апара чиләге. Чучка лаканы. Буаз сыер. Мышкылдык...» ди тазаларга Фирүзәнең әнкәсе. Кунакка барамы, суга төшәме, кибеткә керәме, очраган бер кешегә, сәлам бирүдән элек, үз җырын җырлый башлый: «И-и, ябыгып, тартылып киткәнсең. Күз төпләрең кара янган. Әллә ирең эчәме? Әллә җелегеңә рак мазар керде микән?» дип һәркемнең котын ала. Хатын-кызлар, бигрәк тә өендә кашык-аяк шылтырый торганнары, Гөлбикәне күрүгә урамның икенче ягына ташланалар, тыкрыкларга кереп качалар, һич йомышлары булмаган капкаларны барып кагалар. Кешенең тормышында, белемендә, унганлыгында аның һичбер гаме юк, берәр кеше турында белешергә теләсә Гөлбикә бер сорауны гына бирә: «симезме?» я «ябыкмы?» дип кенә сорый. «Симез» икән, аңа бер бәя, «ябык» икән аңа рәхим-шәфкать юк. Һәммәсенә агуы җитәрлек! Олы кызлары Рауза, «Әткәй, әнкәй, кияүгә чыгам, Янбакты егете белән кушылабыз», дип хат язгач Сәләхетдин хатыны «егетең ябыкмы, симезме?» дип телеграмма суктырган. Зәйдә телеграмманы кабул итмичә бик озак тинтерәткәннәр.

Алма агачыннан ерак тәгәрәми, күп очракта бу наян сүз үтә рас килә, ул атага, кыз анага охшый. Фирүзә дә әнкәсенең бәһа-сүзләрен чырык-чырык көлеп, яратып тыңлап үсте дә, бик яшьли иптәш кызларының тышкы сурәтләренә күз сала башлады. Мәктәп елларында аның

бу гадәт-холкы да тирәнәйде, кызның табигатенә әйләнде. Классташлары аның әрем теленнән бик иртә җык күрделәр! Сипкел битле Руфаниягә дә эләкте, чак кына камытрак аяклы Кифаяга да көн күрсәтмәде Фирүзә, физкультура дәресләрендә, тәнәфесләрдә гел ул булып йөреп күрсәтә иде. Сәләте бар нәләт суккан кызның, ошата! Сул күзе чалыш Нәфисәгә мәктәптә бөтенләй көн юк иде. Фирүзәне тактага чакыралар, чыга, чатнатып сөйли. Укытучы аны күрми, ә ул Нәфисә булып күзен чалышайта, Кифая төсле аягын кәкрәйтә, классташлары егыла-егыла көләләр. Фирүзәгә шул гына кирәк тә! Нәфисәнең партасына каплап елый башлавын, Кифаяның комачтай кызаруын ул гадәти хәл дип исәпли, классташларын көлдерә алса аңа шул җиткән! Берәрсе чәч тарамыйча, тырнак кисмичә яки үтүкләнмәгән күлмәк киеп килсәме, аңа көн бетте! Фирүзә шул сәгатьтә үк стена газетасында көлке мәкалә бастыра, кыяр борын асып, шакшы камыт киертеп сурәтен дә ясап куя. Кулы ята, язуы да матур Фирүзәнең, рәсемне дә оста ясый. Чиста, пөхтә булу өстенә һәрьяктан унган кыз Фирүзә. Чәче ике калын толымга чак сыеп спай гына җилкәсендә ятып тора, китап-дәфтәрләре тышланган, күлмәк, галстугы үтүкләнгән, баш яулыгы, кульяулыклары кардай ак. Җыелышларда гел аны мисалга алып сөйлиләр. Мәктәптә яңгыраган мактау сүзләре өйгә дә бик тиз барып ирешә, ата-ана ул мактауларга үз сүзләрен дә кушып кызга киләчәккә туп-туры юлны күрсәтәләр: «Артта калма, алга чыгарма!» «Артта калганны изәләр!» «Кемнеке дигәндә Югары оч Сәләхетдин балалары дип әйтерлек булсын!» Шушы тоташ мактау кыз күңеленә баллы яңгыр булып ява һәм аңа башкаларны күрәләтә кимсетергә хокук бирә иде. Бөтен мәктәп, бөтен авыл күз текәп, мактап торган классташларына Руфания дә, Кифая да, Нәфисә дә сүз әйтергә базмыйлар. Каршы төшкәнне, сүзен кире каккнны яшьтән үк өнәмәде Фирүзә, кичермәде дә. Якын дуслары, җан сердәшләре булмаса да башкалар аңа ярарга, һич югында ярaклашырга тырышалар иде. Әче теленнән дә, яман холкыннан да бөтен мәктәп куркып, калтыранып тора иде.

Көннәрдән бер көнне теләсә кемнең табигый кимчелегеннән көләргә яралган авыз йомылды да куйды. Кызның чеп-чиста ал битенә бетчәләр чыгып сибелде. Шул хыянәтче төрткеләр Фирүзәнең телен кисте. Башта биттә булдылар алар, аннан сикереп маңгайга менделәр, борын өстен сардылар, кыскасы, ундүрт яшьлек кызның ике бите язгы күк гөсле, әйтерсең кызгылт йолдызлар белән чуарланды.

Үчекләүләр бетте, бәйләнүләр онытылды, шып булды кыз!

«Җәйге кызуларда бетәр әле, үсмер чакта була инде!», дип юатты әнкәсе кара кайгыга сабышкан кызны. Авылларында фельдшер булып эшләүче Вәзилә апасы дару-майларның ниндиен генә алып кайтып карамады, шәһәрдән әллә нинди лосьоннар, кыяр-кабак сулары, француз кремнары кайтартты, Николаев шәһәрендәге «Ал җилкәннәр» фирмасының кремнарын шифалы икән дип ишетеп, аларны эзләп таптылар, берсенең дә файдасы күренмәде. Уку бетте, җәй җитте, каникуллар узды, җәйге челләдә төрткеләр аз-маз җыелып торган кебек булдылар да, көзен, нәкъ укулар башланыр алдыннан, яңгыр артыннан ишелеп чыккан гөмбәләр шикелле, бөтен биткә тараддылар. Маңгайга, борын яфракларына менеп кунакладылар. Колак артындагыларын кеше күрми әле, анда да бар алар!

Аңа беркем үчекләп сүз әйтмәде, үртәмәде, җәберләмәде. Шулай да баштагы көннәрдә ул ике көн дәреска бармады. Ике көн көзгегә каршына утырып тоташтан үкседе. Сердәше көзге иде, дошманы да шул булды.

Укучылар казлар кебек тезелешеп бәрәңге алырга чыктылар — бармады.

Иптәшләре чөгендердә эшләделәр — күренмәде.

Урманга, агач кәүсәләренә сарган корткыч күбәләк күкәен җыеп яндырырга йөрделәр — эз дә басмады. Тавышы матур — элек сәхнәләргә менеп җырлый торган иде — хәзер бетте, эзе дә юк. Бит-маңгаен карчыклар шикелле яулыгы белән каплап килә дә, клубның ят яктысы гөшми торган почмагында мыштым гына утыра. «Нигә Руфания төсле сипкелле, я булмаса Кифая кебек камыт аяклы түгел икән мин?» дип гөрле уйлар уйлый.

Элегрәк, классташ малае Фәрит, очрашканда, кыздан күзен алалмый иде. Фирүзә дә борынын чөеп аңа карап-карап куя иде, хәзер очрашсалар бер генә кычкыра: «Сиңа ни кирәк тагын?» «Нигә челәясең?»

Кайта да мендәргә капланып җылый. Иртән әнисе мендәрне кояшка чыгара.

Ашый да китабын тезенә куеп, көзге каршысына утыра.

«Фирүзә, суга бар!»

«Күрмисезмени, укыйм».

«Фирүзә, мунча як!»

«Дәресләрем күп!»

«Фирүзә, он иләче, кызым».

«Вакытым юк!»

Бармый, якмый, иләми — көзгегә бага да битендәге бетчәләрне саный. Юк, бетмиләр дә, кимемиләр дә — арталар гына!

Руфаниягә дә чыкты таплар, Кифаяга да, Нәфисәне дә чит итмәделәр, берән-сәрән аның битендә дә күренә. Аларга ярый, аларга килешә, берсе сипкелле, икенчесе камыт аяк, өченчесендә чалыш күз! Тик нигә алар Язкилденең иң чибәр, иң пөхтә, иң уңган, иң бай тормышлы Сәләхетдиннең иң иркә кызы җырчы Фирүзәнең ал битен ямьсезләделәр? Бармы дөньяда хаклык?!

Язкилде авылы зур да, болай бик бәләкәй дә түгел, җиде авылны берләштергән «Урал» колхозының бер бригадасы гына, иң олы бригадасы. Дүртне бетергәч алар моннан өч чакрымдагы Түбән авылга йөреп укыдылар. Мәктәп шунда. Тугызынчы, унынчы классларда Фирүзә Түбән авылның ике катлы таш интернатында торып укыячак. Ул бу көннәрне күз алдына китереп уйлый башласа, күз алдында болытлар тагын да куера. Әле монда, өйдә чакта, ялгызың каласың да көзге белән серләшәсең, үзеңә үзең генә текәлеп карап торганда юанырлык мәгънәләр дә табып була. Иреннәре сусыл гына аның, кабарынкы. Керфекләре куе, озын, күз читләренә күләгә төшереп торалар. Кәттерен кенә булса да күкрәкләр дә йомрыланып килә. Тәне ап-ак Фирүзәнен. Тик менә бите, маңгае... Ун күз сиңа карап торганда ничек көзге алдына барып басмак кирәк? Газап булачак интернатта Фирүзәгә, үлем булачак. Әллә аңынчы бетәрләрме?..

Иртән көзгегә карый да көрсенә.

Кичен уфылдый да көзгене каплап куя.

Апасы Вәзилә аны күргән саен көлә: «Аптырама, апаем. Бетәләр алар! Язкилдедә синнән сылу кыз булмас әле!»

Булыр, булыр... Ә Фирүзәнең бүген үк иң сылу буласы килә. «Артта калма, алга чыгарма!» «Артта калсаң, абынырсың».

Әллә дөрес күрсәтмиме, дип, җиде белән көзгене сөртеп карый, ап-ак көзгеләре дөп-дөресне күрсәтә.

Онытмаган булсагыз, Фирүзәнең быел сигезенчене тәмамлап килүен әйткән идем инде. Хәзер алар Түбән авылга имтихан тапшырырга йөриләр. Бүген консультациягә барырга тиешләр иде, машина юк икән. «Машинаны кычыткан ташырга куйдык шул, үскәннәрем», диде бригадир һәм читенсенеп кенә Фирүзәгә карады. Ишетсәләр дә машина булмаслыгына ышанмадылар алар. Язкилдедән сигезенчедә унбер бала. Җиде кыз, дүрт малай. Арада теге Фәрит тә бар. Ничек килмәсен дә

машина? Ел буе йөрттеләр аларны, илтеп куйдылар, барып алдылар, нигә бүген генә җәяүгә калдырсыннар? Имтихан алдыннан... Сигезенчене бетергәндә генә!.. Бер-ике рейс кычыткан кайтарыр да шофер Галәви авызын ерып килеп житәр әле! Озаккамы әллә, әнә генә ич Түбән авыл, терәлеп тора, өч чакрымда гына! Малайлар: «Әйдәгез, җәяү сыпырдык!» дип үгетләделәр, кызлар күпчелек — алар да риза, бер Фирүзә генә каршы.

— Җәяү?! Бүген җәяүгә ризалашсак, алар гомергә машина бирәчәк түгел! — диде ул.

— Ә консультация? — диделәр кызлар бертавыштан.

— Көтеп торсыннар! Янмый торгандыр әле!

Кифая бик карышыр иде, Фирүзәдән курка, тотар да: «Синең камыт аяк белән тәпили башласаң, төш болай да житәр!» дияр.

Нәфисә, «барыйк!» дип бик әйтер иде, шүрли: «Синең чагыр күзең белән кайда ялгыш, кайда дөрес икәнен күреп булмый!» дияр.

Сипкелле Руфания күптәннән аның белән сөйләшми.

Малайлар Фәриткә текәләләр, ул да Фирүзәгә каршы төшеп тормый.

Машина килмәсен дә беләләр, ауныйлар чирәмдә, юаныч тапкан булалар. Ә Фирүзә гадәтенчә читтә утыра, уенга катнашмый, күзе юлда, уе юлда. Кемдер туп алып килде, көн аяз, чирәм яшел, жир тигез, тибәләр генә. Оча туп! Беразга консультация дә, читтә кагаеп утырган Фирүзә дә онытылды.

Бер сәгать дисәм аз, сәгать ярым дисәм күбрәк булыр, шактый уйнадылар, шул чакта авыл ягыннан велосипедлы бер кеше күренде. Малайлар сискәнделәр, нясез калган туп тәгәри-тәгәри Фирүзә янына ук килеп житте. Ул аңа әйләнеп тә карамады. Классташларының: «Җәмил абый килә! Нигә соңга калды икән ул? Бүген футбол матчы билгеләнгән иде бит! Каптык!» дип ашыгыч пышылдауларына да колак салмады. Килүчегә дә карамады Фирүзә. Чыннан да бу аларның физкультура укытучысы, җәен-кышын мәктәпкә я чаңгы, я велосипед белән бара-кайта йөрүче Җәмил Камалов иде.

— Сез нигә монда? — диде ул, велосипедыннан житез генә төшеп.

— Машина килеп житмәде бит, абый.

— Иртәдән бирле машина көтеп ятасызмы?

Җәмил Түбән авыл ягына карап алды.

— Кычыткан ташырга куйганнар. Бер килер әле!

— Җәяүгә ни булган?

Нәфисә Кифаяга карый, Кифая Руфаниягә. Җыйнаулашып бер читтә утырган Фирүзәгә борылалар. Малайларның баш түбән иелә, футбол тубы тибеп тирләгән җилкәләрдән пар күтәрелә.

Фирүзә утырган жиреннән генә тупны аягы белән бер читкәрәк тәгәрәтте дә:

— Без җәяү йөрмибез, абый, — диде.

Һәм башын артка чөеп укытучысына карады. Һич каушамады Фирүзә, битенең бетчәле икәнен дә бер мизгелгә генә онытты, беренчедән, Җәмил әлләкем түгел, аларның терәлеп торган күршеләре Мирфатыйх малае, икенчедән физкультура укытучысы гына, өчле чыгарыр дип куркасы юк, өченчедән... шушы Җәмил Фирүзәнең апасы Вәзилә артыннан йөри. «Күләгәдәй йөри, артымнан калдырмыйм, алга чыгармыйм», ди апасы мактанып.

Җәмил ашыга иде, алай да велосипедын Фирүзәгә табарак тартты.

— Нигә җәяү йөрмисез инде сез?

— Хәзер иң ярлы кеше дә җәяү йөрми. Берәү дә. Без замана балалары.

Башкаларның колак үрә торды, шактый һавалы бу җавапка укытучылары ни әйтер икән?! Нәфисә Кифаяга карый, «әйдә, киттек!» дип

ым кага. Кифая Руфаниягә пышылдый: «Әллә кайчан барып житкән була идек!» Малайларның күз жиргә тәгәрәгән, тузанлы битләреннән кара тир ага. Бер Фирүзә генә хәрәкәтсез. Хәрәкәтсез үк түгел икән, күкрәгенә төшкән калын толымнарын берәм-берәм артка чөйде. Өч минут дисәм азрак, биш минут дисәм арттырган булырмын, мәгәр шактыйга тартылды чирәмлектәге тынлык! Менә бит ул нинди Югары очның Сәләхетдин кызы Фирүзә! Укытучының авызын йомдырды. Тик Жәмилнең авыз йомарга бер дә исәбе юк иде, иркә кыз Фирүзәнең гадәт-холкын бердән өнәмичә йөри, кистереп әйтергә җае чыкканы гына юк иде. Ул велосипед тәгәрмәчен Фирүзәнең тәбәнәк үкчәле ак туфлясы янына ук китереп житкерде.

— Оят! — диде ул аңа туп-туры карап. — Космоска жибәрерлек егетләр-кызлар эшсезлектән симереп монда ятасыз! Уттай эш өстендә машина сорап йөрергә ничек оялмыйсыз?! — Сәләхетдин кызына аерым өлеш чыгарды Жәмил. — Ә сиңа, Мөхетдинова, жәяү йөрү килешеп китәр иде. Спорт ул жәяү йөрү! Өйдә эшләмисең, ата ялкаусың, спорт белән, физик эш белән даими дус булсаң, кайбер кимчелекләрең тизрәк узар иде. Дөньяга дөм орынып жылап йөрмәс идең...

Жәмил абыйлары мактаулы кызга әнә шулай диде. Әллә ни уйлап та әйтелмәгән иде югыйсә, бары тик Фирүзәнең былтыр көз чөгендердән качуын, бәрәңгегә чыкмавын, зарарлы корткычларга каршы көрәшмәвен күз алдында тоткан иде, кыз үзенчә аңлады, Жәмил абыйсы аның бетчәле битен мыскыллый дип кабул итте, мунча чыккандай кызарды, кашы жимерелеп, күз кабаклары өстенә салынды, аскы ирене язгы тамчы кебек менә тамам, менә тамам дип калтырап тора башлады. Жәмил башкасын төпченеп тормады, ул бик ашыга иде, велосипедына атланды да Түбән авылга элдертте, малайлар-кызлар, иркенәеп, сулышлары киңәеп, яңа юылган тәрәзәләр төсле балкып, гөрләшеп аның артыннан иярделәр. Иң алдан Фәрит чаба, аның артыннан Нәфисә сикергәли, менә алар алгарак чыктылар, житәкләштеләр.

Үлде Фирүзә. Бетте Фирүзә.

Чирәмдә бер ялгызы калды.

Талгын гына жил исә, баш очында гына тирбәлә-тирбәлә тургайлар сайраша. Кузгалмады Фирүзә. Байтак утырды.

Гәүдәгә калыкса да ябыклыгы күзне кисеп торган чуар бозау аның янына ук килде, башын иеп иснәде, иреннәрен ялмаштырып толым очындагы ал тасмага үрелде. Башка вакыт булса Фирүзә сикереп торып кулына ни эләксә шуның белән бозауның сыртын төяр иде, бүген эндәшмәде, киресенчә, нигәдер бозауны ифрат нык жәлләде. Ике кулы белән чирәм умырып сузды.

— Мә, аша, аша!

Иң очтагы ишегалдыннан гәүдәгә Фирүзә хәтле генә әби килеп чыгып, акрын-акрын аларга якынлашты.

— Чирле бозау ул, — дип аңлатты әби. — Рәхмәт, миһербанлы бала икәнсең!

Фирүзәнең ике күзеннән тулышып ике чишмә акты.

Консультация онытылды, һәммәсе кирегә китте...

Кинәт Язкилдене яңгыратып этәчләр кычкыра башлады, тавыклар кытаклады, үрдәкләр бакылдады, күркәләр голдырдады. Алар һәммәсе дә: «Фирүзә ямь-сез!» Фиру-зә кот-сыз! Фирүзә артта кал-ган! Фирүзә шушы чуар бозау төсле-е-е!» дип шаулашалар кебек тоелды. Ул сумкасын тез күмәченә бәрә-бәрә Югары очка менеп барганда колагына чаң тавышы килеп ирешге. «Ямьсез! Кот-сыз!» дип чыңлый иде сыман чаң.

Тавышлардан колагы тонып кайтып керсә, энесе Зәйтүн авызын ачып янбакчада жылап тора. Янында баягы котсыз Жәмилнең энесе Әнәс тә бар. Сугышканнар бугай...

— Әй, сугыш чукмарлары! Икегез дә атлагыз әле монда! — дип тамак төбе белән генә кычкырды кыз, малайлар шым булдылар. Бу боерыкка буйсыныргамы, юкмы, дип уйлап алды да, үзен гаепсез санап, Әнәс тә Зәйтүнгә иярде.

— Нигә сытылдың? — диде Фирүзә Зәйтүнне җилтерәтеп.

— Әнә ул, Мирфатыйх тәресе кыйнады.

— Ә син, боламык, шуңа бирешеп тордыңмы?

Һәм Фирүзә аны-моны көтмәгән Зәйтүн-сытыкның янбашына берне кундырды. Малай иелеп, борынын тарта-тарта шыпырт кына үкси башлады. Әнәс аның дер-дер калтыраган иңенә кулын салды.

— Авырттымы, малай? Нык суктымы? — дип сорады ул. Зәйтүн яшьле күзләрен мөлдерәтеп, гаҗәпләнеп әле генә дошманы булган Әнәскә борылып карады. Фирүзә фыр-р итте дә Әнәснең кулыннан сигез бүлкәле кепкасын йолкып алып югарыга чөйде. Кыска гына гомерендә күпне күреп өлгергән кепка кош булып очты да Зәйтүннәр тирәгенең иң куе ботаклары арасында кунып калды. Үзләренә сәер кунак килгәнне күреп Югары оч чыпчыклары куркынып чыркылдаштылар. Фирүзә чабып өйгә керде, сумкасын карават астына ук атып бәрде дә көзгегә килеп капланды. Санарга тотынды.

Берсе дә кимемәгән, күпме вакыт кояшта утырса да битендәге төрткеләр нәкъ илле өч иде... Ул кинәт: «Нигә теге чуар бозауны тукмап җибәрмәдем дә, нигә Мирфатыйх тәресе, мин суккач, Зәйтүнне җәлләде соң әле?» дип уйлады. Үз уеннан үзе куркып китте.

4

Җәмил әллә кайчан мәктәп янындагы спорт мәйданында тугызынчы класс футболчылары тренировкасында булырга тиеш иде. Ул ашыгып өйдән чыгуга, үзләреннән биш-алты өй аша яшәгән Сәрвәрбикә апаны очратты. Больницага барырга чыккан икән бичара. «Төне буе тешем сызлады, чыдар әмәлем юк, Түбән авылга ук төшеп җитә алмам, фельдшер Вәзилә янына кереп чыкканда да ару булыр иде», диде. Яңакларын иске тире бияләй белән җылытып бәйләгән карчык яныннан Җәмил тиз генә узып китә алмады, велосипедыннан төшеп әбекәйне җитәкләде, аннан култыклап ук алды, медпунктка шактый озак төштеләр. Ике урында утырып ял иттеләр, Җәмил әбигә сиздермичә генә кул сәгатенә күз төшереп алса да, карчыкны ташлап китмәде, юк вакытын бар итеп җылы кулдан авыруны Вәзиләгә тапшырды. Вәзилә дә аны тиз генә яныннан җибәрмәде, чыга башлагач өйалдында куып житте: «Аз-маз караганчы гына түз инде, бик чәүчәләк карчык бу Сәрвәрбикә әби, үзем генә тотынырга куркам», диде. «Теш врачы түгел лә мин!»

Кире борылып керергә туры килде, Вәзилә кечә якта бик озак мыштырдады, урындык аркасына башын куйган әби туктаусыз аһылдады. Җәмил, түземлеге бетеп Вәзилә ягына чыкты һәм, сәгатен күрсәтеп: «Безнең бүген бик җаваплы очрашу, ашыгам!» диде. Вәзилә кара белән сызылган нәзек, кыйгач кашларын сикертеп алды: «Һи, синнән башка да тибәрләр әле тупны!» дип куйды. Җәмил, Вәзиләнең тел төбен бик яхшы аңлаганга, сүз кайтарып тормады, инструментларның суда кайнап чыкканын да, Вәзиләнең Сәрвәрбикә әбинең авызына дарулар тамызганын да сабыр гына уздырып җибәрде...

Медпункттан чыгып ике-өч атлам китүгә үк, әчтән әбинең яшьләрчә кетердәтеп көлүен ишеткәч кенә аңа нигәдер сәер һәм бик шикле булып китте. «Әллә бәхетсез юлга чыктым инде бүген?» дип уйлап алды.

Ә болай, чынлыкта, Җәмил бәхетле егет — моны алдан ук белдереп куйыйк. Бәхетне һәркемнең үзенчә аңлавын, үзенчә күз алдына китерүен, хөрмәтле укучылар, үзегез дә бик яхшы беләсездер. Берәүләр бәхетне хезмәттә күрә, эш өстендә татый. Икенчеләр байлык артыннан куа,

көне-төне мал арттыра. Данны бәхетнең иң югарысы дип санаучылар да бар, җирдә халык төрле, кешеләр күп, бәхетнең аңлатмалары да төрле һәм каршылыклы да. Җәмил исә үзенчә бәхетле иде. Максатына ирешә барганы өчен бәхетле. Шулай уйлый егет, шуңа ышана. Максаты да буш хыялларга таянмаган аның, үз рух көченнән, үзенә ышанудан туган, җирле, нигезле максат. Яшьтән үк ул буш өметләр белән яшәмәде, үз тырышлыгына ышанды, үз көченә таянды.. Әле бик бәләкәй чагында, мәктәпкә дә кермәгән иде, язгы ташу тынар-тынмаста Олы суны йөзеп чыгам дип әтәчләнде. Йөзеп тә чыкты. Дөрес, тамак төбе кызышып, ютәлләп атнага якын юрган астында ятты, мәгәр үз сүзен сүз итте. (Олырак малайлар котырткannar иде аны, котыртуын!)

Язкилденең иң биек тавыннан, бөркет оя типкән, Уралның иң соңгы тамырлары арасындагы биек кыядан чаңгыда шуып төштеме? Төште! Бусында беркем котыртмады, шаһиты да бер генә кеше иде — күрше Сәләхетдин кызы Вәзилә. Шуып төшкәндәге рәхәтне белсә идегез сез! Тезләр бер-берсенә тияр-тимәс кенә калтыраналар, колак төбендә ургылып тау җиле сызгыра. О-о, тау җиленең нинди икәнен малай беренче тапкыр шунда татыды! Үзәннәрдә искән чыпчык җиле түгел инде ул, тауда сызгырган бөркет җиле, егетләр җиле! Оча Җәмил, җил аны канатландырып очырта, сикереп-сикереп тә китә, аяклары җиргә тими, егылмый мәгәр, гәүдә нык, сыгылмалы, кулларда көч, кулларда таяклар, чаңгысы да әтисе ясап биргән өрәңге чаңгы.

— Ничек егылмадың син, Җәмил?

Көлә генә Җәмил!

— Ничек барып төшмәдең!

Шаркылдый гына Җәмил!

— Минем котым очты, карап торып үлә яздым!

Кыз авызыннан мондый сүзләр ишетер өчен Җәмил Урал тавының иң биек, иң хәтәр түбәсеннән шуып төшәр иде. Ул куе соры күзләрен тутырып үзе төшкән текә тауга, үзе беренче башлап сызган сукмакка, буй-кыяфәте мәхәббәт һәм соклану белән тулган Вәзиләгә карады. Тау, тау җиле һәм Вәзилә өчесе бер булып нәкъ шул көннән үсмер йөрәгендә урын алдылар бугай...

Бәхет төшенчәсе кеше күңеленә җиңү белән янәшә килә. Җәмил белән дә шулай булды. Бәхет өчен нәрсә кирәк? дип уйлады ул үсә төшкәч. Җиңү кирәк, алга бару кирәк, үз көчеңне раслау кирәк. Тулы бәхетне татыр өчен янында сөйгәнең булу да шарт дип уйлады егет. Валлаһи, шулай дип уйлады. Берәр җирдән укыган идеме, әллә зурлардан ишеткәне булдымы, нәкъ менә шундый уй килде аның бәхет иңгән күңеленә.

Мәктәптә ул географияне һәм физкультура дәресләрен аерата нык яратты. Җир шарында сигез мең метрдан ашкан ундүрт тау түбәсе барлыгын, кайбер каһарман шәхесләрнең бәхет татыр өчен шул биеклекләрне яулап йөрүләрен ул бик яшьли аңлады.

Түбән авылда укый башлагач Җәмил гел чаңгыда гына йөрде. Аның һәвәслеген укытучылар да күреп алды, егетне ярышларга йөртә башладылар, мәктәп ярышларына, мәктәпара ярышларга, аннан ераккарак, күрше-тирә районнарга да алышырга җибәрделәр. Барында да алга чыкты Җәмил, район чемпионы исеме белән армиягә китте. «Укырга кер, сиңа кайда да юл ачык», дигәннәр иде аңа, Җәмил көлде генә: «Солдат тормышын, чын ир язмышын татыйсым килә», диде. Бу сүзләрне ул Вәзиләгә дә әйтте. Вәзилә аңа истәлеккә чиккән яулык бирде. «Яшьлек мәхәббәтемнең бүләге, мин сине көтәрмен», диде кыз.

Вәзилә, Вәзилә...

Күрше Сәләхетдин кызы Вәзилә!

Нинди матур чаклар бар иде! Ничаклы гөнаһсыз багланышлар бар иде Сәләхетдин белән Мирфатыйхлар арасында! Юри дә, күңел өчен

дә, кирәктә дә бер-берсенә бик теләп йомышка йөрешәләр, бәрәңге утырту, алу кебек олырак эшләр ике йортта уртак башкарыла иде. Сәләхетдиннәрдә эш башланса, Мирфатыйхныкылар сибелеп бакчага чыга, Мирфатыйхныкылар эшкә керешкәндә, бил буып күршеләр кереп житә. Эш житми күршеләргә, башлауга тәмамлап та куялар иде! Сугым көнне, чалу итеннән пешкән өреле шулпа ашарга Сәләхетдиннәр чакырса, сыер бозаулагач угыз коймагы ашарга Мирфатыйхлар дәшә. Мунча яксалар да бер-берсен чакырмый калмыйлар, ул чагында мунчадан соң хатыннар гына түгел, ирләр дә чәй генә эчә торган иде. Балаларның туган көнен билгеләп узу гадәткә кермәсә дә бәбәй чәеннән бер-берсен калдырмыйлар иде. Бүләкләр дә ул чаклы зур булмый иде, туйларга өч метр ситсы, өстәл ашъяулыгы кебек затлырак нәрсәләр килсә, бәбәй туена ситсы бер метр да житә, нәни чуар тастымал да бик олы бүләк санала иде. Олы бүләк — чөнки һәммәсенә хөрмәт билгесе, эчкерсезлек үрнәге, дуслыкны ныгыта торган жылы ишарәләр була торган иде.

Берәрсе чирләп китсә яки кул-аягы киселсә, ике йорт бер сулыш ала башлый, хафа уртакка әйләнә, киптергән кура жиләге, жиләк яфрагы, андыз тамыры, сарымсак, уган кишер яки тозлы кәбестә тотып хәзер бер-берсенә кереп киталәр иде. Ул чакта ике кура-хужалык арасында тәбәнәк кенә, утырган эт биеклеге генә читән иде. Ул да чебиләр, бәбкәләр ике арада йөреп бакчаны бөтенләй такырламасын өчен генә үрелгән. Сәләхетдиннәр тавыгы Мирфатыйхларда, Мирфатыйхныкылар Сәләхетдиннәрдә жим тибенә, сарык-бәрәннәрнең бер-берләренә кереп кунган чаклары еш була, этәчләргә хәтле бик тату иде ул чакта! Качкын тавыклар күрше оясына күкәй салса, ул мәсьәлә дә тавышгаугасыз гына хәл ителә, хатыннар бер көлеп куярлар иде дә, беттекитте.

Ике йорт арасында какшамас татулык хөкем сөрде.

Ишле бала-чагалы ике йорт арасында бернинди яшерен сер, гайбәт, көнчелек юк иде.

Мирфатыйх та, Сәләхетдин дә Ватан сугышында катнаштылар, икесе дә яраланып туган илгә кайттылар. Сәләхетдиннең кулы яралы иде, Мирфатыйхның мина ярчыгы тигәннән сул күзе күрмәс булды.

Үткен күз кирәк чакта алдан Сәләхетдин йөрде, кул көче соралганда иң читен жиргә Мирфатыйх ыргылды — тату яшәделәр күршеләр, дөрес яшәделәр. Тату ата-ананың балалары да тату була. Бу сыналган нәрсә. Балалар арасындагы ызгыш иң элек йорттан, ата-анадан башлана. Бигрәк тә Җәмил белән Вәзилә татулаштылар...

Яшьләр үскән саен бу дуслык ныгыды. Өлкәннәр: «Ниһаять, кодакодагый булабыз!» дип сөенешеп йөри башладылар. Күршелекне туганлык белән дә ныгыту ике гаиләнең дә хыялы иде.

Җәмилнең унынчыдан соң армиягә китүе көтелмәгән хәл булды.

«Кайтамы соң!» дип сөйләнделәр күпләр.

«Кайтмаска китүедер», дип юрадылар ата-аналар.

«Кайтмас!» дигәнне ишеткәч, авылда берәү бик сөенде һәм бу кеше Җәмилнең жан сөйгәне Сәләхетдин кызы Вәзилә иде. Вәзиләнең дә алдагы тормыш, мәхәббәт турында үз планнары өлгереп килгән чак иде. Аның планнары да ата-аналар өчен көтелмәгән яңалык булды. Вәзилә Җәмилнең үз сүзен сүз итәргә яратканын белә иде. Сүзен жиренә житкергән кешене генә хөрмәт итүе дә кыз өчен сер түгел иде. Вәзиләнең дә сүз әйтәсе һәм сүзен жиренә житкереп Җәмилнең мәхәббәтен тагын да ныгытасы килеп китте. Әле Язкилдедә, башлангычта укыганда, мәктәпкә Түбән авылдан врач менгәли иде. Врачны шәп трантаска юртак ат жигеп барып алуларын, укытучыларның аны ничек каршылавын, врачның шикәрдәй ак халат киеп биек үкчәләре белән тек-тек кенә басып коридорда йөрүләрен ул бик яшьтән күңеленә өлге итеп сеңдерде. Хисләрен уйнатты, дәртен котыртты Түбән авыл врачларының Язкилде-

гә килеп китүе! Аның да врач буласы килә иде. Әмма Вәзиләнең балачагы авыл урамнарына да шәһәр җилләре килеп җиткән кызыклы бер чорга туры килде. Шәһәр, аның матур урамнары, көне-төне аллы-кызыллы су атып утырган фонтаннар, кино-театрлар, киштәләре байлыктан сыгылып торган мәһабәт кибетләр, бай базарлар, танца заллары кызның төрле якка ташланырга әзер күңелен әллә кайларга алып китәләр иде. Авылга кунаклар кайта, затлы киемнәр кайта, төрле-төрле күчтәнәчләр кайта... Вәзилә алдагы тормышын бары тик шәһәрдә дип кенә күз алдына китерә һәм үзен шәһәрнең иң күренекле больницаларының берсендә иң атаклы врач булырга әзерли иде, шәһәргә, бары тик шәһәргә генә!..

Шәһәр кешесе булуның бердәнбер һәм ышанычлы юлы институт бетереп диплом алу, эшлекле кешегә кияүгә чыгу иде. Димәк, аның кияве буласы кеше дә алдагы шәһәр тормышына бүгеннән әзерләнә башларга һәм шул сукмактан тайпылмыйча алга карап кына барырга тиеш иде.

Бик яшьли дәрт керде Вәзиләгә, шул комачауладымы, бишенче-алтынчыларда гел өчлегә генә укый башлады. Китабын алдына алып утыра, башында уку түгел, шәһәр, аның шаулап торган урамнары күз алдыннан гел китми. Югары оч кызы өчен институттагы конкурслар, керү өчен барган ярышлар, җитмәгән баллар, күз яшьле фаҗигаләр да сер түгел иде. Шуңа күрә ул сигезенчедән соң озын-озак уйлап тормады, тотты да Минзәлә медучилищесына барып керде. Болай өчлеләрне тезеп укып барганда аңа институт ишекләре ябык иде. Керде, түзем генә укыды, диплом алды, шәһәрдә калмады, Язкилде фельдшерлык пунктына мөдир булып кайтты. Асылда ул бары тик Җәмил өчен генә кайтты авылга! Бары аның өчен генә! «Шәһәр, бары тик шәһәр генә!» дигән хыялыннан баш тартканы да, бар тартырга җыенганы да юк иде аның. Бер юл мөмкин түгел икән, алга узар өчен икенчесен — ышанычлысын сайлады Вәзилә. Аныңча, беренче разрядлы спортсмен, республика күләмендә чаңгы ярышларында алдынгы урынга чыккан Җәмил армиядән авылга да кайтып тормастан шәһәрдә, күренекле бер урында урнашып калачак иде. Вәзилә бик тиз генә кияүгә чыгып, Җәмил янына, шәһәргә күчеп китәргә әзер иде.

Нишлисең, үз акылларыңны биреп булмый, Җәмил авылга кайтты һәм Түбән авыл урта мәктәбендә физкультура укыта башлады. Казан педагогия институына читтән торып укырга керде. Аны биш куллап алдылар. Укуы ярап та торсын ди, тырышсын, дипломсыз килеш ир кеше кая бара ала хәзерге заманда? Җәмилнең укырга керүен дә хуплады Вәзилә, өзелеп-өзелеп егетнең авызыннан «шәһәр!» дигән сүз чыгуын көтә башлады. Талантлы һәм перспективалы спортсменның Язкилдедә төпләнеп калуына һич тә ышанасы килмәде аның! Әмма Җәмил ике сүзнең берсендә «авыл», диде. «Авыл спорты» диде. «Авылны сакларга кирәк, авылның киләчәген яшьләр белән ныгытырга кирәк. Спорт — яшьләрне авылда калдыруның мөһим бер факторы», диде. «Ни өчен Голландия, Бельгия кебек бәләкәй генә илләрдән менә дигән югары класслы футболчылар чыга да, ни өчен безнең татар малайлары футбол уйный алмаска тиеш? Футбол — культура үсешен билгели торган уен ул!» дип өстәде.

«Нигә?» диде шаккатып Вәзилә, «синең үз тормышың, үз киләчәген булмас мени?»

«Киләчәгем дә, үз тормышым да авыл белән бәйләнгән!» диде Җәмил көлемсерәп.

Элегрәк булса Вәзилә берсүзсез җиңәр иде, авыз ачарга да ирек бирмәс иде егеткә, әгәр Сәләхетдиннекеләр белән Мирфатыйхныкылар бергә тотынсалар, егетне ә дигәнче борып салырлар иде. Тормыш бик кинәт үзгәрде, тормыш күршеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне дә, ике

күрше арасында еллар узып ныгыган дуслыкны да челпәрәмә китерде. Хәзер алар бер-беренә йомышка бөтенләй йөрмиләр. Бәрәңгене аерым утырталар, аерым алалар. Ике арадагы читәннең кемнеке икәнен оныттып та бетергәннәр иде, читән тагын метр ярымга биегәйгәч кенә Сәләхетдиннеке икәнлеге исләренә төште. Сәләхетдин ара капканы бөтенләй ачылмаслык итеп биклэп куйды, хәзер бер-берсенә керер өчен баш та урамга чыгарга кирәк.

Сәләхетдиннәрдән башланды бугай...

Әллә Мирфатыйхтанмы?

Юк, Сәләхетдиннәрдән ахрысы.

Биш ел дисәм азрак, җиде үк дисәм күбрәк булыр, берзаман, якшәмбе көн иде, Сәләхетдин районнан мотоцикл алып кайтты. Бишеклене. Башта бер атна ишегалдында тырылдаттылар, аннан урамга алып чыгып ай чамасы дырылдаттылар, ай үткәч берәм-берәм дә, төялешеп тә чаба башладылар. Эте-бете утыра да чаба, Вәзилә дә киткән була, бишеккә чүмәшкән Фирүзәнең дә авызы колакта. Ә Сабан туена, Сабан туена... Кулыннан килә, тәмамысы эт икән Сәләхетдин, мотоциклның бишеген алган да урынына зур чыбык чуман утыртып куйган: мәйдан буласы урынга бөтен семьясын чуманга утыртып төште. Шаккаттылар. Бөтен халык көрәш карый, Мирфатыйх хатынының күзе матайда. Бөтен кеше ат чабышын көтеп тора, Мирфатыйх хатыны Гөлмәрьямнең эче яна... Мәйдан янында дәшми түзгән иде, кайткач Сабан туе чәен эчеп бетергәнне дә көтмәде, «әнә, кешеләр Сабан туена машина белән генә төшкәннәр!» дип куйды.

Гөлмәрьям төне буе йокламады, йокламаса да коймагын изәргә онытып Мирфатыйхтан әр ишетте, икенче көнне үк Түбән авыл кибетенә төшеп бик һәйбәт көзгеле шкаф сатып алды. Шифоньер дип атала икән андый шкаф, затлы кешеләрнең түрендә шул була икән. Язуы артына ябыштырылган, төгәл йөз егерме җиде тәңкә. Мирфатыйх, «бәрәч, балаларга киемгә дигән акчаны тоткансың!» дип әрләгәч, шкаф тирәсенә сыенган хатын «күбрәк акча эшләрсең, хәзер заманы шул», дип кенә җибәрде.

Шкаф Югары очта беренче иде. Күрше-каршылар, кардәш-ырулар икешәр рәт кереп карадылар, Сәләхетдин Гөлбикәсе дә түзмәде, йомыш тапкан булып кереп чыкты. Атна дигәндә Гөлбикә дә Зәйнең үзеннән шифоньер кайтартты. Ике көзгелене. Язуын артына кадаклаганнар: йөз дә туксан сигез тәңкә. Күрше-каршы, кардәш-ыру савылып Сәләхетдиннәргә кереп китте, бәһасен белгәч тел шартлаттылар, көнләшүләрен сиздермәслек дәрәҗәдә әйберне мактадылар. Мирфатыйх хатыны Гөлмәрьям кермәде. Аның, кара коелып, пыр тузып келәт белән өйалды тирәсендә итәк җилфердәтеп йөргәнен Гөлбикә чолан тәрәзәсеннән авыз ерып күзәтеп торды. Икенче көнне Гөлмәрьям көтү куганда сыерын да, бозавын да озын чикләвек чыбыгы белән чаж да чож яра иде.

Шуннан китте, китте...

Шкаф артыннан сервант кайтты. Сервант артыннан диван. Диванга трельяж иярде. Трельяж холодильникны чакырды. Сервантлар буш тормады, Гөлмәрьям дә, Гөлбикә дә дистәсе-дистәсе белән чәшке-чынаяк, кашык-чәнечке, бәллүр вазалар, путаллы чәркәләр, балчык сыерлар, мөгездән ясалган әкәмәтләр, дәү-дәү буш дингез кабырчыклары һәм тагын әллә ниләр кайтарып тутырдылар. Бу чәшке-чынаяклар белән чәй эчмәделәр алар, аракыны да кунакларга кырлы стакан белән чөмерттеләр, чәнечкенең әллә ничә төрлесе булса да итне һаман сызганган беләкле кул белән умырдылар, әмма ярсып-ясканып сервант-шкафларны мал белән тутырдылар. Мотоциклларны машиналар алыштырды, хәзергесе көндә Сәләхетдиннең гаражында (ишетәсезме, алты йозаклы, бетон түбәле гаражында!) «Москвич», тора, Мирфатыйхларда «Жигули». Берсенеке чия төсле, икенчесенеке — лимон...

Кара мунчалар ашыгып-ашыгып сүтелде, дәү-дәү ак мунчалар өлгерттеләр. Мунча алдына иске «Саратов» холодильнигы илтеп утырттылар, элеккеге атаклы шарлы башлы тимер караватлар да мунча алдына күчте. Чабынып-коенып чыккач ачы балны тустаган белән шунда «Саратов»тан алып кына эчә торган иттеләр. Өйләр дә танымаслык булып үзгәрде, аларга уңнан да, сулдан да бүксә-бүксә такта верандалар кушып куйдылар. Мичләрне сүтеп өйләрне пар белән җылытуга күчерделәр. Верандалар гына сусынны басмады, йортларны сүтеп, алты, сигез почмаклы егермешәр ниргәле пулатлар салып куйдылар. Элек бәдрәф, хәзер культуралы туалет исемен алган ханәләрне галерея ясап өй белән тоташтырдылар. Карбазларын күмделәр, тәбәнәк капкаларны дәү-дәү МАЗлар, КрАЗлар кереп йөрерлек итеп киңәйттеләр, биегәйттеләр. Урман якын, урман үзебезнеке, урман шалкан бәясе! Телибез икән трактор белән менеп алабыз, телибез икән бульдозер белән сөйрәтеп алып кайтабыз. «Дружба» атлы пычкы өй борынча, һәр кешедә бар, колхоз бензины бушлай, кисәләр генә, йөзәр яшьлек юкәләрне, биш йөз яшьлек имәннәрне егалар гына. Җир гүләп, җир ыңгырашып кала, тракторлар, бульдозерлар юл юк җирләргә күкрәк киереп кереп китәләр.

Кала кунакларына хәзер яңа сауган сөт тә, яңа язган май да әләкми, алар аертылган сөткә Зәйдән кайткан ипине манып ашыйлар да, аллаһы әкбәр, «монда хәлләр алай икән!» дип тизрәк килгән җирләренә таю ягын карыйлар...

Көнчелек дигән сүз кергән арага тиз арада дошманлык дигән мөнәсәбәт нигез салды. Сәләхетдин белән Мирфатыйх кан дошманнарына әйләнделәр.

Балалар яшьрәк чакта бу куалашуда катнашмадылар да диярлек. Ләкин Вәзилә Җәмил турында авыз ачып өйдә сүз әйтергә базмый иде инде. Чөнки Җәмилне бөтенләй аңламый башлады. Кызның күңелендә гел бер сүз булды: «шәһәр! «шәһәр!» Җәмил исә, «авыл» диде дә катты.

Районга эшкә чакырдылар, бармады.

Өлкәгә күчәргә өндәделәр, ризалашмады.

Егетне районга чакыргач, Вәзилә сөенде. Казанга өндәгәч, күккә сикерде. Егет «Язкилдедә калам» дигәч ышанмады.

— Шаяртасың, җаный, — дип бармак янады.

Җәмил, бик гади генә, күптән сыналып бары тик бер нәтиҗәгә килергә мөмкин булган нәрсә турында сөйләгән кебек итеп, көлә-көлә:

— Калам дигәч, калам инде, Вәзилә. Мине беләсен, — диде. Кыз:

— Нигә? — дигән сүздән башканы әйтә алмады.

— Нигәме? — Вәзилә Җәмил маңгаена буразна булып яткан сырны беренче мәртәбә күрде. — Нигә икәнен дә әйтеп була хәтта! Менә иптәшләр белән ашханәгә ашарга гына керәбез. Дүртәү бергә утырабыз. Берәү токмач ала, икенчең борчак ашы, ә мин кәбестә ашы яратам! Монда нигә икәнен аңлатып булмый, һәркемнең төрле-төрлене ашавын гына күзәтәбез. Анда да бергәлек һәм бер төслелек юк! Минем бу заманда авылга ябышып ятуым бәлки сәердер, әмма мин аны үземчә аңлата да алам. Без бик еш кына татар халкы ишле халык, Советлар Союзында да алты миллионнан артык дияргә яратабыз. Халыкның унганлыгын гел-гел гомуми эш белән дә, күплек саны белән дә билгеләп булмый икән. Халкыңның илгә-көнгә даны таралган алдынгы кешеләре дә булу кирәк. Матрос Әсгать Җиһаншиннан башлап академик Сәгъдиевкә чиксез рәхмәтем һәм тиңсез хөрмәтем бар минем. Алар дөньяда татар халкының барлыгын, егетлеген расладылар. Федор Симашовны беләсең инде син. Биш авыл мәктәбен бетерде. Дөнья, олимпия уеннары чемпионы! Гап-гади керәшен малае, ә илгә күпме дан китерде! Татар халкы улы! Футболчы Галимҗан Хөсәенов, хоккейчы Зинәтулла Била-

летдинов, гимнастика остасы Галимә Шөгероваларны ал! Халкыбызның данын кайларга илтмәгән алар!

— Син дә алга чык, күч шәһәргә!

— Минем бик күп талантлы спортсменнар тәрбияләүче педагог буласым килә! Халкыбызның данын тагын да югарырак күтәрәсем килә! Безнең яклардан да менә дигән егетләр чыгарга тиеш.

— Шуннан ни?

— Аңлашылдымы?

— Шуннан ни була дим?

— «Аптыратыйммы, йөдәтимме?» дигән җәфалы бер уен бар! Бәйләнчек адәмнәр ярата аны. Шуны башладыкмы, Вәзилә?

Юк, Вәзиләнең уйныйсы да, Җәмил төсле итеп тирәнтен уйлыйсы да килми, аның үзе күз алдына китергәнчә яшисе килә. Чыгамы татардан чемпион, юкмы, аңа барыбер. Чыга икән, әйдә, аның Җәмиле чемпион булсын, дан казансын, чит илләргә йөрсен, төрле-төрле әйберләр, затлы киемнәр, шаккатыргыч сувенирлар алып кайтсын. Шулай яшәргә мөмкин булганда, һәркайда юл ачылып торганда нигә бу Язкилдедә череп-бурсып ятырга?!

Шөбһәләнде кыз, икеләнде һәм көннәрнең берсендә аның күз алды караңгы төндә яшен уйнагандай яктырып китте: әллә яратмыймы соң аны Җәмил?! Сөймиме?! Яратса, гел карышып, кирегә сукалап торыр идеме? Сөйсә, шундый тузга язмаган сүзләр сөйләр идеме? Сөйгән кеше берни уйлап тормыйча салкын чоңгылга да чума ала, күктән йолдыз чүпли! Ә бу, мүкләк сыер кебек карышудан башканы белми...

Тукта, «сөям» дигәне бармы соң аның? Юк бит!..

Авылда Җәмил күзе төшәрлек, аның игътибарын җәлеп итәрлек башка берәр кыз бармы әллә?!

Вәзилә Югары очтан Түбән очка кадәр өй борынча берәмтекләп санап чыкты, кызлы йортларны айкады, аннан олы урамга керде, Түбән авылдагы мәктәп коллективын кат-кат күңеленнән кичерде. Көнче күңел йөгерек була, кызларны санап, барлап чыкты Вәзилә һәм мондыйрак фикергә килде: Язкилдедә аңа тиң булырлык, аның белән янәшә басарлык кыз юк иде. Тагын бер шиге бар иде барын Вәзиләнең, икс күрше — Сәләхетдиннәр белән Мирфатыйхларның дошманлашуы егеткә тәэсир иттеме әллә, дип уйлады. Ул уеннан бик тиз кайтты, «әйдә, чукынышып бетсеннәр, Җәмил белән без барыбер монда калачак түгел!» дип җиңел генә хәл итеп куйды.

Тәвәккәл таш ярган. Тырышкан ташка кадак каккан. Һәр минутта, һәр секундта, көндез дә, төнлә дә күңелдә бер теләк кенә калсын: Җәмилне моннан алып китәргә! Моннан... китәргә!.. Спорт — яшьлек белән янәшә яши. Яшь чагында Җәмил анда, калада ныгып калырга тиеш. Шәп спортсменнарга фатир беренче чиратта, шәп спортсменнарга һәркайда юл ачык.

Борыны сизгер Вәзиләнең. Теләкләре нык.

Сәләхетдин кызы ике беләген сызганып эшкә тотынды.

Монда, Язкилдедә атлаган саен Җәмилгә аяк чалырга! Авылдан биздерергә. Комачауларга. Сүз таратырга.

Бүген эше-мәшәкатьләре шактый күп булды аның. Бүген ул тынычдиярлек. Бүгенгә көне бушка узмаячак, тормышының олы максатына хезмәт итәчәк. Бүген Җәлил егылып борынын канатачак. Сәрвәрбикә әби белән ул кичтән үк сөйләшеп куйды. «Җәмил Югары очтан күренүгә битеңне иске бияләй белән ябып урамга чык. Тешем сызлый, диген. Булдыра алган хәтле тоткарла аны, әбекәй!»

Буыннары сызлап торган карчык фельдшер кыз белән борчак пешерергә каршы буламы соң?.. Тоткарланды егет. Медпунктка да керде

Вәзилә тозагына эләгеп анда да шактый торды. Җитмәсә, теге сигезенчеләр...

Һәммәсен әйбәткә юрады Вәзилә. Хәзер сабыр гына аның Түбән авылдан кайтуын көтәргә кирәк. Бүген Җәмилләр мәктәбенең футбол командасы районның «Чукмар» командасы белән очраша. Әгәр җиңсәләр, Түбән авыллар республика ярышларына финалга чыгалар. Шуны көтә Җәмил, яздан бирле малайларга тынгы бирми. Яздан бирле тугызынчы класс малайлары шуңа әзерләнәләр. Җиңсәләр, Җәмилнең хыяллары тормышка аша башлый, моннан соң аны Язкилдедән кубарырмын димә!

Тик бүген алар җиңеләчәкләр!

Монысын бер Вәзилә генә белә.

Җәмилләр командасының капкачысы тугызынчы класс укучысы Зөфәр — Вәзиләнең энесе. Өч көн ялынды Вәзилә Зөфәргә, өч көн тәмле сүзләр белән малайны юмалады. (Сәрвәрбикә карчык түгел шул малай, таза, сәламәт, фельдшерның кирәге әллә ни юк!) Сүзләр генә ярдәмгә килмәгәч, браслеты белән сәгать вәгъдә итте. Сәләхетдин тамыры шул, Зөфәр яңа сәгатьле булачак, һәм шушы сәгать Вәзиләгә җиңү, командага җиңелү китерәчәк. Зөфәр капкачы — теләсә тупны тота, теләмәсә — «Чукмар» командасы бер-бер артлы гол кертәчәк!

Тәрәзәдән карап, рәхәт уйлар кочагында тирбәлгәндә Язкилдедә кош-корт шау-гөре башланды. «Әйдә, котырыгыз, котыр! Көзгә туй итәрбез дә, симез-симез үрдәкләрне, күркә түшкәләрен күтәреп шәһәргә күчеп тә китәрбез! Хәйретдин агай чаң кагып озатып калыр! Бигрәк матур яңгырый икән чаң тавышы!»

Хатын-кызның күңеленә теләк инсәме?! Ул аны тормышка ашырмыйча калмый, хөрмәтле укучым. Без, ир-атлар, хатын-кыз аркасында гына оҗмахтан куылган дөнья мәхлуклары, хатын-кызның өстенлеген, хәйләгә маһирлыгын, осталыгын берсүзсез танырга тиешбез!

Җиңүгә ышанып көткәнгә көннең үткәне сизелмәде дә диярлек. Вәзилә Зөфәрне белә иде, ул аңа ышана иде. Көн бераз сүрелә төште, элеккечә чалт аяз һәм тыныч иде, Җәмил кайтыр вакытны чамалап Вәзилә урам якка караган өч тәрәзәне дә киереп ачып куйды, бүлмәләргә коры, хуш исле җәй һавасы кереп тулды; кыз, тәрәзәдән-тәрәзәгә йөреп, елмайган хәлдә, аны көтә башлады.

Шактый көтте, кемдер пунктка керде, ул кемгәдер киңәш сүзләре әйтте, кемнәргәдер дару бирде, укол кадады. Күңеле еракта, күзе юлда, йөрәге сөенечләр тозагында, үзе шатлыклы хәбәрләргә зарыккан иде.

Шул чагында ул Түбән очтан менеп килүче ике кешене е077ктан ук абайлап алды... Икәү! Һич тә ике кеше көтми иде Вәзилә. Әйе, берсе ул. Тик ялгызы түгел. Велосипедының икенче ягыннан, Җәмил шикелле үк рульгә тотынып тагын бер кеше менеп килә иде. Хатын-кыз? Вәзиләнең күңеле шашып-шашып кайнады. Сәкинә! Былтыр гына унынчыны бетереп фермада сыер савучы булып калган Сәкинә! Бая кызларны барлаганда аны исәпкә дә кертмәгән иде Вәзилә, кара син аны, буйга Җәмил абыйсыннан азрак кайтыш булса да ничекләр атлый, башын күккә чөеп җибәргән, чәчләр су күбеге төсле кабарганнар, күзен-кашын ясаган, әйтерсең бии-бии менә! Бер дә сыер савучы димәссең! Әллә пунктка кадәр үк бергә килмәкчеләр инде? Вәзилә бармаклары белән тәрәз пәрдәсен урап тотты да ак җәймә җәелгән тар караватка утырды. Күңеленә моңарчы килмәгән салкын шик төште: араларында берәр нәрсә бармы әллә?!

Ул ашык-пошык тәрәз пәрдәсен рәтләде, вак кына тир бәреп чыккан борынын мамык белән пудраларга керешге. Сак кына ишек шакыдылар.

— Керегез, кер, — диде ул елмаерга бик тырышып.

Ишектән Сәкинә ялгызы килеп керде, керде дә, мактанган сыман, томырылып аңа карап тора башлады. Вәзилә түземсезлек белән тагын берәүнең кергәнен көтте, хәтта кызның артына үрелеп тә карады, тик анда берәү дә юк иде.

— Җәмил абыең кайда? — дип сорады ул дорфа гына.

— Җәмил абый? — Бу исемне әйткәндә Сәкинәнең йөзе яктырды.— Кайтып китте.

— Ничек?

— Шулай.

— Бер сүз дә әйтмәдеме?

— Әйтмәс Җәмил абый! Ул гел шаярта бит! Мине бәләкәй кыз дип уйлыймы?

— Шаярта? — Вәзиләнең коты алынды. Ялгышын аңлады. Җәмил турында бу кыз алдында сүз кузгатырга ярамый иде. Белер иде әле! Бу кызның буе гына түгел, теле дә озындыр, әллә ни уйлавы бар. — Я, үскәнем, ни йомыш?

«Үскәнем» дип Сәкинәне кимсетергә теләсә дә керүче кызның исе китмәде, ул биек, мул күкрәкләрен киерә төшеп Вәзилә алдындагы урындыкка килеп утырды.

— Кулым ярыла, Вәзилә апа.

«Апа» сүзе Вәзиләне усал шөпшә төсле чагып алды, ул күзләрен зур ачып Сәкинәнең кулларына түгел, аякларына карады. Матур иде Сәкинәнең балтырлары, тез башлары, кыска ситсы күлмәге яшерә алмаган тыгыз, тулы ботлары искиткеч килешле иде!

— Кулым ярыла дисеңме? — дип кабатлап сорады ул.

— Әйе. Түбән авыл врачына күренимме әллә дип төшеп бара идем, Җәмил абый очрады да... бергә кайтып киттек.

— Яхшы булган. Яхшы, — диде Вәзилә күзен аяклардан Сәкинәнең кулларына күчереп. — Дөрес эшләгәнсең!

Бик озаклап, бик җентекләп карады ул аның кулларына; йомшак, ак беләкләренә күз салды, иңбашларының йомыры һәм кыйгачлап түбән төшүен чамалады, муенының озын һәм горур икәнлеген абайлады һәм кинәт Вәзиләнең комсыз, көнче күзе кызның күлмәк изүенә томырылды. Коры, салкын тавыш белән сорады:

— Әллә күкрәкчә дә кимәгән инде син?

— Нинди күкрәкчә ул, апа?

— Бюстгалтер дим.

— Нигә ди ул миңа? — Сәкинә көмеш чәчеп көлеп җибәрде. — Кирәкми!

Вәзиләнең үс кышын аранда ятып, язгы нурлар уйнаганда ирекә чыккан дуамал аргамак кебек ыргылды: күргән Җәмил, кызның озын бармакларын да, йомыры иңбашларын да күргән, ситсы күлмәк аша ап-ачык беленеп торган биек күкрәкне дә, тып-тыгыз ими башларын да күргән. Бергә кайтканнар! Янәшә... Бәлки Сәкинә юри аның каршысына чыгып торгандыр әле? Шулай булмаса нигә больницага ук төшеп җитмәгән? Нигә борылып кайткан?! Гомумән, нигә калды соң әле бу кыз Язкилдедә? Театр училищесына укырга бара, артистка була, дип сөйләгәннәр иде түгелме? Барсын иде, шунда югалсын иде. Нигә калган ул авылда? Бу инде моннан китәчәк түгел. Былтыр яз район газетасында аның яшьләргә хаты басылып чыкты. Сәкинә үз чордашларын, үз яшьтәшләрен колхоз-совхозларда эшкә калырга өндәгән иде. «Азат хатын» журналында рәсемен дә бастылар Сәкинәнең. Тик Вәзилә аннан бер тамчы да көнләшмәгән иде, рәсеме дә тонык, ис китәрлек түгел иде. Бер ел эчендә тәмам пешеп, өлгереп җиткән икән бу кыз!

Ниләр сөйләгәнен дә, кулы ярылган Сәкинәгә ниләр тәкъдим иткәнен дә аңламады Вәзилә, сыер савучы сылуны капыл-копыл ишектән

чыгарып җибәрде дә, келәне элде. «Беркемне дә күрәсем килми, беркемне дә!» дип пышылдады ул. Утырып, башын тезенә бөгеп озак кына уйланды, уеның һич элә-тотанагы юк иде, күз алдыннан Сәкинәнең хуш ис бөркеп торган аксыл чәчләре, буялмаса да чия кебек алсуланып янып торган иреннәре китмәде. Җәмил шуларны күрмәгәндер дисеңме? «Авылда калыйк!» дигән өндәмәсен хәтерләмидерме?!

Эх, ялгышкан Вәзилә. Эшне Җәмилдән түгел, шушы кыздан башларга кирәк булган. Әйтәм җирле, соңгы очрашуларда «китик» дигән саен Җәмил, тиле кеше сыман, авызын ера. Авызы ерык, ә сүзе чыкмый. Менә кем икән аның төп сәбәпчесе!

Җәмилнең кайтышлый медпунктка кермәвенең сәбәпчесе дә шушы кызый актыгы гына. Сәкинә белән бергә килеп керсәләр Вәзилә егетнең кыланмышыннан, ярты сүзеннән барын аңлап алачак иде...

Кайчан, ничек өйләренә кайтып житкәндер. Мирфатыйхлар турын ничек узгандыр, өйалдындагы сулы чиләккә абынгач кына Вәзилә исенә килде, чиләкне почмаккарак алып куйды, тавыш бирде, өйдә берәү дә юк иде. Аптырап ишегалдына чыкты һәм лапаста сеңлесе Фирүзәне күреп, кашын җыерды:

— Син нишләп консультациядә түгел? — дип сорады.

Фирүзә иңнәрен сикертте, түшенә яткан толымнарын берәм-берәм җилкә чокырына чөйде.

— Нигә консультациягә бармадың диләр сиңа? Әзерлексез килеш имтиханга кермәкчесеңме? Өчле аласың киләме?!

Сигезенчене аннан-моннан гына тәмамлап, бик күп артык мәшәкатьләргә дучар булган Вәзилә эне-сеңелләренең укуына аерата бер игътибар бирә, бигрәк тә Фирүзәнең, кыз кешенең канына төшә иде.

— Телеңне йоттыңмы әллә?

— Синең Җәмилең, — дип мыгырданды сүзгә саран кыз.

— Нинди Җәмилем? Ни лыгырдыйсың?

— Синең Җәмилең... Хур итте... Мыскыллады.

— Житте диләр сиңа!

— Бәйләнә. Битең бетчәле, ди.

— Юкны сөйләмә. Тапкан сәбәп...

— Үзеннән сора әнә. Кайтты!

— Сорадым ди! — Вәзилә Фирүзәгә ышанмады, сеңлесенең алдарга осталыгы барын белә иде ул. — Зөфәр кайда?

— Кайтмады әле.

— Ә Зәйтүн кайда?

— Мин каян белим?

Корт иле кебек тузгыган мең сораудан мидә берсе генә утырып калды: нигә Җәмил Сәкинә белән медпунктка кермәде? Командасы җиңсә дә, җиңелсә дә ул Вәзиләне күреп чыгарга тиеш иде бит! Әллә Сәкинә берәр сүз әйттеме?.. Бусы булмас, юктыр, Вәзиләнең хыянәте юк, Җәмил бары аны гына ярата, аларның алга барыр юллары бер. Җәмил кайтты, нигә Зөфәр аның янында түгел? Зөфәрне табып кайт, дип Зәйтүнгә кушар иде, ул шайтан арбасы да әллә кая тәгәрәгән.

— Зәйтүн кайда диден әле?

— Белмим дидем ич! — Фирүзә калтыранып кычкырды. — Сугышканнар! Җәмилләр Әнәсе белән!

— Сугышканнар?

— Мин кайтмасам канга батып бетәселәр икән!

— Ни житмәгән тагын аларга?

— Беләсең ич, нигә сорыйсың?

Вәзилә өйгә керде, өс-башын алышты, җиңсез халат киде, тәрәзә кырына утырды. Урам буш иде. Урам сүзсез иде. Эх, ара капка булса, йөгереп кенә Җәмил янына кереп чыгар иде Вәзилә...

Урам бушлыгы да борчый иде кызны, асылда, бер җан иясе булмасын, нигә бу мизгелдә Язкилдедә бөтенесе чәнчелеп китми. Вәзиләнең берсендә дә гаме юк, аның бөтен күңел капшагычлары бары бер шикле ноктага — Сәкинәгә генә барып тоташкан. Җәмил белән уртак язмышлары нәкъ менә Вәзилә теләгән эзгә керә дип торганда, арага йомыры иңбашлы, сусыл иренле япь-яшь кыз килеп кысылсын әле! «Уналтыда, унҗидедә кызның матур чаклары», дигән татарның гашыйклары. Уналтысы, унҗидесе үтте шул Вәзиләнең, үтте.

Унҗидесе узган кызның күңеле сак, сизгер. Җәмил белән Сәкинәнең бер велосипед мөгезенә ике яклап ябышып кайтулары тиккә түгел. Урам уртасыннан туп-туры пунктка карап киләләр бит, ә?!

Чуалган төенне чишәргә Зөфәр кирәк иде, Зөфәр! Кайда йөрер икән ул малай актыгы! Нигә яхшы хәбәрне тизрәк ирештереп апасының яралы күңеленә дәва китерми?! Әллә Вәзилә аңа юкка ышандымы? Сәләхетдиннәр нәселеннән Мирфатыйх улы Җәмилгә тартылган бердәнбер кеше Зөфәр түгел идеме әллә? Аңа ияреп лапаста сабан тәгәрмәчләреннән штанга ясап азапланып маташмадымы? Иртә-таңнан суык җилдә дә сөлге күтәреп Олы суга юынырга чапкан да ул түгелме? Юк, юк! Алары малайлык мавыгулары гына. Зөфәр — Сәләхетдин улы, йорт җанлыклы, төпле малай. Вәзиләнең энесе. Сатмас ул апасын! Алдагы көннәрдә дә гел булышып, сүз тыңлап йөрер.

Күз алларын томалаган шикле пәрдә берзаман ачыла төшеп, Вәзилә ныклабрак караса, күз алдында гына, урамда авызын ерып Җәмил басып тора. Зәңгәр тренировочный җиңел чалбар кигән, өстендә җиңсез, юка күлмәк, кулында баганага менә торган тырнаклар.

— Вәзилә дим, хәерле көн.

Вәзилә эндәшмәде, сүз әйтерлек хәле юк иде. Кызганычка каршы, аның хәле иртәрәк бетеп киткән икән, менә хәзер, Җәмил китергән хәбәрдән соң һушы бетеп егылса да урынлы буласы икән.

— Рәхмәт сиңа, Вәзилә.

— Ни өчен?

— Кара, кара, белмәмешкә салына!

— Икмәктер менә, берни белмим.

— Зөфәрне кыздырып, ярсытып җибәргәнсең.

— Ә?!.

Әллә чын сөйли Җәмил, әллә юри, күзләрендә шаян утлар уйный.

— Кыскасы, син безгә бик нык ярдәм иттең. Мин алда тренер булачакмын. Синең эш методың турында уйларга ярый икән!.. Без җиңдек! Көчлерәк команданы җиңдек! Ну, Зөфәр! Барыбызны шаккатырды! Ягуар, юлбарыс, барс! Уенчының психикасы җиңүдә хәлиткеч фактор була ала. Мин моны элегрәк тә белә идем, Зөфәр мисалында тагын бер кат сынадым. Рәхмәт, Вәзилә.

— Котлыйм, алайса, — диде Вәзилә, калтыранган кулларын артына яшереп.

— Котлавың кирәкми, — диде Җәмил, кычкырып ук көлеп. — Мин барын да беләм.

— Кая барасың син? — Вәзилә сүзне икенчегә борырга тырышты.

— Зәйтүн минем энекәшнең кепкасын агач башына ыргыткан икән. Үзе керергә курка. Шуны менеп алам.

Вәзилә ярты гәүдәсе белән тәрәзә аша урамга сузылган иде инде. Менә Җәмилләрнең капкасы ачылды, Әнәснең ап-ак башы күренде дә капка кинәт ябылды.

— Сугышканнар,— дип дәвам итте Җәмил. — Гел тынычмыйлар, гел чәкәләшәләр. Нигә булыр бу?

— Малайлар сугышмыйча тормый инде, — диде Вәзилә һаман Зөфәр турында уйлап. Җәмил әйткән хәбәр акыл ышанмаслык иде.

Биш минут дисәм күбрәк, өч минут дисәм азрак булыр, шулай —

берсе тәрәзәдә, икенчесе урамда — күзгә-күз карашып торгач Вәзиләнең «ничек булды соң?» дип сорыйсы килде, әмма Җәмил үзенең кая барырга чыкканын хәтерләп аларның капкасына юнәлде.

Җәмил ишегалдында күренүгә лапас күләгәсендә утырган Фирүзә пыр итеп күтәрелде, тырылдап өйгә кереп китте, китабын өйалды идәненә ыргытты да чабып кире әйләнеп чыкты. Көзгесен оныткан икән, аны учында яшереп болдырга чабып менәм дигәндә абынды, түгәрәк көзге кулдан төште һәм ташка бәрелеп челпәрәмә килде. Җәмил Фирүзәнең кыланышын дикъкать белән күзәтеп торды, башын чайкады һәм иңбашларын уйнатып карт тирәк янына килде. Җәмилнең агачка менгәнен карарга өйдән Вәзилә дә чыкты, болдыр култыксасына таянып:

— Көзге ватылуны бәхеткә дип юрасак, син агачка хәвеф-хәтәрсез менеп төшәчәксең! — диде ул, эченнән Фирүзәне тиргәп.

— Мине сынар өчен генә икән, юкка ваткансың көзгеңне! — Җәмил йомшак кына атлап карт тирәк янына барып житте, агачның тубырлы кәүсәсенә карап-карап торды да, «тырнаклар»ны агач төбенә ташлап, учларын төкереклəп бер-берсенә ышкыды, «эһ!» дип бер талпынды, ике сикерде һәм агачның аскы ботагына барып та ябышты. Мәче житезлеге белән үрмәли башлады, байтак менгәч, бер юан ботакны ике куллап селкетергә тотынды. Вәзилә юри, курыккан булып, чыркылдады: «Егыласың!» Аның ничек тә Җәмилне көлдерәсе килә иде, чыннан да егет яфраклар куелыгыннан шаркылдап җавап кайтарды: «Минем егылганны күтәсеңме?» «Юләр!» диде иреннәрен бөреп Вәзилә. Агач янына ук килеп житкән иде, сискәндереп аның аяк башында бер нәрсә шапылдады. Башта Вәзилә кош оясы дип уйлаган иде, иелебрәк караса, кепка төшкән икән. Җәмил дә җиргә сикерде.

— Киярлеге калмаган,—диде кыз, һаман Җәмилне кимсетергә теләп.

— Киярлек,— диде Җәмил, һаман авызын җыя алмыйча.— Әйбәтләп юып киптерәбез дә калыплап куябыз без аны. Өр-яңа булачак!

— Яңаны алырсыз, бер кепка көненә калмагансыз.

«Ни сөйлим мин?» дип сулкылдады аның күңеле, «хәзер ул шушы шакшы кепканы алачак та чыгып китәчәк. Шуның өчен генә кермәгәндер ич?! Кайчаннан ишегалдыбызга аяк басканы юк иде».

Никадәр көләч булырга, сүзләрне сайлап кына сөйләргә теләсә дә Вәзиләнең көндезге ярсуы басылмаган, аның күзләре усаллык чәчеп карыйлар, елмаюы ясалма, салкын, сулышыннан боз исе килә иде.

— Нигә яңаны алырга? Бусы да искермәгән! — Җәмил Вәзиләнең күзләренә төбенә төшәрдәй булып карап торды.

— Ярар, шундый кепкалар кибеттә ауный бугай. Үзем алып бирермен, — дип шаяртырга теләде Вәзилә.

— Юк, Вәзиләкәй, бу кепка — бүләк. Беренче классны әйбәт бетергәнгә әтидән бүләк. Әнәс аны гадел тырышлыгы белән яулап алган. Үз гомерендә беренче олы бүләк. Аны алыштырып булмый.

— Бәй, миннән дә бүләк булыр!

«Бүләк вәгъдә итәргә яратасың икән син!» диде дә Җәмил кызның хафасын арттырды, аның ике бите дә кызышып яна башлады: әллә теге тиле малай... Зөфәр бөтенләй үк чишелеп беткәнме?.. Ах, юньсез Җәмил, малайның серен алгандыр, мөгаен!

— Синнән бүләк алса, бурычы бик зурая энекәшнең, — дип һаман аяусызлана барды Җәмил. — Бирмә инде син аңа бүләгеңне, юмартланма!

Вәзиләнең Җәмил алдында кызарынып-бүртенеп, дәресен белмәгән надан кебек ык-мык торуын ишек ярыгыннан күзәтеп торган Фирүзә кинәт шаркылдап көлә башлады. Моңарчы апасы әйткән «бозаугa» бер дә охшамаган иде Мирфатыйх малае! Вәзилә ялт карап алды, көлүченең тавышы шунда ук киселде.

Алар тагын ни турындадыр сөйләштеләр, тик бу сөйләшү дә мөнәсә-

бәтләрне ачыкламады, араны якынайтмады, киресенчә, ерагайтты гына бугай. Җәмил аз-маз шаярткан булды, юк сүз әйтеп Вәзиләне келдерде, ул аны капкага хәтле озата чыкты. Шунда саубуллаштылар.

Җәмил Вәзилә өчен кердеме? Әллә юкмы? Әмма Вәзиләгә алда ни: чек булырга кирәклеген белдермичә чыгып китте. Моңарчы Вәзилә үзен ниндидер дәрәҗәдә Җәмилнең хуҗасы итеп саный иде. Җәмил бары тик аның хакына яшәргә, аның өчен тырышырга, аның күз карашыннан ни боерганын аңларга тиеш дип исәпли иде. Шулай булачагына фанатикларча ышана иде.

Мәхәббәт сукыр була диләр.

Сукыр булгандыр шул Вәзиләнең мәхәббәте. Язкилдедә Сәкинә шытып калкынганын да күрмәгән, Зөфәр ныгып килгәнне дә абайламаган.

Бүгенге көнгә Язкилденең Югары очында, Сәләхетдиннәр йортында хәлләр менә шундыйрак — хәлләр, турысын әйтергә кирәк, шәптән түгел. Зәйтүн белән Әнәс читән сүтә-сүтә сугышканнар. Фирүзә белән Җәмил абыйсы ызгышканнар. Зөфәр дигән егет аламасы, мөгаен генә, Вәзилә апасын сатып дошман лагерена чыккан. Җәмил белән Вәзилә арасына Сәкинә килеп кергән!

Боларның эчке мәгънәләре нидә? Бер-берсен ачыклыймы бу фактлар? Әллә нәтиҗәсе генә бәйләнгәнме?

Нәтиҗәне күз алдына китерә алмаса да Вәзилә бу аяусыз фактларның бер-берсенә шактый тыгыз бәйләнгәнен һәм язмышының алдынгы көнендә бу, бүгенге мөнәсәбәтләрнең хәлиткеч урын тотачагын чамалый иде. Җиткән кызларның уе — җилдәй җитез!

Ул авызын-борынын мимылдатып кече як ишеге янында басып торган Фирүзәне ике куллап этеп җибәрде дә, олы өйгә кереп, хәлсезләнеп, мәлҗерәп баягы урынына, тәрәзә каршысына килеп утырды. Бераздан Түбән оч ягыннан акрын гына болай таба менеп килүче ике кешене абайлады. Урамда кеше йөрми түгел, әмма килүчеләрнең икәү булуы аны тагын шиккә төшерде, ни тырышса да килүчеләрне танымады. Фирүзәне чакырып китерде: «Күземә чүп кердеме шунда, танымыйм гына. Кемнәр бу?» диде. Фирүзәнең күзе үткен, шундук чәрелдәп кычкырды. «Әй, Зәйтүн бит! Икенчесе Хәйретдин агай!»

Бераздан Вәзилә дә аермачык күрде: Хәйретдин агай малайның колагыннан эләктергән, аны Югары очка сөйри, Зәйтүн исә әллә нинди ямьсез тавышлар чыгарып, акыра иде. «Кыйнаганда барабан гына үз тавышы белән кычкыра», дип уйлады Вәзилә бер дә кирәкмәгәндә. Тегеләр дә ул утырган тәрәзә турына ук килеп җиттеләр. Фирүзә куркып кычкырып куйды. Вәзиләнең күз аллары караңгыланды: Зәйтүннең кулында кеше башы сөяге бар иде! Вәзилә абына-сөртенә урамга чыгып чапты.

5

Чуалган башны тагын да бутар өчен күп кирәкме?

Мөлдерәмә тулы чиләккә бер-ике тамчы гына өстәсәң дә читләреннән ага башлый...

Зәйтүн кулындагы баш сөяген күргәч, Вәзилә чак акылыннан шашмады, ул Хәйретдин агайның ни аңлатырга тырышканын аңлый алмыйча байтак вакыт азапланды. Зәйтүн һаман мышык-мышык жылый иде.

— Менә малаегызны китердем, — диде өченчеме, дүртенчеме тапкыр кабатлап Хәйретдин агай. — Су буенда адәм башы сөяген туп итеп уйныйлар иде.

— Без уйнамадык, тапкан гына идек,— дип сүз кыстырды малай.

«О, ужас!» дип уйлады Вәзилә. Ул караган киноларда кырган кашлы, сыланган керфекле кызлар бер-бер көтелмәгән хәл булганда нәкъ менә шушы сүзне әйтеп, нәзек беләкле кулларын күккә чөяләр иде. Ат

алмасын туп итеп уйнап йөрткәнне күргәне бар, ипи катысын да җирдә тәгәрәтә хәзер авыл малае, бәләкәйрәкләр мәктәп сумкаларын да кар-да-бозда тибеп ярышалар, алма тәгәрәткәннәре бар... адәм башы сөя-ген футбол тубы итеп, мөгаен, Язкилде авылында гына уйнаганнардыр! Берничә урыннан чатнап ярылган, тешләре ыржаеп торган көрәнсу баш сөяге! Адәм башы!

«О ужас!»

Авылда үссә дә Вәзилә бу сүзнең татарчасын белми иде.

### Нәни генә географик белешмә

*Төньяк географик киңлекнең 55 нче градусында һәм көнчыгыш географик озынлыкның 52 градус 30 минутында утырган Язкилде авылы турында, аның Югары, Түбән очлары турында байтак кына сөйләштек инде без, хөрмәтле укучым. Авылның кайбер гражданнары белән дә танышып уздык. Сүз арасында гына Җәмил балачакта гарьләнеп йөзеп чыккан Олы су елгасын да телгә алгаладык.*

*Авылның яме булган Олы су белән тагын да ныграк танышырга вакыт җитте: безнең хикәядәге вакыйгаларга да, кешеләргә дә турыдан-туры катнашы булачак әле аның, булачак! Алай гына да түгел, географик карталарда бөтенләй күрсәтелмәгән шушы елга без телгә алган кешеләрнең язмышында искиткеч бер роль уйнаячак. Менә шуннан соң «кеп-кечкенә инеш кенә» дип әйтеп кара инде Язкилденең Олы Суын!..*

*Матур елга Олы су!*

*Ә болай артык данлы-шанлы да түгел. Язкилдедән биш-алты чакрымда, калын кара урман арасында, ташлы ярда чишмә булып бәреп чыга да, Олы су башы дип аталган ерганаклы үзәннән үтеп, ашыга-кабалана авыл янына килеп җитә. Җәен сабыр гына, серле генә инеш ул, ярларында таллар, уем-уем зирек агачлары үсә, зирекләрне колмаклар чорный, колмак араларында сандугачлар сайрый, бормалы тугайларында кызыл канатлар, ташбашлар, кушбашлр үрчи. Иллә мәгәр язын Олы суның холкы яман! Авылны өч яктан ураган урман кары кузгалып төшә башлаганда Олы суга якын барырмын димә! Каян киләдер аңа шул кадәр көч, каян өстәләдер дуамал гайрәт, урманнан ук шаулап-гүләп килеп чыга да, үзәнлекне тутырып киңәя, тау итәкләренә кадәр сикергән күгелҗем-кара дулкыннарын уйнатып-биетеп түбәнгә омтыла. Ике-өч көн дуамалланып котырына, төннәрен дә тынмый, яралы дию булып улый-бәргәләнә, вак-төяк күперләрне йомычка урынына уйн[illegible]п агызып китә, анда-монда сураеп калган печән кибәннәрен ялмап йота, тал-зирекләрне тамырлары белән йолкып-кубарып ала. Соңгы елларда холкы бигрәк тә яманланды Олы суның! Элегрәк елларда урман кары сабыррак, сызып кына кузгала торган иде. Хәзер ни, кая карама я электр чыбыклары узган, я нефтьүткәргечләр сузылган, урман[illegible]р кишәрлек-кишәрлек тоташтан киселгән, кояш нуры ургылып килеп керә дә кыш тупланган карларны дәррәү кузгата, ашыктыра башлый. Я китә, я башлана кыямәт! Олы судан байтак җәбер күреп, аның дуамал гадәтләрен белсәләр дә, Язкилде кешеләре яраталар үз инешләрен. Олы суны кушып җырлар чыгаралар, читкә китсәләр, шуны сагынып кайталар.*

*Язкилденең зираты авылның түбән ягында, заманында Олы судан хәтсез ерακта иде. Инеш язгы ташуларда ел саен ярларны җимереп үзенә яңа юл сайлый башлады һәм биш-ун ел дигәндә, дулый-дулый, зират янына ук килеп җитте. Мәрхәмәте килер, әрвахларның тынычлыгын бозарга куәте җитмәс, дип йөргәннәр иде, алдагы язда су гомердә булмаганча котырынды һәм киртәне җимереп эчкә үк үтте, бай-*

*так кына иске каберләрне юып китте. Су юашланып үз эзенә төшүгә, хәстәрле язкилделәр зират тирәсен нығыттылар, казыклар кагып тал чыбыгыннан нығытмалар үрделәр, өмә ясап кирtә белән тал арасына эре-эре ташлар тутырдылар. Машина белән ташыдылар ташны. Әмма алдагы язда су тагын шәбрәк акты, биш көн буе тоташ ябырылып дулады, зират киртәләрен, нығып өлгермәгән сай тамырлы тал агачларын гына түгел, дәү-дәү ташларны тәгәрәтәп, үзе белән түбән якка ияртеп китте. Язкилделәрнең болан башы хәтле ташларын Түбән авылның тегермән буасы алдында таптылар. Буа да чыдамаган, киткән иде. Су зиратка ук бәреп кереп быел да байтак каберләрне ялмап йотты.*

*Картлар кайгыга төштеләр. Зиратны алай-болай гына ныгытып, мәңгелеккә йокыга талганнарның тынлыгын саклап калырга җай калмаганлыгын күрделәр. Мәсьәлә үтә җитди иде, шул хакта сүз ике мәртәбә авыл советы сессиясендә каралды, район оешмаларына барып җитте. Иң беренче нәүбәттә авылның төньягындагы тау итәгеннән байтак кына җир кисеп, киртә белән әйбәтләп уратып алдылар. Капка башына куелган ай урагын тимерче Фазулла эшләде. «Савап булыр, оҗмахлы икәнсең», дип карчык-корчык бик мактагач, үз акчасына айны көмеш суы белән дә йөгертте. Яңа зират капкасына ай менеп утырган көннән авыл советы катгый карар чыгарды: «Бүгенге вакыттан иске зиратка мәет куймаска, бу максат өчен бары тик яңа зираттан гына файдаланырга», диелгән иде анда.*

*Тик менә яңа зират расланганнан соң беренче мәет булу белән үк халык арасында шомлы хәбәр таралды: имеш, яңа зиратка беренче булып яткан кеше үз артыннан бөтен нәсел-нәсәбен тарта торган була...*

*Каян, кемнән чыккандыр бу сүз, Язкилде халкы арасында таралып та, кыска гына вакыт эчендә нығып та өлгерде. Авыл советының тыюына карамастан, мәетләрне иске зиратка, елгадан ерак почмакка куя башладылар. Бер ел шулай үтте, ике, өч... Тагын якты язлар килде. Тагын дулады Олы су — тагын язкилделәрдән җир тартып алды, корбан таләп итте. Әллә кайчан йокыга талганнарның каберен тузгытып, аларның ак сөякләрен борылышларга, комлы иңкүлекләргә илтеп салды.*

*Шомга төштеләр язкилделәр! Уен эш мени, тыныч заманда, ут-ядрә чәчрәмәгәндә, бабаларыңның тынычлыгы яз саен бозылсын әле! Шомлы хәбәрләр тирә-якка таралды. Авыл советы председателе районнан авторитетлы лекторлар чакырып, хорафатлар, ышанулар һәм аларның зарарлары турында өч-дүрт мәртәбә лекцияләр тыңлатып карады, әмма үлем-җитем, туу-яшәү җәһәтеннән йолалар, инанулар күп вакытта законнардан да өстен булып калалар.*

*Мәңгелек алдында күпләрнең күңелен икеләну, каушау чорный торган була. Авыл советы председателенең газиз әткәсе дөнья куйгач, яңа зиратның мәңгелек беренче кунагы, мөгаен, ул булыр дип торганнар иде, агай-энеләре, туганнар, кардәш-ырулар җыелып, бер сүздә, бер авызда торып председательне дә җиңделәр. Берәүнең дә тоташ үлем күрәсе килми, бер нәселнең дә үз арасына әҗәлетдинне кертәсе килми иде. Рәиснең әткәсен дә иске зиратка җирләделәр, и авыр туфрагы җиңел булсын, бәлки Олы су акылына килер әле?!*

*Язкилдедә һаман шул гадәтләр, бер үк сүз өстен булып калды...*

*
* *

Менә шулай Хәйретдин агай соң дәрәҗә кызып, Зәйтүн дигән шук малайның колагыннан сөйрәп өенә хәтле китергән иде.

— Бу тинтәкнең әткә-әнкәсе өйдәләрме? — дип сорады ул малайның колагын нык кулыннан ычкындырмыйча.

— Юк, — диде Вәзилә мышык-мышык сытылган энесенә жирәнеп карап.

— Менә күр, туп итеп тибеп йөртәләр бит, ә?!

— Уйнамый идек әле, — дип һаман карулашты малай.

— Каян алдың моны? — Вәзилә «баш сөяге» сүзен әйтергә кыймады.

— Каян булсын, су буеннан, — диде малай тынычлана төшеп. Вәзилә апасының яклап, бу усал карттан йолып аласына шикләнми иде Зәйтүн.

— Әнәс тә шунда идеме? — диде Вәзилә, бая гына күрше малаен капка авызында күрсә дә.

— Юк.

— Нигә моны башка балалар алмаган да нигә син генә шундый юньсезлеккә тап буласың?

Зәйтүн җавап бирмәде.

Хәйретдин агай колакны ычкындырды, ике кулын да билендәге киндер алъяпкычка озаклап сөртте һәм баш сөяген малайдан тартып алды.

— Нишлибез инде хәзер? — диде ул бераз сабырланып.

Болай да буталган Вәзиләнең башында бер уй да юк иде.

— Үлеләр белән нишләргә кирәклеген дә мин белергә тиешме? — диде ул дорфа гына. Хәйретдин агай аңа күтәрелеп карады.

— Син фелшер. Укыган кеше. Мондый чакта синең янга килмичә кем янына барыйк ди без?

— Мин тереләр белән эш итәм, — диде кыз һаман кырыслана барып. Аның тагын да ныграк усалланасы килеп китте, «минем ни эшем бар?» дип күңеле үртәлде, «авыл советы кайгыртсын әнә! Зәйтүннең дә ни гаебе бар? Нигә өйгә алып менгән аны бу карт? Колагын шештереп бетергән! Нигә Хәйретдин агай бу сөякне авыл советына я идарәгә кертеп чыкмаган? Нигә бу файдасыз эшкә Зәйтүн белән мине катыштыра?»

— Ничек- алай? — дип бик аптырады Хәйретдин агай. — Ничек алай? Барыбызның да уртак хәсрәте ич бу! Сезнең туганнарыгыз да шунда ята.

— Юк безнең туганнар анда, — диде Вәзилә кистереп. — Беркемебез дә юк. Без һәммәбез дә сау-сәламәт. Исән.

— Хата уйлыйсың, кызым.

— Малайның колагын өзеп төшерә язгансыз. Ни хакыгыз бар?

— Тәртипсез бала алдында шулай сөйләшәләрме? Тәрбияң шулмы?

— Хәйретдин агай, башка кайгың булмаса, безнең тәрбиягә катнашып йөрмә инде син, яме.

Вәзилә Хәйретдиннең олы кеше икәнен, аның янында тәмсез телле булмаска кирәклеген дә белә, әмма бу минутларда ул аны күрми дә диярлек иде, шәхсән аны кимсетергә дә уйламый, аның күз алдында тату пар — Җәмил белән Сәкинә, егет белән кызның велосипед янәшәсендә атлаган шәүләләре уйный, хәзер алар якында булсалар, Вәзилә аларны чәйнәкләп, өзгәләп ташлар иде. Тик алар юк, каршысында, соры фетр эшләпәсен кашына ук төшереп кигән бөкресе тагын да ачыграк калыккан Хәйретдин агай басып тора, күзләре дымсуланган, яргаланган җыерчыклы кулында — адәм башы сөяге. «Карчыгының кабере исән микән?» дип уйлады Вәзилә һәм Зәйтүнгә:

— Бар, кереп кит! Пөрисең кеше бимазалап! — дип кычкырды.

Зәйтүн, өненә кереп шылган йомран кебек, йомылып кына алар күз алдыннан югалды, ачык тәрәзәдән Фирүзәнең шаркылдап көлгәне ишетелде.

— Ә сез нигә китмисез, Хәйретдин агай? Нигә җан талап монда торасыз? Мин нишләтә алам?

— Китәм алайса, — диде юаш карт. — Мин ни, аптыраганнан килгән. Аптырарлык хәл бит, шаккатарлык. Уйламаганда-көтмәгәндә... Бер җирдә дә мондый хәл юктыр! Борынгы бабаларны әйтәм, авыл өчен урынның шәбен сайлаганнар, мәнә зиратны гына куя белмәгәннәр. Үзләре дә «ни булды безгә?» дип борчылып яталардыр. Рәнҗиләрдер безгә... Җаен таба алмыйбыз бит.

— Авыл советына керегез. Аларга ныгытып әйтегез. Сез олы кеше, сезне тыңларлар, — диде Вәзилә тупаслыгын йомшартырга тырышып.

Карт та бераз йомшады.

— Малайда гаеп юк-югын, мәгәр аз гына гаеп тә бар: туп итеп уйнарга аңа бирәү дә кушмаган. Үзе башлаган! Башкалар куркып карап кына торган! Сезнең башкисәр типкәләп йөртә икән...

Китте Хәйретдин агай.

Үзе дә сизмәстән Вәзиләнең рәнҗүен арттырып китте. Бер сәбәпсез, бер гаепсезгә рәнҗеде аңа Вәзилә. Чынлыкта исә ул бүген бер генә кешегә — үзенә генә рәнҗергә тиеш иде. Әмма адәм баласы шулай яратылган, ул гаебе барын эчке сиземе белән чамалаган очракларда да, гаебен танырга ашыкмый, аны башкаларга сыларга ярата. Ике дә уйлап тормыйча башкаларны гаепли. Без барыбыз да, тыштан гаебебезне таныган булып кылансак та, күңелебез белән бик сирәк очракларда гына төп гаепнең үзебездә икәнен таныйбыз.

Әгәр бүген Вәзилә «командагыз җиңелсен!» дип Зөфәрне үгетләп озатмаса...

Әгәр ул аңа хыянәте өчен чылбырлы сәгать вәгъдә итмәсә...

Әгәр Вәзилә Сәрвәрбикә карчыкны да үзенә ияртмәсә...

Әгәр Җәмилнең матур гына үрелеп барган тормышына аяк чалырга маташмаса...

Әгәр Сәләхетдин белән Мирфатыйхлар гаиләсе яшерен һәм астыртын дошманлык белән яшәмәсә...

Әгәр Вәзилә Җәмил белән Сәкинә каршына айдай балкып килеп чыкса...

Күңеле тыныч булыр иде аның, Хәйретдин агайны да юкка рәнҗетеп, борчып маташмас иде.

Юк шул, Вәзилә Сәкинә белән Җәмил алдына тып итеп чыга алмады, күңеле саф түгел иде аның, кылган эшләре, гамәлләре саф түгел иде. Җәмилгә булган мөнәсәбәте алама иде. Шул аламалык аны тәрәз пәрдәсе артына качырды. Шул саф түгеллелек аның күңеленә чүп-чар шикелле уйларны китереп өйде. Батыр батырны сирәк чакта ярата, матур матурны бер чакта да сөйми. Чөнки матур икәү булса, аның берсе барыбер өстен чыга. Матурлыкның төп шартларыннан берсе — ул кабатланмас рәвештә бер булырга тиеш. Язкилдедә бер матур бар иде — ул Вәзилә иде. Сәкинә дигән матур калкып чыга икән, бу Вәзиләнең үлеме, бетүе, матур буларак югалуы дигән сүз.

Шулай уйлады Вәзилә.

Шулай уйларга тиеш тә иде Сәләхетдин кызы.

Югары Очның Сәләхетдин кызы.

Миңгерәүләнеп килгән Хәйретдин агайны чукый-чукый озатты Вәзилә. Чөнки ул күңеле белән бүген саф түгел иде, гаебен танырга көче җитмәгәч, тормышының көйсезлеген беренче очраган кешесенә — Хәйретдин агайга йөкләп җибәрергә тырышты ул. Зират юлыннан кайгыга батып кайткан картны ул башта ук усал күңел белән каршылады. Вәзиләнең аңа үпкәләве бөтенләй урынсыз, урынсыз гына түгел, тупаслык, гаделсезлек, дорфалык иде. Тик Вәзилә үзендә бүген котырынган бу сыйфатларны бер чакта танычак түгел, танырга җыенмый да, ул карт-

ның авыр адымнары артыннан нәфрәт тулы күзләре белән карап калды. Иң гаҗәбе, аның күңеле җиңеләйде, йөзенә тантана катыш канәгатьләнү чыкты. Кайберәүләр кеше рәнҗеткәннән соң җиңеләеп калалар. Вәзилә әнә шундыйларның берсе иде.

## 6

Инде сүз Зөфәр турында барачак. Чират аңа житте.

Вәзиләнең күңеле аны эзли: «Зөфәр кайда? Кайда йөри ул тилемсә егет?!»

Кайда булсын, Зөфәр баядан бирле Олы су буенда йөри. Бер башы. Ялгызы. Ул өенә кайтырга бик курка иде. Ул бүгенге көннең, бүгенге кичнең тизрәк узуын, мәңгегә кайтмавын һәм онытылуын тели иде.

Без бит барыбыз да аз-маз ваемсызлар.

Шулай түгел мени, хөрмәтле укучым? Без алда бары тик бәхет кенә, бары тик тынычлык кына көтә дип шулкадәр нык ышанабыз ки, барыбыз да һәр даим киләчәккә омтылабыз. Киләчәкнең мәшәкатьләрен, кайгы-сагышларын, авырлыкларны кемдер үз өстенә алыр да, безнең өлешкә бары тик татлы-тәмлесе, яктысы вә яхшылыгы гына калыр дип ышанабыз. Киләчәктән беркем дә начарлык көтәргә теләми! Я, кайсыбызның бүгенге көннән иң кадерле гомер кисәге икәнлеген уйлап куанганыбыз бар да, бүгенге көнне озайтырга, сузарга яки бөтенләй туктатырга тырышып караганы бар?!

Тәҗрибәсез Зөфәр дә бүгенге көнен каргый иде. Тизрәк узуын, онытылуын тели иде. Көннәренең, гомеренең санаулы икәнлеге турында уйлап та карамый иде ул.

Ә бүгенге көн шул кадәр матур, Зөфәрнең тирә-ягы искиткеч бай, кызыктыргыч дәрәҗәдә төрле-төрле иде. Ул Олы су буенда бер максатсыз, мәгънәсез йөреп талчыккач, биек, куе үләннәр арасына кереп күмелде, әмма үзенең гаҗәеп бер матурлык арасына чумуын аңламады. Көн шулкадәр рәхәт, җылы иде, җилсез, тып-тын иде. Һәр тарафта бал кортлары оча, төклетуралар гөжелди, ул исемен белмәгән әллә никадәрле алтын-сары, чуар бөҗәкләр үрмәлиләр, сикерәләр, тәпәләшеп сугышып яталар, кыскасы, болынның һәр карышы үзенчә матур, үзенчә хәрәкәттә иде. Зөфәрнең дүрт ягында да тирбәлә-тирбәлә ганҗә гөлләр хуш ис тарата. Кояш нурлары аның битен, муенын иркәли, футбол ярышыннан соң була торган арганлык, гәүдә авырлыгы каядыр йомшак җиргә сеңә бара иде. Кошлар пыр да пыр аның тирәсеннән очып чыгалар, күккә атылалар, күк үзенең сыек саф зәңгәрлеге белән искиткеч матур иде.

Тормыш, табигать, кошлар дөньясы бүгенге көн, бүгенге мәшәкатьләр белән мәшгуль! Алар ашыкмыйлар, иртәгәге көн тизрәк килсен иде дип теләмиләр, бүгенгенең рәхәт сөенечләреннән тәмам бәхетлеләр иде. Җемелдәп-җемелдәп Олы су ага, тугайларында вак балыклар ялтырашып сикереп куя, комырыкта качып яткан ачкүз кушбаш яр күләгәсенә керә дә, үзенең монда хуҗа икәнлеген белдереп, коерыгы белән шапылдатып суга, су чәчрәтә.

Менә биек-биектән аваз салып ялгыз торна очып үтте.

Икенче җәй рәттән Зөфәр ялгыз торна күрде.

Кайда икән аның башкалары? Бик биектә, сыек ак болытлар дулкыннарына тия-тия очты торна, ә тавышы бөтен күк гөмбәзен иңрәтеп таралды. Торна тавышын ишеткәч, чалкан яткан Зөфәр әйләнде дә җиргә йөзтүбән ятты, үлән сабаклары, кыштырдавык яфраклар аның яңакларына сарылдылар, чәчәкләр иелеп муенын кытыклады.

Тугызынчыда укучы малайлар ни уйлый?

Тугызынчыда укучы малайлар нинди теләкләр белән йокыдан уяна?

Аларга нинди төшләр керә?

Тугызынчыда уйлата, унынчыда биетә. Тугызынчыда малайлар күбрәк унынчы класс турында уйлыйлар. Унынчы класс — тормышның бер баскычын үтү, олы дөньяга чыгарга теләп капка кагу. Тугызынчыда малайлар кыяр-кыймасрак яшиләр, чөнки алда яңа, серле һәм биек капка барлыгын алар чамалый башлый. Унынчыдан соң яңа тормыш башлана. Унынчыдан соң бала ата-ана канаты астыннан чыга яза. Күбесе чыга да, үзенчә тормыш итә башлый...

Тормыш турында сүзләр күп. Билгесезлек һәрвакыт сүзләрнең ишлесен тудыра. Мәктәптә сүзләр бер төрле. Өй арасында ул сүзләр башка мәгънә алалар, үзгәрәләр.

Сүзләр, сүзләр!

Кеше яшәешендә һәрбер аерым сүзнең нинди олы әһәмияткә ия булуына без күп чакта игътибар да биреп тормыйбыз! Сүзләрнең һәркайсысын үлчәп, тәмен белеп, бөтен ләззәтен тоеп сөйләргә безнең вакытыбыз җитми, без яшәргә ашыгабыз, без алтын сүзләрне, алмаз бөртеге кебек бәһасез сүзләрне болай — узышлый гына, эч пошканнан, бодай кибәге очырган төсле генә очырабыз.

Кеше туа. Күзен ача! Нинди бөек минутлар! Кояш аңа көлеп карый. Юк, кояш түгел, әнкәсенең якты чырае гына икән әле бу... Кеше туа. Аның күз алдында якты йолдызлар яна! Юк, йолдызлар салкын, ә бу йолдызлар җылы — бәхетле ананың якты күзләре генә шулай елтырый икән әле! Менә ананың бәхетле иреннәреннән беренче сүзләр пышылдап чыга: «Балам!» «Улым» яки «Кызым!»

Кеше туа. Шушы беренче бөек, изге сүзләрдән соң һәр көн, һәр минут сүзләр дөньясына чума. Өйдә, ата-ана авызында сүзләр бер төсле яңгырыйлар, бала тәпи-тәпи урамга чыккач, башкалар белән аралашканда, чордашларын, иптәшләрен күргәндә өйдә бер төрле яңгыраган сүзләр икенче, кайчагында бөтенләй капма-каршы мәгънәләр алалар. «Яратам» дигән сүзне генә алыйк. Бу сүзне беренче тапкыр һәм кем авызыннан ишетә бит адәм баласы, уйласаң, бик мөһим мәсьәлә! Бала кем авызыннан беренче ишеткәндә аның эчтәлеген аңлый, бәяли ала, хәтеренә сеңдерә дә шушы гап-гади сүзнең серен-моңын күңелендә тоя башлый. Уйлап карыйк әле, хөрмәтле укучым, «манный боткасын яратам» дигәндә хәтерләп каламы ул бу сүзне, әллә «кояш баешындагы моңсу шәфәкъ нурларын үлеп яратам» дигән тезмәдә ишетәме?! Кайсы очракта бала күңеленә кереп кала бу сүз? Югыйсә, «яратам» сүзен «урлашырга яратам», «тукмарга яратам», «җан кыярга яратам!» дигән куркынычлы, дәһшәтле тезмәләрдә дә бердәй иркенлек белән кулланырга һәм максатка ирешергә мөмкин ич! Телнең мөмкинлеге чиксез, бала һәммәсен ишетә. Без сүзләрнең чын мәгънәсе турында уйланабызмы, сакмы без?

Бала — гөнаһсыз җан, язылмаган ак кәгазь, чишмә челтерәгәндәге ак дулкын, мөлдерәп торган саф күзләре белән ата-анасының ачык йөзенә карап күзен ача, уяна, елмая, көтә. Эти-әни аны сүзләр дөньясына — катлаулы һәм бер изге илгә алып керә.

«И туган тел, и матур тел, Әткәм-әнкәмнең теле!» — дип әйтәмә алар? Әйтә аламы?

Ленин, Ватан, Туган ил, Казан дип телебезнең иң изге, иң бөек сүзләрен яшьтән үк бала күңеленә сеңдерә аламы? Сүзләрнең иң күбесе, иң кадерлесе, иң мөкатдәсләре бала күңеленә ата-ана аша иңә. Онытмыйк без моны, хөрмәтле укучылар!

Зөфәрнең хәтеренә сеңеп, уелып калган беренче сүзләр менә мондыйрак иде... (Бала күңеле уңдырышлы кыр — ни чәчсәң шуны урырсың!)

Өй. Порт. Өй. (Сүзнең чыгыш килешен бер дә кулланмыйлар Сәләхетдин абзый белән Гөлбикә апа: пар кош шикелле сайрыйлар — «Өй-

лән» дигән мәгънә юк, «өйгә» дигән юнәлеш килеш кенә бар!) Өйгә кайтырга тиеш. Һәммәгез дә өйгә алып кайтырга тырышыгыз. Шулай кирәк, чөнки өй — байлык, өй — изге, өй — мәңгелек. Өй — безнеке. Мал-туар. Кием-салым. Җиһаз. Сыер. Сарыклар. Симез казлар. Каклаган каз. Каз бәлеше. Каз мамыгы. Каз каурые. (Бер капчык җыеп тапшырсаң, уч тутырып акча бирәләр). Һәммәсе ӨЙ сүзе белән бәйләнгән. Һәм юллар ӨЙгә таба кайта.

Тагын сүзләр. Сүзләрдән мәгънә ясала. Мәгънә бала күңеленә сеңә бара. Кеше. Кешенең кулы үзенә таба кәкре. Үз күлмәгең үзеңә якын. Брат братның көтү көткәненә дә рад. Кешегә ышанма, үзеңә таян. Артта калма, алдыңа чыгарма — югыйсә өлешсез калырсың.

Ата-ана балаларга, шул җөмләдән Зөфәргә дә, сүзләре белән генә түгел, эш-гамәлләре, тормыш мисаллары белән дә бары тик шушы кагыйдәләрнең генә изге кулланма булырга яраклы икәнен расларга тырыштылар.

Ана җае килсә дә, килмәсә дә атаны мактады: «Атагыз мал таба белә. Юк җирдә дә таба ала. Кулыннан эш килә. Эш әмәлен белә. Хәстәрен күрә. Тапканын башкалар сыман читкә чәчеп бетерми, өйгә алып кайта! Башкалар эчә, ул кабып та карамый, чүп-чар кеше белән аралашмый».

Ата да ананың дәрәҗәсен күтәреп яшәде: «Анагыз сакчыл. Бөртеккә дә исраф итми. Иш янына куш ясый белә. Йорт җанлыклы. Саран дисеннәр, исегез китмәсен. Әйе, саран. Юмарт булып бирәүнең дә ожмахка кергәне юк әле. Юмартлык — диваналык. Юмартлык — даны олы, кабыргасы коры.»

Ата белән ана үз сүзләренең буш түгеллекләрен тормышлары бөтенлеге белән дәлилли килделәр. Мал-туар арта тора. Кош-корт ишәя. Былтыр, әйтик, абзарда бер сыер күшәгән булса, быел аның янында башмак тана да печән кәмши. Димәк, яренгә ике бозау булачак. Берсен сугымга калдырсаң, икенчесен базарга алып чыгарга да була. Татарларга да дуңгыз симертү харам түгел икән, ике чучка аласың, йорт арасында бөтен калдык-постыкны ашап тора, талымсыз мал, ә акчаны китерә! Акча — кодрәт ул! Тавык-чеби, бакча җимешләре, машина-машина бәрәңге хуҗалыктан чыгып китә дә акча, кием-салым, йорт җиһазы булып кайта. Дөрес, башкалар да мал асрый, әмма Зөфәрләрдә бер тиен акча өчен җан кыярга әзер торалар, акчага табыналар, байлыкны барыннан да өстен куялар. Кешеләрнең дәрәҗәсен бары тик мал таба алуы белән генә бәялиләр.

Зөфәр бала чактан ук йорт эшләрендә катнашып үсте. Шулай да йорт арасындагы чышын-пышыннардан читтәрәк булды, чөнки мал, байлык аны берчакта да кызыктырмады. Беренчедә этисе бүләк иткән өч җәпле пәкене ятим Мөхетдингә биреп кайтты, чуар бияләен беренче киеп чыккан көнне үк югалтты, китапларын иптәшләренә биреп торды, тирә-күрше малайлары гел аның чанасына утырып шуалар иде. Ә Зөфәр көлә-көлә тауга чананы үзе сөйрәп менде.

— Дурак! — диде этисе.

— Рәт чыкмас бу нәзек муеннан, мал кадерен белми, — диде әнисе.

Зөфәр бишенче класста спорт белән мавыкты. Моңа әлеге дә баягы Җәмил абыйсы сәбәпче булды бугай. Кышын кыска нейлон куртка, җәен җиңел зәңгәрсу костюмнан йөри башлады малай.

— Ни котыра инде бу бала? — диделәр беравыздан ата белән ана.

Арага Вәзилә кысылды, ул спортсменнарның бай булуларын, мисаллар белән аңлатып биргәч, Сәләхетдин абзый белән Гөлбикә апаның авызы, акча санагандагы кебек ерылды. «Тик данлы һәм маллы булу өчен калада торырга кирәк» дип ачыклады Вәзилә. Олылар мәсьәләнең бу ягына игътибар итеп тормадылар, кызларының кая омтылганын алар беләләр иде инде.

Вәзилә күрше егете Җәмилгә гашыйк булганнан бирле Зөфәрнең бәясе күзгә күренеп артты. Зөфәр спорт ярата башлаган көннән аның бәясе тагын бер баскычка сикерде. Җәмил Түбән авылда укыта, ә Вәзилә гел-гел мәктәпкә барып йөри алмый иде. Җәмилен коллективта, эш арасында күрә алмый иде ул. Аптекага даруга төшкән чакларында гына мәктәпкә кагылып чыга, анда да үзенең барлыгын укытучылар коллективына, аерата яшьрәк хатын-кызларга күрсәтү өчен генә керә. Киенеп-ясанып бер-ике минут боргалана да: «Менә, мин дә бу дөньяда бар! Җәмилемә кагыласы булмагыз!» дип кисәтеп чыга кебек. Үзенне күрсәткәндә башкаларны да күрә алу сәләте бөтен кешегә дә бирелмәгән. Вәзилә әнә шундыйлардан иде, башкаларның Җәмиленә булган мөнәсәбәтен һич сиземли алмый иде. Ә сизәсе килә! Егетнең эчен-тышын белергә тели Вәзилә, кем белән очрашканын да, нилләр сөйләшкәнен дә; күпме акча алып кайда тотканын да, нәрсә ашап, нәрсә эчкәнен дә белергә тели! Зөфәр шуларның барысын да белешергә һәм түкми-чәчми апасына тапшырып торырга тиеш булды. Ул апасы кушканнарны бик читенсенеп, гарьләнеп кенә үти башлаган иде, тора-бара күнекте тагын. Хәтта бу хезмәт ошый да башлады! Ул Җәмил абыйсы артыннан күзәтә, сыный, ә абыйсы, олы булса да, берни сизмичә йөри бирә, сөйләшә, көлә. Зөфәрнең укытучы алдында яшертен бер өстенлеге бар иде хәзер. Күрше авыл, районнарга чыкканда Вәзилә аерата вакчыл һәм таләпчән була иде. «Кызлар белән очрашмадымы? Кайда кунды? Чыгып йөрмәдеме?» дигән сораулар белән малайның башын әйләндереп бетерә. Вакчыллык белән янәшә Вәзиләнең юмартлыгы да арта, кушылган эшнең ничек төгәл үтәлүенә карап, Зөфәргә вак-төяк бүләк тә эләгә, акча да биргәли апасы. Бинокль бүләк итте апасы — алды Зөфәр. Әти-әнисе акчага бик саран малай өчен бинокльле булу ифрат зур мәртәбә иде!

Вәзилә апасының таләпләре һаман шулай булыр дип белә иде Зөфәр һәм берзаман ике арада шундый сүз дә чыгар дип башына да кертеп карамаган иде. Ә апасы тотты да: «Җәмил абыең бала-чага түгел, аңа авыл спорты белән хушлашырга вакыт. Минем кияүгә чыгасым килә! Авыл гыйбатына чыгып адәм көлкесенә калырым юк. Менә шул: бүген сезнең команда җиңелергә тиеш!» диде. Аннан мәгънәле генә итеп: «Кем кемне!» дип өстәде.

Малайны апасының соңгы сүзләре аерата нык куркытты. Димәк, эш моның белән генә бетәчәк түгел, алла тагынниләрдер көтә икән әле! Ниләр булуы мөмкин? Нәрсәне ишарә итә аның усал апасы? Бәлки, Җәмилне агуларга кушар ул, үтерергә? Аннан булыр, булыр...

Куркуы чамасыз булса да, Зөфәр бик тиз ризалашты дисәк, дөрес әйтмәбез. Башта аның коты очты. Капкачы малай иң беренче чиратта иптәшләре алдында, кыр уенчылары каршысында җаваплы икәнлеген үзләштереп өлгергән иде инде. Шулай да апасыннан курку өстенлек алды, курку кешенең ихтыяр көчен изә, курку кешедән яңа кеше әвәли, малай Вәзиләнең үгетләренә бирешә, «ярар инде алайса», диде, «бер-ике туп кертерләр», диде. Апасы сәгать бүләк итәргә булды. Сәгатьле буласы да килә иде егетнең, чөнки Түбән авыл мәктәбенең югары классларында сәгатьсез егет бер ул гына иде. Әтисе: «син барыбер ватасың аны» дип алдырмады. Әнисе: «Әтиең дөрес әйтә», дип егетнең авызын каплады.

Бүген алар командасы җиңелергә тиеш булды.

Түбән авыллар бер гол кертсә, Зөфәр каршы якның ике тубын үткәрәчәк. Шундый уй белән ул юлга чыкты. Җәмил абыйсын көтеп тә тормады. Шундый фикер белән тренировка үткәрде. Шундый мәкерле ышаныч белән капкага басты.

Менә ике як уенчылары да кырга чыгып сибелде. Ак күлмәкләр, зәңгәр трусиклар. Сары майкалар һәм кара трусиклар. Судьялар чык-

ты, сыбызгы сызгырды, Җәмил абыйсы: «Я, Зөфәр, бөтен өмет ныклыгы синдә!» дип читкәрәк китте. Туп, ике як малайларын да әйдәкләп, тамашачы укучыларның сулышын кыздырып, кыр тирәли арлы-бирле йөгерә башлады, очып та киткәләде. Башта аның чабуында бер генә мәгънә дә юк иде, бара торгач ул да акылга утырды, ике як капкасына таба да җитезрәк узарга кереште.

Зөфәр күз алдында тигез кыр.

Зөфәр күз алдында иптәшләре, аларны байтак кискен уеннарда бер тән, бер җан иткән команда.

Бер кырыйда Җәмил абыйсы.

Әнә, туп нәкъ аның каршысына атылып килә! Оча, сызгыра, сакчы малайлар аның артыннан өлгерә алмыйлар, өмет бары тик Зөфәрдә! Һәм ул очып барып тупны кочаклап алды... Вәзилә апасы да, өйдәге мәкерле килешү дә, бүләк сәгать тә шушы мизгелдән онытылды. Ул мәчедән дә җитезрәк кыланды: сикерде, очты, мәтәлчек атты, аркасына ятты, тәгәрәде, түше белән бишәр метр шуып барып йөгерек тупны каплады, кочаклады, аягы белән типте, башы белән сөзде, корсагы белән бәрде, кыскасы, һәммәсен кыланды, әмма бер гол да керттермәде. Аңа, ялгышмы, уйлапмы, өч мәртәбә китереп типтеләр, биш-алты малай өстенә егылып измәсен изделәр, бер тапкыр уң кулының баш бармагы каймыкты, шундук шешеп чыкты, терсәкләре җиргә ышкылып суелды, теше канады, тез капкачлары сызлады, кабыргалары авыртты, пирчәткәсенең бармакчалары тишелеп бармаклары тышка чыкты, әмма Зөфәр бер гол да керттермәде. Аның капкасы сихерләнгән, пичәтләнгән иде.

— Ни булды сиңа бүген, егет? — дип котлады аны Җәмил абыйсы.

Ә иптәшләре аны иңнәренә утыртып кыр буйлап бер әйләнеп чыктылар, бөтен Түбән авылны яңгыратып «ур-ра!» кычкырдылар.

— Ни булды? — дип кабатлады Җәмил.

— Белмим,— диде ул оялып кына.

Белә иде, ялганлады, белеп бетермәсә дә сизенә иде. Аны Вәзилә апасының сүзе — хыянәткә өндәве котыртты. Апасының оятсыз тәкъдиме җенләндерде. Бер ел интернатта торып укыган, сүзләрнең башка мәгънәләре дә барын төшенә башлаган, футбол уеннарында бердәмлек рухы, коллективизм сеңеп өлгергән малай актив рәвештә Сәләхетдин абзый белән Гөлбикә апа кысасыннан ычкынып маташа иде инде.

Уеннан соң Түбән авыл буасына төшеп су коендылар, Зөфәр укытучы-тренерын бер читкәрәк алып китеп күңел серен чиште:

— Апа артыннан йөрмә, Җәмил абый,— диде ул.— Бетерәчәк ул сине.

Һәм өйдә булган мәкерле килешүне түкми-чәчми абыйсына сөйләп бирде.

Җәмил абыйсы артык сүз озайтып тормады, көлеп куйды, әмма аның соры күзләре җитдиләнде, калын кашлары җыерылдылар. Ул Түбән авылдан Язкилдегә менеп җиткәнче велосипедына атланмады. Уйлары зур иде, уйлары авыр иде. Юлда ул Сәкинәне очратты. Һәм хәерле сәгатьтә очратты. Сәкинәне күреп, күз салып йөри башлаган чагы иде. Икеләнә торган вакыты иде. Бүген ул аңа башка күз белән карады. Аның житкән кыз булуын да, очкынланып торган саф күзләрен дә, үзенә төбәлгән карашның эчкерсезлеген дә күрде. Кайнар карашның мәхәббәтле күзләрдә генә булуын ул бик яхшы аңлый иде...

Зөфәр өйгә кайтырга курыкты.

Язкилденең Түбән очына җиткәч ул иптәшләреннән аерылып калды. «Ник каласың?» дип сорадылар, эндәшмәде, кызарынып башын түбән иде. Аның хәзерге минутта Вәзилә апасы белән очрашасы килми иде. Гомумән, бүгенге көннең, уенның һәм җиңүенең булмавы хәерлерәк иде аның өчен. Чөнки бүгенге хәлләрнең иртәгәге, алдагы бик күп күңелсезлекләргә нигез буласын ул аңлый иде инде. Хәзер өйдә Вәзилә

апасы да авторитет, аның сүзе закон. Кулында диплом. Тапканын өйгә алып кайта. Өс-башын үзе юнәтә. Мал таба. Хәзер әти-әнисенең вәгазьләре янына Вәзиләнең дә тавышы кушылып китә. «Малайлар, юк-барга акча әрәм итмәгез. Хәзер дөнья үзгәрде. Байлык кирәк дөнья күтәргә! Дус-иш, туганнарны хәзер бары тик акча гына берләштерә».

Ата белән ана бер-берсенә карап куаналар.

Ата белән ана Вәзиләгә карап елмаялар. «Безнеке! Безнең кан! Үзебезнең тамыр!»

Алар елмая, ә Зөфәргә куркыныч.

Кайтмады, Олы су буена төште дә болында күмелеп ятты.

Карыны ачты малайның, эче чурлады. Ул яткан килеш кенә як-ягын күзәтте: кузгалаклар бар, әнисләр, арырак бер төп кәкы да күренә. Зөфәр тезләнеп, бөтерә-бөтерә кузгалак ашый башлады, эченә ачы су йөгергәч ашыйсы килү тагын да көчәйде. Ул кәкы эзләп бара башлады һәм зират коймасына төртелде. Күтәрелеп карады, сискәнеп китте: капка янында гына, эчтә, тезенә баш сөяге куеп Хәйретдин агай утыра иде. Зөфәр аңа эндәшмәде, күрмәмешкә салышты. Аннан сәерсенеп борылып карады, куркып та китте, картның кыяфәте мәзәгрәк иде. Гәүдәсе бер якка иңгән, күзләре йомык, чырае көлсу төстә. Алай да, Хәйретдин агай малайның кыштырдавын ишетте, күзләрен ярым ачып аңа борылды, төссез, коры иреннәрен чак кыймылдатып:

— Кем булды әле анда? — дип пышылдады.

— Зөфәр мин, Югары очның Сәләхетдин малае, — диде Зөфәр тиз-тиз.

— Нишләп йөрисең монда? — дип хырылдады карт.

— Минме? — Зөфәр ялганлады. — Бозау эзли идем, Хәйретдин агай.

Картның ирен читләренә аз гына саргылт күбек чыкты, ул тагын да ныграк янтайды, күзе шарланып акайды.

— Хәйретдин агай дим!

Зөфәрнең йөрәге өзелеп төшкәндәй булды, ул өметсезләнеп һәм куркып як-ягына каранды, карт һушсыз иде, ә тирә-юньдә бер җан иясе дә күренмәде. Зөфәр кычкырып тагын Хәйретдин агайга эндәшеп карады, җавап ишетелмәде, аның кул бармаклары язылдылар, баш сөяге тезеннән җиргә тәгәрәде. Егет кайнарланып алга-артка талпынды, фуражкасын салып чирәмгә ташлады, биленнән һәм муеныннан кочып картны шуңа яткырды. «Инфарктмы?» дип уйлады ул.

— Хәйретдин агай! Хәйретдин агай дим! Хәзер Вәзилә апаны алып киләм.

Картның балавыздай сары бит очында дәү чебен арлы-бирле йөри, ул учларын шапылдатып чебенне куды да картны күләгәгә күчерергә уйлады. Базмады, «әллә ярый аны кузгатырга, әллә юк!» диде дә, сикереп торып, томырылып авылга чаба башлады. Җир буе киттеме икән, арттан карлыккан тавыш белән берәү аңа кычкырды.

— Әй, Сәләхетдин малае! Әй, Зөфәр! Узды! Бетте!

Коты чыгып борылып караса, зират киртәсенә ябышып Хәйретдин агай басып тора. Улмы, әллә өрәгеме? Зөфәрнең чәчләре кыймылдады, тәне аңкавына ябышты, ияге исерек кеше кебек биеде. Карт тагын, бу юлы ачыграк итеп кычкырды:

— Әй, Зөфәр, узды!

Ул тез буыннарының калтыравын көчкә тыеп карт янына кайтты.

— Кая чаба идең син алай?

— Авылга.

— Нигә?

— Апаны алып килмәкче идем.

— Сәләхетдин малае диденме әле син?

— Үзе.

— Йөрмә. Апаң кирәкми. Чирләштерәм мин. Булгалый. Тик бүгенгесен апаңа да, башкага да әйтмә. Сер тота беләсеңме?

— Беләм, — диде Зөфәр кызарынып.

— Алайса, шул. Хәзер чүт кенә хәл алам да кайтам. Апаң кирәкми. Ә син нишләп монда чуаласың? Зират тирәсе яшьләр өчен түгел...

Хәйретдин агай малайдан җавап көтеп тормады, аның каңгырап йөрүенең сәбәбен аңлаган төсле Зөфәргә теләктәшлек белән яратып карады, көрсенеп куйды, күлмәк итәген кайтарып авыз читен сөртте, эшләпәсен арткарак этәрде, иелеп баш сөяген алды: беравык карап торды, тагын бер көрсенде, сөякнең туфракка буялган күз урыннарын тезенә сөртә-сөртә вак-вак атлап зират эченә китте. Сөякне куак астына куйды, җиргә тезләнеп ике кулы белән дә йөзгән кебек хәрәкәтләр ясап коры яфракларны җыештырып китерде, җентекләп күмде, күренмәслек итте. Тезләнгән килеш хәтсез генә карап торды, дога укыдымы, теләк теләдеме, аңлап булмады, зираттан чыкканда Хәйретдин агайның кансыз, юка бармаклары калтыраналар, ирен чите уйнап-уйнап китә иде...

## 7

Ул көнне Зөфәр өйгә кайтмады. Хәйретдин агай янында каравылөендә калды. Алар авылга кайтканда Минниса карчык, кәстрүл белән боткасын тезенә куеп, баскычта утыра иде, күренеп тора, хафаланган, борчылуы йөзенә чыгып, яңаклары сураеп эчкә кергән...

— Озакладың, сиңа әйтәм, — диде ул картына елмаеп карап — Кайда йөрдегез болай?

Карчыгын күргәч, Хәйретдин агай керфексез күзен кысып, Зөфәргә баш какты, «сер бирмә!» янәсе, һәм:

— Болын яныннан урап мендем. Печән чабарлык урыннарны карадым. Кышка да әзерләнергә кирәк бит! — диде.

Ботканы олы-олы агач кашыклар белән бик яратып ашаганнан соң биш-алтышар чынаяк чәй эчтеләр. Күңелле үк булып китте, Хәйретдин агай мәзәк сөйләп карчыгын туктаусыз көлдерде, үзе һе-һе дип куанып утырды, мәгәр сизгер карчык картының нигәдер кәефе киткәнлеген бер карауда ук аңлаган иде. Ашны олылап табын янында сүз кузгатмады, ашап-эчеп туйгач, капылт кына сорап куйды:

— Әллә чирләбрәк торасыңмы, сиңа әйтәм?

Хәйретдин агай шыпырт кына тагын Зөфәргә күз кысты һәм Миннисаның соравына җавап бирмәде.

— Менә, аллаһы боерса, озакламый печәнгә төшәрбез! Узган кыш та атка ризык такы-токырак булды. Быел мул итеп әзерләрбез дим. Сарай тирәсен дә ныгытасы бар, улак башындагы почмактан су да үтә, түбәне ябарбыз! Эш күп!..

Әле генә, зират капкасы янында үлем хәлендә яткан Хәйретдин агайның киләчәк турында, бары тик алдагы эшләр турында гына сөйләшүе Зөфәргә кызык һәм мәгънәле күренде. Аның тырышып-тырышып ботка ашавы, дөньяны-көнне мактый-мактый чәй эчүе дә бер дә юкка түгелдер кебек тоелды: алдагы тормыш барлыгына ул Миннисаны гына түгел, үзен дә ышандырырга тырыша иде бугай. Карт белән карчык бер-берсен бүлдермичә, әмма җай килгән саен, бер-берсен куәтләп, көч биреп сөйләшеп утырып калдылар. Зөфәр:

— Хәйретдин агай, каланчага менеп төшимме? — дип сорады.

— Мен, мен, — диде карт нигәдер сөенеп.

Зөфәр каланчага ашыгып менде, менгәч тә Югары очка карады. Өй тирәсендә хәрәкәт сизелмәде, күрше Мирфатыйхлар ишегалдында гына кемнәрдер тиз-тиз йөренәләр иде.

Аннары ул Түбән оч ягына — Зәйдән кайта торган олы юлга борылды. Юл тыныч түгел, дәү-дәү йөк машиналары уза, җиңел машиналар тыз да быз бер-берсен куалыйлар, мотоцикллар чаба. Байтак карап торса да аларның чия төсле «Москвич»лары күренмәде. Вәзилә апасы ике тапкыр янгын сарае янннан узып китте. Медпунктка барып житте дә бер урында әйләнгәләп йөрде, эчкә кермәде, беркем белән очрашмады, авыр гына атлап, кире борылып өйгә кайтып китте. Ул каланчада песи булып йомылып утырган атаклы капкачыны күрмәде. Килешли Җәмилләргә кереп «Зөфәрне кайда калдырдың?» дип сорарга ниятләгән иде, кереп тормады, күңеле җавап белән канәгатьләнер дәрәҗәдән узган, әгәр Зөфәр каршысына килеп чыкса ул аны... әллә нишләтер иде!

Җәмилгә дә ачулы иде Вәзилә — шиксез!

Сәкинәгә дә, Зөфәргә дә ачулы иде. Тик Җәмилне дә, Сәкинәне дә берни эшләтә алмаслыгын бик ачык аңлый иде ул һәм аның бар җыелган ачу дулкыннары Зөфәр өстенә ябырылырга тиеш иде. Чынлыкта, Вәзиләнең медпунктта эше юк, күрәсе кешесе дә юк, ул бары үч ярсуына буылып Зөфәрне генә эзли иде. Дөрес эшләде Зөфәр каланчага ук качып, Вәзилә Хәйретдин агайны да, Минниса карчыкны да күреп узды, әгәр малай да алар янында булса оятлы итә иде атаклы футболчыны, измәсен изеп арыш кабартмасы ясый иде!

Җәмилне кулга иләштердем, Зөфәрне колым ясадым дип ышанып йөргәндә генә, икесе дә бер көндә кызның юлына аркылы-яттылар. Уйга калды Вәзилә. Соңарып килгән акыл — һәрвакыт хәсрәт ул. Төште хәсрәткә Вәзиләнең башы! Җәмилгә, Зөфәргә, үзе үскән Язкилде авылына башка күз белән, читтән килгән кеше күзе белән карады.

Бик үзгәргән икән авыл! Матурайган. Йортлар бер-берсеннән шәп. Коймалар бизәкле. Капкалар сәнгать әсәрләре кебек. Мунчалар, амбарлар, келәтләр бер-берсеннән олы. Һәркайсы ярты ындырны алып утыралар. Гараж ишекләре тимерле. Тимерле ишекләрдә йозаклар. Тимерле ишегаллары асфальтланган. Телевизор мачталары Язкилде өстеннән узган болытларның итәкләреннән тартып алырлык. Нинди рәвешләре генә юк аларның! Түгәрәге, өчпочмаклысы, дүрткеллесе, һәр хуҗа мачтаны һәм антеннаны күршесенекенә охшатмаска тырышып ясаган һәм теләгенә ирешкән. Нинди генә антенналар юк Язкилде күгендә!

Авыл кешесенең характеры йортында, нигезендә чагыла.

Авыл кешесенең кемлеген капка бигенә тотынгач ук белеп була.

Авыл кешесенең байлыгы, ярлылыгы, уңганлыгы, ялкаулыгы ихатасының бөтен ноктасыннан күзгә кереп, кычкырып ук тора.

Вәзиләнең аяк табаннары кычытты — аның шушы минутта ук авылыннан мәңгегә качасы, шәһәр арасына кереп югаласы килде. Шәһәрдә үзеңчә яши аласың! «Үзеңчә яшәү» Вәзиләчә кеше белән аралашмыйча, катнашмыйча һәм үз гаилә серләреңне берәүгә дә чыгармыйча яшәү була иде. Белә Вәзилә, укыганы да бар, ишетеп тә белә — шәһәрдә бер йортта, бер этажда күршеләр булып яшәгән кешеләр дә бер-берсен белмиләр, йомыш-юлга кермиләр, кунакка да читләрне, ерактанрак чакырырга тырышалар. Бу хәлне газеталарда хурлап, «заманыбызның әшәке чире — некоммуникабельность» дип атап йөртәләр. Хурласыннар, эт өрер — кәрван йөрер, ә Вәзиләнең нәкъ менә шундый тормышта яшисе килә, күршеләренең бәбәкләренә туп-туры чекрәеп карап, эндәшмичә генә, киерелеп узып китәсе килә. Кунакка җәһәннәмнән — күршеләр белмәгәннәрне чакырасы килә. Әгәр Җәмил аныкы гына булса, аның сүзен генә тотар булса, әгәр аны кадерләп кенә яшәр булса, карурмандагы ялгыз йортта да яшәргә риза Вәзилә. Әгәр Җәмиле бер-бер кодрәт белән аның хәзерге уйларын белеп килеп чыкса һәм «әйдә, җанашым, бүгеннән лесник булып китәм, миннән калма!» дип кулын сузса, Вәзилә

бер минут та икеләнеп тормас иде. Күзе күрмәс иде мондагы артык мәшәкатьләрне. Мәшәкатьләр тормышны бутый, күңелдә шик тудыра. Мирфатыйх йорты белән Сәләхетдин йорты арасына татулык бер чакта да кайтмаячак. Җәмил белән Вәзилә кушылып авылда калсалар да бу ике йорт арасындагы бетмәс көнчелектән вакытсыз гүргә керәчәкләр.

Ярты сәгать дисәм аз, сәгать ярым дисәм күп булыр, шактый таптанып йөрде Вәзилә медпункт тирәсендә. Моңарчы пункт тынычлану урыны иде, бүген, Сәкинә аяк басканнан соң, дөньяның бу тыныч почмагы да җан биздергеч җәһәннәмгә әйләнде.

Моннан ары ничек яшәр дә Вәзилә, Җәмилен нинди ысуллар белән үзенә кире кайтарыр. Егетне югалтуына бер тамчы да шикләнми иде ул шушы авыр минутларда. Сагышлы, кичке минутларда...

Зөфәр, әлбәттә, биек каланчада торып, апасының күңелен нинди каршылыклы, усал һәм рәхимсез уйлар биләгәнен белә алмады! Усал уйлар кайнаган күңел — тәмугтагы сумала казаны ул, хөрмәтле укучым! Языклы кешеләрнең күңелләре тулы казан! Дөрес, Зөфәр апасының усаллыгын да, рәхимсезлеген дә белә, әмма барыбер аны яхшы күңелле, тырыш кеше дип саный. Җәмил артыннан шпионлык кылырга кушуы да егетне яратканы, көнләшүе аркасында гына булды ич аның, дип юата үзен Зөфәр. Бүген җиңелергә боеруны да Зөфәр үзенчә — бары тик гыйшык бәласе дип кенә кабул итте. Ялгыша иде егет, Җәмилне өзелеп яратканнан тумады кыз күңелендәге ул мәкерле уйлар, андый фикерләр Вәзиләне — Югары очның үз сүзле, кире беткән Сәләхетдин кызын яратканнан гына туды.

Тик үсмер егет, каршылыкларда чыныкмаган бер катлы егет, алай тирән уйлый белми иде әле, апасын ярата иде ул.

Ул Вәзиләнең үченнән бигрәк йодрыгыннан ныграк курыкты. Абыйсы Хәйдәр кайтып өлгерсә, Вәзиләгә Зөфәрне тукмарга ирек бирмәс бирүен. Хәйдәр күренми, Хәйдәр!

«Хәйдәр» дидем дә, хөрмәтле укучым, тукталып калдым.

Безнең хикәядә шактый кешенең исеме телгә алынды. Югары очның шактый малай-кызлары күзгә күренеп калды, инде берсе дә буталмасын, һәркайсысы үзенә тиешле урынны алсын өчен, шушы урында, сүзебезне бүлеп, авыл советыннан алынган бер белешмәне теркәп китик.

### Кыска гына белешмә

*«Бу белешмә биреләдер Язкилде авыл советы тарафыннан шул ук авыл гражданы Сәләхетдин Билялетдин угылы Мөхетдиновка шул хакта, ягъни, бүгенгесе көндә аның гаиләсендә түбәндәге кешеләр исәпләнәләр:*

*1. Мөхетдинов Сәләхетдин — гаилә башы.*

*2. Мөхетдинова (кыз чагында Гаделшина) Гөлбикә — аның хатыны.*

*3. Мөхетдинов Габбас — улы, бүгенгесе көндә Әлмәттә яши, өйләнгән, универмагта грузчик.*

*4. Мөхетдинова (Җаббарова) Рауза — кызы, бүгенге көндә Чаллыда яши, кияүдә, кибет мөдире.*

*5. Мөхетдинов Хәйдәр — улы, авылда үз янында яши. Механизатор.*

*6. Мөхетдинова Вәзилә — кызы, медпункт мөдире.*

*7. Мөхетдинов Зөфәр — улы, укучы.*

*8. Мөхетдинова Фирүзә — кызы, укучы.*

*9. Мөхетдинов Зәйтүн — улы, укучы.*

*Җиде бала анасы буларак Мөхетдинова Гөлбикә «Ана даны» ордены белән бүләкләнгән. Өченче дәрәҗәдә».*

Гербовой пичәт һәм имзалар белән расланган шушы белешмәдән сез Хәйдәрнең өченче бала булуын да, механизатор икәнлеген дә белдегез инде. Алдарак без Язкилде авылында кызу эш өсте булуын, һәркемнең эштә булырга тиешлеген, идарә карарының ныклыгын һәм идарәдә шулай дип уйлауларын искәртеп узган идек инде. Колхоз идарәсендә Хәйдәрне дә бүген эштә дип беләләр һәм ул печән оны ясаучы агрегатта хезмәт күрсәтә дип исәплиләр иде.

Тик бу юлы идарәдә ялгышалар иде.

Хәйдәр бөтенләй колхоз эшендә түгел.

Хәтта авылда да юк.

И балалар, балалар! Бала һәркемгә газиз, керпенең дә баласы йомшак, карга баласы да ак...

Габбас үсеп житте дә өйләнгәч өйдә өч кенә көн торды. Әлмәткә күчте. Күчүенә рәнҗегән иделәр, «бурычын түләмичә ычкынды», эшкә универмагка урнашкач куанышты лар: «Авызы-борыны майда булыр!» Габбаслар хәзер ике елга бер генә авылга кайталар, Әлмәт — Язкилде юлын Гөлбикә апа такырлый. Кызлары Раузаны Түбән авыл егете Чаллыдан кайтып алды. Райпотребсоюзда эшләүче егет иде, берсүзсез, дүрт куллап бирделәр. Кибетче иде Рауза, тора-бара мөдир дәрәҗәсенә иреште. «Шулпасы күршедә кайнаса да ите бездә пешә!» Раузаның һәм кияүнең яраткан сүзе. Бу сүз Сәләхетдин абзый белән Гөлбикә апаның да йөрәгенә бик ята! Чаллы юлын да буш тотмый Гөлбикә апа, яңа шәһәрнең базарларын, кибет-складларын, бәләкәй ларекларын гына түгел, якын елларда кайда, нинди кибет ачылачагын шәһәр төзүче иң хәбәрдар кешеләрдән дә төгәлрәк белә.

Хәйдәргә ата белән ана аерым бер өмет багладылар.

Укуы өчле-тугызлы, тәртибе кеше арасында килделе-киттеле булса да Хәйдәр өйдә бик яшьли кул арасына керде, вак-төяк йомышка ярый башлады. Эшкә кулы ята иде малайның. Бер вакыйгадан соң Сәләхетдин абзый улын аерата яратты. Лапас артында әллә ничә елдан бирле җыйналып килгән тирес тавы бар иде. Бер язда аталы-уллы шул тиресне ындырга чәчәргә булдылар. Тирес тыгызланып агачка әверелгән иде. Бер көн чаптылар, икенче көнне ызаннар буйлап ташыдылар. Икенче көнне кич белән Хәйдәр әтисенә болай диде: «Болай интеккәнче шартлатыйк без бу тауны, әти!» Сәләхетдин көлеп куйды һәм улына буш эш белән маташмаска кушты. Хәйдәр кире иде, төннең төн буе йокламады, сифон баллонына мул итеп дары тутырды, дарыга марганцовка кушып болгатты, шушы масса эченә нәзек кенә электр үткәргече урнаштырды. Кесә фонары батареяларыннан алтыны бергә берләштереп электр үткәргеченә тоташтырырга әзерләнде. (Ул чагында Язкилдедә электр юк иде әле!) Икенче көнне лапас баганасы артына посып батареяларны тирес астына чокып урнаштырылган сифонга тоташтырды... Дөрес, «тирес шартлаткыч агрегат эшләмәде», әмма малайның тырышып азаплануы, әмәлен табарга омтылуы ата күңеленә бик хуш килде. Хәйдәр энисенең күңелен дә бик тиз яулап алды, җеп эрләгече ясады да, өч-дүрт кичтә энисенең бар булган йонын эрләп бетерде. «Бу малайдан эш чыга!» диде ата. «Өмет бар моңарда!» диде ана.

Сәләхетдин абзый Хәйдәрдә үз дәвамын күреп куанды.

Хәйдәр сигезенчене теләр-теләмәс кенә тәмамлады, аны мактаптан этеп-төртеп дигәндәй чыгардылар. Бөтен коллектив «тугызынчыга кил мәсә генә ярар иде», дип теләк теләде. Хәйдәр Мөхетдинов тугызынчыга бармады, моны белгәч, педколлективта танца кичәсе үткәрделәр. Сөенечтән!

Хәйдәр бер җәй комбайнда ярдәмче булып йөрде дә көзгә Чистайга авыл хуҗалыгы техникумына барып керде.

Монысына да кул куйдылар.

«Чүлмәкчедән күрмәкче» булдымы, әллә күрше Мирфатыйх улы Мидхәтнең Чистайга барып уку нияте әлегрәк тә булганмы, һич уйламаганда, истә-оста югында Хәйдәр белән Мидхәт бер агымга туры килделәр, бер бүлмәләрдә укыдылар, бергә практикага йөрделәр.

Мирфатыйхлар йорты белән Сәләхетдиннекеләр пыр тузышып көнләшә, байлык артыннан куышып, мал җыеп ярыша торган аралгы чак иде. Гөлбикә белән Гөлмәрьям бер-берсен күрә алмаслык дәрәҗәгә килеп җиткәннәр иде! Дөрес, терәлеп торган күрше булarak, бер урамтыкрыклардан йөрергә туры килә, дошманлыкны ачыктан-ачык белдереп булмый, белдерергә дә ярамый, урам-сукмакта очраганда алар зәһәр елмаешып кына сәлам алышалар, хәл-әхвәл дә сораштырган булалар. Әмма алар әллә ни гомердән бер-берсенең йортына аяк басмыйлар, берсе йортында ни барын кермичә дә бик яхшы белеп, тикшереп торалар. Өйдә чакта Гөлбикәнең күзе Гөлмәрьямнәрдә, Гөлмәрьям өйдә туры килгәндә ике күзен дә Гөлбикәләрдән алмый. Кергән-чыккан кеше, сөйләшенгән сүз, ялгыш кына яңгырап киткән ызгыш-талашлар, берсе дә күршеләрнең игътибарыннан читтә калмый. Ишетәләр, тыңланалар, җыеп баралар, икенче көнне үк халык арасына чыгаралар. Бик арттырып, матурлап чыгаралар.

Һәр тарафта кискен каулаш бара!

Күбрәк, мулрак, симезрәк, артыграк булсын!

Ике дошман нигездә үскән егетләр чит урында — Чистайда бергә туры килделәр. Сөйләшүләре, читләшүләре башта иптәшләрен шиккә төшергән иде, аларның авылдашлар икәнлеге бик тиз фаш булды. Иптәшләре алардан егылып көлде. Көлкедән ничек тә котылырга кирәк иде, ничектер янәшә түзеп яшәргә, авылдан коерык булып килгән дошманлыкны онытып торырга иде. Сүздән сүз чыкты, уйны уй ялгады. Язкилде тумалары, авылны сагынышкан чаклары булды, яши-яши Хәйдәр белән Мидхәт бергә чәй эчтеләр, сөйләшкәләп тә алгаладылар. Өйдән килгән кадерле күчтәнәчләр уртак табынга менде, Гөлбикә апа чәкчәкне бик тәмләп әзерләсә, Гөлмәрьям апаның пәрәмәчләрен күрүгә авыздан су килә иде. Дошманлык онытылмады, дошманлык тарихи аскы катламнарда гына калып торды. Күмелде.

Малайлар үсеп, ныгып, иңнәре киңәеп, егетләнеп авылга каникулга кайттылар. Яңа гадәтләре аларга Язкилдегә кадәр ияреп кайтты... Тик авылда ике күршенең хәле элеккедән дә яманрак иде. Мидхәт Хәйдәр янына керергә чыкты.

— Кермә! — дип бер генә кычкырды Мирфатыйх.

Хәйдәр Мидхәтләргә керергә җыенды.

— Йөрмә! — дип бер генә җикерде Сәләхетдин.

Гөлмәрьям Мирфатыйхны, Гөлбикә Сәләхетдинне куәтләделәр.

— Кермәсен!

— Йөрмәсен!

Икенче көнне капка төбендә бер-берсен күрделәр, танымаганга салышып берсе кырлар ягына, икенчесе Түбән очка карады... Көндез очрашмыйлар, кичен бер-берсен күрмәскә тырышалар, танцада клубның ике читендә биләр, Югары очка аллы-артлы кайталар.

Ләкин дошманлыктан ничек котылмак кирәк?!

Җәй узды, ямьле җәй... Көзен алар тагын Чистайда очраштылар һәм дошманлык бер дә булмаган төсле, күрешеп, белешеп йөри башладылар, бергәләп чәй кайнаттылар. Бәрәңге пешерделәр.

Дошманлык һич кӧтмәгәндә үзен сиздерде.

Практика вакытында булды бу яман хәл. Егетләрнең икесен ике тракторга утыртып учхоз җирен сөрергә куштылар. Бер әйләнделәр кишәрлекне Хәйдәр белән Мидхәт, ике урадылар, тәмәке тартырга, фи-

кер уртаклашырга тукталдылар. Икесе дә аракыны яратып эчә һәм тәмәкене тәмләп тарта башлаган вакыт иде.

Көн эссе, көн бөркү, ник чыпчык җиле иссен... Яндыра! Икәүләшеп трактор күләгәсендә чүмәштеләр. Суыралар, тарталар, черт тә черт төкерәләр. Ике авыздан, дүрт борын тишегеннән зәңгәр төтен ургылып чыга да һавада озак кына бөтерелеп йөри. Зәп-зәңгәр рәшәле чиксез гөмбәздә күкнең йөрәге тургай талпына.

— Минем трактор шәбрәк, — дип ирәйде кинәт Хәйдәр. Кичә сыра кушып эчелгән аракыдан аның ми тамырлары котырып сызлый иде. — Син арттан сөйрәлеп йөрмәсәң мин кишәрлекне тизрәк үтәр идем.

— Мактанчык! — диде Мидхәт җиргә төкереп.

— Әллә ышанмыйсыңмы?

— Трактор трактор инде! — диде исе китмичә генә Мидхәт. Аның бер дә юкка сүз көрәштерәсе килми иде.

— Минеке көчлерәк! — диде Хәйдәр һаман кабарынып. Егетнең башчатный, күз алдында аллы-кызыллы түгәрәкләр иде. — Әйдә, ышанмасаң, сынап карыйбыз. Җиңә алсаң, сиңа бер ящик аракы!

«Сынап карыйбыз» дигәндә Мидхәт куркып калыр дип көткән иде Хәйдәр, әмма ике гаилә, ике егет арасында барган сүзсез көнчелек, каршылык, көрәш, бер-берсен яратмау, күремсезлек, гаделсезлек белән дә теләсә нинди бәхәсне хәл итәргә әзер булу үзенекен итте — алар кул сугыштылар, тракторларны сабаннардан аердылар һәм ике ДТ-75, ике гайрәтле гыйфрит бер-берсенә каршы таранга китте. Бер килеп бәрелештеләр тракторлар, моторлар өзмәс үкерде, металл ышкылган тавыш колакларны ярды. Чигенеп, тагын берсенә каршы икенчесе китте, күзләрен кан баскан егетләр бер-берсен изеп, таптап китәргә әзер иделәр.

Техникум яңа ике тракторын югалтты.

Техникум ике егетен югалтты.

Хәйдәр белән Мидхәткә шгәлер «боксер» кушаматы тактылар һәм судка бирделәр. Егетләрнең армия сафларына китәр чаклары җиткән иде, шул гына аларны аяп алып калды, ата-аналарына шактый штраф түләттеләр дә, егетләрне шыпырт кына озаттылар...

«Штраф түләргә» дигән язу кайткач Сәләхетдин Хәйдәрне үз янына чакырып кертте дә:

— Җиңдеңме ичмасам шул сөмсез Мирфатыйх малаен? — дип сорады.

— Җиңдем, — диде үкчәсе белән идән тырнап Хәйдәр.

— Алайса, ярый. Түләсәк тә түләрбез шул,— диде Сәләхетдин акча янчыгын селкеп.

Мирфатыйх та Мидхәттән допрос алды:

— Шул Сәләхетдин тилесенә җиңдермәгәнсең лә? — дип сорады.

— Җиңдермәдем,— диде Мидхәт муенын кашып, күккә карап.

— Ярый алайса, түләрбез инде,— диде Мирфатыйх, хатыныннан акча янчыгын тартып алып.

Егетләрне армиягә бер айда алдылар.

«Бер частька гена эләкмәсәк ярар иде!» дип теләде Хәйдәр.

«Бергә җибәрмәүләрен сорармын!» дип уйлады Мидхәт.

Теләкләре кабул булды, егетләрнең берсен көнчыгышка, икенчесен көнбатышка озаттылар.

Егетләр икесе бер елда, аллы-артлы диярлек, армия хезмәтеннән кайттылар. «Машина алып бирсәң авылда калам»,— диде Хәйдәр әтисенә. «Авылда калсаң, машина алып бирәм», диде Мирфатыйх Мидхәткә.

Сәләхетдиннәр йортына тиз арада чия төсле «Москвич-412» кайтты. Мирфатыйхныкылар лимон төсле «Жигули»ны абзарларына алып кайтып яптылар да, ел дигәндә таш идәнле, бетон түбәле, тимер ишек-

ле, алты йозаклы гараж җиткереп тә куйдылар. «Карак түгел, җил дә үтмәс» алар салган гаражларга!»

Шулай итеп егетләр авылда калды. Башта икесе дә трактор да эшләделәр. «Берүк икесен ике басуга куегыз, югыйсә бетте баш!» диде Сәләхетдин. «Бәладән башаяк», диде Мирфатыйх акча янчыгын хатынына сузып.

Ике дисәм аз, өч җәй дисәм күп булыр, тракторда эшләгән егетләр ялынып-ялварып башка эшкә күчтеләр. «Эссе! Башыма ут каба. Тазалыкка туймыйм» — диде үгез кебек Мидхәт.

«Акчасы аз төшә, өйләнәсе бар!»— диде Хәйдәр.

Мидхәт механизатор булып терлекчелеккә күчте, Хәйдәр чия төсле машинасына утырып чыгып югалды. Бер атна күренмәде, ике атна кайтмады, төгәл утыз биш көн югалып торды Сәләхетдин Хәйдәре. «Эчеп йөридер әле ул боксер», диештеләр кешеләр. «Караклашып йөридер, шайтан!» диючеләр дә булды. Сәләхетдиннекеләр дәшмәделәр, Мирфатыйхлар йортыннан күңелле җыр яңгырады:

Бар, зимагур, кайт иленә,
Кайтсаң иген игәрсең,
Чабатаңны сука итеп
Бутылкаңны җигәрсең.

Сәләхетдин тумасы — җете соры күзле, юка ирене һәрчак кысылган Хәйдәр йодрыкларын йомарлап юкка гына йөрми иде читтә. Ул авылдан-авылга, колхоздан-совхозга, әрмәннән-грузинга, бригадирларга, әртилләргә юкка гына кагылып, эшләренә кысылып, төпченеп йөрмәде: колхозларда договор белән эшләүче бригадалар белән танышты, белеште, законнарны өйрәнде, документ үрнәкләрен күчереп алды. Кирәк икән юхаланды, кирәк икән ялтыны куйды, тагын да сүзсезләнеп, авызын йомып авылга кайтып төште. Язкилдедә яшьтәшләре белән кичке уеннарга чыгып йөрмәде, көндезләрен телевизор карады, кичләрен бик күп адреслар белән хат язды.

Икенче язда, карлар эреп юллар төшкәндә, үз ишләреннән җиде кешелек бригада туплап, күрше район колхозларының берсендә договор белән терлекчелек комплексы сала башлады. Үзен дә аямады, иптәшләренең дә җанын алды. Эшләгән эшләре көлеп тора иде, акчасын да кушуч тутырып алдылар. Бригадасында ике доцент, өч студент һәм бер бик әйбәт инженер — ташчы бар иде. Бер караңгыдан икенче караңгыгача баш күтәрми эшләделәр, төшке ашны аяк өсте генә капкаладылар, аракы белән мавыкмадылар, клуб тирәсенә эз басмадылар, хатын-кыз артыннан йөрмәделәр.

Акча!.. Акча дип таң аттырды Хәйдәр, акча дип кичен озатып җибәрде. Кышын олы өй янына тагын бер өй җиткерделәр, Хәйдәргә өйләнергә кирәк иде. «Тораммы-юкмы монда, белмим, әмма резервта йорт булу бер чакта да зыян итмәс», диде ул әтисенә. Сәләхетдиннәрдә җыр яңгырады, Мирфатыйхларда «траур» иде.

Язкилдедән дә, Түбән авылдан да үзенә яраклы кәләш таба алмады егет, «бусы арык», диде әнисе; икенчесен «симез, арты тегермән ташы чаклы», дип бракка, яраксызга чыгарды, улының гайрәтен чигерде.

Кызны читтән, Гөлбикә апаның күзе җитмәгән җирдән табарга кирәк иде. Ниһаять, бик озак эзләгәч, чия төсле «Москвич» бик күп юлларны таптагач, Хәйдәрнең күңеленә ятышлы кыз табылды. Ул Зәй-Чаллы юлы өстендә диярлек урта кул гына Байгол дигән авылда яшәп ятучы Гөлсабира исемле кыз икән. Әтисе, якын туганнары юк, әнисе белән икәү генә яшәп яталар. Кыз бар яктан да Хәйдәргә ошады.

— Кайсы ягын ныграк яраттың? — дип сорады ата улыннан.

— Аз сөйләшә.

— Хуп, әйбәт сыйфат,— дип мактады ата. — Тагын кайсы төше ошады?

— Өр яңа «Жигули» бар.

— Бәракалла,— диде ата. — Нигә сүзне шуннан башламадың? Күп сөйләшә торган кеше «Жигули» ала аламы?! Хәере белән килсен!

## 8

Гөлбикә дә килен буласы кеше белән бик нык кызыксынды, «ябыкмы, симезме?» дип сорады. «Кочаклап ятканым юк бит әле!» дип ачуланырга өлгермәде дулкынланган Хәйдәр, анасының гадәтен бик яхшы белгәнгә сүзне озынга сузмады:

— Таманча гына инде,— дип куйды.

Шуннан арысын ата белән ана сорашып тормадылар, һәркайсысы улыннан ишеткән кадәресен зиһеннәрендә сеңдереп, уйларында таркатып йөрделәр. «Машиналы килен! Мирфатыйхларның танавы җимерелә икән! Алар кылдый-былдый матае да булмаган Түбән авылның Хәлилрахман кызын алырга йөриләр!» дип уйлады Сәләхетдин. «Таманча гына ди! Бу инде Гөлмәрьямнең булачак килене төсле шүрәле түгел!» дип уйлады йөзе алланган Гөлбикә...

Ике көн, ике төн узгач кызның исемен, яшен белештеләр. Исеме дә җанга ятышлы икән, Гөлсабира атлы ди, яше генә ата белән ананы бераз уйга калдырды: Гөлсабира Хәйдәрдән төгәл дүрт яшькә олы — егерме тугызда икән инде. «Әйдә, диде соңрак ата, малайның кадерен белер. Машинасы өр яңа ич, яшь машина!» «Тормышлары ышанычлырак булыр, азып-тузып, мал таратып йөрмәсләр», дип килеште ана.

Хәйдәр булачак хатыны турында артык озаклап уйламады, аны машина бик нык кызыктырды. Энекәшләр үсеп килә, әле әтисе дә көчендә, семьяда бер машина белән генә яши торган түгел иде. Дөрес, тырышса Хәйдәр үзе дә машина юнәтә алачак, ә болай, тәгәрәп авызга кереп торганы барында нигә юкка көч сарыф итәргә?! Ул гаражны киңәйтү турында сүз кузгатты, әлеге машина да авылда торырга тиеш иде. Аннан тагын күз күрер... Шулай итеп Сәләхетдиннекеләр килен төшерергә әзерләнә башладылар.

Гөлбикәнең күңелендә һаман бер шик кала килде, улының «таманча гына» диюенә ышанып ук бетмәде ана, бүген иртә таңнан алар кыз карарга барырга чыктылар. Рульдә — кияү булачак Хәйдәр...

Алар киләсен беләләр иде, көтеп алдылар. Кодагый буласы кеше, «аз-маз ярдәм итәрсең» дип, Байголның ашка-суга гына түгел, телгә дә шактый оста карчыкларының берсе булган Миңлеҗамал карендәшен дә чакырып китергән иде, йокысыз төн үткәреп, тынгысыз таңны чак-чак уздырган ике карчык, кунакларны баскыч төбенә чыгып, кулларын кушырып баш орып каршы алдылар. Ишегалдына кереп, болдыр турына килеп туктаганчы Гөлбикә машинадан төшмәде, уклау йоткан сыман туп-туры утырып барды.

Ниһаять, төштеләр, күрештеләр.

— Менә, әни, киленең Гөлсабира шушы була инде,— диде Хәйдәр, капка ябып арттарак калган кызга таба борылып. Тездән шактый түбән итәкле эре чәчәкле ачык күлмәк кигән, эре сипкелле битле, җирән чәчләрен кистереп бөдрәләткән урта буйлы кызга карап Гөлбикә мең уй уйларга өлгерде: «Усал түгелме? Мине санлап торырмы? И ходаем, ирне ир итәрме? Мал кадерен белерме?» Әмма күңелендә болардан да өстен бер генә уй иде: «Аз гына арыграк икән, каһәр суккыры!» Кодагыйга карап ул нибарысы бер уйлады: «Симергән, нәләт! Кул арасындагы йорт эшләрен дә кызына тапшырып түрдә тик утыра икән бу тәмле тамак!»

Кодагыйларның бер-берсенең җете күзләре астында ничек аяк атлауларын, ничек бусага аша чыгуларын, ничек сүз катуларын, өйгә кергәч ничек сынашуларын, дога кылуларын бәйнә-бәйнә сөйләп хәзерге заман татар карчыкларының бик күп серләрен ачып булыр иде, ләкин безнең максат ул түгел бүгенгә. Гөлбикә белән аның кодагые Миңлесорур безнең әсәрдә төп урынны тотмыйлар, шуның өчен Байголда чакта сүзне кыскартыйк әле без! Ә кыскасы шул: кодагыйлар бер-берсен ошаттылар, ошатмасалар бергә, кара каршы утырып ике самоварны екканчы чәй эчә алмаслар иде! Гайбәтче Миңлеҗамал карчык та Гөлбикәне яратты, (Гөлбикә хәйләкәр, кеүгә үк күчтәнәчләрне аңа тоттырды!). Хәйдәр кияү дә ошады аңа. Сүзе-өне юк, өстәл почмагына мыштым гына килеп утырды, әңгәмәгә кысылмады, берәр сүз кушсалар көлеп-елмаеп ике-өч сүз белән генә җавап бирде. Гөлсабира, кодагыйларның килешеп китүен күреп, кая басканын да белмәде. «Сине җиңәм мин!» дип уйлады ул кайнанасына карап. «Ә сине бөтереп кенә алам!» дип уйлады киявенә карамаска тырышып.

Аракы эчеп, тәмәке тартмый торган кияү — кыз аналарының хыялы! «Тартмыйм» диде Хәйдәр һәм Гөлсабирага карап күз кысты. Тарта иде. Тәмәкене убыр урынына ашый иде. «Әллә берәр генә чәркә тотасыңмы, кияү! Бик бәләкәйне генә?» диде Миңлесорур егетне сынар өчен. «Эчкәнем юк!» диде Хәйдәр, әллә ышанмасларын белеп, өстәп куйды: «Мин рульдә бит, әби!» Ул сыйдан баш тартты. Чынлыкта исә руль-мазар дип тормый, теләсә кайчан эчә ала, күп тә эчә, иртәннән төмерә башлаган көннәре бар, алай исерми, эчкән килеш тә машина йөртә алуы белән мактанырга гына яратмый иде.

Гөлсабираны бер генә нәрсә шикләндерде: Хәйдәрләрнең семьясы ишле иде. Ул җәһәттән дә егет аны бик тиз, аз сүз белән тынычландырды: «Бүлмәләр җитәрлек. Яңа өй безнеке. Сеңелләр китә. Энекәшләрне үйтсән, алда күз күрер. Аларны да озатырбыз».

Гөлбикә юл буе улына тукып килде:

«Әллә ниләр вәгъдә итмә, чамалап сүләш. Баргач эчә күрмә, аракы чалаган тел — дошманга ялланган тел булыр. Сатар үзеңне! Эчкең килсә, бер яртыны алдым, кайтыр юлга чыккач чөмерерсең. Бездән сер алып калмасыннар, без аларныкын алып китик!»

Кыз карау уртак фикер, уртак телләр белән тәмамланды: туйны Сабан туе тирәсенә, июнь ахырынарак билгеләделәр. «Кызымны ерак җиргә җибәрергә бер дә уйламаган идем бит!» дип шыңшый башлаган Миңлесорурны ахирәте Миңлеҗамал кече якка чакырып кертеп себерке сезз генә чабып чыгарды: «Тинтәк! Төшкән җирендә таш булсын дип теләк телә! Ахмак!» дип. Гөлсабираның яшенә ым кагып алды. Аш-су остасының чышын-пышынын бу якта да ишеттеләр, әмма куллар сугылган, вәгъдәләр бирелгән иде, аны-моны күпертеп тормадылар.

Карчыклар мыштырдаган арада Хәйдәр Гөлсабираны, чолан ишегенә терәп, коймак исе килеп торган калын иреннәреннән үбеп алды.

Кодагыйлар җылашып калдылар.

Хәйдәр бик әдәпле кыланып кәләшенә кул бирде, кыз ике куллап аның беләгенә сарылды: «Килеп йөр, Хәйдәр, берүк онытып бетермә. Саргайтырсың инде!» дип инәлде.

Егет белән кызны Хәйдәр бригадасында ике ел рәттән эшләгән студент таныштырган иде. Алар Хәйдәргә кадәр үк Байголда эшләгәндә Гөлсабираларда квартирда торганнар икән. «Алтын кыз» диде студент. «Алтын» сүзе Хәйдәрнең колагын иркәләгән иде.

Бүген менә кәләше егеткә бер дә ошамады. Авызын ныграк ерганда гына җемелдәп китә торган алтын тешләре дә ошамады, кояш яктысында кызыл кан булып күренгән алкалары да, алтын суы йөгерткән чәчләре дә ошамады. Күз карашыннан ук кәләшнең туймас җан икәнлеген

тоеп утырды егет. Иң нык ошаганы өр-яңа, нибарысы өч йөз житмеш километр узган «Жигули» булды. Бусы чын мал инде! Һәм Хәйдәр аның бердәнбер хуҗасы булачак. Үлчәү табасына салганда «Жигули» ягы баса иде.

Саубуллашып чыгып киткәч, кул болгап калган Гөлсабира белән чын күз яшьләрен чыгарган ана күздән гаеп булгач, Хәйдәр җиңел сулады, авылны чыкканчы алар бер сүз дә алышмадылар. Гөлбикә апа, бик авыр көрәшләрдә җиңеп чыккан батыр кыяфәтен саклап, кулларын тезе өстенә салып, тәрәзәдән иген кырларын, бәрәңге басуларын күзәтеп бара иде.

— Машиналары әйбәтме?— дип белеште һәм улы җавап бирмәгәч,— болай бик матур күренә икән,— дип фикерен ныгытып алды.

Әнисе белән бер уйда барулары Хәйдәргә ошамады, ул җәһәт кенә борылды да чия төсле «Москвич»ны юл читендәге куаклыкка алып кереп туктатты.

— Ай аллакай гынам, ник кердең? — диде Гөлбикә апа, як-ягына каранып.

— Чишмәсе бар, — диде Хәйдәр, янындагы сумкадан стакан чыгарып. Гөлбикә апа артыгын сорашып тормады, улының кул хәрәкәтләреннән, житдилегеннән ул барын да аңлады. Ана кеше бер нәрсәне генә белми калды: әйткәнебезчә, булачак килен Хәйдәргә бер дә ошамады, һәм хәзер, барган саен, ара ерагайган саен ныграк ошамый иде. Юк гаепләр табарга да әзер иде Хәйдәрнең ачулы җаны. Мондый чакта күңелен аракы белән генә юата торган, тынгысыз җанын исереп кенә юмаларга күнеккән Хәйдәргә бераз тамак төбен чылатып алырга кирәк иде. Ул, әдәп саклап, бер чакта да әти-әнисе янында эчми иде, бүген дә шулай итте, анасына карамыйча гына шешәне алды, ипи сыныгы белән каклаган каз кисәген бармак арасына кыстырды һәм шактый читкә китеп, каен күләгәсенә сузылып ятты. Гөлбикә апа да моменттан файдаланды, чишмәне эзләп тапты, учы-учы белән алып салкын суны кайнарланган киң битенә сипте.

Байтак югалып торды Хәйдәр, машина янына килгәндә, кулында буш шешә һәм таплы стаканнан башка бер әйбер дә юк иде.

— Кузгалыйк әйдә,— диде ашыктырмыйча гына Гөлбикә апа.

Мондый чакта улына сүз кушарга ярамаганны белә ул, белә!

— Хәзер, хәзер,— диде Хәйдәр, юл ягына күзен төндырып карап. Менә аның кашлары җыерылып күтәрелде, маңгаена эзләр сибелде, аскы ирене өскесе астына кереп качты, сулышы ешайды, борын яфраклары алланды. Ул кулындагы буш шешәне агач төбенә китереп сылады, учын тезенә ышкып алды һәм ишеккә ташланды.

— Утыр тизрәк! — дип кычкырды ул ят тавыш белән.

— Ай аллам, ни булды тагын?

— Утыр диләр сиңа! — диде, кай арада кереп өлгереп машинасын кабызырга маташкан Хәйдәр. Син ашыкканда буламыни, кабынмый гына машина, бер талпынып карады Хәйдәр, ике, газны көчәйтеп карады, ниһаять, кабынды, мотор күндәм генә эшли башлауга Хәйдәр бар көченә педальгә басты, «Москвич» ургылып алга ашыкты. Ул арада аларның борын төбеннән генә өлгергән лимон төсе кергән сап-сары «Жигули» узып китте, рульдә Мидхәт, арткы урында киерелеп, алагаем зур, калын келәм кочаклап Гөлмәрьям утыра иде. Гөлмәрьям Хәйдәрнең машинасын күрмәде, машинаны да, кашы иләмсез җыерылган Хәйдәрне дә Мидхәт кенә абайлады, абайлагач та тизләгеп арттырды. Хәйдәр исә Мидхәт машинасы артыннан ук килә торган аллы-артлы «КамАЗ»ларга юл бирергә мәҗбүр булды, шактый көтәргә туры килде. Ул асфальтка, олы юлга чыкканда сары лимон хәтсез еракка тәгәрәгән иде инде.

Сәләхетдин абзый белән Гөлбикә апа таза йөрәк биргәннәр улларына, закускасыз диярлек, бер үзенә бер яртыны эчеп бетерсә дә кулы нык Хәйдәрнең, күзе әллә кайларны күрә. «КамАЗ»ларны куып узды, башка ыбыр-чыбыр машиналарны артта калдырды, күзе алда, керфек какмый, бер төшеп, бер менеп барган дугалы асфальт юлдан җилдәй тәгәрәгән сары машинаны ычкындырмый. Вакыты-вакыты белән Мидхәтнең машинасы аның күзенә сары шайтан, гыйфрит булып күренә башлый, ул тешләрен кысып алгарак иелә төшә, газны бер көчәйтә, таучыкларда чак кына акрынаеп та ала. Юл буендагы баганалар, агачлар, каршыга килүче машиналар колак яныннан очкан ядрә кебек кенә выжлап калалар.

— Ипләбрәк, ипләбрәк! — диде Гөлбикә апа, аракы эчкән улына эндәшергә ярамаганын онытмаса да. — Ипләп!

— Ипләргә вакыт юк, — диде Хәйдәр борылмыйча гына. — Күрмәдең мени, кем узып китте мине?!

— Мирфатыйхныкылар идеме әллә алар?

— Шулар.

— Үзләренә күрә түгел тагын, алга чыккан булалар. — Гөлбикә ап үзе дә сизмәстән улын кыздырып җибәрде.

Зәйгә җитәргә тугыз-ун чакрым калганда Хәйдәрнең «Москвич»ы озын торбалар төялгән прицеплы машинаны куып җитте. Дәү «Урал» эче, күе төтенен бөркеп акрын гына үргә таба үрмәли иде. Мидхәт прицепны җайлап кына узып өлгерде, Хәйдәр килеп җитүгә каршы яктан машиналар туктаусыз агылды. Пионерлар төялгән кояшлы автобуслар узды, ялга баручыларны көньяк җылысына тәгәрәтүче җиңел машиналар үтте, йөк машиналары тоташтан үтә торды. Хәйдәр һич алга бара алмады. Ул прицеплы машина шоферына йодрык күрсәтте, әнкәсенә ишеттермичә генә суганлап-борычлап русча-татарга сүгенде. Инде, кагыйдәләрне бозып, уңнан узар иде, ул якта текә яр, текә ярлар буй-буй бетон баганалар белән читләнгән. Ирнә күперенә төшкәндә ул прицепны да, башка машиналарны да узды, әмма күз күреме кадәр ераклыкта алда да, артта да лимон төсле «Жигули» юк иде. Ул як-ягына каранды, урман, болын юлларына күз салды, әмма Мидхәт бер җирдә дә күренмәде. Ул тезенә йодырыгы белән авырттырып китереп сукты:

— Уздылар! — диде теш аралаш. — Утырганда син мыштырдамасаң алга чыгармый идем мин аны!

— Аларның машинасы яхшырак худлы мыни соң? — дип сорады Гөлбикә апа бераздан.

— Юлы бит, машиналар чебен урынына оча! — диде Хәйдәр алдагы юлдан күзен аерырга да куркып.

Аларның Зәйдә йомышлары юк иде, үзәк урамнарга кагылып та тормадылар, арткы аулак урамнар аша узып Язкилдегә кайта торган юл башына чыктылар. Азык-төлек кибете алдына туктаган сары лимонны икесе дә берьюлы абайлап алды.

— Әнә ич алар!

Гөлмәрьям апа кыймшанмыйча да үз урынында утыра иде, ниндидер бәләкәй төргәк тотып кибеттән чыккан Мидхәтне күргәч сикереп үк алды:

— Әнә чыкты!

«Москвич» сары «Жигули» янына ук килеп туктады. Мидхәтнең авызы ерылды, кысыграк күзләрен тагын да йома төшеп:

— Я, ничек Хәйдәр, куып җитеп булдымы? — дип эндәште.

Машина эчендә җәелеп утырган Гөлмәрьям апа аяк астына салынган киртләчләрен селкетеп көлә башлады.

Ах, шул сүзләреңне әйтмәгән булсаңчы, Мидхәт!

Көлмәгән булсаңчы син дә, Гөлмәрьям апа!

Әмма эш узган — сүз телдән ычкынган, майлы иреннәрдән көлү гөрләп чыккан иде. Мидхәт сүзләре Хәйдәрне җәберсетсә, Гөлмәрьямнең бер дә юктан көлке чыгаруы Гөлбикәгә бер дә, бер дә ошамады.

— Яхшы,— диде калайланган күзләрен елтыратып Хәйдәр.

— Яхшы ук түгел инде! — дип үртәште Мидхәт.

— Үз юлыбызга чыгыйк! Карап карарбыз! Кем кемне!

— «Москвич»ның «Жигули»ны куып узганы юк, белмәсәң бел!

— Минеке уза!

— Юкка мәтәштермә, Хәйдәр.

Сәләхетдин Хәйдәрен тыярлык түгел иде хәзер, ярсуыннан кулларын кая куярга белми, йодрыгы белән тез башларын туктаусыз төя иде.

Кайтыр юлга бергә диярлек кузгалдылар. Мидхәт жай белән генә алга чыкты.

— Бәйләнмә шул юләргә! — диде Гөлмәрьям.

— Бәйләнмим, үзләре сагыз кебек ябышалар,— диде күңелсезләнеп Мидхәт. Хәйдәр белән сүзгә килүнең яхшылык белән бетмәслеген ул бик яхшы аңлый иде. Машиналар бер-берсенә тагылып диярлек Зәй-Сарман трактына чыктылар. Ирнә күперен үткәч Хәйдәр Мидхәтне куып узды һәм бераз баргач машинасын юлга аркылы куйды. Машинасыннан төште һәм кулын изәп Мидхәтне үз янына өндәде.

— Хәзер сынашабыз, — диде ул юлга карап. — Аулак. Юлны әйтәм, машиналар күренми.

— Кирәкми, күрше,— диде Мидхәт бәхәсне йомшартырга теләп. — Син салган.

— Салса ни? Син салмаганмы?

Күршесенең оятсызлыгына Мидхәтнең дә ачуы чыкты.

— Салсам да бусма сеңдерәм, синең шикелле шыр тилереп йөрмим,— диде ул дорфаланып.

— Шыр җибәрдеңме?

— Юк. Курыкмыйм. Куышмыйча да бик яхшы беләм...

— Беләсең, әбиеңнең келәсен!

— Куып житә алмыйсың?!

— Узып та китәм!

Мидхәт аракыны әле генә эчеп чыккан иде, Хәйдәр тирләгән кайнар кулы белән аның иңбашына ябышкач, аның ачуы артты, ул күршесенең кулын иң хәрәкәте белән кагып төшерде.

— Бәйләнмә, егет!

— Бирәләсеңме?

Аракы парлары Мидхәтнең кан тамырларына йөгерде:

— Ну что ж, — диде ул, — тик энеенне төшереп калдыр.

— Калдырмыйм. — Хәйдәргә хәзер ни әйтсәләр дә каршы төшәргә әзер иде ул.

— Что ж,— дип кабатлады Мидхәт. Бераз кәгеп алса, кызлар янында һәм базарда ул гел русча сөйләшә башлый. — Пеняй на себя!

Хәйдәр юлга аркылы куйган машинасына таба атлады.

— Әни,— диде Мидхәт, ишеккә иелеп. — Син төшеп мине шушында рак көтеп тор. Бу йолкыш этәчне акылга утыртыйм инде. Узам да хәзер үк сине алырга борылып киләм.

Гөлмәрьям, улы сүзенә буйсынып келәмен кочаклап машинадан төште дә дәү әрекмән төбенә барып утырды.

Хәйдәр дә энисенә шыпырт кына эндәште:

— Әллә син дә төшеп торасыңмы?

— Юк,— диде кабарынып Гөлбикә.— Шул карачкының келәм кочаклап утырганын карап торыйммы, ходавәндәм. Син узарсың!

Ишетмәсәң ишет, я хода. Гөлмәрьям күршесе «карачкы»!

Сез иштеттегезме, хөрмәтле укучым? Бу хурлык тамгасы, яман сүз мине үткән гомергә кайтарды, улларым Мидхәт һәм Хәйдәр белән мавыгып, без аларның газиз әнкәләре Гөлмәрьям белән Гөлбикәне бөтенләй онытып бетергәнбез! Ярамый, һич тә ярамый! Шашкын куышу башланганчы аз булса да аналарның күңел пәрдәсен күтәреп карыйк.

Бүген авыз тутырып әйтергә дә уңайсыз, әйтми калырга да ярамый, ышанасызмы-юкмы, заманында Гөлбикә белән Гөлмәрьям ахирәт дуслар иде. Әйе, әйе, җырларда мактала торган, телләрдән-телләргә күчеп йөри торган чын дуслар иде алар! Берсе Түбән оч кызы, икенчесе Олы урамда туып үссә дә, сабый чактан ук гел бергә булдылар — курчаклы уйнадылар, тәтәй җыйдылар, бишташ чөйделәр, качышлы, әбәкле, арка кагышлы, пиштиле уйнадылар — азмы матур уеннар бар иде атаклы Зәй ягының Язкилде авылында! Барын да уйнадылар Гөлмәрьям белән Гөлбикә, аерылмас тату дуслар, ишегалларында, тар тыкрыкларда бәббкә-чебиләр белән бергә аунап, песи борчагы, карга борыны ашадылар, ындыр артларына чыгып шепкән удылар. Берсе агач букча, икенчесе киндер букча асып беренче класска җитәкләшеп барып керделәр. Язларның берсендә, иң ягымлысында, иң татлысында, Олы су ташып, тынып, ярларына кайткач, яр битләренә сап-сары кимәшә башлары чәчәлеп утырганда, сандугачлар кунган талларда бәрмәнчекләр — тал песиләре чәчәккә әйләнгәндә бәби итәкле матур күлмәкләрен киеп беренче тапкыр су буена уенга бергә төштеләр.

Югары очта ике дус, ике яшьли дус үсә иде. Беренчесе Сәләхетдин, икенчесе Мирфатыйх. Шул язда, шушы җәйдә алар көлешә-көлешә янәшә кайткан, иңбашларын сикертеп атлаган Язкилде чибәрләре Гөлбикә белән Гөлмәрьям артыннан иярделәр. Әй кызык та иде ул чаклар! Кызлар кайта алдан чыкы-чыкы, Мирфатыйх белән Сәләхетдин аларга якынаерга базмыйлар, бигүк артта да калмыйлар.

Күк гөмбәзе чамасыз биек, йортлар-агачлар саф көмештән коелган, аяк асты йомшак чыклы чирәм, урам-тыкрыкларга хуш исләр кереп тулган. Ямьле Олы су буенда һаман уен бара, бишле биниләр, җырлыйлар, «Кыз алыш» уйныйлар. Анда олыраклар, парлылар калды. Гөлбикә белән Гөлмәрьямнең дә адымнары җиңел, сулышлары иркен, йөрәкләр беренче тапкыр дөп-дөп тибә, күңел кытыклана, гел көләсе килеп тора. Чөнки алар артыннан үсмер егетләр килә! Икәүләшеп абына-сөртенә юрттыралар! Борылалар да чыкы-чыкы киләләр кызлар, борылалар да пырхылдап көлеп җибәрәләр. Гөлбикә кыюрак:

— Әй, малайлар, бозавыгыз кайтмадымы әллә? — дип эндәшеп алды.

Бу сүз генә малайларны кыюландырмады, алар да көлештеләр, тик якынаерга базмадылар.

— Әниләре эзләп чыгып, ярып алып кайтыр әле менә,— дип ахирәтен куәтләде Гөлмәрьям.

— Ярырлар менә! — Ике үсмер тып та тып басып алар янына чабып килде, ай нурында күзләрен елтыратышып байтак тик карашып тордылар...

Ике егет гел бергә, ике дус кыз да бергә йөриләр... Беренче мәхәббәт хатын да алар икесе исеменнән ике егеткә атап яздылар. «Без сезне сөябез!» дип хат ахырында чуклы чәчәкләр арасына җырлар өстәделәр.

«Без сезне сөябез!»

«Без дә!» диделәр малайлар һәм ахирәт кызлар белән очрашырга җай гына эзләп йөри башладылар. Кульяулыкларны бергә чикте кызлар, егетләренә дигән ак пирчаткаләрне бергә бәйләделәр, киндерне алмаш-тилмәш бер станда суктылар, бергә тукмадылар. Кияүгә диган бирнәләре дә бер төсле иде аларның, туй бүләкләре дә. Туйны да икесе бер җәйдә, атна аша гына уздырдылар, башта Гөлбикәнекен, аннан

Гөлмәрьямнекен. Икесенең бер очка, күрше киленнәр булып төшүләренә чиксез куандылар. «Бергә гомергә!» дип җырлар җырладылар...

А-а, беренче тапкыр су юлын үтүләр!..

Беренче мунчалар, йокысыз төннәр, татлы таңнар... Сөйләшергә уңайсызланганда ярты ымнан, күз карашыннан, кул хәрәкәтеннән бер-берсен аңлый иде яшь киленнәр, бөтен Югары очны, Олы су буйларын яңгыратып рәхәтләнеп көлешә торганнар иде. «Киленнәр төште, очыбызга ямь керде!» дип куанып, ходайга рәхмәт укыдылар Сәләхетдин белән Мирфатыйхның әтиләре.

Тамак туйгач кына кашыкның нинди икәнен карыйсың...

Ике гаилә арасындагы мөнәсәбәтләрнең ничек һәм кайчан чатнавы турында мин алданрак сөйләп узган идем инде. Ирләр арасындагы дошманлык бер төсле булса, хатын-кыз арасында туган дошманлык меңгә төрләнә, миллионга тармаклана.

Кыскасы, кайчандыр, моннан байтак еллар элек ахирәт дуслар булып йөрешкән ике хатын арасына бүген якын барырлык түгел! Элек ак алъяпкыч ябынып, чәчләрен талир тәңкәләр белән бизәп, йөгерә-йөгерә Олы судан кайтып килгән кыйгач кашлы, нәзек билле Гөлбикә белән хәзер машинада күперен, ачуыннан кабарынып утырган юантык хатын арасында җир белән күк аермасы бар инде! Әрекмән күләгәсендә ачы, зәһәр игле тирен сөртеп, аяк очындагы келәмнән күзен алмыйча утырган җингәчәйне дә элеккеге Гөлмәрьям дип әйтү мөмкин түгел иде. Икенче хатыннар иде инде болар, «шайтан токымнары» иде...

Шулай итеп, ярыш башланды!

Зәй-Сарман юлы такыр, чия төсендәге «Москвич — 412» белән сары лимон кабыклы «Жигули» берьюлы диярлек алга ыргылдылар. Авызы чалшайган, теше ырҗайган Хәйдәрен күреп Гөлбикә ап-ак булды, үзенең хәвефле эшкә тарыганын тирәнтен үк аңлап алды, кан качкан иреннәре белән «ләхәүләләсен» укыды. Хәйдәрне туктату турында уйларга да, өметләнергә дә ярамый иде. Машиналар юлны илләп бертигез дәрәҗәдә шактый ара уздылар. Аннары тигезлек югалды, әле берсе, әле икенчесе улап-ярсып алга чыкты. Моторлар тыелгысыз гүләде, тәгәрмәч шиннары әллә нинди авазлар чыгарып чиңадылар, як-якка вак чуер ташлар сибелде, сыек тузан күккә күтәрелде. Спидометр уклары туктаусыз уйнап, сикереп торды.

«Узам!» диде тешләрен кыскан Мидхәт.

«Уздырмыйм!» дип пышылдады иңак сөякләрен сынар дәрәҗәгә җиткереп кыскан Хәйдәр.

Машиналар бер-берсенә тия язып калалар, ике арада зәңгәрсу очкыннар сибелә. Әмма урта юлга ерак та калмады. Хәзер озын гына үр төшәсе... Хәйдәр Мирфатыйх тиинтәген шунда калдырырга тиеш. Икесе дә салмыш, икесе дә ачулы, икесенең дә күзе тонган, алар юл читендәге «юл төзәтү эшләре бара!» дигән язуны да, чекрәеп торган тамганы да күрмәделәр. Очып диярлек барган шәйкә ике машина икесе дә казылган җиргә борыннары белән барып төртелделәр.

Чия төсендәге машинаның дүрт ишеге дә урыныннан каерылып чыкты, арткы ишеккә тотынган Гөлбикә апа эчтән суырылып чыгып әллә кая читкә очты, Хәйдәр маңгае белән ал пыялага килеп сыланды, машинасы капланды... әйләнеп аякланды, тагын капланды һәм... дүрт тәгәрмәченә утырып, канауда янтаеп туктады. Мидхәтнең лимоны капланмады, ян белән бераз шуып барды да таш өеменә килеп сыланды.

Өчесе дә исән иделәр.

Юл тузаны утырып та өлгермәде, канау артыннан Гөлбикә апаның сыкраган тынкыш тавышы ишетелде:

— Кулым, ай кулым! Үләм!

Хәйдәр дә исән иде исәнен, маңгае ике җирдән каз күкәе хәтле булып шешеп чыккан, яңагы тирән җәрәхәтләнеп канга манчылган, күкрәк

капкачы яньчелгән иде. Ул машинасыннан чыкты да, иелеп кан косты, авызын ачу белән сөртә-сөртә машина ишекләрен жыярга тотынды, соңгы ишеккә ябышып яткан гәүдәне күргәч кенә әнисе барлыгын хәтеренә төшерде.

— Әни, син монда мыни?

— Кулым, беттем! — дип өзгәләнде ана.

Гөлбикәнең кулы сынган иде. Аннан-моннан бәйләштереп, яньчелгән ишекләрне машинага төягәч Хәйдәр моторны кабызып карады, машина йөри, ул үз ходында иде!

Хәйдәр «ишекләр харап булды» дип йөргән арада кысыла-кысыла Мидхәт тә көнгә чыкты. Аны танырлык түгел — бите-күзе кан, иреннәре умырылып... Машинасының уң ягы яньчелеп эчкә кергән, пыялалар ватык, бензин багы кабартмага әйләнгән... «Шартламаса гына ярар иде!» дип куркынды Мидхәт һәм Зәй ягына борылып карады. Күз кабаклары шешенгән иде, ул кәләмен күтәреп тыр-тыр йөгереп бирегә килүче әнисен күрә алмады. «Әле дә ярый аны утыртмаганмын», дигән уй да килеп китте аның зыңлап торган башына. Шул чагында Хәйдәр көндәше янына килде. Сары лимон йөгерекнең ни хәлгә төшүен күргәч эчен уып хихылдарга тотынды.

— Ничек? Уздыңмы? Уздыңмы, ә?! Ха-ха-ха!

— Ертык тишектән көлә, — диде Мидхәт, иреннәрен кулы белән тота-тота.

— Минем машинага чурт та булмаган, менә син ничек кайтырсың?!

— Хәйдәр,— диде Мидхәт.— Бар, минем әнине генә алып кил. Ул анда коты чыгып ятадыр. Я йөрәге ярылып үләр.

Хәйдәр әнисенә карады.

Иөзен чыткан Гөлбикә башын селкеде.

— Иөрмә, тизрәк бульнискә кайтыйк. Чыдар әмәлем юк. — Һәм тоташ уфылдарга, ыңгырашырга кереште. — Ай, үләм! Үләм! Бетүләрем шушы икән...

Хәйдәр бик кызганган төс белән кулларын җәйде.

— Синең анаң теркелди, минем әнине тизрәк апкайтырга кирәк,— диде ул. Ишекләрне арткы утыргычка төяделәр, Гөлбикә апа бу юлы алга, улы янына утырды.

— Нгытып ябыш! — дип боерды Хәйдәр.

— Берүк акрын кайт,— дип ыңгырашты яралы ана.

— Әнине барып ал әле, ди тегә. Анда барып йөрерлек ди безнең хәл! Инспектор-мазар күргәнче тизрәк авылга сызыйк димн!

Һәркемнең үз кайгысы, Гөлбикә апа тезенә сыгылып төшә дә «ай, кулым! Сынык кул белән ни хәлләр итәрмен? Туйда, кодагыйлар алдында ничек күренермен?!» дип хафалана. Хәйдәр аны ишетми дә, үз-үзенә сөйләнеп кайта.

— Да-а... Төзәткән хәлдә дә яңа булмый инде ул! Мондый ук буяуны каян табасың?.. Энекәшләргә калыр бу машина.

— Үзең җәяүгә калырсыңмы?

— Гөлсабира яшәсен!

Хәйдәрнең өйләнү, өйләнмәве нәкъ шушы урында, шушы минутта хәл ителде. Чия төсле машина эчендә җилләр уйнамаса, белмим, кияүле була алыр идеме икән Байголның сазаган кызы! Тегесен дә, моның да кат-кат үлчәп, чамалап караганда Хәйдәрнең күңеленә шик-шөбһәләр килеп киткәнен бая ук әйтеп узган идек инде. Икеләнүләр тиз онытылды, күз алдында балкып торган машинасы янында алтын нурларга күмелеп Гөлсабира гына җемелдәп калды.

Түбән авыл кешеләре Хәйдәрне, аның дүрт ягыннан җил узып йөргән йөны коелган ала-кола машинасын күргәч, бармак белән төртә-төртә, күзләре белән карый-карый көлә башладылар.

— Ни булды?

— Юл бит... Булды инде,— диде Хәйдәр.
— Кыз урларга барган җирдән кыйнап кайтарганнар!
«Ну бу авылны!» диде ачуына буылып Хәйдәр һәм Вәзиләне хәтерләде: «Дөрес сөйли сеңел! Качарга кирәк моннан!»
— Бетергәнсең машинаңны!
— Гөл итәм әле мин аны! — дип мактанды Хәйдәр.
Машинаны һәр җәһәттән җентекләп карап, әллә никадәр сүзләр сөйләшкәч кенә, кешеләрнең күзе Гөлбикәгә дә төште.
— Бәй, әниең дә монда икән ич! Ни булды аңа?
— Аз-маз кан түктек әле!
Көч-хәл белән больница ишеге янына барып җиттеләр. Гөлбикә апаның чыраена үлем сарысы йөгерде, иреннәреннән кан качты. «Үләм» дип ыңгырашты ул. Хәйдәр ике куллап тотып, күтәреп диярлек әнисен баскычтан менгерде, ярымкараңгы коридорга барып керделәр, ике дә атламадылар — ак ишектән чыгып килүче бер кеше белән бәрелешә яздылар. Ир кеше ахылдап алды, юньләбрәк карасалар, чыгып килүче Сәләхетдин үзе икән бит. Хәйдәрнең әткәсе. Гөлбикәнең газиз ире...
— Нишләп йөрисез монда? — диде ул кырыс кына.
— Ә син, әткәсе? Ничек болай? — дип иңрәде Гөлбикә.
— Егылып сул кулны сындырдым.
— Ә?! — диделәр ана белән ул бер авыздан.
Аннары өчесе дә бер мәлгә шашып тынып калдылар.
— Әнинең дә кулы сынды. Юлда капландык. Ике тапкыр тәкмәрләдек. Әле дә ничек исән калдык,— дип аңлатты Хәйдәр ашыга-ашыга.— Сул кулы...
— Ходай саклады инде,— дип үксергә кереште Гөлбикә.
Әле генә уң кулын гипслап Сәләхетдин чыккан бүлмәгә күз яшьләре белән битендәге кан тапларын юа-юа, ыңгырашып, ыңгырашу арасына дөньясына, шушы каһәр суккан шайтан арбаларын уйлап чыгарган галимнәргә, машиналарны авылга кайтарып саткан кибетчеләргә ләгънәтләрен кушып укына-укына Гөлбикә кереп китте.
Бер кичтә аларның икесен ике палатага больницага салдылар: Сәләхетдин ирләр янында сыйды, Гөлбикә апаны хатыннар палатасына арба белән тәгәрәтеп алып керделәр.
Хәйдәр машинасын Язкилде авылына куды, бер урында да ут янмый иде, төн дә караңгы, күзе дә күрер-күрмәс дәрәҗәгә җитеп шешенгән иде. «Гөлсабира яшәсен!» дип уйлады егет. Алдагы тормышның бар якты хыяллары хәзер Байголның сүзгә саран, әмма машиналы кызы белән бәйләнгән иде...

## 9

Рәвешен китереп, җиренә җиткереп тозласаң кыяр да бик ләззәтле, бик тансык аш була бит ул, хөрмәтле укучым! Искиткеч тәмле була ул!
Бу эштә безнең Зәй якларында, бигрәк тә Язкилдедә Сәләхетдинне уздыра алган кеше юк. Менә ул тозлаган кыярны авыз итеп карагыз сез... Дөнья бәһасе торырлык итә бит шул тавык җимен! Ул тәсе, ул исе, елның кайсы вакытында табынга куйсаң да бүген түтәлдән өзгән сыман кештердәп тора аның тозлы кыяры! Бер чакта да уртасы куышланмас, җебемәс, болай да тәмләп ашарга була, теләсәң салатка куш, теләсәң рассольникка тура, кайда да йөзгә кызыллык китерәчәк түгел.
Авылы-авылы, ягы-ягы белән бит ул; бер авылда бәрәңге шәп үсә, ярмаланып, ап-ак булып, ярылып-ярылып тора. Икенче авылларның мактанычы — суган. Алтын шарларны үреп-үреп келәтләргә асып куялар да, үзләре дә шаккатып, әйтерсең берьюлы чыккан мең кояшка сокланып карап торалар — бигрәкләр дә матур була инде шул эре суган

бавы! Өченче берәүләр шалканны шәп үстерә, татлы, сусыл итүнең серләрен белә. Язкилде авылының мактанычы — кыяр.

Татарлар да яшелчәнең тәмен белә башладылар. Әле сугышка кадәр генә, «бәбәйләсе хатын тәпсерли», дип, агач җамаяк тотып, күрше рус авылына тозлы кәбестәгә яки якын-тирәдәге керәшен авылларына гөмбә-гөрәҗдәгә китәләр иде. Тозлы кыяр эзләп әллә кай җирләргә баралар, күз күрмәгән бәһаләр түли иделәр. Шөкер, хәзер яшелчә үстермәгән авыл юк, яшелчә яратмаган кеше калмады, яшелчә табын түрендә, ашка кишер, кәбестә турыйлар, салат ашыйлар, ике-өч буын узу белән безнең халыкта да кәкре аяклар, кыска ботлар бетеп, озын аяклы, озын торыклы адәмнәр килеп чыга башлар, зифа буйлылар күбрәк булыр!

Ашыйлар икән — кирәк! Кирәк икән — кемдер үстерергә тиеш. Файдасы күп, мәшәкате дә җитәрлек яшелчәнең. Үстерә белергә кирәк, әмәлен табарга!

Сәләхетдин абзый газетадан бер фельетон укыган иде. (Инде сүз уңаеннан гына Сәләхетдин абзыйның бары тик һава торышы турындагы һәм фельетоннарны гына укуын әйтми китмичә ярамыйдыр шәт?!) Имеш, бер отставкадагы полковник шәһәр янындагы калдык-постык чокырлар арасыннан алты сутый җир кистереп ала да, киртәләп, бер ел эчендә аны тигезли, ашлый-ашламалый, икенче язда бакча тутырып торма чәчә. Ачы торма. Редька ди аны руслар. Ашлаган яңа җир, елы да килә, торма да шул кадәр шәп булып, эре булып, тигез булып өлгерә ки, әлеге абзый уңышын базарга алып чыкса, бөтен кеше ах итә! Хуҗа да күрә, монын товары базарда бер! Торманың килосын башкалар егерме биш тиеннән сата, ул тота да унбиш тиеннән сата башлый. Башка сатучылар кычкыралар моңа, үртиләр, «юләр, тинтәк» диләр, сукраналар, ә монын мыегы да селкенми, сатуы сату, үлчәү табасы биеп тора, кулы-кулына йокмый. Кая ул, башкаларның тормасына әйләнеп караган кеше дә юк, моның тормасын чират торып, талаша-талаша, мактый-мактый алып та бетерәләр. «Тагын юкмы?» дип уртадан чыгармый торалар. Икенче көнне нишләсеннәр, базарның хокукы зур, бөтен базар ничарадан-бичара, теге абзыйны сүгә-сүгә торманың бәһасен унбиш тиенгә төшереп сата башлый. Ул арада торма төяп тагын теге абзый килеп җитә, базар бәясен белешә, һәм бик шәп торманы ун тиеннән сатарга тотына. Ун тиен! Әйдә кил, ал, сөен! Тормасы шәп, бәясе юнь, моның товарын күз ачып йомганчы алалар да бетерәләр.

Башкалар — тормаларын мактап тамак карлыктырганда, абзыем куен кесәсен калынайтып кайтып та китә. Нишләсеннәр бичара сатучылар, иртәгесе көнне болар да килосын ун тиеннән сатарга мәҗбүр булалар. Тагын теге «юләр» килеп җитә һәм беркемнән белешеп тә тормыйча товарын сигез тиеннән сатарга тотына. Җире алты сутый, торма уңган, шартлап тора, кабыгы юка, әрчесәң ачысы чәчрәп күзгә кереп тора, юк итәләр моның товарын, базар торманы ялмап йота... «Менә мәрхәмәтле бәндә, менә яхшы бәндә, урынын оҗмахта булсын», дип мактый-мактый алалар торманы. Кыскасы, торма бәясен биш тиенгә төшерә...

Икенче язда́ якын-тирә авылларда берәү дә торма чәчми, «әй, диләр, килосын биш тиеннән сатып җәфаланганчы лутчы мин кыяр утыртам, яки кишер чәчәм!».. Теге абзый тагын алты сутыен тутырып торма чәчә, вакытында тырмалый, вакытында сукалый, вакытында ашлама бирә, тагын котырып үсә, уңа торма һәм берзаман, көне җиткәч, хуҗа уңышны базарга төяп алып чыга. Торма беркемдә юк, базарында бер! Ә бәһасе? бәһасе... килосы бер сум! Бер сум! Сатып алучыларның авы-

зыннан су килә, бәһасен ишеткәч күзләре тона, яныйлар тегеңә, «өеңә ут төртербез», диләр... Нишләсеннәр, сатып алалар! Ә яшелчә сатучылар телсез кала! Көчләп сатмый бит ул, көчләп такмый, көлемсерәп тик тора. Бер сум тек бер сум! Базар бәяне үзе билгели, кодрәте зур. Кирәк торма, салатка да кирәк, бәбәй табарга җыенган хатынга кирәк, авыруга да кирәк, һәммәсенә тансык!

Кара көзләргә кадәр килосын бер тәңкәдән сата бу, сатып бетерә.

Икенче язда бөтен тирә-як шашып-шашып торма чәчә, ә булган хуҗа алты сутыен тутырып кишер белән кыяр утырта. Өченче елда кәбестә үстерә... Үзегезгә мәгълүм инде, базарда кыяр запастагы полковникта гына була. Яки кишер аңарда гына... Менә шулай.

Сәләхетдин бу фельетонны кат-кат укыды, кисеп алып иң кадерле кәгазьләре янына сандыкка салды. «Юк, торма үстереп акча җыйган абзый дурак түгел, моны язып аны тәнкыйтьләргә тырышкан журналист юләр!» дип уйлады Сәләхетдин. «Әгәр безнең авыл хуҗалыгында шундый йомыры башлар утырса, шундый киң илебездә, шундый-шундый җиребез барында без берчакта да яшелчә, җиләк-җимеш җитми дип зарланмас идек!»

Сәләхетдин үзен йомыры башлы дип саный иде.

Югары очлар кишер чәчә, кыяр утырта, кара яздан парник ясап, тирес ташып чиләнәләр. Кәбестәсен әз-мәз үстерәләр, помидорны да читкә куймыйлар. Теге газетадан соң Сәләхетдин абзый төп игътибарны кыярга юнәлтте. Аның да тозлысына. Яшел кыяр бөтен кешедә дә бер чамада өлгерә, базарда бәһасе юнь, озак саклана торган товар түгел, хәзер шиңә, саргая башлый... Иллә мәгәр тозлы кыяр башка! Бәрәкәт белән генә сатсаң кыш буена җитә, бәясе югалмый, торган саен арта гына бара. Һәр көздә өч-дүрт мичкә кыяр тозлый башлады Сәләхетдин. Соңгы ике мичкәне Сабан туенда гына ача, бәйрәм тирәсендә, ишле кунак кайтканда, рәхәтләнеп, аяк терәп, кешенең күзенә карап кыярына теләгән бәясен сорый ала иде.

«Әмәлен белергә кирәк!» — Сәләхетдин белән Гөлбикәнең яраткан сүзе.

Сәләхетдин абзый бик ерактан башлады.

Олы су башы урамыннан, көн озын якты кояш караган тауҗыктан йөзьеллык бер имәнне сайлап алды. Аулак чакта Хәйдәр белән шуны аударды. Кеше-кара юкны чамалап өенә ташыды. (Өе Югары очта, каян, кайчан кайтып кересең — беркем белми кала!) Имәнне метрлап турады. Бүкәннәрне сигезгә ярып күләгәдә, талгын җил күчеп йөргән җирләстә генә киптерде. Аннан мичкәгә ярарлык итеп яра башлады: кабаланмыйча, һәр ярканы йөз кат әйләндереп карап, агачның юнәлешен, сызыкларын җайлап кына ярды. Пычкы тартырга беркемне чакырмады, берүзе маташты. Имән өлгеләрне, төплеккә яраклы кисәкләрне мунчага кертеп парда тотты. Суда яткырды, киптерде. Инде кәмәленә кертеп һәр өлгене тигез итеп юнды, ышкылады, пыяла белән шомартты. Хуш ис аңкытып торган имән өлгеләрне мичкә итеп тезгәндә җырлап җибәрде... Тезде, кыршаулады, төпләде... Иң актыктан мичкә эченә эрегән кайнар балавыз йөгертте. Кыяр өлгереп килгән көннәр иде. Шуннан гел бертигез генә, бер чамадарак таза кыярларны өзеп сап-салкын чишмә суы белән яхшылап юды, корытты һәм зур тас белән мичкә янына тартып китерде.

Иң әүвәл мичкәнең балавызланган төбенә бер кат итеп кара карлыган яфрагы түшәде. Яфракларның да бозыгын түгел, ям-яшелен, тазасын, куырылмаганын гына өзде. Яфрак түшәк өстенә вак-вак туралган сарымсак бүлкәләрен сибеп чыкты. Шуннан соң гына бер-берсенә тидереп, әмма иркен ятырлык итеп кыяр тезде. Кыярлар кукуруз тешләре төсле тигез тезелешеп, матур булып яттылар. Аның өстенә Сәләхетдин абзый ваклап тураган укроп сипте, чия, имән яфрагы аралаштырды.

Сарымсак өлешләрен гел кушып торды. Астагылары күмелгәч тагын бер рәт кыяр түшәде. Бу юлы арага алдан ук әзерләнгән имән шакмаклар да кыстыргалады. «Имән тәме кыярга сеңә, чир-чордан саклый», дип аңлатты ул читтән генә карап торган хатынына. (Олы, җаваплы эшләрне Сәләхетдин бер чакта да хатын-кызга ышанып тапшырмый иде!) Мичкәне шулай җентекләп тутыргач, ул ике тапкыр иләк аша үздырган тозлы су агызды. Кыярлар яфраклар, имән шакмаклар арасында язга тиклем утырырга тиешләр иде.

Көзге бәйрәмнәрдә беренче мичкәне Биш авыл базарына алып чыктылар, бик әйбәт узды. Ике мичкәне курка-куркарак җәйгә калдырганнар иде, Сабан туй алдыннан баздан чыгарып ачып карасалар исләре китте: кыяр яңа гына түтәлдән өзеп алган кебек нык һәм тәмле иде. Сәләхетдин абзый мичкә тирәли бот чабып йөрде: «Һай, да рәхмәт полковникка! Һай да рәхмәт газетчыга! Өйрәттеләр бит хәйләгә!»

Сәләхетдин кыярының даны китте.

Базарында ул бер иде. Кайчан чыкса да бер. Башкалар да аның сыман кыландырып карыйлар, кыяр урынына базарга тоз боламыгы гына алып чыгалар: куышланып, мыңгыланып беткән апыра исле кыярларны күргәч сатып алучылар, танауларын тотып, Сәләхетдин янына чиратка йөгерәләр.

Кыскасы, биш-алты ел эчендә Сәләхетдин күрше Биш авыл базарында гына түгел. Зәй, Сарман якларында да атаклы кыярчы булып танылды. Бер елны да аның уңышы зарарланмады, кыярына шадра, тап төшмәде, елдан-ел әмәлен күбәйтә барып ул үз эшенең остасына әйләнде.

«Аның бит мең төрле сәбәбе бар! Мичкәгә дигән имәннең кайсы тауда үсүенә кадәр шарт! Кояшлы якта үскән имән кирәк. Шуннан башлана ул. Аннан ары тагын мең шарты бар!» дип куя иде ул аерата кәефе килгән төннәрдә хатынына. «Тик аны кешегә белдерергә генә ярамый!»

Байлык белән саранлык килә. Саранлыкка сүзсезлек ияра.

Шуннанниләр булганын, йортка ниләр кайтканын сез беләсез дә инде, кадерле укучым! Сәләхетдин, Гөлбикәләр турында, аларның Мирфатыйхныкылар белән ничек яшәүләре турында без аз сөйләшмәдек.

Сәләхетдиннәр йортында кыяр — патша. Кыяр — культ. Әгәр Язкилде адәмнәре борынгы графлар кебек үз гербларын булдырсалар, Сәләхетдиннең герб уртасында, кытыршы яфраклы яшел кыяр чәчрәп торыр иде! Кыяр түтәлләре арасына бала-чагадан беркем керми. Рөхсәт юк. Кыяр бакчасына ялгыш-мазар тавык-чеби керсә, өйдә җәнҗал, талаш! Кыярны Сәләхетдин оста үзе җыя. Иплэп кенә, чүгәләп кенә өзә дә бәби биләгәндәй киндер алъяпкычына тутыра. Кыяр тозлаган көн— бәйрәм көн. Шулпалы бәлеш пешә андый көнне, Гөлбикә апа чолан сандыгыннан «чистай малайларын» берәм-берәм кертеп тора. Кыяр җирен көздән үк карыйлар, йомшарталар, ашлыйлар, өф итеп кенә тоталар...

Ә язның үз мәшәкатьләре. Кыярны соңгы кыраулардан сакларга, суны таманча гына сибеп, һәр төпнең үсүен күзәтеп, билгеләп торырга кирәк. Һәр төпне!

Су!

Йортта кое бар, тик аның суы каты. Сәләхетдиннәр кыярга суны Олы судан алып кайталар, җәй буе шуннан ташып сибәләр. Бала-чага, олылар — һәркем үзенә куелган норманы үтәргә тиеш. Балалар унар чиләк ташыса, олыларга аннан да күбрәк төшә. Ялгашлар тула, кисмәкләр тула, кәстрүлләр тула, лакан да мөлдерәмә утыра. Су җылына, аны кичке яраударда, көн сүрелгәч, кояш баер-баемаста саклык белән генә, бер яфрак та изелмәслек, бер сабак та сынмаслык итеп, җентекләп кенә сибәләр. («Әгәр кыярның бер яфрагы гына сытылса да аның җимешен тозларга ярамый, бозыла һәм мичкәне боза!»)

Су!

Су ташу газап. Элегрәк елларда малайлар әтиләре күрмәгәндә ялгашларга кое суы тутырып куярлар иде, әмма Сәләхетдин зирәк, бармагын чылатып чәчен сыпырып кына карый да ялгашны тибеп аудара: «Үтерәм!» Хәзер андый хаталыклар кабатланмый, кыярның тормыш тоткасы икәнен балалар да белә.

Су!

Ниһаять, Язкилде авылына да су килде — водопровод үткәрделәр, һәр ун йорт исәбеннән бер колонка куелды, чык та чыжлат чиләгеңне! Син бөереңә таянып күккә караган арада тула да куя! Идәнеңне ю, малга эчерт, мунчаңа ташы! Көмештәй су, урман чишмәсеннән килә, эчәргә татлы, юынырга йомшак. Рәхәтләнде Сәләхетдин кыярлары! Хәйдәр оста егет, каян тапкандыр, ничек юнәткәндер, бер машина тимер торба кайтарып аударды. Чокырны җыйнаулашып казыдылар. Шулай итеп Сәләхетдиннекеләр суны ишегалдына ук үткәрделәр. Мунчага да керде су, бакчада да кран бар: бор да тор, ага да ага! Хәйдәр берсен Әлмәттән, икенчесе Чаллыдан иске ванналар алып кайтты, янәшә торган ванналарда су бик әйбәт җылына.

Күрше Мирфатыйхлар кыяр белән мавыкмый, ашамый да, балалары ашаса да кулларыннан бәреп төшерә. «Тавык җиме, тозлы су!» дип кенә йөртә. Аларның яшелчә бакчасы зур, өйләргә су килгәч, бакча тагын да зурайды. Семья ишле, кәбестәсен үстерергә кирәк, чөгендерен, кишер-укробын. Мирфатыйхныкылар да ярата яшелчәне. Сәләхетдиннән күрмәкче, алар да бакчага бер ванна алып кайтып куйдылар, ванна янына тирән генә чокыр казып эчен бетонладылар, тирән кое казыдылар. Коега да водопровод суы тутыралар. Анысы запаска.

Явымлы елларда су һәркемгә дә җитә. Су турында авылда сүз чыкмый. Әмма соңгы елларда һаваның һич тәртибе булмады, я бик явымлый, яки җәйләр буе җир коргаксып, мөлдерәп утыра. Җитмеш икенең җәен генә алыгыз, Кама аръягында өч ай рәттән бер тамчы яңгыр төшмәде. Урманнар көеп утырды, кырлар-уҗымнар янды, эсседән каз бәбкәләре тәгәрәп үлде.

Андый елларда водопровод суы җитми. Андый елларда афәт...

Сәләхетдин Югары очта. Иң актыккы кеше. Су кытлыгын иң ныгы ул тоя. Аның кыяр бакчасы татый. Кыярга аңа су ай-һай күп кирәк! Йомшак та, чиста да чишмә суы аның кыярларына үтә дә килешә. Сәләхетдин краннарын ачып куя да чормага менеп, маңгайдагы ай аша Мирфатыйхларны күзәтә. Аларда ага су, ага! Иртән дә агып килә, кичен дә туктамый. Ә Сәләхетдиндә су юк, түтәлләре әлсерәп утыра, дәүдәү ванналары буш, ялгашлар коргаксыган, балаларны куып та Олы чуга йөртә алмыйсың. «Кем көянтә белән су ташый хәзер? Оят!» ди Вәзилә. Аңа Фирүзә кушыла: «Без замана балалары!» Мал-туарга коедан эчертәләр, өй арасында да ул ярый, карлыган, кура җиләгенә дә шуннан сибәләр, әмма кыярга татлысын кирәк. Кыяр — тормыш, кыяр — автомашина, бензин, кыяр — яңа тун, кыяр — модный күлмәк. Кыяр — такта. Кыяр — йорт, байлык. Кыяр — авыл арасында абруй. «Килосын өч сумнан сатам мин аның!» Ай рәхмәт теге полковникка. Тагын шундый берәрсе килеп чыгып су мәсьәләсен дә хәл итәргә өйрәтсә икән...

Карый Сәләхетдин, Мирфатыйхныкылар су кадерен белмиләр, урман чишмәсеннән ерак юл үтеп килгән кадерле нәрсәне карлыганга сибәләр! Аяк киемен дә шул су белән юалар, идәннәренә дә шул, тузанлы машинага да шлангтан шуны сиптерәләр. Аларга ага, иртән дә килә, кичен дә килә! Сәләхетдиннең краны богыр-богыр утыра, аккан чакта ага, акмаганда тама. Төнлә торып буш савытларның һәммәсенә күздән тутырып куйгалый ул, әмма кемнең төн саен йокы калдырып убыр шикелле йөрисе килсен?

Ачуы килә Сәләхетдиннең.

Кыяр түтәлләренә караган саен ачуы арта. Мирфатыйхларга кадәр су тигез генә менә, чама белән тотсалар, яки ачкүзләнеп теләсә ничек агызмасалар, Сәләхетдингә дә менеп җитәчәк бит ул! Элек шулай иде! Бер әйтеп карады Сәләхетдин Мирфатыйхка, ике кисәтте, тегеләр колакка да элмәделәр. «Әйдә, эти, кызык итик үзләрен, казыйк та торбаларын томалап куйыйк», диде Хәйдәр. Анысына ук йөрәкләре җитмәде.

Көннәрдән бер көнне — беренче июнь иде, җәй башы — Сәләхетдин Түбән очтан бик каты ярсып кайтты. «Кече улыңны тый, зират тирәсендә шуклана башлаган», диде авыл советы председателе. «Әгәр Хәйдәрең колхозда эшләмәсә, чарасын күрербез», диде колхоз рәисе. «Сезнең йортта совет тәртибе урнаштырасы бар», диде парторг Мәймүнә.

Ачуланып-күбенеп кайтып керсә, кыярлар сулып утыра, ялгашлар буш, ванналар корып кипкән. Өйдә адәм заты юк. Лапастагы куэлага көзгесен куеп Фирүзә китап укып утыра. Зөфәр дә юк. Хәйдәр дә кайтмаган, Гөлбикә аның белән бергә Байголга килен карарга киткән. «Кыяр карасы урынга килен карап йөри, тинтәк!» Вәзилә вак-төяк йорт эшләренә катнашмый башлаган чак, ни әйтәсең — китәсе кыз...

Кранны борып карады, тамчы су юк торбаларда. Чормага менеп ярымайга борынын тыкса, күрә, Мирфатыйхларнын бөтен савыт-сабалары күздән тулы, Мирфатыйх түтәл арасында йөри, майкачан гына, чалбар балакларын сызганган, яланаяк, авызында тәмәке, күперен утырган карлыган куакларына резин шлангтан сибә суны, керендерә генә. Коя! Аяк бармаклары арасыннан күбекле кара ерганаклар йөгерә. Сандугачын әйт син аның, Мирфатыйх бакчасында сайрый, кеше бар дип тә тормый, өздерә генә...

Күзе тонды Сәләхетдиннең. Менгән җиреннән иплэп кенә төште дә чоланга кереп бер бәләкәйне шешә авызыннан гына эчте (кем бу заманда аек килеш күрше белән сөйләшә ала?!), иплэп кенә Мирфатыйх янына кереп китте. Адымы салмак, аракының хәрәкәте тиз иде, күршегә кереп җиткәнче, башка менде. Ә Мирфатыйх сиптерепме-сиптерә!

— Краныңны яп,— диде Сәләхетдин.

— Ни бар? — диде Мирфатыйх исе китмичә генә.

— Безгә су менеп җитми.

— Мин гаепләме аңа?

— Ансын белмим. Яп.

— Сибеп бетерим, аннары ябармын.

— Болай да бакчаңны сазга әйләндергәнсең инде! — Сәләхетдиннең тавышы калтыранды, маңгаена бөрчек-бөрчек тир чыкты.

— Күңел булганчы суламадым әле,— диде Мирфатыйх, штан балакларын күтәреп. Сәләхетдиннең бакча уртасына кереп, боерык биреп торуын ул бер дә ошатмады.

— Болай куалашуың яхшыга илтмәс! — диде янап Сәләхетдин.— Җиткән, җиткән! Бөтен җирең су гына!

Мирфатыйх та карчыгыннан качырып бер бәләкәйне кәгеп чыккан иде, ул да күзенең агы белән генә күршесенә карады да:

— Юк әле! Син коры калгансың! — дип кычкырды. Һәм шлангысын туп-туры Сәләхетдингә юнәлтте. Сәләхетдиннең якасы төймәләнмәгән күлмәге манма су булды, юка чәче маңгаена төшеп сыланды, ачык авызына су керде... Мирфатыйх көлеп үк җибәрде.

— Менә болай ярый! — диде ул.

Күз чокырларын йодрыгы белән сөртә-сөртә Сәләхетдин акыра башлады:

— Карун! Җитмәде инде сиңа. Комсыз. Өйрәтәм әле мин сине!

Мирфатыйхка эше ошап китте, ул Сәләхетдинне туктаусыз шәбәртә иде.

— Өйрәтте диярләр!

Сәләхетдин шлангка барып ябышты, алар тартыша, ызгыша башладылар; юк-барлар, үткәннәр искә төште, әшәке сүзләр яңгырады, шлангны эләктереп алган Сәләхетдин Мирфатыйхка сибәргә керешге, ахыр чиктә шул булды — Сәләхетдин резин көпшәне тартып алырга маташкан хуҗаны нык кына этеп җибәрде. Мирфатыйх та кызган иде, ничек инде, ул үз бакчасында, хуҗа, кемдер эт җан монда кереп аны кыдырып, боерып йөрсен әле! Чәчләре агарган, тешләре ямьсезләнгән ике күрше, элеккеге ике дус, яшьтәшләр, бала аталары бер-берсен төрткәли, тарткалаша башладылар. Мирфатыйх Сәләхетдиннең күлмәк изүен аерып төшерде, «әле син алаймы? дип, Сәләхетдин күршесенә ташланды, юеш җирдә аягы таеп китте... Авызы кыегайды, куллары мәгънәсезгә һавада буталдылар, ул арты белән егылды, таянам дигән уң кулы ванна кырына эләгеп, сынып та чыкты, кан күренде. Карт сөяккә күп кирәкмени?!..

Сынган кулын күлмәк җиңе белән Фирүзә бәйләде.

Сәләхетдин акыра-бакыра медпунктка төште. Тик Вәзилә анда булмады. Вәзилә Җәмилдән ничек үч алырга икән дип баш ватып Түбән очта йөри иде. Медпункт тирәсендә давыл булып йөргән этисен калан чадан Зөфәр күреп алды һәм Хәйретдин агайны ияртеп яралы янына барып җитте.

— Кайда Вәзилә? Үтерәм мин аны! — дип кычкырды Сәләхетдин.

— Чү, чү... Алай ярамый! — Хәйретдин агай иң дуамал кешеләрне дә тынычландыра ала иде.— Хәзер ат җигәбез дә Түбән авылга алып төшәбез.

— Төрмәдә черетәм мин ул чалышны! Ранный кулны сындырды! Минем кемлекне белми әле ул!.. Чалыш тәре!..

Хәйретдин агай кушуы буенча Зөфәр тиз генә ат җигеп килде, Хәйретдин агай көчләп диярлек арбага Сәләхетдинне утыртты һәм ягымлы гына итеп атка дәште:

— На, малкай! Әйдә, теркелдә! Ә син, Сәләхетдин, сабыр бул!

— Судка бирәм мин аны!

— Кемне? — дип кабатлап сорады Хәйретдин агай, гәрчә кем турында сүз барганын ул байтактан төшенгән иде инде. Хәзер ник сораганына үкенде, чөнки Сәләхетдин авызындагы сүзләрне эт җыеп алмаслык иде.

· — Кемне булсын? Безнең очта эт бер генә. Карун тәре. Шәфкатьсез. Кешелексез. Муены астына килгере. Дөмеккере. Тамагына сөяк торгыры. Яшен суккыры. Каткыры. Бетсен, тавык үләте йоксын. Муены астына килсен. Чукынсын. Шүрәле белән кочаклашсын.

Ат Хәйретдин агайның каулавына карамастан акырын бара. Зөфәр урәчәгә ябышкан әткәсенең каргаганын авыз ачып тыңлап, шаккатып бара иде. Ул Хәйретдин агайдан:

— Кемне каргый ул шулай? — дип сорады.

— Кемне булсын? Мирфатыйх абзаңныдыр инде!

Юк, Сәләхетдин Мирфатыйхны гына түгел, медпунктында булмаган, иң кирәк чакта ярдәм күрсәтмәгән кызы Вәзиләгә дә, иң эссе чакта югалып калган Хәйдәргә дә, Гөлбикәгә дә эләктерә иде. Машинасы белән Хәйдәр өйдә булса үшән атта теркелдәп барыр идеме Сәләхетдин??!

Зөфәр артта калды, иярмәде. Әтисен ямьсез итеп күрәсе килмәде аның. Күрше Мирфатыйх турында да әшәке сүзләр ишетәсе килмәде егетнең. Тренеры, киңәшчесе, менә дигән укытучы Җәмил абыйсының этисе ич Мирфатыйх! Нигә тыныша алмыйлар икән алар икесе? Кай-

чандыр дус булганнар бит, бер-берсенә кунакка йөрешкәннәр. Ә хәзер әтисе ни ди? «Дөмеккере!» диме...

Әтисенең Мирфатыйх абый белән дус чакларын Зөфәр бик томанлы гына хәтерли иде.

## 10

Ул сүзләргә Хәйретдин агай да игътибар итте, колагы рәнҗеде аның. «Дөмеккере!» диме? «Каткыры!» диме?!

Егет булып житеп килгән улыннан һич читенсенмичә шундый әшәке сүзләрне сибәме?! Ярый, Хәйретдин агайны кешегә дә санамасын ди инде... Улы монда бит, Зөфәр!.. Сүгенгәнне ишеткәне бар Хәйретдин агайның, ара-тирә сугышкалап та ала кеше дигәнең, бигрәк тә яшь-җилкенчәк кыдрач, авызларына аракы кердеме куллар хәзер якага менеп китә... Әмма каргаганны күпме яшәп Хәйретдин агай беренче тапкыр ишетте. Кем кемне каргый диген әле! Бездә, Татарстанда, Кама аръягында, Зәй төбәгендә, Язкилдедә!..

Язкилдедә гел яхшы кешеләр генә яши дип ышана иде Хәйретдин агай. Талашлары очраклы хәл, чәкәләшеп алуларының да сәбәпчесе бары тик шул каһәр суккан шайтан суы дип кенә белә иде. Монда бит Мирфатыйх белән Сәләхетдин. Терәлеп торган күршеләр, яшьтәшләр, чордашлар, фронтовиклар гына түгел! Һәммәсен бик яхшы хәтерли ул. Белә! Алар бит, алар... Әллә оныттылармы алар?

Һәр халык яхшы гореф-гадәтләре, кунакчыллыгы, тәмле теле, хатын-кызларның буй җитмәс сафлыгы, горурлыгы белән мактанырга ярата. Чиләбегә баргач, базарда иске-москылар рәтендә, ике татарның Тукай теле белән дөнья сасытып ызгышып ятуларын ишеткәч, Хәйретдин агай соң дәрәҗәдә аптырап аларның янына барды: «Кардәшләр!» диде ул, тыны бетеп, «икегез дә ару ата балаларына охшагансыз, нигә алай үзегезне кадерсезләп, башка халыкларны көлдереп талашасыз?!»

Тегеләр ачудан күгәренеп бердәм рәвештә Хәйретдин агайны тетеп ташларга җыенганнар иде бугай, ак сакалны тиргәргә оятларына көч килдеме, шыпан-шыпан гына икесе ике якка кереп киттеләр.

Анда, читтә, сине беркем белми, син ирекле кош, дүрт ягың кыйбла, сүзеңә үзең хуҗа. Ә монда, туган авылыңда, нәсел-нәсәбеңне бөтен кеше белеп торганда, әле ерак бабаларның исеме телдән төшеп онытылмаганда, токымыңның дәвамы күз алдында...

Сәләхетдинне больницада калдырып чыкканнан бирле гел бер уйлар тирәсендә йөрде Хәйретдин агай. Менә хәзер дә, атын туарып япты, алдына печән салды, «нәсел-нәсәбеңне» диде дә, бик аптырап, ватылып каланчаның түбән баскычына барып утырды.

Сәгать дисәм азрак, ике сәгать үк дисәм күбрәк булыр, һушын җыя алмыйча да утырды, аптырау узмагач, дөньясына хәйран калып, тотты да Кирамнарга китте. Сер итеп кенә әйткәндә, әнә шул базарда ызгышып яткан татарларны очратканнан бирле аның Чиләбедән җаны бизде...

Кич булды, көтү кайта башлады, урам буйлап вәкарь белән башларын чайкап бурадай сыерлар узды, һавага әче әрем һәм татлы сөт исе таралды. Кемнендер ачык тәрәзәсеннән күңелләрне хушландырып музыка тавышы яңгырады. Яңгыратып балалар көлештеләр. Тук казлар каңгылдашты. Каланча янында Хәйретдин агай былтыр көз генә утырткан җиде каен яфраклары кичке җилдә күңелләрне күтәреп җилфердәп алдылар. Ул Кирамнарга китте. Һәр кәҗәне, һәр сарыкны күзеннән уздырып акрын гына барды Хәйретдин агай. Үз малы юк, Миннисаның кәҗәсе иркә, туры өйгә — сый янына кайта. Көтү кайта дип чыгып чабасы юк, шулай да бүген мал-туарны аерата дикъкать белән күздән кичерде ул. Сыерларның кемнеке икәнен белергә тырышты, танығач ху-

жаларын күңеленә китерде, аларның кушаматларын, кем нәселеннән икәнен күңелендә барлады. Уйлаган саен, барган саен, таныш хайваннар белән очрашкан саен аның күңеленә кичке караңгылык тула барды.

Язкилде дә шыксыз булып тоелды аңа. Чиләбе кебек ук һавасы тын юлларын буа, көчне-дәрманны ала иде. Ул, соңарып авылга кереп, кайда кунарга аптырап калган юлаучы кебек, сыер-сарыкларны аралап урам уртасыннан барды. Кайбер йорт турында туктап уйланып торды: «Кем иде соң әле боларның бабалары?.. Әһә, Шәйхетдин солдат нәселеннән болар!.. Ә монда кылый Сәфәр балалары. Урыннары оҗмахта булсын. Ил алдында бер чакта да яман исемнәре таралмады!»

Нәсел башын, олыларны хәтерләгәндә аның йөзе сүрән генә ачылып китә дә, уй җебе бүгенгә, бүгенге кешеләргә, йорт-нигезләрнең бүгенге хуҗаларына әйләнеп кайткач саран яктылык та югала, яңак итләре суырылып эчкә керә, тигез җирдә дә абынып куя иде. Бу йорт хуҗасы да аракы эчә, монысының улы тәмам алкоголик булып бетте, болары илдә булмаганны, былтыргы Сабан туенда сугышып, бер абыйлары өч елга төрмәгә элакте. Бусы өч тапкыр хатын алып аерды, өч җирдә өч ятим үсә... Водопровод суы Югары очка менеп җитә алмаса да, аракы дигән зәһәр су йортларның һәммәсенә дә бик мул агып керә, бер җирдә дә тоткарлык аңа юк!

Соңга калган мал-туарны куркытып, тәрәзәләргә, капкаларга әче тузан исе таратып, сөт, эрем исен зәһәр бензин исе белән күмеп, колак тондырып берьюлы, аллы-артлы алты-җиде мотоцикл узды. Гомергә беркемгә авыр сүз әйтмәгән, тәмле телле, сабый күңелле Хәйретдин агайның авызы бүген иман белән ачылмады: «Шушы җен арбасын уйлап чыгарган кешене колагыннан каланчага асып куясы иде!» диде ул.

Кирамнарга барып кергәндә күз бәйләнә башлаган иде инде. Кирам хатыны сыерын сауган, бер кәтү сарыкларын өерләп киртә аранга куып керткән, ишегалдында ике-өч оя каз белән кәҗә тәкәсе калган, җиде кызың һәм бер взвод киявең булгач казны шулай асрамый да булмый, ә кәҗә тәкәсен Кирам мәзәк өчен тота иде...

— Хуҗа өйдә юкмы әллә? — дип сорады Хәйретдин агай, кайнар су белән чиләк юып маташкан хатыныннан. Хатын сүзсез генә лапас ягына ишарәләде. Кирам күлмәкчән генә, яланаяк, кузлага менеп атланган. Калын йон баскан барабан корсагын кашып тәмәке пыскыта икән.

— Әй, Хәйретдин агай,— дид[illegible]л иренеп кенә.— Яманлап йөрисең, әле генә аштан торган идек.

Хатыны аның сүзен ошатмады:

— Нигә олы кешегә алай дисең? — диде ул.— Аш та бар, ите дә житәрлек. Хәзер чәй куям. Уз өйгә, Хәйретдин агай.

— Рәхмәт. Уза ук тормам.

— Бия ни хәлдә? — дип сорады Кирам кинәт.

— Бия? — диде, аңлап бетермичә Хәйретдин агай. Аның уйлары әле бик еракта, акыл ирешмәслек ераклыкта иде.— Ә-ә бия дисең икән! Җиктек әле, комын койдык. Сәләхетдин кулын сындырган, аны Түбән авылга, больницага [illegible]аттык.

— Ни булган ан[illegible]

— Кем белеп бетерсен,— диде Хәйретдин агай томанлы гына.— Таеп егылганмы шунда...

— Карт сөяк тиз ялганмас,— диде белдекле төс белән Кирам.— Сугыштан беләм. Яшьләр госпитальгә кереп тә урнашалар, җылынып та өлгермичә чыгып китәләр иде. Ә олыларның эш харап! Сәләхетдингә ничә яшь инде?

— Әллә тагын.

— Алар ничәнче елда каралырга барды әле?

— Элеккеләрне онытып бетергән син, Кирам! Нишләп олырак булсын, миннән яшьрәк ич ул!

— Шулай микәнни? — диде бик гаҗәпләнгән булып Кирам. Сүзсез тынлыктан соң, Хәйретдин агай:

— Әйдә әле, капка төбенә чыгыйк,— дип чакырды. Кирам хатыны тәрәзәдән кычкырып калды:

— Ерак йөрмәгез, чәй яңартам! — Ире өчен чиратыннан тыш пожаркада яткан кешегә аз булса да яхшылык эшлисе килә иде аның.

— Кирам,— диде Хәйретдин агай, каядыр ерактагы йортларга карап.— Син чык инде бүген эшкә.

— Ә син? — Кирам канәгатьлек белән һаман корсагын кашый иде.

— Кәефем юграк. Кан басымым әйбәт түгел минем.

Ул үзенең байтактан сәламәтлеккә туймавын, берничә мәртәбә гипотанический криз кичерүен, бүген шул хәлнең зират янында кабатлануы, күңеленә шом керүен, күңелгә шом керүнең яман фал икәнлеген Кирамга сөйләп бирергә уйлады, кемгәдер сөйләп җиңеләергә кирәк иде аңа, әмма сөйләмәде, көлемсерәп җиргә карап торды да:

— Әҗәлетдин бабайдан хәбәр килде бүген! — дип куйды. — Иртәгәдән эштән китәм. Булды. Рәис янына төшеп белдереп куям. Бүген үк. Аннары шул, мине яңа зиратка җирләсеннәр.

— Кит сәнә! — диде Кирам куркынып.

— Ниеннән куркасың аның? Олы су килеп каберемне тузгытканны көтеп ятыймммы?? Тау битеннән Язкилдегә карап яту үзе бер бәхет булачак.

— Язмаганны сөйләмә, Хәйретдин агай! Я ышандырырсың. Ярты авыл синең агай-эне. Язкилдегә мур килүен, рәттән кеше кырылуын телисеңме? Син барын да ияртеп алып китәчәк бит аларның!

Хәйретдин агайның йөзе агарып яктырып китте, ул көрсенеп алды.

— Ярты авыл дисеңме? Хи-хи, агай-энеләр хәзер!.. Чиләбедән кайтканга кайчан? Күпме туйлар узды, бәйрәмнәр үтте, берәрсе чакырдымы мине?

Кирам ык-мык килде, сыңар күзен кысып, офыкта кабынып маташкан йолдызга карап катты.

— Сакалына эт эчәгесе бәйләнгере! — дип ычкындырды ваемсыз Кирам.— Үлгәч кайда ятсаң да барыбер түгел мени?

— Шундый каргану да бар мыни? — дип кызыксынды Хәйретдин агай.

— Ризалыгыңны бирсәң, ну каргыйлар инде сине! — дип сүз кыстырды Кирам.

— Һәй, минем кемгә кирәгем бар?

— Куй әле анысын. Бик хәтәр сүз әйтеп ташладың әле син, Хәйретдин агай. Үлү турында сөйләшмик әле.

Кирам хатыны капка ачып чәйгә чакырса да, алар кузгалмадылар, Хәйретдин агай, үз-үзенә әйткәндәй сөйләнеп алды:

— Шулай икән ул дөнья! Яшисен, яшисең дә, берзаман тормыштан туеп та китәсең икән...

Хәйретдин кузгалып киткәндә таудай корсагын түгел, башын кашып калды Кирам, «вәт син, агай! Хәйретдин агай булдымы бу? Тормыштан туйдым, дидеме? Яңа зиратка барып ятырга ихлас күңеленнән ризалыгын белдердеме?»

Өченче тапкыр чәйгә дәшеп карасалар да, кунак ризалашмады, рәхмәт тә әйтмәде. «Иртәгедән эштә бер башың каласың. Бүген үк төшеп жит. Мин яңадан анда бармыйм», дип сменщигын ныгыткач, Хәйретдин агай өенә юнәлде.

— Бәй, карт, нишләп болай кайтасы иттен? Янына барырга гына чыга идем,— диде Минниса, мөмкин кадәр ягымлы тавыш белән.

— Үләргә кайттым, Минниса, үләргә,— диде Хәйретдин агай нык итеп.

Минниса карчык коелып төште...

Урман колак, кыр күз, дигәннәр. Урман-кырлар арасында утырган Язкилде авылы мең күз, мең колак, биш йөз тел ул! Югары очта төчкерсәләр, Түбән очта ишетеп торалар. Олы урамда кикерсәләр, Югары очта «бәракалла!» дип куялар.

Ямьле җәйнең беренче көне шулай үтте.

Иртәнге, көндезге, кичке вакыйгалар, ниһаять, сүз булып өй эчләренә күчте, булып узган хәлләр турында аш, чәй өстәлләре тирәсендә катлы-катлы, чуклы-чачаклы әңгәмәләр кузгалды.

Сүзне, әлбәттә, Зәйтүн белән Әнәстән башладылар.

«Имеш, Сәләхетдин башкисәре белән Мирфатыйх йомыкые бер сүздә булып, өй борынча йөргәннәр, әтәч-тавыкларга аракылы ипи тараткannар. Кош-кортлар исерешеп гауга чыгарганнар, өч әтәч сугышып җан биргән, тавыклар күкәйләрен үз ояларына салмаганнар. Сырурбикә карчык Тугашлар тыкрыгыннан кычыткан арасыннан бер алъяпкыч күкәй җыеп кергән. Әгъләмнәрнең күркәсе тончыгып үлгән. Мәгъмүрәнең ике чебиен тилгән алган. Тегермән буасы артында төлке иснәнеп йөргән. Тауга менгәндә авызында ак тавык иде, ди...»

Китә сүзләр, тарала, кузгала юраулар.

Ашлар суына, ясап куйган чәйгә чебен төшә, телевизор онытыла.

Киносеансны бүген сәгать ярымга соңга калып башлыйлар...

Сүзләр шуның белән тәмамлана дип уйлыйсыңмы, кадерле укучым?! Кысылып үлгән бәбкә өчен дә, тавык урлаган төлке өчен дә малайларны сүгәләр: «Азынды бала-чага, олыларны санлау юк, өй арасында эш табалмыйлар да менә азып-тузып йөриләр! Юк, Сәләхетдин балаларыннан юньле кеше чыкмас... Мирфатыйхныкылар да әллә кем түгел!»

«Сәләхетдин кызы бетчәле битле Фирүзә букчасы белән чирле бозауны ярган икән, чак үтермәгән» диләр...

Җәмилнең ни эшләп йөргәнен дә беләләр! Аның Вәзиләдән качып фермага төшкәнен, кичке савымга кадәр Сәкинә янында бөтерелгәнен, сыер сава торган аппаратларны көйләшеп йөрүен, эш беткәч, икесенең дә Олы су аръягындагы, тау итәгендә «подручком гулять итүләрен» күреп торганнар да «быел көзгә туй буласы!» дип нәтиҗә чыгарганнар. «Мирфатыйх малае Җәмил Сәләхетдиннең фельдшер кызы Вәзиләне ташлаган икән, өйләнергә ата-анасы рөхсәт итмәгән ди. Хәзер Мөсбах кызы Сәкинә артыннан чаба имеш...» «Әй, аларның әллә кайчан вәгъдәләре булган инде, Сәкинә унынчыны бетергәнне генә көткәннәр». «Сәкинә чукынчык Җәмиле өчен генә фермада калган икән әле!» «Гәҗитләрдә мактап яздылар бит шуны!» (Соңгысын кызлы аналар әйтә, ни генә димә, Мирфатыйх малае Җәмил мактаулы егет!)

Мич арасыннан комган тотып йөз яшьлек Зөләйха карчык чыга, дугадай бөгелеп, учын колагы янына терп: «Ә? Нәрсә? Әмриканнар сугыш башлаган диме? Кайда?»

Карчыкны көйләп-чөйләп чәй янына утырталар, алдына бал-май куялар. Зөләйха әби тына...

Зәйтүн актарып чыгарган баш сөягә дә бик күп сүзләр кузгата: «Кемнеке булыр икән? Кайсы бәхетсезнеке? Әй, аллам!»

Белмиләр. Онытылган. Исемнәр язып, елларын әйтеп таш кую, чардуганнар бастыру, аларны караштырып тору Язкилде авылында соңгы елларда гына очраштыра иде. Ә болай туа кеше, вафат була, утырып бер жылыйлар да догалы авызлары белән мәрхүмнең исемен кабатлап җир куенына тапшыралар. Әллә шул кадерсезлек өчен усалланып зиратка һөҗүм башладымы изге Олы су?! Ата-бабаларыгызның, борынгыларның исемен яд итмисез дип үпкәлиме? Тарихыгыз чыпчык борыны хәтле генә бит сезнең, Язкилде ваемсызлары,— дип ярсыймы?! Тари-

хы юк халык — юк халык, бүгенгеләр дә хаклы рәвештә иртәгә онытыла. Үткәннәрне хәтерләүнең юллары бик күп, төрле-төрле, кайчагында ялгыз кабер ташы да еллар, гасырлар өчен җавап бирә...

Белмиләр. Онытканнар. Хәтерләргә тырышмаганнар...

Табын янындагы сүзләр азая, зират турысында сөйләшә башлауга күңелләргә курку иңә. Һәркемнең соңгы юлга чыгасы бар...

Вәзилә дә курка.

Вәзилә җанына тынгы табалмады бүген. Аның Җәмилгә әйтәсе сүзе бар. Авылдан китәргә теләгәнең нигезе итеп әнә шул убылып, җимерелеп барган зиратны телгә алмакчы. «Монда калганнарның сөякләренә дә тынгылык юк ич, сукыр!» димәкче ул. Шуңа күрә Вәзилә, шашыпшашып, урамнар буйлап очтан очка чаба, Олы су ярына төшеп менә, аръякта боегып утырган биек-биек сенаж башнялары артында гына кыз белән егет йөридер дип башына да китерми. Кызы — Сәкинә, егете — Җәмил.

Хәйретдин агайның чирләгәнен ишетсәләр дә ышанып бетмиләр, ул агай аларга әкиятләрдәге үлемсез ил агасы, мәңгелек булып тоела.

Хәйдәр белән Мидхәтнең машина ярыштыруын да кызык итеп сөйлиләр...

«Чистайда трактор башына җиткәннәр иде инде алар, вәт син, әй Үз машиналарын да әрәмгә чыгарганнар икән! Байлык симертә! Сәләхетдин малаеның башы эшли, Байгол авылыннан кыз ала икән, бирнәгә машинасы килә, ди... Ә Мирфатыйхның Мидхәте юләр, бер дә Җәмилләренә охшамаган. Аттан ала да, кола да туа шул. Сүзгә килгәннәр! Салганнардыр әле! Сәләхетдин малае эчә! Күпчеп, көеп беткән инде. Мидхәт дә каба! Ярата! Рәхәтлеккә чыдый алмый хәзерге яшьләр. Рәхәтлек боза кешене. Элек итле ашны бәйрәм-сәйрәмнәрдә генә күрә идек. Кысыр ашка катык ката алсак сөенә идек. Балаларга икесенә бер кукәй — җеп белән кисеп ашата идек. Май — базарга, күкәй — базарга, йон — базарга, ит налугка иде, шул — байлык боза».

Үзеңне онытып, күршене сүгү, күршене орышканда үзеңне юмарт, акыллы, сабыр итеп күрсәтү бик ансат бит ул! Сиңа каршы сүз әйтергә базмаган бала-чагаң алдында тик утырасың мактанып!.. Рәхәт!

Сүз малайлардан аналарына күчә!

«Гөлмәрьям үзе дә шунда булган. Карап торган. Келәмен кочаклап күзен тоз итеп көтеп тора бугай! Җитмәгәнме аларга келәм? Ну, Гөлбикәсенә эләккән. Сул кулы шартлап сынып чыккан, ди». «Әйбәт булган. Төс аларга. Җитмәде инде, туймады инде, гуҗлар!»

Сәләхетдин белән Мирфатыйхның сугышканын да, Сәләхетдиннең каргаганын да ишеткәннәр. Авыл гөҗләп тора: «Иртән малайлары, кичкә кырын үзләре сугышкан!»

Бусына аерата нык гаҗәпләнәләр. Элгәре Язкилдедә бер дә сугышуфәлән булмый торган иде. Берәрсе ялгыш төртеп җибәрсә дә аны бик олы әдәпсезлек, юньсезлеккә чыгарып, телдән-телгә күчереп еллар буе мисал итеп сөйлиләр иде. Малайлар сугыша, үсмерләр чәкәләшә, мәгәр олылар һәрчакта да, кызган бәхәсләрдә дә сабырлар иделәр. Олы кеше, аксакал арага кысылып бәхәскә тиз үк чик куя ала иде. Ни булды бу олыларга? Нишләп алай үзгәрделәр алар?

Баш ваталар, җавап таба алмыйлар. Сүз һаман аракыга барып терәлә. Шул явыз котырта кешеләрне!

Язкилдедә күптән мондый җанланыш булганы юк иде!

Хәбәрләрнең хәбәре, җанланышның төп сәбәбе Хәйретдин агайның васыяте булды.

«Яңа зиратка кем беренче булып барыр?» Бу сорау, белгәнебезчә, авылны байтактан киеренкелектә тота иде. Кем килер? Бүгеннән һәркемгә мәгълүм — ул кеше Хәйретдин агай булачак.

«Барса да барыр шул», диештеләр авылдашлар, «жылап калыр кешесе юк, Минниса карчыкка ялгызлык яңалык түгел, нишләрсең, үзе дә олыгаеп бара... Хәйретдин агайның карчыгы җир куенында, балалары таралышкан. Әйдә, барсын, яхшы сүз белән искә алырбыз үзен. Әйбәт яшәде, игелек белән үлә дә белде, диярбез».

Башта, кызулык белән, рәхмәт укыдылар, мәңгелеккә изге сәфәр теләделәр. Сүз азайгач, күңелләргә уй килде. Иң элек, элеккеге күршеләр уйга калды. Миннәхмәт тә борчылып уйлады. Сабирҗан да.

Миннәхмәт Сабирҗаннарга барып керде.

— Ишеттеңме?

— Ишетмәгән кая?

Сүз ялганмады, Миннәхмәт кул болгап «әй» дип эчтәлексез бер ым ычкындырды да, шомлы күләгә сыман, эреп тә югалды, чыгып китте. Сабирҗан, Миннәхмәтнең кергәнен онытып, үзе аларга сугылды.

— Ишеттеңме?

— Тиле икән Хәйретдин агай.

— Безгә рәнҗемәгәндер бит!

Ике күршене дә шушы каһәрле сорау борчый иде.

— Алай булмаска тиеш,— дип, бер-берсен юатырга тырыштылар.

...Язкилде өстенә тынгысыз төн иңде. Язкилде күгендә тынгысыз болытлар куерды. Июньнең сыек нурларын сүгеп шул чагында Югары очка Хәйдәр кайтып җитте. Аның белән бергә диярлек өйгә Зөфәр кайтып керде. Вәзилә белән Фирүзә «Бәхетсезләр без! Кыярга суны кем ташыр?» дип җылаштылар да, гомергә булмаганны, печәнлектә кочаклашып йокладылар. Зәйтүн үзенә күз булмаганнан файдаланып чолан идәненнән өч литрлы банка белән җиләк вареньесы алып керде һәм прәннек мана-мана аның яртысын состы, яртысын идәнгә агызды...

Әнисе, әтисе янында больницада шактый озак торылган икән, Хәйдәр артыннан ук диярлек, Мирфатыйхлар турында трактор тавышы яңгырады, ут көлтәләре тирбәлде. Сарысы коелган «Жигули»ны трактор белән сөйрәткәннәр икән. Машинаны этеп-төртеп гаражга кerttеләр дә биш йозаклап шартлатып бикләделәр.

— Ник бикләсең? — дип сорады Мидхәт.

— Өйрәнелгән гадәт,— диде Мирфатыйх абзый. Үзеннән дә дәү кәләм күтәреп капкадан кереп килүче хатынын күргәч аның җылыйсы килде.

— Кайтып җиттеңме? — диде ул ачуланмыйча гына.

— Кайтуын кайттык та...

— Әйдә, мал табылыр. Төзәтербез машинаны. Баш исән булсын! — Сәләхетдиннең сынык кулын күргәннән соң Мирфатыйх кинәт айныган һәм песи кебек юашланып калган иде.— Әнә анда Хәйретдин агай бик начар, ди.

— Юк сүздер. Аңа ни булсын? — Гөлмәрьям дә куркып кайткан иде, хәзер йөгеннән арынып, иренең җылы сүзләрен ишетеп, җиңел сулады.

— Юк түгел ди шул менә! Ята ди! Яңа зиратка куюларын сораган!

— Сорагач, куярлар да. — Гөлмәрьямнең бу хәбәргә дә исе китмәде.

Мирфатыйх кына пошаманлана иде, ул соңарган кичке чәй янында тагын ике-өч тапкыр Хәйретдин агайның «үтенеч»ен телгә алса да, өйдәгеләрнең бу сүзгә дикъкать итмәүләрен, туктап тынып калды.

* * *

Түбән авыл больницасында кешеләр тынычсыз йокыга талгач, кулының сызлавына, башының авыртуына чыдый алмыйча Сәләхетдин ишек алдына чыкты һәм баскычта утырган хатынын күреп бик гаҗәпләнде.

— Бөркү,— дип акланды Гөлбикә. — Эреп ага яздым.

— Шул кадәр симермиләр аны! — Сәләхетдин хатыныннан читкәрәк барып утырды.

— Яшь чак түгел инде,— диде Гөлбикә.

— Ни булды соң сезгә? Кая бәрелдегез? — Сәләхетдин җикеренеп хатынына карады.

— Син сорама, мин әйтмим дигәндәй, үзеңә ни булды?

— Җанын алам мин аның!

Кемнең җанын, кайчан һәм ничек аласын да сөйләргә җыенганда гына больница капкасы ачылып, аннан машина килеп керде. Олы урамнан Бибиәсманы бәбәй табарга китергәннәр икән. Яңа хәбәр больницага аңа ияреп килде: Хәйретдин агай үләргә ята икән, үзен яңа зиратка куюларын сораган.

— Бик әйбәт булган,— диде Гөлбикә исе китмичә генә. — Яшен яшәгән дигәндәй... Менә монда булды әле эшләр! Үлдем дип торам.

Сәләхетдин хатынын кызганып бер сүз дә әйтмәде, киресенчә, сынык куллы хатынына сау чактагы төсле итеп кычкырып куйды:

— Чүпрәк баш, чүпрәк баш! Ни beләсең соң син? Кабак баш!

— Ай аллам, нигә холыксызланасың? Ни әйткән әле мин?

Сәләхетдин аңлатып тормады, тәмәке төпчеген җиргә бәрде дә, палатасына кереп китте. Төне буе керфеге йомылмады, уйлады да уйлады, тик аның уенда машинаны ваткан юньсез Хәйдәр дә, чак кына үлми калган Гөлбикә дә, тиздән судка биреләчәк Мирфатыйх чалыш та юк иде, ул төне буе тоташтан Хәйретдин агай турында, аның әҗәлен сизгәч әйткән васыяте турында гына уйлады.

## 11

Кичәге көн ел кебек озын булды, чөнки гадәттән тыш вакыйгаларга бик бай иде ул. Бүгел Язкилдедә гадәти көн. Гадәти иртә. Шул ук кояш. Шул ук урам-тыкрыклар. Йортлар да төн эчендә үзгәрмәгәннәр. Олы су өстендә генә сыек томан кичәгедән озаграк торды. Башкача һичбер үзгәреш юк, буласы кичә булып беткән...

Бүген дөнья тын! Гәрәй-хан да читәнгә менәргә ашыкмый, келәт тирәсендә тибенеп йөри. Дөрес, кырын күзе белән генә кичә канлы сугыш кырына әйләнгән карлыган куагы ягына карап ала. Тавыклар да тыныч, җырлый-җырлый хуҗалары тирәсендә йөренәләр, кытаклый-кытаклый ап-ак йомыркаларын салам ояларга тәгәрәтәләр. Үрдәкләр дә юашланган, күркәләр дә куләгәдән чыкмый. Гараж тирәләре дә иртә-таңнан тып-тын. Торбалардагы чишмә суы Югары очка кадәр менеп җитә. Фирүзәнең консультациясе дә юк, кызыл тапларның да бишесе кипши башлаган. Юып киптерелгән, калыпланган сигез бүлкәле кепкә Әнәснең кабак башында өр яңадай утыра. Зөфәрнең дә футбол ярышына барасы юк, ул апасы Вәзилә торганчы ук Хәйдәр белән печән оны әзерләүче агрегат янына киткән. Хәйдәрнең дә эше җайлы, үзе теләп колхоз эшенә чыккан. Каланчада да яңа кеше тора. Зират янындагы бушлыкта малайлар чын туп тибәләр. Кичә консультациягә барырга чыккан малайлар барысы да шунда.

Көн кичәгедән дә матур, кичәгедән дә җылы, кичәгедән дә хуш ислерәк. Әмма матурлык белән генә көннәр истә кала алмый — вакыйгалар кирәк тарих өчен, эш, җиңеш кирәк! Матурлык белән генә дөнья алга бармый.

Вәзилә, бик иртә уянса да, һаман җитешеп эшкә китә алмый, зиһене таралган, бер эшкә барып тотына да, аны тәмамламыйча икенчесенә ябыша. Җәмил үзенең футболчыларын җыеп Кырынды өстенә, юкә урманына, яфрак себерке әзерләргә китте. Эти больницада, әни больни-

цада. Берсенең уң кулы сынык, икенчесенең сул кулы. «Ичмасам, нигә икесенең дә сул кулы сынмаган?» дип уйлады Вәзилә. Фикеренең мәгънәсе булмаса да шулай уйлады. Иөгереп кенә больницага төшәр иде, халыктан оят. Ничек кеше күзенә күренергә? Я, кайсыгызның, кайсы авылда бер үк кичтә ата белән ананың кулы сынганын ишеткәне бар? Дөньяда очрамый торган хәйран вә вәйран эшләр булып узды Язкилдедә. Күкрәве бөтен кешегә ишетелде, янгыры да бөтен җиргә яуды, яшене генә Вәзиләнең бер үзен сукты!

Җәмил янына кереп чыгар иде — өйдә юк.

Җәмил янына урманга китәр иде — аралары бозык.

Зәйтүннең урамга чыгарга җыенганын күреп ул аяк тибеп кычкырды:

— Кая?!

— Урамга чыгам.

— Кымшанма, сугыш чукмары! Аңгыра бәрән!

— Ник кычкырасың? Мин синең улыңмы әллә?

— Минем улым синең кебек аңгыра булса, мин аны...

Вәзилә Мирфатыйхлар өендә ни булганын белми, мәгәр Мидхәтнең ямьшәйгән иске сумка тотып, ындыр артлатып чыгып китүенә карагандa, аларда да хәлләр булганга охшый. Мирфатыйх абый эшкә чыкмады, ул да кеше күзеннән качып, өйдә яшеренеп ятадыр булса кирәк. Гөлмәрьям апа тавыкларга җимне югарыдан торып, болдыр баскычыннан гына сибеп җибәрде дә кереп югалды.

— Мәгез, ачкаклар, тыгыныгыз!

Хәйретдин агайның хәле шәптән түгеллеген дә ишетте Вәзилә. Минниса карчык көтүгә кәҗәсен кугач ук килеп җитте: «тамагына да капмый, чәен дә юньләп эчмәде, түшәмгә караган да тик ята», диде ул бик нык кайгырып. «Теле бармы соң?» диде Вәзилә. «Ара-тирә сораштырып та куя... Сораганның да энәсе-җебе юк. «Миннәхмәт күршенең бабасы кем атлы иде әле», ди. Әле Сабирҗаннарны сораша, әле башкаларны. Әллә кайчан дөньялыкны куйган адәмнәрне нигә телгә алып торырга? Баргач сөйләшерләр иде әле. Кыямәт көн килми калмас. Кайсы җирең авырта, дим, башын гына чайкый... Сезне дә белеште. Сәләхетдиннең абзасы кайда әле хәзер, ди...»

Вәзиләнең исе дә китмәде Миннисаның бытырдавына, әҗәле килгән карт ни сорамас та, өендә авыруы бар карчык ниләр уйлап чыгармас?..

Кичәге очрашулары искә төшкәч Вәзилә бүген дә кызарып куя. Бик төшәсе иде Хәйретдин агай янына, бик карыйсы иде, урамга чыгарга, кеше күзенә күренергә генә уңайсызланды. Вәзилә төшмәде, Минниса карчык яңадан менмәде, өй арасында йөреп, вак-төяк тастымалларны юган булып Вәзилә чак-чак кына көнне уздырды, кичне житкерде. Кояшны аркан белән офыкка тартып төшерердәй булды. Хәйдәр белән Зөфәр төшке ашка кайтмадылар, Хәйдәргә нык кына эләгә иде югыйсә! Машиналары худта булса, выжт иттереп кенә Түбән авылга төшеп менәр иде Вәзилә, ата-анасы сукранып, каргап ятадыр анда...

Больницада ул иң элек хатын-кызлар палатасына барып керде. Гөлбикә апа яткан җиреннән торып, аңа ияреп, ишегалдына ук чыкты. Бик биек карт каенга аркаларын терәп эскәмиягә утыргач кына Вәзилә сорау алырга кереште:

— Нишләдегез сез? Адәм хурына калдырдыгыз!

— Нишләдегез дип, кеше малын урлап суймаган.

— Бөтен авыл гөр килә. Тәүлек буе беркемнең теле туктап торганы юк, бирдегез гайбәткә ризыкны!

— Атаңның гаебе юк! Мирфатыйх чалыш суккан аңа, сугып еккан. Атаң аны судка бирәчәк. Монда белеште инде. Өч ел рәттән эләгәчәк Мирфатыйхка...

— Шул гына җитмәгән иде.— Вәзилә тәмам аптырашта калды.— Мирфатыйхны өч елга төрмәгә тыгалар, мин аның улына кияүгә чыгарга йөрим!

— Чык соң! — Гөлбикә бу хәбәрне дә бик тыныч кына тыңлады.— Сез моннан китәсе. Әгәр бу юлы йомшаклык күрсәтсәк, Мирфатыйх безне урамга да чыгармас. Кулда форсат барында әлпиен укытырга кирәк аның.

Вәзилә ике кулы белән кайнар башын тотып бер сүзне кабатлады:

«О ужас! О ужас! Кыргыйлар...»

«Әти кайда?» дигән сорау юк, «хәле ничек?» дип белешү юк, Вәзилә үз кайгысын кайгырта иде, моны аңлаган ана күңеле бик нык рәнҗеде, алай да аны-моны сиздермичә:

— Җәмил ни ди соң? — дип сорады.

— Җәмил белән сөйләшерлек хәлдәме мин? Сез нишләгәнегезне беләсезме, азрак хурлык турында да уйлыйсызмы?

Вәзиләнең тавышы торган саен ныграк яңгырады, больницаның ачык тәрәзәләреннән хатын-кыз башлары күренә башлады.

— Акрын,— дип бүлдерде кызын Гөлбикә.— Хәйдәр өйдәме? Малтуарны барлап яптыгызмы? Көн бик эссе булды, әткәннең кыярларына суны син сибәрсең, ыбыр-чыбырны йөртмә.

— Чукынып китсен кыярларың. Малларыңны мур кырсын!

— Чү, чү, тилермә! Син китәсе кыз. Ә без ничек яшәрбез? Балаларны аякка бастырасы бар. Атаң әйтә...

— Әти? Кайда ул? Мин килгәнне ишетмәдеме әллә?

Гөлбикә аңа бик аптырап карады.

— Бәй, мин сезне юлда күрешкәнсез дип торам. Авылга менеп китте, Язкилдегә. Аймылыш булдыгыз микәнни, ай аллам.

— Мин Олы су буйлап төштем.— Вәзилә юлга ни өчен чыкмавын аңлатып тормады.— Өйгә кайтып киткәндер инде. Кыярлары бетә дип коты чыккандыр. Берни дә булмаган кыярларына.

— Юк,— диде әнисе уйчан гына.— Өйгә кайтып китмәде ул. Өйгә булса бер хәл иде... Атаң Хәйретдин агаң янына китте.

— Нигә? — диде түземсезләнеп Вәзилә.

— Әйтә мени ул? Хәйретдин агайның үләргә ятканын, яңа зиратка күмәргә васыять иткәнен ишеткәннән соң атаңны алыштырып куйдылар мыни, телдән калды. Көне буе сөйләшмәде. Ашамады. Борсаланып тик йөрде. Караңгы төшер-төшмәстә чыдамады, китте менә.

— Шашкандыр ул! — диде Вәзилә, Хәйретдин агай белән кичә булып узган күңелсез очрашуны хәтерләп. «Әллә шуны да ишеттерделәрме әтигә?» дип тә борчылды.

Аналы-кызлы бер-берсенә байтак кына карашып утырдылар, әмма аларны якынайтырлык сүз дә, уй да юк иде.

*

* *

— Өйдәләрме болар?

Минниса карчыкның ябылып бетмәгән ишеге тавышсыз гына ачылды, кулын ак марлялар белән урап аскан Сәләхетдинне күргәч карчык чынлап ук каушап китте. «Гомергә бусагамны атлап кермәгән кеше килгән... Хәйретдин агамның хәле мөшкел икән!» дип курыкты ул. Тавышка Хәйретдин агай да калкынды, агач карават шыгырдап куйды, ул, ишек ягына күз салып, сүрән генә:

— Кер, кер. Син йөрисең икән,— диде дә көрсенде.

Сәләхетдин исән кулы белән артсыз урындыкны караватка янынарак сөйрәп китерде, урындык аякларыннан ямьсез эз тырналып калды, ул

аны күрмәде дә, эчкә баткан хәсрәтле күзләрен тутырып Хәйретдин агайга карады. Ялыныч, ялвару гына түгел, өмет җылысы да бар иде аның кайнар карашында.

— Нихәлләрдә соң? — Сәләхетдин тавышын йомшартып эндәшергә тырышты да йөткерде, учы белән юеш иреннәрен ышкыды.

— Ятам әле шунда,— Хәйретдин агайның сакалы тирбәлеп алды.

— Авырткан җирең дә бармы?

— Артык сызланган төш юк-югын. Мәгәр...

— Ни исәпләр белән ятасың соң, Хәйретдин агай? — Сәләхетдиннең каушавы тагын да көчәя төште.— Ни уйлыйсың?

Хәйретдин агай ашыгып җавап бирмәде, «әле кайчан гына, Түбән авыл юлында, арбага янәшә утырып төшкәндә минем дөньяда барлыкны да онытып, юлны-кырны сасытып барган Сәләхетдинме соң бу кеше?» дип уйлады ул. Сәләхетдинне байтак интектергәч кенә аның иреннәре авыр гына ачыла башладылар:

— Исәпләр күп, әмма очына чыгар әмәл генә юк. Әҗәл яканнан алганда үз сорауларыңа да җавап табалмагач, әйтсәм дә әйтим инде, нинди кеше буласың ди инде? Нинди җан?!

— Нинди әҗәл? Ни сөйлисең син? Җир җимертеп эшләп йөргән кеше!

Хәйретдин агай Сәләхетдингә көлемсерәп карап куйды, туң чыраена җылылык йөгерде.

— Эх-хе-хе! — дип сузды да карчыгына эндәште.— Кая, ни мыштырдыйсың, карчык? Самоварың тереме?

Минниса карчык башын аска иеп, яулык читен тешләп, өстәл әзерләргә тотынды.

— Бая ни әйтә башлаган идең әле син? — дип сорады Хәйретдин агай юри тавышын нечкәртеп. Сүзе кызгандырып, мескен булып чыкты аның. Сәләхетдин гипсланган кулын, «менә, күрәсеңме?» дигән сыман, селкетеп куйды.

— Миңа бер хәбәр ишеттерделәр әле...

— Нинди хәбәр икән ул? — дигән булды Хәйретдин агай.

— Белмәмешкә салынып ятма сана! — дип калкынды Сәләхетдин кызып ук.— Хәбәрне син салгансың ич!

— Шулай да булсын,— дип килеште юашланып Хәйретдин агай.

— Ул сүзеңне кире ал, Хәйретдин агай,— диде бик нык ялварып кунак.— Ялгыш ычкындырган син ул сүзне! Тереләсең син, валлаһи дип әйтәм, әҗәлгә бирешә торган адәмме син? Менә мин нинди исәп белән йөрим әле, сине санаторийга җибәрергә кирәк, дәваланырга!

— Дәваланырга? Кем җибәрсен ди мине?

— Менә мин җибәрәм.— Сәләхетдин тагын йодрыгына йөткерде.— Путевкасын да табам, акчасын да түлим. Юлына да бирәм, барырына, кайтырына дигәндәй, һәммәсен түлим. Тик ул сүзеңне кире ал! Үлә калсаң, иске зиратка күмдер. Бөтен расходларын үзем күтәрәм. Әйдә, яхшылык миннән дә булсын. Синең яхшылыкка гомер буе рәхәтләндек.

Гомергә Хәйретдин агайны бар дип белмәгән, кунакка баргач тешләгән шикәрен кулъяулыгы белән төреп алып кайта торган Сәләхетдиннән мондый сүз чыккач, Хәйретдин агай торып ук утырды, ак ыштан балагының баулары идәнгә төшеп асылынды. Күче яктан кисә башлаган ипиен тотып шаккатып Минниса килеп чыкты.

— Өзлегеп китмәссеңме, сиңа әйтәм?

— Чәеңне ашыктырма, карчык,— диде Хәйретдин агай. Аның йөзенә елмаю җәелде, күзләренә нур тулды.— Ала-ай!.. Кыяр ничек быел, Сәләхетдин кордаш? Уңыш шәп булачакмы?

— Кыярның монда ни катнашы бар?

— Кыяр акчасына җибәрәсеңдер инде син мине?

— Анысында синең эшең булмасын, Хәйретдин агай.

Хәйретдин агай тавышсыз гына көлеп алды.
— Терел дисең инде?
— Терел дим.
— Үлмә дисең инде?
— Үлмә дип тә әйтәм.
— Боерып кына эшләнә торган эш түгел бит. Әҗәлетдин абзаң якаңнан алса, әллә ни тырпылдый алмассың.
— Ә син алдырма! — дип боерды Сәләхетдин. — Йөз яшәгән карчыклар бар Язкилдедә. Шиһабетдин картны өч тапкыр паралич сукты, муены бөгелми, авызы кыек, йөри! Үлсә, әнә ул барсын яңа зиратка... Карчыгы да «менә, менә» дип усак яфрагы күк җилфердәп кенә тора.
— Нигә мине җәллисең дә, Шиһабетдин картны кызганмыйсың син? Җибәр аны санаторийга, савап булыр. — Сәләхетдин дәшмәгәч, Хәйретдин агай урынына менеп ятты, түшәмгә карады. — Үләсе килми дисең инде, Сәләхетдин?
— Яши генә башладык бит, Хәйретдин агай. — Кунак аның караватына иелә төште, авызыннан суган кыягы исе бөркелде. Капкан ахры бераз. — Бөтен нәрсә житеш, йорт-җир байларча, мал-туар абзар тулы. Бәләкәй малай да бар ич әле минем. Беренчене бетерде. Аны кеше итәсе бар.
Тагын ниләр сөйләшкән булырлар иде, Минниса карчыкның самовары кайнап чыгып, өстәл башына менеп утырды, чәшке-чынаяклар тезелде, шул арада ишек ачылды, йөткергән калын тавыш килеп керде.
— Ярыйдыр бит? Керергә рөхсәттер!
Өч баш сәерсенеп ишек ягына борылды, анда кыенсынып, борчылып кына Сәләхетдиннең күршесе Мирфатыйх басып тора иде.
— Исән-сау гына торасызмы? — диде ул күзен челт-челт йомып.
Мирфатыйх бүген ап-аек иде, ул Хәйретдин агай янында кичәге дошманын күргәч, тагын да ныграк айныды, айныгач телсез калды, чәй дә эчмәде, өстәл янына якын да килмәде, бусага янында чүгәләп, кабызмаган папиросын бармак араларында әвәләде. Уртак сүз юк иде. Хәйретдин агай бу ике күршенең, ике дошманның ни өчен аның бусагасын таптауларын сизенә, мыек астыннан гына елмаеп та ала, тәне җиңеләеп, теле кычытып сөйләшәсе килеп китте. Баядан бирле китәргә ашыккан Сәләхетдинне дә җибәрмәде, «төн озын ич, кая ашыгасың?» диде. Сүз арасында гына Мирфатыйхка да атап эндәште: «Көткән эшең юктыр, утыр әйдә!» диде.
Тик тегеләр тел язмадылар, каш астыннан гына бер-берсенә карашып юк-барны сөйләшеп вакыт уздырдылар. Ниһаять, хуҗа түзмәде:
— Мирфатыйхның нигә кергәнен беләм! — дип ычкындырды.
— Гаепләмә, Хәйретдин агай, хәл белешергә генә кердем.
— Рәхмәт анысына да. — Хуҗа көлемсерәп карчыгына күз кысты.— Яшә дисең инде, Мирфатыйх?
— Яшә, яшә!
— Үлмә дисең инде?
— Нинди үлү? Иртәрәк бит әле!
— Үлә калсаң, яңа зиратка күмәргә рөхсәт бирмә дип тә өстисеңме?
— Анысы инде бигрәк тә кирәк! — Мирфатыйх кулындагы папирос, ниһаять, сынды, ул аны кесәсенә салып куйды.
— Алай икән, алай.
Сәләхетдин ишек катына барып басты:
— Китим инде мин, — диде. — Я сугәрләр...
Хәйретдин агай аңа күз дә салмастан һаман сорашуын дәвам итте:
— Бәлки мине үз акчаңа ялга, дәваланырга да җибәрерсең, Мирфатыйх? — диде Хәйретдин агай. Мирфатыйх та чүгәләгән урыныннан торды, ашыгып-ашыгып:

— Алай итәргә дә була. Телэгең бар икән, әйдә, бар, дәвалан... — диде.

Өйдә тынлык урнашты, Миннисаның самовары акрын-акрын гына сүнде, чожлавы ишетелмәс булды. Ишек тоткасына ябышкан Сәләхетдинне Хәйретдин агай тагын туктатты:

— Ашыкма, әнә Мирфатыйх та чыгам ди...

Тәки үзенекен итте Хәйретдин агай, Мирфатыйх белән Сәләхетдинне бер ачылган ишектән чыгарып җибәрде.

Алар урамга төшкән тәрәзә яктылыгын читләтеп узып бераз янәшә бардылар.

— Син нишләп йөрисең монда? Ни йомыш бар синең Хәйретдин агайда? — диде калын тавышы белән Мирфатыйх.

— Ә сиңа монда ни калган? — диде Сәләхетдин кызып.

— Хәйретдин агай минем туганым.

— Синеңме? Юләр! Ул миңа туган тиешле кеше.

Алар Хәйретдин агайны бүлә алмыйча урам уртасында кичәге кебек талаша башладылар, бераздан икесе дә тыелып, нидер хәтерләп сүзсез калдылар, шактый озак дәвам иткән паузадан соң, нәсел җепләрен тикшерә башладылар.

— Синең Әюп бабаңның фамилиясе ничек иде әле?

— Оныттың мыни. Мортазин иде!

— Минем Билал картның да фамилиясе Мортазин иде ләбаса!

Сәләхетдин белән Мирфатыйхның хәтерләре ул кадәр озын түгел иде, шәҗәрәләре язып кулдан-кулга күчмәгән, әмма кеше хәтерли алган кадәресе дә бик җитте: Сәләхетдин белән Мирфатыйх туганнан тумышканнар иде.

Беләләр иде, туганлыкны саклыйлар иде, еллар үтү белән бөтенесе онытылган, хәтердән чыккан!..

Ни уйларга тиеш инде мондый чакта Сәләхетдин?

Мирфатыйх ни әйтергә тиеш?!

Юк-юк, хөрмәтле укучым, сез миннән аны көтмәгез. Булмаганны яза алмыйм. Алдарга намусым бармый. Мин гомерем буе чынлыкның тугры колы булдым, шулай булып калырмын да. Таләпчән укучыларга хөрмәтем зур, әмма сез дә мине аңларга тырышыгыз: кочакларын җәеп бер-берсенә ташланмадылар алар — ике туган, ике күрше, ике көндәш... Гомер буе араны бүлеп килгән зәһәр дулкыннар аларны бик ерак ярларга тотып аткан иде, икесенең кан кардәшләре икәнне белгән хәлдә дә Сәләхетдин белән Мирфатыйх арадашлык сүзләрен тапмадылар. Тын гына, зираттан кайткан кешеләр сыман, салмак кына Югары очка атладылар. Әле ярый, шөкер, төн тын, һава тымызык, урамда ара-тирә яшьләр генә очраштыргалады, яшьләрнең олыларда гаме юк.

Мондый очракта нишләргә?

Ничек яңадан туганлашырга? Мөмкинме бу? Бармы аның юллары?

«Кичәге өчен кинә саклама, ялгышлык миндә. Әйдә, безгә керик тә яртыны сындырыйк», дип әйтергә уйлый Мирфатыйх... Туганлыкны ныгытырга тагын шул шайтан суын чакырырга туры киләчәген аңлап, тыелып кала. Аек баш бернинди чарасын уйлап таба алмый, аек баш катткан, томаланган.

Сәләхетдиндә дә ул уй бар, чоланда сандык артында яртысы да булырга тиеш. Чакырсаң, керер, ә яртыны Хәйдәр чөмереп бетергән булса? Тагын оятка каласы була...

Тәки шулай телсезләр шикелле сөйләшмичә, сукырлар кебек бер-берсен күрмичә, иңнәрне иңгә тиюдән сакланып Югары очка кадәр менделәр.

Капка төбенә җитәрәк Сәләхетдин алгарак чыкты, Мирфатыйх кыяр-кыймас кына:

— Ничек соң анда, Гөлбикәнең хәле бик яманмы? — дип сорады.
— Өч-дүрт атнасыз ипкә килмәс диләр.
— Менә син агай, ә!
— Булды инде хәлләр! Юләрлекләр күп булды.
— Нишләргә соң хәзер?
— Кем белгән анысын? Баш каткан.
— Әллә болай итәбезме?
— Ничек?
— Хәзер син больницага барасыңдыр бит?
— Барсам?
— Хәл белергә мин дә төшәр идем. Гөлмәрьям берәр нәрсә хәстәрләр шунда.
— Ә син аны әйтәсең икән.
— Ә син ни уйлыйсың?
— Гөлбикә төзәлер дә чыгар, Хәйретдин агай белән нишләргә диген.
Мирфатыйх күршесенә сабыр гына карап торды.
— Әллә болай итәбезме? — Сәләхетдин сүзен дәвам итте. — Икәүләшеп путевка юнәтеп, юл акчаларын түләп картны ялга озатабызмы? Акча үземдә дә бар, мәгәр ике туганы исеменнән булса, күңеле күтәрелер иде. Әнә ич, алты ел урыныннан тормаган сызлау буын Нажияне армиядәге малае Тәлгать Әзербайҗанга Нафталан каласына өч ел рәттән алып барган иде, теркелдәп йөреп китте Нажия. Сыерларын саткан нар иде, савар кешесе юк, хәзер сыер алдылар, гөбердәтеп сава, күз тимәсен!
— Нигә? Мин карышы түгел! Акча бар! — Мирфатыйхның теленнән «аракы» сүзе чак ычкынмады...
Сөйләшәләр Мирфатыйх белән Сәләхетдин.
Хәйретдин агай уртак сүз, җанлы әңгәмә кузгатты, кыяр турында, келәм бәяләре турында да түгел сүз, әмма алар бирелеп, кызып-кызып, рәхәтләнеп сөйләшәләр. Сөйләшә алалар икән.
Авызыгызга бал да май сезнең, күршеләр!
Сез дә үз халкыгызның матур сүзләрен онытмагансыз икән әле! Шәфкать, мәрхәмәт, туганлык дигән олы сүзләрнең сезнең телгә күптән кергәне юк бит инде, Сәләхетдин белән Мирфатыйх! Сөйләшүне онытмагансыз икән, аракыдан башка да сөйләшер сүзләр әйтә аласыз. Тик нигә болай соңга калып сөйләшәсез дип сорыйсы килә. Хәйретдин агайны якасыннан әҗәлетдин алмаса... Нигә якыннарыбыз соңгы юлга чыкканда гына тормыш турында олы итеп уйлый алабыз икән без?!
Олыларның, кичә кичтән генә сугышып яткан күршеләрнең, озак һәм дусларча сөйләшеп торуларын ике йорттан ике кеше күзәтеп торды. Сәләхетдиннәрнең ачык тәрәзәсендә пәрдә артына Вәзилә поскан иде. Мирфатыйх хатыны Гөлмәрьям ишегалдына ук чыгып, капка артына качып, колагын ярыкка куйган иде. Тез башлары чәнчешә башласа да түзде, әңгәмәне тыңлап бетерде. Тик берни дә аңламады. Мирфатыйх белән Сәләхетдин түгел, каяндыр читтән килгән артистлар сөйләшә кебек ишетелде аңа. Шул кадәр ят иде ул ишеткән сүзләр — «әллә җен алыштырдымы аларны?» дип уйлады Гөлмәрьям һәм белгән догаларын хәтеренә төшерергә маташты. Иренең зирәклеге белән горурланды: «Әһә, эшне судка җибәрмәс өчен тырыша бу. Мулладис!»
Вәзилә татулыкның серен табалмады, ул да баш ватып эзләп карады, әмма ике күршенең дошманлыгын бетерерлек сәбәп юк иде. Дөресен әйткәндә, ул сүз агышының эченә кереп тормады, Вәзилә Җәмилне көтә иде. Ул өйгә кайтмаган әле. Аның болай соңарып йөрүе бик-бик шикле иде. Әгәр бүген көндез аларны Сәкинә белән бергә күрмәгән булсалар, ул бу хәтле үк кыйналмас иде. Күргәннәр шул, күргәннәр! Ишеттерделәр.

Мирфатыйх Югары очның соңгы капкасы төбенә хәтле Сәләхетдин күршесен озата килде. Шунда алар сүзсез генә кочаклаштылар да бугай...

Сәләхетдиннәр этәче кычкырып җибәрде.

— Ятыйк, соң инде,— диде Сәләхетдин.— Больницадан качты дип эләкмәгәе. Таңнан барасы булыр.

— Тизрәк терелегез. Хәйретдин агайны да карыйсы бар. Картны әҗәлгә бирергә ярамый.

— Ярамый,— дип килеште Сәләхетдин.

Ул кергәч Вәзилә ут кабызды.

— Качып кайттыңмы? — диде ул һаман Җәмил турында уйлап.

— Кайттым әле.

— Мирфатыйхны сагынып кайттыңмы? Әй чүкердәшкән булалар! Кичә сугышып ятканнарын онытканнар.

— Онытырсың да,— диде ата сабыр гына.— Алай явызланма. Хәйретдин агайның хәлен белешергә кайткан идем.

— Синнән башка белешер кеше беткәнме?

— Туган тиешле ул безгә. Якын туган.

— Нинди туган?

— Ул, мин, һәм менә Мирфатыйх күрше троюродныйлар икәнбез. Барыбыз да Мортазиннар тамырыннан шытып чыкканбыз. Бабаларыбыз шул фамилияне йөртә иде безнең.

— Мирфатыйх абый дамы?

— Ул да, кызым.

— Чын сөйлисеңме?

— Чын. Иң чыны.

— Җәмил дә миңа туган тиеш булып чыгамы?

— Хас шулай. Бик якын туганың ул синең. Без аны онытып кына җибәргәнбез.

Вәзиләнең өстенә салкын су койдылар. Вәзиләне, аягын-кулын бәйләп, янган утка аттылар... һәм мондый халәт бер кискен мизгелдә үтеп тә китте. Нигәдер бушанып, рәхәт тынычланып калды аның күңеле.

— Әти, чыннан да Мирфатыйх абый синең кан кардәшеңме? — дип кайтарып сорады кыз.

— Әйе, әйе,— дип кабатлады ата йокы аралаш. Ул чишенеп урынына менеп тә яткан иде.

Вәзилә урамга чыгып китте. Капка баганасына аркасын терәп торды. Авыл очына, кырга чыкты. Кире борылып кайтты. Үзенең бер чакта да Җәмилне яратмавын, үзсүзләнеп, яшьтән үк аның хуҗасы булырга омтылып кына бәйләнеп, əзәрлекләп азаплангавын аңлады. Яратмады ул аны. Җәмил дә аны яратмады.

Күкрәге җиңеләеп, сулышы киңәеп китте кызның.

Димәк, Җәмил аның туганы... Хәзер ни генә булса да егет алдында аның йөзе ак.

Сәкинә каршысында да ул олы булып калачак. Җәмил ташламады аны, Сәкинәгә алыштырмады, туганлыклары ачыклангач, Вәзилә үзе ташлады егетне. Үзе! Барлык төеннәрнең чишелеше иде бу.

Сөенечен кем беләндер уртаклашасы килде Вәзиләнең, өстенлеге белән мактанасы килде. Өстенлеге белән мактаныр кеше Язкилдедә бер генә иде. Чибәр, сылу Сәкинә иде ул кеше. Хәзер үк Сәкинәне эзләп табарга да, горур башын югары чөеп: «Апаем, мин сиңа Җәмил абыеңны бүләк итәм. Мин аның белән күрше буларак кына дуслашып йөрдем. Без бит якын туганнар. Әллә ни уйлама!» дип әйтеп салырга.

Кузгалды кыз. Нияте нык. Бара башлады. Җир буе киткәч, алар сызгыра-сызгыра кайтып килүче Җәмил белән йөзгә-йөз очраштылар.

— Хәерле төн! — Вәзилә сандугач булып сайрады.

— Хәерле төн,— Җәмил соң дәрәҗәдә гаҗәпләнде.— Кая барыш?

— Сөенче алырга!
— Кемнән?
— Иртәгәге көннән! — диде Вәзилә һәм егеткә орынып Олы урамга, Сәкинәләргә таба йөгерде.

Җәмил урынында озак кына борсаланып аунады. Вәзиләнең тантаналы сәер тавышы, әйткән сүзләре аны хафага салды. «Сәкинәгә бер-бер яманлык эшләп ташламасын бу көнче күбәләк!» дип уйлады ул.

Вәзиләнең көнчелеге узган иде инде. Өметсезлеккә төшкән кызын әтисенең хәбәре очыртып, дәртләндереп җибәрде.

Йокыга киткән Сәләхетдин кулы яман сызлап уянды. Кул сызлаган саен ул ерак тарихка, бабаларына юнәлде. Бүгенгене уйлады. «Хәйретдин агайны күрә торып үлемгә бирмәскә кирәк» дип кабатлады ул күңеленнән. Хәйретдин агайны уйлаган саен кул сызлавы кимегән төсле була иде.

Мирфатыйх та тозагыннан ычкына алмады. Юк өчен күршесе белән сугышып ятуы күз алдына килә дә кан тамырлары чемердәп китә иде аның.

Веранда идәнендә Зәйтүн йоклый.

Олы өй диванында Фирүзә җәйрәп ята.

Зөфәр лапас өстендә, печәнлектә.

Ишегалдында ачык һавада, гараж стенасына терәлгән раскладушкада Хәйдәр ята. Сеңгән. Ара-тирә ыңгырашып ала. (Эчкән килеш ятса гел ыңгыраша ул.)

Сәләхетдин гырлый, гырлаган тавышы урамга чыга, Олы су буена барып ишетелә.

Җәмил дә татлы уйлар белән йокыга тала, кулларын иснәп карый, бармакларыннан Сәкинәнең чәч исе килә...

Әнәснең юрганы идәнгә савылып төшкән, ул тезләрен чәнчеп бөгәрләнеп яткан, иреннәре чәпелди, иреннәре елмая, ул татлы төш күрә булса кирәк...

Таң ата. Олы су башы агара, таң җиле кыштырдап килеп җитә. Таң җиле кырлар, болыннар өстенә, Язкилде урамнарына туклык-татулык исен — башак исен алып килә. Кош-кортлар уяна, маллар калкынып бикле ишекләргә, капкага үрелә ләр.

Гәрәй-хан да куначадан очып төшә. Горур басып, кызгылт түшен киереп ишегалдын бер әйләнә, ике, һәм, пыр итеп очып биек читәнгә, Сәләхетдиннәр читәненә куна һәм дөньяны таң калдырырлык итеп иркен тавыш белән «кикри-күк!» дип кычкырып җибәрә.

**Нәни генә белешмә**

*Кошлар һәм хайваннар чыгара ала торган авазларның серен ачарга адәм уллары бик күптәннән омтылганнар. Кошларның «сүзлек составында» нинди мәгънәләр барын һәм аларның тавышлары аша, нинди хәбәрләр тапшыралар икәнен галимнәр бик күп еллардан тикшереп киләләр. «Казларның сүзлек составы» дигән китап Франциядә XVII гасырда ук басылып чыккан. 1800 нче елда немец натуралисты Ветцель эт, мәче һәм тавыкларның телләрен өйрәнеп махсус «Сүзлек» төзегән. 1807 нче елда Дюпон де Немур козгыннар «сүзлеге»н төзи. «Шул хезмәте өчен,— дип яза француз табигать галиме П. Флуранс,— де Немур ике ел дәвамында аяк-кулларын өшетеп бетерде». Инде бераз соңрак, 1890 елда америкалы Р. Гарнерның «Маймыллар теле» исемле атаклы китабы дөнья күрде. Өйрәнү хәзерге көндә дә дәвам итә. Тавыклар, мәсәлән, егерме алты төрдә сигнал бирә алсалар, чебиләрнең белеме сайрак — алар алты төрдә генә хәбәр сала алалар. Песнәк егерме төрдәге сигналларны белә...*

*Күрәсез, хөрмәтле укучым, кошлар телен өйрәнү безнең көннәрдә дә туктаусыз дәвам итеп килә икән! Язкилде авылыннан да атаклы спортсменнар гына түгел, берәр табигать галиме дә килеп чыгар әле мөгаен! Без ул чагында өченче июнь тирәсендә, талгын татлы җил исеп торганда, төрмә стенасы биеклеге читән башына менгән кызгылт әтәчнең ни хәбәр иткәнен, шаять, сезгә дә төшендереп бирә алырбыз. Әлегә, бигайбә, кичә шушы читән башыннан бәреп төшерсәләр дә курыкмаган әтәч, тагын менгән, якты таң агарткан дөньяны яңгыратып серле аваз салган:*

*— Кикри-күк!..*

*1979 — 1980 еллар.*

---

## Укучының күңел дәфтәренә

### Чуваш мәкальләре һәм әйтемнәре

*Авылдашлар югында авыл үзе дә булмый.*
*Кеше — кеше белән кеше.*
*Дустан мәхрүм калудан — үләттән үлү артык.*
*Ерактагы туганыңнан якын күрше яхшырак.*
*Яхшы агач начар җимеш бирми.*
*Юлга чыксаң юлдашың үзеңнән яхшы булсын.*
*Дуссыз кеше — тамырсыз агач.*
*Көтүдән аерылган сарык бүрегә ризык була.*
*Әйбер урланган төштә каракның кулы калмый.*
*Өрмәгән эт астыртын тешли.*
*Дошман башына дошманнар җитсен.*

*Берсен берсе юган куллар икесе дә чиста була.*
*Җәй сипкәнне кыш җыя.*
*Әле тотмаган аюның тиресен сатып йөрмә.*
*Суга кермичә йөзә алмыйсың.*
*Су янында йөргәндә аяк чыланмый булмас.*
*Ялкау этккә — үле куян.*
*Хаклык кояштан да якты.*
*Хаклык белән кыюлык — ике игезәк бала.*
*Тел ашыкмасын, кул тиз эшләсен.*

*Башың булса, чәче үсәр.*
*Олы юлдан килгән яшьлек — киткәндә сукмак эзли.*
*Түзә-түзә таш та ярыла.*
*Мактанчык кеше — буш янчык.*
*Гаеп яшерү — үзе бер гаеп.*
*Бер юләр зат югалтканны мең акыллың табалмас.*
*Ашлык кибәксез булмый.*
*Туңганны җылыт, ачка аш каптыр.*

*Яңгыр чылатса, кояш киптерә.*
*Кара тавыкның йомыркасы ак.*

---

## Фәнис Яруллин

### Өйрәт, тормыш

Гашыйк яшьләргә бирсәм мин
Бу дөньяның йөгенен —
Гашыйклар артык бәхетле,
Сизмәс афәт килгәнен.

Сабыйларга бирер идем,
Беркатлы алар артык —
Хәйләкәр, явыз кешеләр
Алып китәрләр тартып.

Гайрәтле ирләр кулына
Тапшырыр идем дә, тик
Көчлеләр көчкә ышанып
Саксыз кыланырлар бик.

Бирер идем акыл җыйган,
Күпне күргән картларга —
Ерак яшереп куярлар
Үзгәртмичә сакларга.

...Кемдә бар сабый сафлыгы,
Ирләр йөрәклелеге,
Гашыйкларның соклануы,
Картларның зирәклеге —
Дөньяны шуңа бирәмен,
Икеләнмичә бер дә.
Ә мондый күркәм сыйфатлы
Аналар гына җирдә.

### Туган көнеңә

Җирнең бер гади кызыдыр
Бәлки син күпләр өчен.
Миңа син — тылсымлы чишмә.
Йотлыгып эчәр өчен!
Бик күпләр әле белмиләр
Синең кем икәнеңне —
Гомерем бакчасындагы
Соңгы гел икәнеңне.

Белмиләр, синсез торганда,
Җаным буш икәнлекне.
Синең шунда оя корган
Соңгы кош икәнлекне.
Җирнең бер гади кызыдыр
Бәлки син күпләр өчен.
Миңа син — соңгы бер учак
Дөньялар суынган чакта
Җылынып китәр өчен!

## Куллар

1

Куллар мәңге иҗат итеп торган,
Шулай килгән борын-борыннан.
Куллар белән туган бөтен нәрсә,
Куллар белән дөнья корылган.
Тормыш дигән төзелеш мәйданында
Төземәгән куллар ни генә:
Ташны ташка бәреп утлар тапкан,
Җылы керткән куыш-өенә.
Шәрә тәнне куллар киендергән,
Ач тамакны куллар туйдырган.
Кешеләрне хезмәт кеше иткән,
Ә хезмәтне — куллар тудырган.

2

Иң беренче нинди сүз әйткәнмен,
Дөньяны мин ничек ачканмын?
Әниемнең итәгенә тотынып
Кайчанрак тәпи басканмын? —
Күп нәрсәләр инде онытылган,
Сакламаган хәтер боларны.
Мин ахрысы күзем ачу белән
Күргәнмендер эшчән кулларны.
Хәтеремдә: әнкәй киндер суга,
Ярты өйне алган станы.
Кулы ничек тотып өлгерәдер
Җеп корсаклы шома сосаны.
Ак җеп сузып выж-выж йөри соса
Әле сулга, әле уң якка,
Әйтерсең лә шаян үрдәк йөзә
Су салынган тирән улакта.
Ярдан ярга килеп бәрелә дә
Тагын чума дулкын-җепләргә.
Тәрәзәдән кергән нурлар белән
Әнкәй җебе сузыла күкләргә.
Җепләр, җепләр... Күпме эрләнгән дә
Күпме киндер шулай сугылган!
Ничә еллар кылыч төшмәгән бит
Ару белмәс әнкәй кулыннан.
Кылыч, ләкин сугыш кылычы түгел,

Тормыш кылычы, хезмәт кылычы,
Салкыннардан безне саклап килгән
Әнкәй кулларының җылысы.
Җылы безгә бик күп кирәк булды,
Бигрәк салкын иде еллары.
Кочаклардан безнең каерып алып
Әтиләрне сугыш урлады.

...Вакыт аргамагы алга чаба,
Куып тора еллар елларны.
Үткән белән бүгенгенең җебен
Тоташтыра әнкәй куллары.

## Өйрәт

Өйрәт, мине, тормыш,
Күп нәрсәгә өйрәт:
Мәңге чүкелә торган
Сандал булсын йөрәк.
Кеше күңеленә
Туры юллар өйрәт.
Сагыш күмәлмәслек
Олы моңнар өйрәт.
Җырга кертер өчен
Сихри сүзләр өйрәт.
Ул сүзләрдән кеше
Тетрәп куйсын кинәт.
Дошманнардан дусны
Аерырга өйрәт.
(Алдануың белү
Авыр бит ул бигрәк.)
Ач син серләреңне,
Юмартлыкка өйрәт.
Җанны кызганмаска
Нинди булу кирәк?
Өйрәт саранлыкка,
Саранлык та кирәк.
Вәгъдә өләшергә
Яратабыз күбрәк.
Тагын шуны белим:
Батырлыкка өйрәт —
Курыкмыйча керим
Янса да ут дөрләп.
Дөньяда ни булмас —
Куркырга да өйрәт.
Хыянәт эшләүдән
Гел курыксын йөрәк.
Өйрәт катылыкка,
Өйрәт йомшаклыкка,
Өйрәт горурлыкка,
Өйрәт сабырлыкка.
Өйрәт, әйдә, тормыш,
Сернең барчасына.
Тик өйрәтә күрмә
Зарланырга гына.

## Табыну

Булган заман —
Табынганнар потка,
Табынганнар утка.
Табигатькә, Ай, Кояшка,
Җансыз ташка...
Вакыт узган.
Табыну калган.
Кешеләр бит табына һаман
Яки малга,
Яки данга,
Кемдер көчкә,

Кемдер мәхәббәткә, хискә.
Кемдер җырга,
Кемдер кырга,
Кем — диңгезгә,
Ә кемнәрдер серле күзгә.
Берәү табына матурлыкка,
Берәү табына батырлыкка,
Берәү табына тапкырлыкка.
Кайберәүләр һич тә юкта
Табыналар үз иренә,
Хатынына, баласына.
Шыксыз гына бер кәчек тә
Әверелеп китә кайчак
Кемнәрнеңдер алласына,
Ә мин менә, мәҗүсидәй,
Табынып яшим һаман утка.
Нинди көчле давылда да,
Коеп яуган явымда да
Сүнми торган сихри утка —
Кешеләрнең күңелендәге
Нур сибүче яктылыкка?

●

Элек, никтер,
Сокланганны хәтерләмим
Сайрап торган тургайларга,
Ак чәчәкле тугайларга,
Очып үткән торналарга,
Шаулап аккан елгаларга,
Түшәктәй йомшак комнарга,
Еракка киткән юлларга,
Ымсындырган үр-тауларга
Сызылып аткан ал таңнарга...
Кая ул чак сокланырга?!—
Тургай бары кара нокта,
Ә чәчәкләр печән генә —
Малларыңа азык юкта.
Торналар — көз хәбәрчесе,
Суыкның соң яме бармы?
Ә елгалар язлар саен
Агызганнар коймаларны.
Комлык — буш җир, кемгә файда?
Анда бар да корып кипкән.
Юллар — әйләнеп кайтмаска
Әтиләрне алып киткән.
Таулар тагын бәла генә —
Арба тартып менә-менә
Үсми калган хәтта буйлар —
Ачу килә иде шуңар...
Ә шулай да бөтенесе
Сеңеп калган икән җанга.
Юкса сөенер идеммени
Сызылып аткан һәрбер таңга.

## Йөрәк

Ничә гасыр буе хирурглар
Аңлар өчен кеше йөрәген
Тырышканнар... ләкин йөрәк кенә
Яшереп килгән үзенең серләрен.
Скальпельләр камилләшә барган,
Арта барган һаман осталык.
Профессорлар тау-тау хезмәт язган
Өмет чишмәсеннән көч алып.
Һәм, ниһаять, егерменче гасыр
Якынайтып изге теләкне —
Кыюларның кулына ачкыч бирде,
Ачып карар өчен йөрәкне.
Хирурглар, сезнең кулыгызда
Күпме корал хәзер, күпме көч!
Сезнең өчен йөрәкләрнең хәзер
Калмагандыр инде сере һич.
Безнең генә — шагыйрьләрнең генә
Камилләшми һаман коралы.
Шуңа микән йөрәкләрнең серен
Белеп бетералган юк әле?!..

●

Үзеннән зур йөк күтәргән бер кырмыска
Оясына кайтып бара тиз-тиз генә.
Авыр йөген төшерми ул ялгышып та,
Ахры, йөге кадерледер бик үзенә.
Барган юлда биеклекләр очрап куйса,
Тын да алмый менеп китә, калмый өркеп.
Офыктагы ал яулыклы кояшка да
Сирәк-мирәк кенә ала күзен сирпеп.
Яңгыр яусын, җилләр бәрсен һич туктамый,
Һәр очраган каршылыкны җиңә кыю...
Юк, кырмыска түгел лә бу, син барасың
Күтәреп зур мәшәкатьле, авыр сөю.

## Рөстәм Кутуй

# СӨЕНЧЕ

хикәя

Эссе бөркеп торган тирәкләр тезелешкән юлдан күпергә табан бер атлы юртып төшеп килә. Күпергә кергәч, тарантасы яман нык дыңгырдап ала. Тарантас артыннан, кулларын кылычтай болгый-болгый, нидер кычкыра-кычкыра, ялан аяклары белән күпшек тузанга бата-чума, бала-чага чаба. Юл буендагы ала каргалар, канатларын салмак җилпеп, югарыга күтәреләләр дә, атлы узгач, яңадан җиргә төшәләр.

Көн үзәгендә чиллә кояшы отыры нык кыздыра. Шуңа күрәдер апак казлар судан чыкмыйлар — талгын инеш өстендә рәхәтләнеп йөзеп йөриләр. Чем-кара канатлы карлыгачлар исә күпернең астыннан ук очып чыгалар, һич курку белмиләр. Иске күпер сайгаклары ат тоягы астында моңсу гына ыңгырашып калалар.

Уенчык шикелле җыйнак өйләр тау итәгенә сыенып утырганнар да елтыр күзләрен кояшка төбәгәннәр. Юлаучы атын кырый йортның капкасы төбенә туктатты да, тарантасыннан төшеп, кулъяулыгы белән тирләгән муенын сөртеп алды. Ул арада малай-шалай, тузанлы юлдан тәмам туеп, чирәмгә тәгәрәште. Сыек кына япьле юкәгә кунаклаган чыпчыклар дөнья бетереп чыркылдашырга тотынды.

— Тәки куып җиттегез бит, әй! — диде юлаучы.

— Җиттек шул.

— Нык кудың да соң атны.

— Кавалерия шул без үзебез дә.

— Икенче юлы узып та китәрбез әле, — диештеләр малайлар.

— Каралып беткәнсез, карга куркытырлык булгансыз, — диде юлаучы.

— Коенгач, агарырбыз әле.

Юлаучы шунда кесәсеннән бизәкле кәгазьгә төргән конфетлар чыгарып җиргә сипте. Малайлар, чыпчыклар сыман, дәррәү ябырылдылар, аннары инде сабыр гына чәйнәргә керештеләр. Юлаучы алардан:

— Помыш белән йөрим бит әле. Маһруй карчыкның өен белмисездер? — дип сорады.

— Беләбез. Әнә генә ич. Капка төбендә кукырайган этәч йөренә.

— Бераздан атны да эчертәсе булыр әле.

— Үзебез эчертербез.

Кояштан күз чагыла. Юлаучы урам аша чыгып, кукырайган этәчкә якынлашты. Бер-берсенә усал гына карашып алдылар. Шуннан соң этәч, күзен алартып, кикриген кызартып булса да юл сабырга мәҗбүр булды.

Ачык тәрәзәдән радио уйнаганы ишетелә иде.

— Маһруй әби! — дип тавыш бирде юлаучы.

Малайлар:

— Чукрак ич ул! Ныграк дөбердәтегез. Председатель туп куймакчы иде әле. Күк күкрәгәнне дә ишетми ул Маһруй әби,— диештеләр.

Таяк белән кече капканы тукый башлагач, казык башларына кибәргә эленгән пыяла банкалар зыңлашып куйдылар.

Ап-ак пәрдәләрне як-якка аерып, тәрәзәдән пөхтә генә әби тышка күз салды. Әбинең кулында дисбе, иреннәре кыймылдый иде. Малайшалайга бу хәл көлке тоелды. Әби шул чагында гына эшләпәле чит кешене күреп алды. Әстәгъфирулласын әйтеп, кече капканы ачарга йөгерде.

Җеп шикелле нәзегәйгән чәч толымына таккан чулпыларын чыңлатып, иркен ак күлмәкле, арык гәүдәле, ачык йөзле карчык кояштай балкып килеп чыкты.

— Юлчы мин, узып барышлый сугылдым. Дронов дигән кеше буламын,— дип, танышырга исәпләп, теге кеше кулын да сузып караган иде югыйсә, әмма карчыкның чит кеше белән күрешәсе килмәде.

Башын кырын салып, җыерчыклы йөзенә елмаю галәмәте чыгарып, тыңларга әзерләнде.

— Кызың Алсу кереп әйтергә кушкан иде... Малай тапты бит Алсу... Онычың бар, ягъни мәсәлән...

Әби аның сүзен җүпләп ияген кагып торды, кояш ягына да ымлап алды. Гәрчә берни ишетмәсә дә, аңлаган булып кыланды. Чынында исә дөнья аның өчен әллә кайчан телсез киного әверелгән иде инде.

Аңлата алмый гаҗиз булды юлаучы.

— Инде ни хәл итим икән? — дип, эшләпәсе белән битен җилләтеп алды.— Ирен кыймылдатканны аңлар идең, ичмасам. Югыйсә кичкә хәтле берни төшендерә алмам... Ал-су ма-лай тап-ты! Ма-лай! Үә-үә!

Шабыр тиргә батты юлаучы. Ә бермәлне әбинең йөзкәйләре үзгәреп китте, кабаланып, канатлардай кулларын күтәреп төшерде, чулпыларын чыңлатып алды. Юлаучы моңа сөенеп, зиһененә тагы да ныграк сеңдерү нияте белән:

— Алсу шул. Онычың бар. Үә-үә! Әнә бит эшләр кая тәгәри. Мин үзем күрше авылга барам,— дип сөйләнде.

Бала-чагаларга кәмит күрсәтүдән бер дә ким түгел инде: Маһруй әби, юлаучының авызыннан күзен дә алмыйча, баскан урынында биеп тора; кызарынган, тирләп-пешеп чыккан абзый ике кулын болгыйболгый нидер төшендереп маташа. Тарантаска менеп кунаклаган малайларның көлә-көлә тәмам эчләре катты.

Онычының тууына тәгаен ышангач, Маһруй әби әлеге чит кешене җиңеннән әләктерде дә, ай-ваена карамыйча, алма бакчасына алып кереп китте. Русча фәкать «чичас, чичас»ны гына белгәнгә, дәшми тормас өчен, әлеге белгәнен кабатлады.

Август ае. Алмалар коела башлаган вакыт. Кызарып пешкән берәвесе, әнә, бакча уртасындагы өстәлдә ята. Агач араларыннан аяз күк йөзе күренә. Бакчада тып-тын.

Маһруй әби өстәлдәге пешкән алманы юлаучының кулына көчләп диярлек тоттырды да йөгереп кенә өенә кереп китте. Йөгерүенең дә рәте-чираты калмаган инде: атлаган саен мәзәк кенә чүлегеп куя да, егылмагаем тагын дигәндәй, кулларын як-якка болгап ала. Иләмсез дәү башмагы лаштыр-лоштыр килә.

Кунак эскәмиягә утырды да алмага тешләрен батырды, үз алдына гаҗәпләнеп сөйләнеп куйды:

— Августы да узып бара...

Шушы гади генә сүзләрдән нишләптер күңеленә әйтеп бетергесез рәхәт булып китте. Бакчадагы алма исе дә рәхәт өсти иде. Әнә, агач

төбендәге мәче дә, гамьсез генә борынын сузып, хуш исле саф һаваны сулый. Кунак һавада йөзеп йөргән нәфис пәрәвезнең битенә төшүен дә сизмәде — язгы ташудай узып барган гомеркәен уйлап, истәлекләргә кереп чумган иде. Күз алдында гына үрмәләп менүче елтыр үрмәкүчне дә күрмәде. Мәченең мыштым гына якынлашып, авыл халкына хас кызыксыну белән үзенә текәлеп торуын да абайламады. Уйлады да уйлады. Менә туа кеше, агачтан алма өзеп ашар өчен, бәхет җимешен татыр өчен туа... Менә ул яшен яшәгән, ашын ашаган. Маһруй карчыкка яхшы хәбәр китерде; Маһруй әби, гәрчә колагы ишетмәсә дә, аның изге хәбәр китерүен күңеле белән сизде, куанычы йөзенә чыкты... Хәлдән тайган бал корты кап-кайнар өстәлгә төшеп егылды. Агай аны алып учына салды, саклык белән генә өрергә тотынды. Шуннан бал корты, гүя кечтеки генә самолет, канатларын эшкә җикте — пырылдап очып китте, озакламый күздән үк югалды.

Ул арада Маһруй әби өстәлгә ап-ак эскәтер китереп япты, өстәл күрке итеп кояштай ялтырап торган җиз самоварын китереп утыртты, кызыл бизәкле чынаякларын куйды, вареньесын алып чыкты. Үзе һаман:

— Сөенче бит, сөенче...— дип кунагына таныш түгел сүзне яратып кабатлады. Хәер, аның калтырап чыккан тавышыннан бу сүзнең тирән серен, тылсымлы көчен аңлау читен түгел иде.

Чәй эчмичә генә табын янынннан торып китәргә базмыйча, кунак сыйланырга булды, эш юктан гына, самовар корсагында иләмсез төскә кергән кыяфәтен күрсәтте. Маһруй карчык аны, улыдай якын күреп, сыйларга керешә, хәтта бушап калган көзге җир шикелле арык кулы белән аркасыннан да сөеп куйды. Аның башындагы чәчәкле ак яулыгына, күгелҗем чык тамчыларыдай җемелдәгән колак алкаларына, җыерчыклы келәч йөзенә, гомер буе тынгы белмәгән, әле дә табын буйлап житез йөргән кулларына карап тора торгач, кунакның кинәт күңелләренә рәхәт бер талгынлык йөгерде, һәм ул, карчыкның аны аңлау-аңламавын бөтенләй кайгыртмыйча, кинәт кенә теле ачылган кебек, сөйләп китте:

— Минем дә әнием исән бит әле. Уймак дип йөртәм үзен. Бәпбәләкәй ул. Мин бит иләмсез зур. Менә табулары, ай-һай, кыен булгандыр. Йөкле чагында шулай бер мәлне нәүрәпкә тәгәрәп төшкән. Күк күкрәүдән коты алынган да, аны-моны абайлап тормаган инде, билгеле. Ә миңа чуртым да булмаган. Үзе әле хәзер дә минем өчен ут йотып яши. Суык тимәсен дип, җылы оекбашлар бәйли. Кайттым исә, еларга тотына. Үзе, рәнҗетмим тагын дип, елмаеп азаплана. Кин күңелле, сокланмгыч бер зат инде әнием...

Маһруй әби, гәпләшенең һәр сүзенә төшенгән кеше төсле, ияк кагып, ул сөйләгәнне җуплап утырды, аннары көйле тавышы белән:

— Сөенче бит, сөенче,— дип кабатлавын белде.

Бакчада яфраклар талгын гына кыштырдашалар, гәпләшеп утыручы ике кеше өстенә күләгә төшерәләр. Һәммә җиргә тынлык үзенең үтә күренмәле канатын җәйгән сыман. Һәммә нәрсә гүя үз урынын да, колакны рәнҗетерлек бер генә аваз да ишетелми.

Кунак, сыйлаган өчен рәхмәтләр әйтеп, әбине кочаклап саубуллашты да бакча ишегенә табан атлады. Әмма карчык аны тукталырга мәҗбүр итте:

— Чичас, чичас,— ын кабатлап, бакчаның түренә йөгерде.

Озак та үтмәде, бер алъяпкыч алма күтәреп килеп тә чыкты. Кызарып пешкән эре-эре алмалардан искиткеч тәмле ис бөркелә, авыздан сулар китерә. Маһруй әби алмаларын алъяпкычы-ние белән юлаучыга сузды, үзе әлеге дә баягы:

— Сөенче, сөенче. Рәхмәт инде! — дип бер үк сүзләрне кабатлады.

Кунак бу сүзне Маһруй әбинең яраткан бер сүзе диеп кенә кабул итте һәм тизрәк саубуллашу ягын карады.

Коймага бәйләп калдырган аты зарыгып көтә иде. Урам бушап калган. Юлаучы башын күтәреп күккә карады. Зәңгәр күк йөзендә алама бер болыт кисәгеннән гайре берни күзгә чалынмый.

Тарантас җай гына кузгалды. Кояш, атның янбызына төшеп, көмеш тәскә кертә. Ак алъяпкычтагы алмалар ул арада сикерешә дә башладылар. Баягы малайлар авыл очындагы койма курасына кунакланнар. Әле генә судан чыкканнар да юеш чәчләрен сыйпаштыргалап азапланалар иде.

Юлаучы аларга:

— Сау булып торыгыз,— диде.

Малайлар исә:

— Хушыгыз. Икенче юлы барабан ала килегез,— диештеләр.

Тарантас яңадан үрне төште, биек тирәкләрнең нәкъ уртасыннан ярып узды, иске күпердән дыңгырдап алды. Тарантаска печән салынган иде, хәзер менә шул печән гүя саф көч, яшәү дәрте бөркеп тора. Юлаучы, бер алманы учында биетеп, авыз эченнән генә нинди́дер көйне сузып маташты. Уйлары һаман әле Маһруй әби тирәсендә тулганды:

— Күр инде, туган улымыни!

Шул чагында үзенең әбисе хәтеренә килеп төште. Гомер буе Жихариха булып йөрде, йөрде дә үләр көннәре килеп җиткәч кенә чын исеме ачылды: Софья Тарасовна икән ләбаса Жихариха дигәнең! Олы караватның бер почмагында бөрешеп кенә яткан иде. Чия чәчәк аткан чакка туры килде. Улыннан хат-хәбәр көтеп тилмерде, бичаракай. Тиктомалга югалды да куйды улы. Урамга чыккан җиреннән ай күрде, кояш алды. Каян табасың ди аны, үзе хәбәр бирмәгәч. Әбисенең арада бер яраткан, иң чирләшкә, иң майкап улы иде шул үзе дә. Сыбызгы ясаудан башканы белмәде, бер генә һөнәре дә юк иде. Аркасына ертык биштәр асып, сыбызгысын сызгырта-сызгырта, дөнья гизәргә китеп баргандыр инде. Ярты ел буена ник бер хәбәре килсен. Шуның хәсрәтеннән әби кеше тәмам түшәккә егылды. Саташкан чагында да коргаксыган иреннәре белән: «Кайтсана, кошчыгым... Кайтсана, багалмам...» — дип кабатлады. Кошчыгы туган оясына кайтмады да кайтмады. Канатында тагын юньле хәбәр дә китермәде. Югыйсә, күрше-күлән дә, шул ук гозерне кабатлап, дога кылып карады. Файдасы барыбер тимәде...

Юлаучы гүя әллә кайчангы язны яңадан күрде, чия чәчәгенең татлы исен иснәгәндәй булды.

Шунда гына ят сүзнең төп аслына төшенде. Ни икән бит, әй, яхшы хәбәр китергән кешегә шулай бүләк бирәләр икән бит! Чукрак карчык кабатлаган матур сүз әнә шул гадәтне аңлата икән ич!

— Сөенче,— дип куйды юлаучы үзалдына.

Ул арада инде авыл сырт артында, түбәндә утырып калган иде.

Ә менә минем үземнең берәрсенә изге хәбәр китергәнем булдымы соң?

Моңарчы гомеремдә дә алай дип уйлаганым булмады: көн артыннан көн агылды, як-ягыма борылып карарга вакыт тимәде. Менә хәзер тукталдым да гомер юлыма ныгытып күз салдым.

Тирән хәтер коесыннан учым белән суны бушатырга азапланып, бер сәгать утырдым, ике сәгать... Кешеләрнең йөзләре бер-бер артлы караңгылыкка кереп югала торды, хәтерем исә беткәннән-бетә барды. Шулай ук берәүгә дә куанычыннан тетрәндерерлек хәбәр китергәнем булмады микәнни? Бер дә әйбәт түгел бит әле. Күр инде, чигәгә кан йөгерде. Иң җиңеле: ник булмасын, булгандыр, диясе дә — вәссәлам!

Үз-үзеңне алдап булмый икән. Үҗәтләнеп, хәтеремнең иң ерак, иң караңгы почмакларына күз салам. Тик берни таба алмыйм. Тынлык үземне һич кенә дә читкә җибәрми, гүя кыршау кысылганнан кысыла бара. Хәтта карусыз дусларым — китапларым да миннән йөз чөерделәр.

Шулчак хәтеремә Гильен шигыре килә:

Дөньяда бит мин туганны
Беркем көтеп тормаган...

Бик үк алай сөенерлек түгел инде бу юллар.

Хәрабәләр эчендә калмадым калуын, шулай да бер сорау һич тынгы бирми миңа: гомер эчендә бер сөенечле хәбәр китергәнем булдымы кешегә, әллә юкмы?

Русчадан **Кыям МИҢЛЕБАЕВ** тәрҗемәсе.

---

## Укучының күңел дәфтәренә

**Якут мәкальләре һәм әйтемнәре**

*Ялгыз йомырка бик тиз бозыла.*
*Бер ахмак нәрсәдер җуйса йөз акыллың табалмый*
*Ике аягы барның бер теле булмый калмый.*
*Күп йөргәннәрнең аягы керле, күп сөйләгәннең авызы пычрак.*
*Бер төкергән төкерегеңне кире йота алмыйсың.*
*Җәяүлегә җайдак тиң түгел.*
*Симез эт белән саран бай — икесе дә бер төсле*
*Пычак үз сабын кисми.*
*Җил теләсә кайсы яктан исә.*
*Яхшы сүздән зуррак байлык юк.*
*Кул авырткан җирне сыйпый, күз яраткан затка төшә*
*Мәхәббәт күздә яши.*
*Атны йөртеп алалар, юлны йөреп беләсең.*
*Җайдакка кизләү күрсәт, җәяүлегә таяк бир*
*Буш сүз сөйләү — комнан бау ишү.*
*Чүп сүзнең хатасы булмый.*
*Көчсез кеше бәхәс ярата.*
*Көймәсенә утыртты да ишкәкләрен бирмәде.*
*Кешегә дип баз казысаң, үзең килеп төшәрсең*
*Күп мөгрәгән сыерның савым сөте аз була.*
*Кизәнү дә, сугу да — икесе үк бер нәрсә.*
*Аюның үзен күргән дә эзе буйлап эзләп киткән.*
*Диңгездә батучылардан бокалда батканнар күбрәк.*
*Бер сөзелгән сыерны барча сыер да сөзә.*
*Җеп нечкә җирдән өзелә, пычак очыннан сына*
*Хатынны назлау кирәк, бала — иркәләүне сөя, камчыны болгау яхшы, ә мылтыкны — чистарту.*
*Тамырсыз кеше — төп башы.*
*Тузмый торган кием юк.*
*Яшел агач кортлы булалмый.*

---

## Равил Фәйзуллин

# АВЫЛ ДӘФТӘРЕ

### Туган ягым

Беләм, кояш астында бар
шундый шифалы яклар:
кадасаң чыбык җиренә —
яшьнәп чыга яфраклар!

Минем дә бар үзем өчен
шундый як — Туган ягым:
дога иңгән һәр төшеннән
чишмәләр чыга аның!

Анда кайтсам — күз алышына,
күрмим фәкыйрьлеген дә...
Кара уйга урын юк шул,
нур тулгач күңелеңә!

Тычкан утын — учак саныйм,
картны яшь итеп күрәм.
Һәрбер сайраган кош — былбыл,
гөл — һәрбер үскән үлән!

Учак урыны кебек һәр төш —
баскач — табанны пешерә!
Һәр тараф — Илемә булган
бурычны искә төшерә.

...Өсте генә көл үткәннең,
терелә ут — өр генә!
Һәр сулышың бер җыр монда,
вакыт тап, кайт, йөр генә!

●

Инешләр ага да ага.
Ә таллар торып кала.
Кешеләр килә дә китә.
Таулар утырып кала.

Таулар, таллар күпне белә.
Тик алар дәшми генә...
Алар өченме күк күкрәп,
сызды бер яшен әнә?

## Йолдызлы күк гөмбәзе астында

*Чистайларның уты күре-*
*нә диләр,*
*Аюкүл түбәләреннән*
*карасаң...*

Жырдан

Алатай чишмәсе, Тәпәнлек үзәне...
Таубашы мәйданы, Әчебаш урманы...

Ни бары —
бер меңләп кешегә газиз бу исемнәр.

Энҗеле-йолдызлы күк-гөмбәз астында
Җир кебек, борыннан яши бит алар да!
Үзәннәр,
инешләр,
аланнар...

Авылдашлар өчен алар —
үзләре дә ишетмәгән —
Килиманджаро,
Кояшлы сукмаклар,
Ниагаралар...

Бу бәләкәй бөек кешеләрнең
күккә сыймас шатлыкларын,
дөнья кадәр хәсрәтләрен
үзләрендә саклый алар
буыннан — буынга,
дәвердән — дәвергә.

## Авыл. Кич. Капка төбе

Ятсыныпмы, сагаепмы,
авылдашлар җайлап кына,
сөйләшәләр урап-урап,
сүзләрне бик сайлап кына.

Күренеп тора — ачылмыйлар,
бик чишелеп китәргә юк
исәпләре. Ишетәм гүя:
«Бүген бар син, иртәгә — юк...»

Мин дә артык эчкә кермим,
әйткәннәрен җөпләп торам.
Тыштан бер сүз, эчтән һәркем
үз уйларын үзе кора.

Мин дә эчтән үземә әйтәм:
«Туйдырма син, ялыктырма!..»
Тәмәке төтене аша
күрәм — йортлар, яңа урам...

Әнә, бабамнар нигезе...
Хәзер анда кем бурасы?
Агайларның исемен белмим,
«кемнеке?» дип бик сорасы...

Аннан китәм ялгыз. Юлым —
чишмә буе, зират, урам...
Күп торсам Туган нигездә
тагын бер-ике көн торам.

Сау булыгыз, авылдашлар!
Мин бит монда кунак кына...
Ял итәргә дулкынына
кунган акчарлак кына...

## Әйтелмәгән монолог

*Нәбиуллина Шәмсенурның*
*якты истәлегенә*

Туфрак,
үлән,
аваз,
яңгыр — барсы БЕЗ.

Бүтән инде мәңге картаймам мин...

Шушы таулар кебек,
йолдызлар күк
калырмын мин үзгәрешсез
кемнәрнеңдер хәтерендә.

Бүтән инде мәңге картаймам мин.
Соңгы сурәт булып, шушы төс калыр:
салынкы йөз, талчыккан күзләр...

Кичке уенлы кыз чакларны беркем белми.
Яшьтәшләрем бар да гүрдә. Карточкада сурәтем юк.
Җир җимерткән таза чакны күпләр белми.
Бик аз калды замандашлар...

Бу соңгы чик сурәте дә җуелыр бер,
офыктагы шәфәкъ шикелле,
әле исәннәр күңеленнән...

Ә шулай да, боекмагыз,
бүген җиңү минем, оланнар!
Бүтән инде мәңге картаймам мин!..
Мәңге картаймам...

## Яшьлегендә чибәр булган бер чал әби сүзләре

*Кем белән каралдың —*
*шуның белән агар!*

Әнисенең әйткән сүзе

— Башта ни карадың?

— Күзенә карадым!
Зәп-зәңгәр күзенә!..
Күзендә чагылган
үземә карадым!
Аннан соң... изерәп,
җәйге төн күгенең
йөзенә карадым...

Әрләмә, каргама,
хәлемә кер, әни!
Мин теләп алдым бит
бәхетле ярамны!
Ышанасыңдыр бит —
мин фәкать агардым!
Күңелем агарды!

Уйларым агарды!
Сөюдән кешеләр
чистара бит бары!

Тик аннан соң гына,
ятларның сүзеннән
йөзләрем каралды...

...Әнием, рәнҗемә!
Мин тагын агардым.
Йөзләрем агарды.
Чәчләрем агарды...
Кабере генә аның
(син белгән егетнең!)
тора әле каралып...
Бураннар керүгә
ул да, әни, агарып,
агарып...

## Мираж

*Ю. Әминовка*

Су өсләп томанда —
күренә
        берьюлы
                бар да:
ап-ак чияләр дә,
        кызыл баланнар да,
                бәс сарган таллар да...

Бар да—
йөгерәләр минем алга!
...Көтә алмыйм шул вакыт тарга!

Ниндидер бер ялгыз акчарлак
һаман минем белән—
бәргәләнә җанда,
үрсәләнә җанда!

●

Элекке калын урманның
калган тышы гына!
Ярты чакрымнан күренә
очкан кошчыгы да...

Кая серле землянкалар?
Качкын сукмаклары?
Хәтерләсә хәтерлидер
кара карга бары...

●

Туган якның һәр нәрсәсе
гадәтидән бүтәнрәк.
Имәннәре — гел баһадир!
Ә күлләре — түп-түгәрәк!
Үрләре дә биек тау күк!

Авылдашлар өчен
үзең генә
булганыңнан һәрчак кимрәк...

## Туганнарга

*Бергә чакта үскән идек,*
*Тал тамырлары кебек!*

Жырдан

Безне бергә кайчак кайгы гына
җыя хәзер Туган нигезгә...
Без төрлебез төрле тарафларда
мәшәкатьле Тормыш — диңгездә.

Шатлыкларның, хәтта бәйрәмнәрнең
көче җитми очраштырырга.
...Ә бит беркөн беребез ким булып,
туры килер басып торырга!

*1979 — 1980*

# КПССның XXVI СЪЕЗДЫ КАРАРЛАРЫН — ТОРМЫШКА!

## МАКСАТЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ

*Халык хуҗалыгы бурычларын хәл итүдә югары уку йортларының фәнни потенциалын файдалануның нәтиҗәлелеген күтәрергә.*

«1981—1985 елларга һәм 1990 елга кадәрге СССРның экономик һәм социаль үсешенең төп юнәлешләре»ннән.

### I. Иҗат рухы



Иптәш Л. И. Брежневның Үзәк Комитет исеменнән ясаган Отчет докладын, КПССның XXVI съезды материалларын укыганда, иҗади программаның колачына гаять зур горурлану хисе кичерәсең. Аның һәр өлеше халыкның тормыш хәлен яхшырту, җәмгыятьнең һәр членына камил үсеш тәэмин итү турында олы кайгыртучанлык белән сугарылган. Чын мәгънәсендә, фәнни нигезгә корылган реалистик, гуманлы программа! Шуның белән бергә әлеге программаның уңышлы төстә тормышка ашырылуы һәркайсыбызның гомуми эшкә кертә торган өлешенә, куелган максатларны үтәү өчен чаралар сайлауга аңлы, партиячел, компетентлы якын килүгә бәйле икәнен аңлыйсың. Һәм үзеңә йөкләнгән эш өчен гаять зур җаваплылык хисе тоясың. Фән белән шөгыльләнүче кешегә исә икеләтә җаваплылык төшә. Чөнки фән — социалистик җәмгыятьнең бәяләп бетергесез хәзинәсе. Фәннең турыдан-туры житештерүче көчкә әверелә баруы хакында Маркс ачкан законның тирән мәгънәсе бүгенге шартларда аеруча ачык күренә. Без фәннең, эш коралларына һәм чараларына әверелеп, житештерүче көчләрнең матди элементлары тамырдан үзгәрүенә шаһит. Бу җәһәттән «Төп юнәлешләр...» дә анык, әйтергә кирәк, революцион программа билгеләнгән. Бу программа үзенең ахыргы нәтиҗәләре белән тирәнтен социаль әһәмияткә ия. Фәннең бүгенге казанышлары нигезендә техника, технология һәм хезмәт средстволарын тагын да үстерү, житештерү мөнәсәбәтләрен, барлык башка мөнәсәбәтләрне камилләштерә, хезмәтне җиңеләйтә, аның иҗади үзенчәлеген көчәйтә, буш вакытны арттыра, шәһәр белән авыл, акыл хезмәте белән физик хезмәт арасындагы аермаларны эзлекле төстә бетерүгә булыша.

Шул ук вакытта фән җитештерүче көчләрнең шәхси элементларын, ягъни кешеләрне камилләштерүгә хезмәт итә. Һәм җәмгыятьнең зур рухи байлыгы да ул. Партиянең XXVI съезды карарлары бу байлыкны хезмәт кешесенең шәхесен формалаштыру һәм үстерү өчен тулырак файдалануны да күздә тота. Аларның рухландыргыч көче — иң элек фән һәм техника үсешенең гуманистик асылында. Фәннең теге яки бу өлкәсендә эшләгәндә аның нәтиҗәләре совет кешеләренә хезмәт итәчәген алдан ук белеп торасың.

Бу җәһәттән ирексездән фән кешеләренә багышланган әдәбият, публицистика һәм сәнгать әсәрләрен хәтердә барлыйсың да, үз-үзеңә сорау куясың: аларда игелекле фәнни максатларның социаль асылы, гыйльми проблемаларны хәл итү өчен фидакарь эзләнүләрнең эчке мотивлары, фән кешеләренең фикер көрәше тирәнтен ачыламы соң? Кызганычка каршы, һәммәсендә дә түгел. Ә бит зур,

атаклы галимнәрне тирә-юньдәге күренешләрне танып-белү омтылышы гына түгел (хәер, бу — үзе генә дә зур этәргеч), ә барыннан да бигрәк халкыңа, илеңә хезмәт итү кебек бөек идеаллар рухландыра.

Съезд материалларында алда торган бурычларны хәл итүдә югары уку йортлары фәненең роле үсәргә тиешлеге басым белән күрсәтелә. Мәгълүм ки, 1978 елның 6 апрелендә КПСС Үзәк Комитеты һәм СССР Министрлар Советы, «Югары уку йортларында фәнни-тикшеренү эшләренең нәтиҗәлелеген күтәрү турында» карар кабул итеп, игътибарны гыйльми көчләрне экономик, социаль яктан илебезне тагын да үстерү планнарында каралган иң мөһим проблемаларны хәл итүгә туплаРга кирәклегенә юнәлткәннәр иде. Әмма фән һәм техниканың актуаль мәсьәләләрен академия һәм тармак фәнни учреждениеләре хәл итәргә тиеш, ә вуз фәне ирешелгән казанышларны популярлаштыру белән генә шөгыльләнсен дигәнрәк фикер белән әле хәзер дә очрашырга туры килә. Югыйсә, уйлап баксаң, фәнне үстерү һәм техника үсешен тизләтүнең гаять зур колачлы программасын югары уку йортлары фәненнән башка ничек ерып чыгарга мөмкин? Вузларда, Отчет докладында Л. И. Брежнев күрсәтеп үткәнчә, фән докторлары һәм кандидатларының яртысы диярлек тупланган лабаса. Сүз дә юк, вуз һәм «саф» фәнни-тикшеренү институтлары эшендә үзенчәлек бар. Сүз дә юк, вуз хезмәткәре берничә эшчәнлекне (фәнни, укыту, тәрбия, җәмәгать, хәтта кайбер очракларда производство эшчәнлекләрен) берьюлы башкара. Әмма шуларның нигезендә фәнни эшчәнлек өстенлек итә. Бүгенге вуз укытучысын бүтәннәр тарафыннан тупланган фәнни белемнәрне популярлаштыручы итеп кенә күз алдына китерү мөмкин түгел. Ул — беренче чиратта «идеяләр генераторы», аннары гына фәнни белемнәр авторларыннан берсе. Алай гына да түгел, ул — хәзерге шартларда үзенең һәм башкаларның идеяләрен гамәлгә кертү өчен башлап йөрүче, һәрхәлдә, шулай булырга тиеш. Фәнни һәм укыту-тәрбия эше арасында «кытай стенасы» була алмый. Укыту процессы хәзерге заман фәне һәм техникасы казанышларына (әлбәттә, ул казанышларның тарихи юлын да кертеп) корылуы, хәзерге производство һәм культура дәрәҗәсенә йөз тотуы зарур.

## 2. Гыйльми мәктәп булдыру җиңелме?

Баштан ук әйтеп үтик: В. И. Ульянов исемендәге Казан дәүләт университетындагы һәм элекке, һәм әле юл ярып кына килә торган төп гыйльми юнәлешләр фәнне үстерү, техника прогрессын тизләтү буенча партия съезды билгеләгән бурычлар белән бик аваздаш.

Фән юлына җитди адым ясаган һәр кеше фән тарихында, чын эшләрдә, эз калдырырдай мәктәп яки юнәлеш булдыру турында хыялана. Ләкин мондый бәхеткә һәркем ирешми. Фәнни иҗат тарихы белән азмы-күпме таныш кеше яңа гыйльми мәктәп яки юнәлешнең ничек һәм нинди кыенлыклар аша барлыкка килүен яхшы белә. Тик яшәп килгән мәктәпнең абруен саклау яңасын тудырудан җиңелрәк эш түгел. Сүз традицион эзләнүләр кысасында яңа, перспектив, фундаменталь юнәлешләрне тотып алу зарурлыгы хакында бара ич. Бу исә, беренче чиратта, гыйльми остазның үз шәкертләрен яңа идеяләр белән ничек мавыктыра, яңа максат һәм аңа ирешү чаралары белән ничек коралландыра алуына бәйле.

Фән-техника революциясе колач җәйде, дибез. Ә революционерларсыз революция була аламы? Юк, чын фән революционерларыннан башка фән-техника революциясе киңәя дә, тирәнәя дә алмый. Гыйльми мәктәп һәм юнәлешләр шундый революционерлар җилкәсендә бара.

Казан университеты үзенең фән революционерлары белән элек-электән дан тота. Әйтик, химия мәктәбе турында сүз чыктымы, ул академик Борис Александрович Арбузов, аның күп санлы шәкертләре йөзендә алга килеп баса. Ул бүгенге химия мәктәбенең төп үзәген билгеләп, буыннар арасындагы күпъяклы бәйләнешларның уртасында тора.

Әгәр багланышларның үткәненә бер караш ташласак, алдыбызга Ватан фәненең горурлыгына әверелгән галимнәрнең образлары җанлана. Әлбәттә инде, иң элек, бу мәктәпнең бишеге янында торган, үзенең лабораториясен Россиядәге алдынгы химия фикере үзәгенә әйләндергән Н. Н. Зинин образы күз алдына килеп баса. Казан химикларының революциягә кадәрге төркемендә А. М. Бутлеров та аерым бер урын тота. Аның эшен шәкертләре Б. В. Марковников, А. М. Зайцевлар дәвам итә, аннары ул дәвам үз гомерен органик фосфор һәм органик күкерт кушылмаларын өйрәнүгә багышлаган, фосфор органикларының мәктәбенә нигез салган А. Е. Арбузовка килеп тоташа. Аның белән бергә күренекле шәкертләре — Б. А. Арбузов, В. В. Евлампиев, Л. Н. Парфеньев, А. И. Разумов, Г. Х. Камай һәм башкалар эшләде. 200 дән артык хезмәт язган А. Е. Арбузовның хезмәтләре Совет хөкүмәте тарафыннан югары бәяләнде: 1943 һәм 1947 елларда аңа Дәүләт премияләре, 1957 елда Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелде, алты Ленин ордены белән бүләкләнде. Ул фәндә талантлы оештыручы һәм зур җәмәгать эшлеклесе иде. А. М. Бутлеров исемендәге химия фәнни-тикшеренү институтына нигез салып, аның директоры булды, озак еллар органик химия кафедрасын, СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалын җитәкләде.

Аңардан эстафетаны улы һәм хезмәттәше Б. А. Арбузов кабул итеп алды. Ул 1960 елдан бирле университеттагы химия институтының директоры. Галимгә 1951 елда Дәүләт премиясе, 1978 елда (А. Н. Пудовик белән икесенә бергә) Ленин премиясе бирелде.

Б. А. Арбузов — күп төрле фәнни һәм җәмәгать мәнфәгатьләренә ия шәхес. Ул үзенең остазларыннан актив тормыш позициясен, коллектив белән эшләү осталыгын кабул итеп алды. Аның фән өлкәсендә, укыту һәм оештыру эшендә зур сәләт күрсәткән күп санлы шәкертләре бар. Җеп аңардан университетның химия мәктәбе традицияләрен бүген һәм иртәгә үстерәсе шәхесләргә сузыла. Яшьләрне тәрбияләүдә Б. А. Арбузовның шәхси сыйфатлары зур роль уйный. Профессор А. И. Коновалов, мәсәлән, шул остазыннан соң органик химия кафедрасына җитәкчелек итеп, фәндә яңа сүз әйтергә өлгерде, Казан химиклары мәктәбенең данын арттыру, халык хуҗалыгының катлаулы бурычларын хәл итү хакына тикшеренүләрне уңышлы дәвам иттерә. Ул хәзер университетның ректоры иде.

Монда дәвамчанлык, галимнәрнең киң карашлы, иҗтимагый актив булуы, фән алдында, халык алдында җаваплылык хисе тоюлары сәбәпле Казан химиклары мәктәбе — фән-техника прогрессының һәрчак алгы сызыгында. «Төп юнәлешләр»дә алдан билгеләнә торган үзенчәлекләргә ия булган яңа матдәләр һәм материаллар алуның химик-технологик процессларын булдыру, яңа дарулар эшләү, үсемлекләрне химик саклау чаралары җитештерү, синтетик каучук чыгаруны арттыру, югары сыйфатлы полимерлар табу зарурлыгы әйтелә. Безнең университет химиклары бу бурычларны хәл итүгә сизелерлек өлеш кертә алалар. Аларның фәнни бурычлары шушы проблемалар белән бәйле.

Невклид геометриясенә нигез салган Н. И. Лобачевскийдан башлап, Н. Н. Парфентьев, В. А. Яблоков, П. А. Широков, Г. М. Гагаев, М. И. Әлмөхәммәдов, шулай ук Н. Г. Четаев, Н. Г. Чеботарев, В. В. Морозовлардан соң хәзерге өлкән буын вәкилләре Б. Л. Лаптев, А. З. Петров, А. П. Норден, Ф. Д. Гахов, И. Г. Салихов, Г. Г. Тумашев, М. Т. Нужин һәм аларның күп санлы шәкертләренең математиклар мәктәбе хакында да иркенләп сөйләргә булыр иде. Даны дөньяга таралган физиклар мәктәбен дә читләтеп узарга ярамас. 1944 елда Е. К. Завойский ачкан парамагнит резонансы физикада яңа өлкәгә — магнит радиоспектроскопиясенә нигез салды. Ул хәзер СССРда, АКШта, Англия, Франция, Япония һәм башка илләрдә кызу темплар белән үсә. Е. К. Завойский башлап җибәргән юнәлеш С. А. Альтшулер җитәкчелегендә дәвам иттерелә. Хәзер парамагнит резонансы өлкәсендәге бу зур галим һәм мөлаем кешенең шәкертләре — Ш. Ш. Башкиров, Б. И. Кочелаев, Н. Н. Непримеров, М. М. Зарипов, К. А. Вәлиев һәм башкалар уңышлы эшли.

Вузларда яңа гыйльми юнәлешләр төрле юллар белән барлыкка килә. Берәүләре традицион фәнни мәктәпләрдән аерылып чыга, икенчеләре күрше фәннәр белән

чиктәш өлкәләрдә туа, өченчеләре социаль практика, дүртенчеләре яңа белгечләр буенча кадрлар әзерләү ихтыяҗлары җирлегендә борынлана. Ләкин һәр очракта да иң мөһиме — фән-техника үсешенең, экономик һәм социаль прогрессның төп тенденцияләрен, яңарак, киләчәге өметле юнәлешләрне күз уңында тоту.

Әйтик, бездә 1978 елда механика-математика факультетыннан хисаплау математикасы һәм кибернетика факультеты «башка чыкты». Хәзерге производствоны күтәрүнең төп юлларыннан берсе — аны автоматлаштыру һәм аңа җитәкчелекнең югары дәрәҗәсен тәэмин итү. Бу бурычларны хисаплау техникасыннан башка хәл итеп булмый. Шуңа күрә халык хуҗалыгында хисаплау математикасы һәм кибернетика белгечләренә ихтыяҗ бик зур һәм ул арта барачак.

Казан университеты галимнәре, шушы ихтыяҗны алдан күреп, фәнни тикшеренүләр һәм белгечләр әзерләү эшен байтактан башлап җибәрделәр. 1957 елда математик анализ лабораториясе булдырылды. Фактта бу — Казанда беренче хисаплау үзәге иде. Әзерлек эшен алгебра кафедрасы мөдире В. В. Морозов башкарды. Ул әлеге тармакка Я. И. Заботин, А. В. Сульдин, Н. Т. Халитов, В. И. Шуликовский, Р. Г. Бохараев кебек сәләтле яшьләрне тартты. 1958 елда хисаплау математикасы кафедрасы ачылды. Анда 60 нчы еллар ахырында гомуми һәм махсус математик анализ буенча яңа юнәлеш үзенә юл ярды. 50 нче елларда кибернетика проблематикасы үсә башлады. Һәм менә 70 нче еллар ахырында белгечләр әзерләүгә керешелде. Факультет студентлары электрон-хисаплау машиналарын конструкцияләү теориясе буенча белгечләр һәм система программистлары булып чыгалар. Мәгълүм ки, «Төп юнәлешләр...»дә табигатьне саклау чаралары махсус бүлеккә туплап бирелгән.

Галимнәребезнең алдан күрүчәнлеге нәтиҗәсендә университет табигатьне саклау өлкәсендәге чараларның нәтиҗәлелеген күтәрүгә өлеш кертергә әзер. 1969 елда ук, СССРда беренче буларак, университетта табигатьне саклау һәм экология кафедрасы ачылды. Аңа мәрхүм профессор В. А. Попов җитәкчелек итте. Әлеге өлкәдә белгечләр әзерләү белән беррәттән, табигатьне саклау теориясен эшләүгә керешелде. Бу кафедрада нәтиҗәле экологик система булдыру максатында шәһәр һәм шәһәр яны территорияләрен өйрәнү үзәктә тора.

Билгеле, сөйләнгәннәрдән Казан университеты фәне гел танылган гыйльми мәктәпләрдән һәм яңа юнәлешләрдән генә тора икән дигән нәтиҗә ясарга кирәкмәс. Кызганычка каршы, күп кенә гыйльми подразделениеләр тема ваклыгыннан җәфа чигәләр. Гыйльми көчләр аерым-аерым эш итә. Кайбер хезмәткәрләр тырышлыкларны зур, чиктәш проблемаларга туплауга бик ашкынып тормыйлар. Фәнни эшләрне планлаштыруда, тикшеренүләргә үз вакытында төзәтмәләр кертүдә, эш барышына контроль ясауда, ирешелгән нәтиҗәләрне производствога һәм укыту процессына кертүдә байтак җитешсезлекләр яшәп килә.

## 3. Киңәшле эш таркалмас

Фәнни эш — иҗтимагый эшчәнлек ул. Җәмгыять фән хезмәткәренә бурычлар рәвешендә социаль заказ бирә. Галим карамагында — белем, тикшеренүнең ысули принциплары, узган һәм хәзерге буыннарның тәҗрибәсе: Фәнни эшнең нәтиҗәләре күмәк тырышлыклар белән генә матди, социаль һәм рухи кыйммәтләргә әверелә. Кыскасы, фәнни эшчәнлекнең иҗтимагый үзенчәлеге объектив шартлар белән билгеләнә.

Социалистик җәмгыятьнең хәзерге, нык үскән чоры фәнни хезмәтнең иҗтимагый үзенчәлегенә үзгәрешләр кертә. Һәрнәрсәгә комплекслы караш таләп ителгән хәзерге шартларда фән үсешендә аның төрле өлкәләренең бер-беренә керешүе төп гамәлгә әйләнеп бара. Табигать, математика, техник һәм иҗтимагый фәннәр чигендә яңа гыйльми мәктәп яки юнәлешләр барлыкка килә. Хәзерге заман галиме алдына проблема килеп баса. Нишләргә: чиктәш проблемаларны тирәнтен белү өчен берничә фәнне өйрәнергә тотыныргамы? Әмма фәннәр бихисап

Аларның һәркайсына информация һаман саен күбрәк туплана бара. Һәр ун-унбиш ел саен ул ике тапкыр арта. Ә фәнни хезмәткәргә күрше фәннәрдән информация алу гына җитми, аны эштә кулланырлык дәрәҗәдә иҗади үзләштерергә кирәк. Шуның өстенә әле күрше фән хезмәт күрсәтә торган социаль тормыш ихтыяҗларын да белү мәҗбүри. Чиктәш берничә фән арсеналын үзләштергән галимнәр бар барын. Без әле генә Б. А. Арбузовның химия проблемаларын хәл итүдә физика алымнары куллануын әйтеп уздык. Әмма бу һәркемнең дә кулыннан килми, андый мөмкинлек һәр кешегә дә бирелмәгән.

Фәнни һәм практик бурычларны тормышка ашыруның икенче ысулы да бар — ул да булса төрле профильле гыйльми коллективлар тырышлыгын зур фәнни мәсьәләләрне чишүгә туплау. Соңгы елларда университетта гыйльми юнәлешләрне һәм темаларны эреләндерү, комплекслы итүгә кагылышлы байтак эш эшләнде. Дәүләткүләм әһәмиятле, бик четерекле эш! Күз алдына китерегез: фән һәм техника укыту үзәге буларак, Казан университетында 66 кафедра, 2 фәнни-тикшеренү институты, астрономия обсерваториясе, 9 проблемалы лаборатория бар. Фәнни-тикшеренү эшләрендә 900 профессор һәм укытучы, 800 хезмәткәр, шул исәптән 1 академик, 2 СССР Фәннәр академиясе члены-корреспонденты, 103 фән докторы һәм 530 фән кандидаты тикшеренү алып бара. Алардан 12 се — РСФСРның атказанган, 20 се — ТАССРның атказанган фән эшлеклесе, 8 е РСФСРның атказанган культура работнигы.

Гыйльми юнәлешләрне эреләндергәндә, гыйльми һәм матди көчләрне берләштергәндә зур кыенлыклар очрый. Алар байтак сәбәпләргә бәйле. Беренче сәбәп вузларда озак вакытлар буе кечкенә төркемнәр булып эшләү гадәте яшәп килүдә. Һәр төркем үзенең фәнни йөзен табарга омтыла, хәлбуки омтылыш күп очракта матди ресурслар, тиешле кадрлар һәм гыйльми мөмкинлек белән «терәтелми». Икенче сәбәп — гыйльми мәктәп һәм юнәлешләрнең инде табылган йөзен югалтудан, башка гыйльми юнәлешләргә кушылудан өркү. Өченчесе — яңадан әзерлек узу, «туган» фәнеңнең бусагасын атлап чыгып, икенче фәннең ишеген шаку, танып-белүдән яңа алымнарын үзләштерү кыенлыгы. Ниһаять, психологик киртәне дә онытмыйк. Тупланып килә торган коллективка кушылган галим «яңа» тәртипләргә, язылмаган законнарга буйсынырга, «чит» кешеләр белән уртак тел табарга тиеш була ич. Әлеге процесс шома гына узмый (җәя эчендә генә әйтик: художестволы һәм публицистик тикшеренү өчен гаять кызыклы процесс ул). Боларның һәммәсен аңларга мөмкин, әмма моның чор таләбе икәнен дә онытырга ярамый.

Әлеге эшне җайга салуда оештыру чаралары зур роль уйный. Мәгълүм карар кабул ителгәннән соң университетта фәнни-тикшеренү бүлеге, факультетларда фәнни бүлекләр төзелде. Алар ярдәмендә төп гыйльми юнәлешләр ачыкланды: үсеп килә торган 40 лап юнәлеш планы төрле дәрәҗәдә тикшерелеп, нәтиҗәдә 18 төп юнәлеш билгеләнде.

Унынчы бишьеллыкка аяк басканда 248 тема өстендә эшләгән булсак, 1980 елда инде 197 тема калды. Директив органнарның карарлары һәм фән-техника дәүләт комитетының фәнни-техник программалары нигезендә башкарыла торган темалар саны (1975 елда — 14, 1980 елда — 27 тема). Беренче тәҗрибә үк гыйльми юнәлеш һәм көчләрне берләштерүнең инде уңай нәтиҗәләр бирә башлавын раслый. Бер-ике мисал: мәгълүм ки, Татарстанда нефть чыгару елдан-ел кими бара инде. Шушы хәл физик, механик, математик, геолог һәм нефтьчеләрне «Нефть һәм газ ятмаларын эшкәртүне камилләштерү» дигән комплекслы программаны хәл итүгә туплады. Узган бишьеллыкта продуктив катламнардагы үзгәрешләрне тикшерү нигезендә, нефть һәм газ ятмаларын эшкәртүнең торышына төпле-нигезле караган хезмәт тәгәлләнде.

Әдәби җәмәгатьчелеккә инде билгеле булганча, СССР Фәннәр академиясенең художество иҗатын комплекслы өйрәнү комиссиясе белән берлектә Казан университетында профессор Й. Г. Нигъмәтуллина җитәкчелегендә Татарстанда рус һәм татар әдәбиятын комплекс-система белән тикшерүче нигез төркем оештырылды. Бу төркем XIX гасырның соңгы чорында рус әдәбиятының үсүен, хәзерге татар прозасының торышын яңа карашлардан торып өйрәнде. Совет кенчыгышы

әдәбиятларында социалистик реализм эстетикасы һәм политикасы, яктылык музыкасы теориясенә караган кызыклы хезмәтләр язылды. Әдәбият торышын фәлсәфи, функциональ, социологик, психологик, тарихи-әдәби яктан бер бөтен итеп карау аның үсеш юнәлешләрен алдан күрергә мөмкинлек бирә.

Табигать һәм иҗтимагый фәннәр вәкилләренең тырышлыкларын бердәм бурычны үтәүгә туплау тәҗрибәсе дә бар. Университетның математиклары һәм политэкономнары профессорлар Я. И. Заботин һәм В. Ф. Семенов җитәкчелегендә «Математик алымнарны һәм электрон-хисаплау машиналары куллану нигезендә производствоны планлаштыру һәм идарә итү системасын камилләштерү» дигән комплекслы проблема өстендә эшлиләр. Алар предприятиенең хуҗалык эшчәнлеген оператив планлаштыруның экономик-математик алымнарын тәкъдим итте.

Әлбәттә, болар — әле беренче генә адымнар, ләкин өметле адымнар. Гыйльми юнәлешләрне берләштерү коллектив туплау һәм максат билгеләү белән тәгәлләнми, ә башлана гына. Хезмәт бүленешен дөрес тормышка ашыручы, фәнни-тикшеренүнең бердәм концепциясен булдырган һәм уртак фәнни алымнар белән коралланган коллективлар туплау өчен җиң сызганып эшләргә кирәк әле.

Кафедралар һәм факультетлар арасындагы чикләрне «җимереп» гыйльми көчләрне университет күләмендә эреләндерү беренче чорны гына кичерә әле. Икенче чор — гыйльми көчләрне Казан һәм республика, алай гына да түгел, Урта Идел төбәге күләмендә туплау шулай ук аерым юнәлешләр буенча бөтен илдәге югары уку йортлары һәм учреждениеләр белән элемтәләрне ныгыту. Әлеге җәһәттән кайбер нәрсәләр эшләнде, билгеле. Бер очракта темаларны эшләүгә читтән өстәмә көчләр тартылса, икенче очракта университет хезмәткәрләре илдәге бүтән гыйльми үзәк вәкилләре белән бергәләп комплекслы программаларны тормышка ашыралар.

Фәнни бәйләнешләрне ныгытуның нәтиҗәле чарасы — фәнни-техник дуслык килешүләре. Университет коллективы узган бишьеллыкта шундый 135 килешү төзеде. Аларны үтәүдә бик күп предприятиеләр, югары уку йортлары тармак институтлары, СССР һәм союздаш республикалар академияләренең институтлары коллективлары катнашты.

Фәнни эшләрне туплау һәм юнәлдерү дәрәҗәсе яңа баскычка күтәрелергә тиеш. Монда аерым инициатива һәм тырышлыклар гына мәсьәләне киң колач белән хәл итә алмый. План органнары һәм фән-техника дәүләт комитеты, министрлыклар һәм ведомстволар белән берлектә, гыйльми көчләрне максатчан программаларны үтәүгә туплауда төп үзәкләргә әверелер дип өмет итәргә кала. Ләкин, шул ук вакытта, КПССның XXVI съездында әйтелгәнчә, «фән үзе дә һәрвакыт «тынгысыз» булырга, кайсы участокларда торгынлык һәм артта калу барлыгын, белемнәрнең хәзерге дәрәҗәсе кайда тизрәк, уңышлырак алга барырга мөмкинлек бирүен күрсәтергә тиеш».

Фәнни элемтәләрнең өченче дәрәҗәсе — чит илләрдәге, бигрәк тә социалистик илләрдәге, югары уку йортлары һәм фән учреждениеләре белән хезмәттәшлекне ныгыту. Фән-техника — интернациональ күренеш. Алар өчен дәүләт чикләре юк. Әлбәттә, фәнни тикшеренүләрнең максаты аны хәл итү чараларын, нәтиҗәләрен файдалану иҗтимагый стройның үзенчәлегенә бәйле. Шуны да онытмаска кирәк: фәнни элемтәләр — төрле ил галимнәренең үзара аңлашу, уртак тел табу чарасы да. Тормыш раслаганча, алдынгы карашлы галимнәрнең иҗтимагый прогресс, җир йөзендә тынычлыкны саклау хакына тырышлыкларын туплаулары бик тә әһәмиятле.

Унынчы бишьеллыкта безнең университетыбыз галимнәре Лейпцигтагы К. Маркс исемендәге, техник университет (ГДР) һәм П. Хилендорский исемендәге Пловдив университеты (БХР) коллективлары белән фәнни техник хезмәттәшлек килешүен тормышка ашырдылар: безнең физикларыбыз немец галимнәре белән берлектә атом-төш парамагнит резонансы өлкәсендә эшлиләр. Тикшеренү нәтиҗәләре 13 хезмәттә бәян ителде. Пловдив һәм Казан университеты математиклары гомумиләштерелгән пространстволар геометриясе өлкәсендә актуаль мәсьәләләрне хәл итәргә омтылалар.

Профессор Д. Г. Тумашева җитәкчелегендәге татар теле кафедрасы Сегед университетының (ВХР) алтай секторы белән тыгыз элемтәдә тора. Бу элемтәләрнең нәтиҗәсе буларак, венгр университетының тюркология буенча специальләшүче студентларга татар теле укытыла, безнең галимнәр редакциясендә венгр дуслар тарафыннан татар теле дәреслеге эшләнде.

Кыскасы, һәр факультетның социалистик илләрдәге югары уку йортлары һәм фәнни учреждениеләр белән элемтәсе бар. Шуңа өстәп, университетның үсеп килүче илләргә гыйльми кадрлар әзерләүдә ярдәм итүен дә әйтергә кирәк. Узган бишьеллыкта егермедән артык кеше Алжирда, Эфиопиядә, Мозамбикта, Әфганстанда һәм башка илләрдә укытып кайттылар.

«Төп юнәлешләр...»дә иң элек социалистик һәм үсеп килүче илләр белән, шулай ук социаль системалары төрле дәүләтләрнең янәшә тыныч яшәү принципларыннан һәм халыкара киеренкелекне йомшарту зарурлыгыннан чыгып, Советлар Союзы белән хезмәттәшлек итәргә теләүче капиталистик илләр белән тотрыклы фәнни-техник элемтәләрне тормышка ашырырга кирәклек күрсәтелә. Фәнни-техник хезмәттәшлекнең бу дәрәҗәсе дә камилләштерелергә тиеш.

## 4. «Мәңге яшел тормыш агачы...»

Күптән түгел барган тагын бер бәхәс хәтердә. Берәүләр университетка гамәли тикшеренүләр дәрәҗәсенә төшү килешми, ул төпле-нигезле бурычлар белән генә шөгыльләнергә тиеш дип раслыйлар иде. Университет галимнәренә дә гамәли мәсьәләләр белән шөгыльләнү фарыз дигән авазлар да ишетелә килде. Дөрес, күп хәлләрдә «алтын урталык» хупланмый үзе. Хәлбуки, югары уку йортлары, заман кушканча, нәкъ менә төпле-нигезле һәм гамәли тикшеренүләрдә урталыкны иң кулай эш дип сайлап алдылар. Ләкин бер хакыйкать бар: танып-белү үзмаксат түгел. Ул ахыр чиктә тормыш ихтыяҗларына, кешеләрнең бик күп сорауларын канәгатьләндерү зарурлыгына нигезләнә. Без фәннең социаль юнәлеше хакында сүз алып барганда, аның казанышларын тормышка: производствога, культурага, көнкүрешкә һ. б. өлкәләргә кертүне күздә тотабыз. Фәннең тормыш белән бәйләнеше, теорияне практикага әверелдерү бурычы аеруча кискен торган дәверләр була. Күрәсең, без шундый дәвердә яшибез. Нык үскән социализм шартларында иҗтимагый үсешнең бар ягын киң рәвештә һәм тиз үстерү бик мөһим: фәнне дә, техниканы җитештерүне, культураны һәм социаль тормышны да. Фәнни-тикшеренү нәтиҗәләрен яңа техникага, технологиягә, рухи байлыкларга, кешеләрнең белеменә һәм инануына әйләндерми торып, илне экономик һәм социаль үстерүнең киң колачлы программасын уңышлы төстә тормышка ашыру мөмкин түгел. «Ярышны ничек оештырырга» әсәрендә В. И. Ленинның Гете сүзләрен хуплап куллануын хәтерлик: «Теория, дускай, төссез ул, мәңге яшел тормыш агачы». Хикмәт шунда, теориягә практика җан кертә, аны практика төзәтә һәм дөресләгән сыный. Вуз фәненең нәтиҗәлелеген күтәрү турындагы алда әйтелгән карарда һәм нигезле, һәм гамәли тикшеренүләрне дә, шулай ук теоретик эзләнүләрдән башлап конструкция һәм технологиягә, алынган нәтиҗәләрне тормышта куллануга кадәрге эшләрнең бөтен комплексын планлаштыру зарур дип әйтелгән.

Беренче чиратта төпле-нигезле һәм гамәли тикшеренүләр нисбәтен планлаштыру күздә тотыла. Фундаменталь тикшеренү хакында сүз барганда, кайберәүләр аны иҗтимагый тормыш белән бәйләнмәгән күзаллау теориясе дип уйлый. Фән тарихы исә шуны күрсәтә: яхшы теория һәрвакыт тормышка йөз тоткан була. Казан университетындагы гыйльми мәктәп һәм юнәлешләрнең үсеше дә шуны раслый. Дәлил рәвешендә механикларның эшен алып карыйк. Аларның гыйльми юнәлеше күптән инде бөтен илгә билгеле. Г. Г. Тумашев, М. Т. Нужин, Л. А. Аксентьев, Н. Б. Ильинский, А. Б. Салимов кире читләр мәсьәләләренең гыйльми теориясен эшләделәр. Бу — теоретик механиканы үстерүдә зур өлеш булды. Аның асылы алдан билгеләнә торган үзлекләргә ия булган җисемнәрнең

формаларын ачыклаудан гыйбарәт. Бу нәтиҗә тормышта, аерым алганда, гидроаэромеханикада һәм су чистартуда зур роль уйный. Әлеге теорияне шартлату эшләрендә уңышлы кулланырга була. Университет механиклары Н. Б. Ильинский җитәкчелегендә дөнья практикасында беренче буларак су корылмаларының иң уңышлы рәвеше һәм зурлыгы проблемасын хәл иттеләр. Әлеге нәтиҗә Нурек гидростанциясен корганда кулланылды. Хәзер аны 25 буа төзегәндә файдаланырга җыеналар. Мондый фактларны байтак китерергә булыр иде.

Без фәнни эшләрнең хуҗалык килешүләре нигезендә башкарылуын күздә тотабыз. Алар гадәттә гамәли фәннәргә нигезләнә. Соңгы елларда бу өлкәдә җитди үзгәрешләр булды. Беренчедән, хуҗалык килешүләре нигезендә башкарыла торган фәнни эшләрнең күләме үсте. Әйтик, әгәр ул 1976 елда 2050 мең сумлык булса, 1980 елда исә 2450 мең сумлык иде. Икенчедән, мондый фәнни тикшеренүләрнең тематикасы эреләндерелде. 1975 елда 130 тема (һәр теманың уртача еллык бәясе 23,1 мең сумлык) эшләнсә, 1980 елда исә 86 тема (уртача еллык бәясе 35 мең сумлык) башкарылды. Өченчедән, озаграк вакытта исәпләнгән тикшеренүләрнең өлеше артты. Хәзер договорларның 80 проценттан артыгы күп елларга исәпләнгән.

Ләкин, әйтергә кирәк, фән һәм тормыш бәйләнешләренең әһәмиятле бу рәвеше генә тикшеренү нәтиҗәләрен производствога күпләп кертү бурычын хәл кыла алмый. Бер мисал белән аңлатыйк. Университетның доцент В. Н. Подымов җитәкчелегендәге физиклары казан агрегатларын импульсив чистарту алымын тәкъдим иттеләр. 1975 елда Төньяк торба заводында уздырылган беренче сынаулар ук бу алымның моңа кадәр кулланылып килгән барлык алымнардан өстен икәнен күрсәтте. Башкалардан аермалы буларак, бу алымны кулланганда чистарту вакытында казан агрегатларын туктатып торырга кирәкми. Файдалану өчен уңайлы, экономик яктан отышлы. Әлеге алым Магнитогорск, Түбән Тагил, Караганда, Орск-Халилово металлургия комбинатларында, башка заводларда һәм ГЭСларда киң кулланыла. Ул илнең 63 предприятиесендә кертелде һәм 10 миллион сумнан артык табыш бирде инде. Ул су казаннары булган теләсә кайсы предприятиедә һәм оешмада кулланыла ала. Әлеге фәнни нәтиҗә 5 тапкыр халыкара күргәзмәләрдә һәм күргәзмәләргә, ике тапкыр СССР Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсенә куелды һәм 1 көмеш, 2 бронза медаль алды. Хәзерге вакытта аңа бик күп сораулар алына, әмма аларны канәгатьләндереп булмый. Монда югарыгы оешмаларның ярдәме кирәк. Бәян ителгән факт түбәндәге нәтиҗәгә китерә: фәнни тикшеренүнең аеруча җитди казанышлары регуляр һәм оператив төстә гомумиләштерелергә һәм Дәүләт комитеты планына кертелергә тиеш. Бу — хәзерге шартларда аеруча мөһим, чөнки фән-техника яңалыкларын производствога кертү чаралары һәр предприятиенең үсеш планында урын ала. Андый планны төзүдә, предприятие коллективыннан тыш, партия-совет органнарының, фәнни коллективларның, кызыксынучы министрлык һәм ведомстволарның катнашуы максатка ярашлы булыр иде. Икенче төрле әйткәндә, фән һәм техника казанышларын производствога кертү планы «астан» һәм «өстән», шулай ук «сулдан» килгән тәкъдимнәр нигезендә төзелергә тиеш. «Сулдан» дигәндә без нәкъ менә фәнни коллективларның инициативасын күздә тотабыз.

Безнеңчә, министрлык һәм ведомстволарның конкрет заказларын үтәүне киңәйтү фән белән производство арасындагы элемтәләрне ныгытуның нәтиҗәле формасы була ала. Янә конкрет мисалга мөрәҗәгать итик. 1975 елда кәгазь промышленносте министрлыгы университет галимнәренә суга чыдам шомарткыч ясау өчен кәгазь аслык эшләп чыгаруда катнашырга тәкъдим итте. Андый шомарткычның СССРда эшләнгәне юк, ә аңа ихтыяҗ ифрат зур иде. Шомарткыч җитештерү өчен чит илдән җиһаз сатып алынган, әмма кәгазь аслык булмау сәбәпле ул тик торган. Университет химиклары бик тиз нәтиҗәле эзләнүләр уздырдылар, практиклар ярдәмендә шомарткыч кәгазь өчен аслык җитештерү технологиясен эшләделәр. Шул рәвешле, илдә суга чыдам шомарткыч җитештерелә башлады. Ул ВАЗда уңышлы кулланыла һәм чит илләрдәге шомарткычлардан калышмый. Бу яңалык тиз таралыр дигән өмет бар. Ни әйтсәң дә, заказчысы министрлык үзе бит.

Әлбәттә, югары уку йорты фәненең производство белән элементләрен ныгыту бурычлары саналганнардан тыш та җитәрлек. Тикшеренү нәтиҗәләрен производствога кертүдә, мәсәлән, галимнәрнең, гыйльми коллективларның активлыгы һәм җаваплылыгын күтәрүгә басым ясыйсы килә. Бу өлкәдә чамадан тыш тыйнаклык гомуми эшкә зыян гына китерә. Фәнни эш сөземтәләрен тормышка кертү — галимнең шәхси эше генә түгел, ә бәлки партиячел һәм гражданлык вазифасы ул. Хәзерге югары уку йорты хезмәткәренең тормышка актив карашы аның фәнни, укыту-тәрбия, җәмәгать эшенә генә түгел, ә фәнни эшенең нәтиҗәләлегенә, производствога, культурага укыту процессына кертүе белән дә билгеләнә. «...Фәннең производство белән тыгыз интеграциясе,— диде иптәш Л. И. Брежнев партиянең XXVI съездында,— хәзерге чорның катгый таләбе». Һәм ул фән-техника эшлеклеләренең, инженер һәм проектлаучыларның, тармак һәм производство җитәкчеләренең шушы таләп югарылыгында булу өчен барысын да эшләячәкләренә Үзәк Комитет исеменнән ышаныч белдерде. Менә шушы олы җаваплылыкны бер генә минутка да онытырга ярамый.

Аңлашыла ки, университет фәненең нәтиҗәлелеген, хәзерге тәртип буенча, сумнар белән генә үлчәп бетереп булмый. Гамәли тикшеренүләр генә турыдан-туры экономик файда бирә. Ә нәтиҗәсе бүген генә бирә алмый торган төпле нигезле тикшеренүләрнең бәясен нәрсә белән үлчәргә? Фән кадрларын әзерләүне? Университетта ел саен 5—6 фән докторы, 100 дән артык кандидат әзерләнә. База югары уку йорты буларак, ул узган бишьеллыкта Казан югары уку йортларына кафедраларга җитәкчелек итү өчен 9 доктор, илдәге югары уку йортларына 250 кандидат җибәрде.

Университетта эшләүче галимнәрнең өчтән бере — иҗтимагый һәм гуманитар фән вәкилләре. Унынчы бишьеллыкта филология факультетында гына да 17 дәреслек һәм уку ярдәмлеге язылды. Мөдире профессор Р. И. Нафигов булган КПСС тарихы кафедрасы галимнәре В. И. Ленин биографиясенең Идел буе чорын өйрәнеп, Ленинианага гаять зур өлеш кертәләр. Алар шулай ук Идел буе һәм Урал алды халыкларының иҗтимагый фикер үсешен, партиянең нык үскән социализм дәверендәге эшчәнлеген тикшерәләр. Политэкономия кафедрасы (мөдире профессор В. Ф. Семенов) нык үскән социалистик җәмгыять экономикасының закончалыкларын, фәнни коммунизм кафедрасы коллективы профессорлар К. Ф. Фасеев һәм М. Х. Фарукшин җитәкчелегендә социалистик һәм коммунистик төзелеш закончалыкларын, шулай ук дөнья күләмендә идеология көрәшен, янсә СССР тарихы кафедрасы галимнәре фән докторлары И. М. Ионенко һәм И. Р. Таһиров җитәкчелегендә Идел буенда Октябрь революциясе тарихын өйрәнү җирлегендә җитди хезмәтләр иҗат итәләр. Монда башка кафедраларның хезмәтләрен дә санарга мөмкин. Әлеге хезмәтләр — кыйммәтле рухи байлык, хезмәтчеләрен идея-политик яктан тәрбияләү чарасы, белгечләр әзерләү базасы.

Гәрчә югары уку йорты фәнен үстерүдә зур бурычларны уңышлы хәл итү өчен объектив шартлар бар. Сүз иң элек социализм шартларында фәннең игелекле вазифасы, КПСС һәм Совет дәүләтенең аны үстерү турында даими кайгыртучанлык күрсәтүе, совет галимнәренең иҗтимагый активлыгы һәм җаваплылыгы, аларның максат, дөньяга караш, танып-белү методологиясе уртаклыгы, халыкка хезмәт итү омтылышы турында бара. Совет фәне һәрчак шуның белән көчле булды һәм шулай булып кала. Аның бер отряды булган университет коллективы да, XXVI съезд идеяләре һәм планнары белән рухланып, унберенче бишьеллык һәм аннан соңгы чор бурычларын хәл итүгә лаеклы өлеш кертер.

**Ш. Т. ХӘБИБУЛЛИН,**
Казан Дәүләт университетының фәнни эшләр буенча проректоры, профессор, физика-математика фәннәре докторы.
**Ф. И. ӘГЪЗАМОВ,**
журналистика кафедрасы мөдире, доцент, тарих фәннәре кандидаты.

## ПУБЛИЦИСТИКА

### Анатолий Нагнойных

# БРАТСК КАҺАРМАНЫ

*Редакциядән: Бу очерк — Братск су электр станциясенә нигез салучы һәм аны тәгәлләүче Иван Иванович Наймушин турында. Совет властеның беренче елларында ул балалар йортында тәрбияләнеп үскән, Татарстандагы «Гуж» дигән артельдә йөкче, Алтай шахталарында күмер чабучы булып эшләгән. Ике мәртәбә рабфакка укырга керә алмый калган, татар егетенә рус теленнән инша язу читен булгандыр, күрәсең. Рус телен өйрәнер өчен ул Толстойның «Сугыш һәм тынычлык» романын күчереп язып чыккан...*

*Наймушин җитәкләгән коллектив илебезнең көнчыгышында иң көчле һәм куәтле индустрия үзәге булган Братск — Усть-Илим комплексын төзи. Ике шәһәр, ике мәшһүр су электр станциясе, ике урман промышленносте комплексы, гаять зур Коршунов тау-баету комбинаты, Братскидагы алюминий заводы... Ләкин мондый гади санап чыгу белән генә Наймушин шәхесе турында әллә ни сөйләп булмый әле. Ул — легендар кеше. Братск су станциясенә кадәр дә, хәтта аннан соң да илебездәге бер генә ГЭС салуны да биш ел эчендә башкарып чыкканнары юк иде әле! Братск ГЭСының һәм башка объектларның вакытыннан элек сафка басулары бер хәл. Аларның дәүләткә сметада каралганнан арзанракка төшүе дә сокландыргыч. Наймушин кешеләрне яңача эзләнергә һәм эшләргә, тәвәккәллектән курыкмаска өйрәтте.*

*Аның иң төп оештыручы сыйфаты стратег була белүеннән гыйбарәт иде. Себергә килеп төшкәч үк, ул Братск су электр станциясе төзелешенең тар ведомстволылык кысаларына сыймаячагын аңлап ала. «Дөнья читендә су электр станциясе төзеп кую эшнең яртысы гына әле»,— дип саный ул. Ул төп максатын бу тирәләрдә промышленность комплекслары коруга юнәлтә. Һәм шундый кору эшенә җиң сызганып керешә. Гадәти, күнегелгән фикерләрдән, тар карашлардан аерылып торганга күрә, аның бу теләге күп кенә каршылыкларга да очрый. Аның Братск су электр станциясен корган-дагы тарихи тәҗрибәсе әле һаман өйрәнелмәгән килеш тора, аны хәтта Красноярск һәм Саян-Шушенск кебек эре станцияләр төзегәндә дә игътибарга алып бетерә алмадылар.*

*Наймушин Себердә электр энергиясенең җитеп бетмәячәген алдан күрә алды. Тагын бер мәсьәлә бар: Братск станциясен корган кешеләрне, эш беткәч кая куярга? Зур авырлык белән туплангын коллективның төзелеш тәмамлангач таралырга дучар булуы ихтимал иде. Һәм Наймушин, бөтен җаваплылыкны үз өстенә алып, яшертен генә булачак Усть-Илим су электр станциясе урынында әзерлек эшләре җәеп җибәрә. Аны да моңарчы булмаганча кыска вакыт — нибары җиде ел эчендә төзеп бетерәләр.*

I

„Сорау сорау хәлендә калырга тиеш түгел»,— дигән тәгъбир Иван Иванович Наймушин чыгарган күп санлы үткер әйләнмәләрнең берсе иде. Ул бик күп мәртәбәләр кабатлаган әчтәлекле әйтемнәр искә төшкәндә, күз алдына бер фоторәсем килеп баса шикелле: салкыннан бәс белән капланган кечкенә генә бер ат, чанада — толып һәм эт тиресеннән тегелгән галәмәт зур бияләй кигән бер кеше. Колакчыннары ияк астыннан бәйләп куелган бүреге йөзен каплап бетерә язган.

Бу рәсемгә ниндидер бер альбомга рәсемнәр сайлап утырган чагында тап булгач, мин ирексездән:

— Узган гасыр каян килеп чыккан монда? — дип сорадым.

— Узган гасыр түгел бу, Наймушинның Усть-Илимга баруы,— диделәр миңа.

Тагын бер рәсем күрсәттеләр. Монысында да шул киемнәрдән ул. Янында — Гидропроект институтының Ангара экспедициясе башлыгы Леонтий Ефремович Медведев, элемтә участогы баш инженеры Игорь Всеволодович Баженов, механизатор Владимир Михайлович Перевезенцев, юлчы Гай Михайлович Вольдейт, электр үткәрү идарәсе башлыгы Борис Григорьевич Зимин. Фоторәсем астына: «Монда Усть-Илим электр станциясе салыначак, 1980 елның январе»,— дип язып куелган.

Наймушин менә нинди кеше ул! Братскига 1954 елның октябрь азагында килеп төшүгә үк, ул өч ай эчендә Братск һәм күрше районнардагы бөтен поселок-авылларда булып чыгарга өлгерә, аучыларның тайгадагы кышлакларына барыр өчен әллә нинди юлларны белеп ала, җирле халыкның үз төбәкләрен яхшыртырга омтылган хыялларын үзенекедәй кабул итә. Һәм шуның өчен көрәшә башлый. Күрсәтмәләр, аңлатмалар яза, телефоннан шалтырата, Иркутскига, Мәскәүгә чыгып китә. Инде 1956 елны ук моңарчы күрелмәгән хәл китереп чыгара: 11 нче августта илебезнең Министрлар Советы Братск су электр станциясен төзү проект заданиесен раслый, ә бер айдан соң, 11 нче сентябрьдә Себернең бу төбәгендә промышленность һәм гражданнар корылмалары салуның бердәм төзү индустриясе базасы оештырылу турында карар кабул ителә.

Инде менә Усть-Илимга, Юан Борынга да килеп чыгалар. Братск ГЭСы буасы ул чакта корылып кына килә торган була әле: дүрт миллион ярым тонна бетонның беренче мең тонналары гына салынган. Зур бетон заводын эшкә җигәсе, чуер таш сортлау хуҗалыгын җайлыйсы, субподряд оешмалары базасын корасы бар әле. Урман промышленносте комплексын һәм шәһәрне сала башлау да — иң әһәмиятле эшләр сафында.

Ләкин Наймушин аларның барысын да хәл ителгәнгә санап куя инде. Аларның эшләнәсенә тулысынча ышанган хәлдә Юан Борынга китә, Ангарадагы өченче су станциясенең язмышын кайгыртырга керешә. 1953 елны Гидропроект төзегән схема нигезендә Илим тамагыннан өстәге буа кыска вакыт эчендә һәм яңа төзелеш базасы оештырып тормастан, Братскиныкына гына таянып буылыр дип карала.

Наймушин моның белән килешми. Тормыш аны бары тик эре станцияләрнең генә промышленность, шәһәр һәм поселоклар белән әйләндереп алыначагына үзе өйрәтеп куйган инде. Юан Борындагы станцияне аның Братскидагы кебек үк куәтле итеп күрәсе килә — шул чагында гына зур территориядә яңа, матур киләчәк башланачак. Юан Борын янында рәсемгә төшкәч, Иван Иванович үзе белән килгән Медведевка:

— Мәскәү безнең монда булуыбыз белән кызыксыначак. Бу фото безнең җавабыбызга дәлил булыр,— дип елмая.

Тик законга әйләнеп беткән диярлек гадәтне ничек үзгәртергә? Булачак төзелешнең урынын билгеләүләр генә дә моңа кадәр еллар буена сузыла иде. Братск ГЭСы урынын тикшерү 1949 елда ук башланган, әзерлек эшләренә исә бары тик 1954 елда гына керешәләр. Шул арада электр энергиясе алырга мөмкин булганын кем исәпләп чыгарсын?

Каты салкыннар чигенүгә, Наймушин үзе белән Юан Борынга барган ике кешене — Вольдейт белән Баженовны чакырып ала. Ул аларны күптәннән карап йөри инде. Егерме биш яшьлек Вольдейтны ул хата җибәрмичә диярлек эшләве өчен хөрмәт итә, ә Баженовка ул теләсә нинди урында бер-ике сәгать эчендә телефон элемтәсе булдыра алганы өчен сокланa.

— Җылындыгызмы инде?— дип каршылый ул аларны. Братск ГЭСы төзелеше начальнигының тел төбен аңламаганга икесе дә ләм-мим эндәшми тора. Аның йөзе бу мизгелдәге уйларын бөтенләй сиздермәскә мөмкин, дәшми торуын хәерлерәк...— Юан Борын салкыныннан җылынып җиттегезме дим!

— Күптән!

— Алайса юлыгызга ак җәймә! Тагын бер барып карагыз!

Наймушин юри шулай итә. Шаяру яки табышмаклы ым белән сүз катып, ул

аңгәмәдәшенең уйлана башлавына, инициатива күрсәтүенә ирешә. Кешеләрнең куйган бурычны үтәү сәләтен шулай тикшереп карый.

— Игорь Всеволодович, авыллардан күпме эшче көч таба алырсың икән?

— Карарга кирәк,— дип җавап бирә Баженов.

— Бар, ике күзеңне дүрт итеп карап кайт. Менә, Вольдейт белән бергәләшеп. Элемтә белән юл бергә йөри.

— Бернинди проект юк ич әле, Иван Иванович!

— Ник мин сине үзем белән ияртеп йөри дип беләсең? Юллар сала беләсеңме?

— Беләм дә бит...

— Беләсең килсә, Вольдейт, мине беренче тапкыр төзелеш башлыгы итеп билгеләгәндә мин үзем дә курка калган идем. Аңлашыламы?

Алар чыгып киткәч, Наймушин Медведевка шылтыратып алды:

— Леонтий Ефимович?.. Мин сине Юан Борынга киткәнсең дип торам инде... Уйларга да кушмыйлар?.. Минем яныма кереп чык әле син!

Леонтий Ефимович Медведев — Гидропроектның Ангара экспедициясе начальнигы. Наймушин аны ишек төбенә үк барып каршылады да, ике куллап күрешкәч, кәнәфигә әйдәп утыртты.

— Синең тикшерүчеләрең кайда, Леонтий Ефимович?

— Илимда, Юан Борын турындагы тәкъдимебез каралмаган да ич әле...

— Аны нигә үзеңә карамаска соң?

— Моны Мәскәү хәл итә.

— Тикшерүчеләреңне Юан Борынга җибәр.

— Телим дә бит, ярамый. Мәскәүдә иртәгүк белеп алачаклар.

Наймушин Медведевка озаклап карап торды. Бөтен сугышны кичкән кеше, орденнары бар, ә холык-фигыле белән буйсынучы гына булып калган.

— Ул чагында Наймушинны Мәскәүгә җибәрергә дигән тәкъдим бар. Каршы килмәссеңдер ич?

## II

Америка Кушма Штатларының күренекле дәүләт эшлеклесе Леррел Гарриман Братскида самолеттан төшүгә үк Наймушиннан:

— Капларга әзерме соң әле сез? — дип сорады.

— Инде капладык,— диде Наймушин сүз гап-гади бер эш хакында барган дагы шикелле тыныч кына. Дипломат гадәте Гарриманга гаҗәпләнүен, хәтта югалып ук калуын сиздермәскә ярдәм итсә дә, Наймушин аның бу мизгелдәге кичерешләрен яхшы аңлады. Кичекмәстән казанлыкка юнәлделәр.

Машина халык ташкынын көчкә генә аралап барды. Иван Иванович Ангараны буар өчен салынган күпердә Гарриман белән ни хакында сөйләшкәндер, билгесез. Гарриман шундый четерекле елганы бууның ни икәнен бик яхшы белә. Кичә сигездә башланган эш, әнә, төгәлләнгән дә инде, унтугыз сәгатьлек көрәштән соң митинг башланган.

Гарриман Братскида берничә төн куна. Безнең илгә беренче генә килүе түгел, русларның әллә ничә «тылсымын» күргәне бар, тик ул шундый «җәһәннәмдә» зур бер шәһәр салынып ятуга соклануын яшерми. Тикмәгә түгел. Ангара белән янәшә йөз дә өч промышленность комплексы корыла, ул исә үз эченә биш йөз объект белән 196 торак йорты, социаль көнкүреш предприятиесен алып тора. Шуның өстенә 260 чакрым автомобиль, 200 чакрым тимер юлын, 325 чакрымга сузылган инженерлык корылмаларын сафка кертү мөмкинлеге булдырыла.

Һәм боларның барысы да — коллективның биш еллык эшчәнлеге җимеше! Иң гаҗәпләндергәне — бөтен бурычларның да бары тик бер генә төзү оешмасы тарафыннан башкарылуында. Шул нигездә территориаль производство комплексы барлыкка килә.

Моннан тыш «Пурсей» һәм «Братск» совхозларының производство биналары сафка баса, колхозларда дистәләгән сыер абзарлары салына. Наймушин тәкъдиме

һәм аның күзәтчелеге белән авылларга электр кертелә. Бер заманны Братск МТСы кырларында ул үги бала шикелле тынып калган тугыз комбайнга тап була. МТС директорына сугыла. «Ник комбайннарыгыз тик тора? Озакламый бураннар кузгала ич инде!» — «Үзйөрешле комбайннар ул, Иван Иванович, двигательләре начар. Коллекторларын алыштырудан туктаганыбыз юк. Инде менә куярга берәү дә калмады». Икенче көнне иртүк Наймушин директорга: «Коллекторлар җибәрдем. Тик аларның асфальт җәю катокларыннан алынганны оныта күрмә. Калсалар, кире җибәрегез»,— дип шалтырата.

Мәгълүм булганча, Гарриман мактауга үтә саран кеше. Шуңа карамастан, кайтып китәр алдыннан ул: «Братскины күрмәгән кешенең белеме тулы була алмый»,— дип әйтеп сала.

— Чираттагы очрашу Усть-Илимда булыр,— дип елмая аңа Наймушин.

Әмма Вольдейт белән Баженовның докладлары аны сагайта кала. Киләчәк юлның яртысы үрләрдән торачак, унсигез елга һәм уннарча инеш аркылы күпер салырга кирәк. Җирле эшчеләр юк диярлек, ир-атны бармак белән генә санарлык, тораклар да җитми. Һәр авылга нибарысы өч дистәләп кешене урнаштырып була. Димәк, яңа поселоклар корырга кирәк!

Бу юлы Иван Иванович Мәскәүгә поездда барырга күнеккән гадәтен ташлап торырга булды — самолет белән очты. Ә Мәскәүдә исә гадәтләренә хыянәт итмәде. Сугышка кадәр үк инде ул министрлыкның оператив бүлеге начальнигы була, хәзер, Мәскәүгә килгән чагында гел диспетчерлар бүлмәсенә кереп утыра. Пальтосын яки плащын үз элгеченә элеп куя да, «үз» өстәленә утырып, эшкә керешә. Диспетчерлар аның килүен ничектер алдан белеп алалар да кайчандыр ул эшләгән өстәлне бушатып куялар. Бу юлы да шулай булды. Ул иң әүвәл Гидропроектка шалтыратырга уйлады.

Юан Борын турындагы мәсьәлә институтта гел бәхәс кенә кузгата икән әле. Ул анда ачуыннан кайнап килеп керде. Моны сизеп алдылар да сабыррак булырга тырыштылар.

— Шулай анысы, Иван Иванович, Юан Борын янында су станциясе Илимдә корганныкыннан бер ярым мәртәбә куәтлерәк килеп чыгар иде. Аның караны аны Илимдә ике ел чамасы алданрак корып булачак, җитмәсә, ул арзанракка да төшәчәк, ник дисәң, аның янында төзелеш базасы оештырып торуның кирәге калмаячак.

— Кайчан салып бетерү сезнең кайгы түгел!

— Билгеле, бусы сезгә бәйле, тик безнең дә үз фикеребез булырга тиештер ләбаса.

Юан Борынның буа буылачак ярларын тикшерү үткәрелмәүне сәбәп итеп, Гидропроект Ленинградтагы елга транспорты гипросы белән сүз куешу һәм килешү төзүдән дә баш тартты. «Сездән башка да яшәрбез әле!» — дип кызды Наймушин һәм Ленинградка юл тотты. Анда аны игътибар белән һәм аңлап тыңладылар. Шундук килешү төзелеп, Александр Иванович Обрядинны экспедиция башлыгы итеп билгеләп куялар.

Наймушин Мәскәүгә кайтып, министр белән очрашу мөмкинлеге алды. Киләчәк сөйләшү хакында уйланып ятканда ул ерак истәлекләргә бирелде.

...Авыр кырык беренче елның октябрендә аңа Йошкар-Олада җылылык электр станциясе төзү бурычы тапшырылган иде. Анда ике эре завод эвакуацияләнгән булган. Ул анда фондсыз-нисез, бернинди материалсыз, кирәк-яраксыз килеш, хәтта эшчеләрне тукландыру вәгъдәсе дә ала алмыйча чыгып китә. Иң беренче эш итеп, ашханә, аннары кибет салдыра. Шул чагында аның: «Тук кеше белән сөйләшүе җиңел»,— дигән «канатлы» сүзе телгә керә. Бөтен нәрсәне эшли, җиһазлар гына таба алмый. Министрлыкта да берни белән ярдәм итә алмыйлар. Бу вакытта ул — Энерго министрлыгының оператив бүлек мөдире, хуҗалыкны яхшы белә. Кирәкле казаннарны табып ала. Тузганнар. Министрлыкта да, проектлаучыларны да казаннарны эшкә җигәргә мөмкин икәнен исбатлап бирә, Йошкар-Оладагы җылылык электр станциясе берничә айга алданрак сафка баса.

Ул чагында Наймушинга Брянск җылылык станциясен торгызу бурычы йөкләнә. Министрлык аңа хәтта транспорт та бирә алмый. Аның нибарысы

Йошкар-Оладан алып килгән бер тракторы белән ике автомобиле генә була. Брянскига барып, аннан бер кеше иртәгә кайтып керә дә, транспорт начальнигын чакырып алып, аны механик итеп билгеләтә. Ул кеше Брянск урманнарындагы партизаннар хәрәкәтендә катнашкан булган һәм заманында машиналар ташлап калдырылган урыннарны яхшы хәтерли икән: бер ел эчендә автомобиль паркында җитмеш сигез машина барлыкка килә... Әйе, авыр заманалар да бар иде. Хәер, хәзер дә җиңел түгел. Төзелеш киңлеген чагыштырырлыкмы соң?

Министр аны, шаярып:

— Усть-Илим турында шаулап йөрерлек булгач, син Братскины корып бетергәнсең дип уйларлык,— дип каршылый.

Наймушин тыныч кына:

— Братск — проблема түгел инде,— дип җавап бирә.

— Чынлапмы?

— Алтмыш беренче елны беренче агрегатны җибәрәчәкбез. Ә шуннан соңгы ике елда — калганнарын.

Министр аңа сынап карап куйды.

— Миннән сиңа ни кирәк соң?

— Гидропроектны Юан Борын ярын быел ук тикшереп чыгарга һәм юл проектлауны быел ук башларга мәҗбүр итүең. Ангараны мин үз өстемә алам...

— Әгәр дә без якын арада төзергә керешмәсәк?

— Бөтен төзүчеләр агым ысулы кертә. Су станцияләре өчен бу бигрәк тә кулай. Әйдә Министрлар Советына язабыз?

Министр белән сөйләшү юкка булмый. Юан Борын янында Усть-Илим станциясе салыначак урынны тикшерү башлана. Көзен Мәскәүдән хәбәр дә килеп төшә: Юан Борын яры дәүләт комиссиясе тарафыннан раслана.

III

Братск ГЭСы төзелеше начальнигы киңәшмәләрне, утырышларны, озын бәхәсләрне өнәп җиткерми. Ул мәсьәләләрне башлыклар яки эшчеләр белән күзгә-күз карап хәл итүне артыграк күрә. Вольдейт белән 1962 ел башында Усть-Илимга юл салу хакындагы сөйләшү болай бетә:

— Власть җитмимени, Гай Михайлович? Мә, ал! — һәм Наймушин Вольдейтка юллар салу идарәсенең баш инженеры итеп билгеләнүе турындагы боерык суза. Аның яшь җитәкчеләрне тәрбияләп үстерүгә үз карашы, үз алымы була. Башта ул аларны күзәтеп йөри дә, күңеленә хуш килгәннәрен сайлап, аңа җаваплы бурыч йөкли. Ул үз шәкертенә күбрәк ирек бирүдән курыкмый, тик тикшереп, күзәтеп тора, ял вакытын ничек үткәрүенә кадәр игътибар итә. Зур мөстәкыйль эшкә өлгереп җиткәннәрен бик рәхәтләнеп югарырак оешмаларга җибәрә. Хәзер Братск ГЭСы төзелешендә читтән килгән бер генә җитәкче дә юк. Бу эре төзелеш оешмасының хәзерге җитәкчеләре Л. И. Яценко белән Ф. Л. Каган үз хезмәт юлларын Братскида прораб булып башлаган кешеләр.

Вольдейтка боерык сузган вакытта Иван Иванович аңа:

— Бу власть, Гай Михайлович, проектчылар белән кыюрак «сугышыр» өчен генә түгел,— диде.— Юл сала башла!

Бер атнадан тайгада юл ярырга тотындылар.

Тайгада тагын бер аралык ерасы бар иде әле. Анысы электр тапшыргычы линиясе өчен. Наймушин электр тапшыру линияләре сузу идарәсе башлыгы Зиминны дәшеп алды.

— Син илле сигезенче елны минем белән Юан Борынга ник барган идең?

— Тагын бер планнан тыш эш белән илһамланыргадыр.

— Кайда соң ул илһамың?

— Сызымнарын сыздык. Проектчылар белән киңәшәсе калды.

— Эшең барып чыкмасын дисәң, киңәшче эзлә: Борис Григорьевич, яңа төзү-монтаж идарәсе оештыр да бөтен трассада эш башла.

— Штатсыз-нисезме?

— Үзем кул куям. Мәскәү алдында үзем җавап бирәм.

Наймушин министрлык алдында Усть-Илим ГЭСы төзелеше идарәсе оештыру мәсьәләсен кузгата. Министр моны шаяртуга гына калдырырга тырышып карый, планлаштыру органнарының Ангарада өченче станция салуны билгеләмәвенә таяна. Наймушин җаваплылыкны үз өстенә алырга карар кыла. 1962 елның 22 нче августында Братск ГЭСы төзелеше составында Усть-Илим ГЭСын сала башлаячак яңа оешма барлыкка килә. Наймушин боерыгында күрсәтелгәнчә, 1962—1963 елларда бөтен проект-смета документларын, автомобиль юлы, электр тапшыргыч һәм элемтә линияләрен сузу эшләрен оештыру проектын тәгәлләү дә карала.

Наймушин Юан Борын янына кичекмәстән, «десант» җибәрергә һәм матбугат игътибарын шунда юнәлтергә дигән кыю бер карарга килә.

Танылган бораулаучылар бригадиры Перетолчин квартирында телефон телгә килә: «Иптәш Перетолчинны иртәнге сәгать тугызда Наймушин көтә».

— Уз, командир, утыр,— дип каршылый аны Наймушин.

— Төшенеп җитмәдем,— ди Перетолчин.

— Син Түбән Илим районында туганмы әле? Юан Борын янындагы бөек төзелешне башлап җибәрергә барасыңмы?

— Барам!

Усть-Илим десанты хакындагы хәбәр яшен тизлеге белән тарала. Аэрофлот кассаларына үзәк матбугат журналистлары ашыга. Александра Пахмутова белән Николай Добронравов та юлга чыга, күп тә үтмәстән, алар «Усть-Илимга хат» дигән гаҗәп матур җыр язалар.

...Братск ГЭСы төзелешенең 1963 елгы структурасын раслаганда министрлык Усть-Илим ГЭСы төзелеше идарәсен сызып ата. Моның берничә сәбәбе атала: бер җирдән дә финанслау булмаган, су станцияләрен коруны яңа ысул буенча тормышка ашыру принципиаль хәл ителмәгән, иң мөһиме — план органнарында өченче станция беркайда да телгә алынмаган.

Наймушин Мәскәүгә чыгып китә. Яңа министр Петр Степанович Непорожний Иван Ивановичның күптәнгә танышы була.

— Сабыр ит, Иван Иванович. Минемчә, гидротөзелешнең яңа принциплары хакында сездә махсус киңәшмә уздырырга кирәк!

— Братск ГЭСы тәҗрибәсеннән дә яңарак тагын ни булуы ихтимал икән соң?

— Галим-голәмадән узарга тырышма инде син, Иван Иванович.

— Үз иминлекләре өчен калтырап торган галимнәрдәнме?

— Һәрнәрсәнең үз вакыты була.

Братскига әйләнеп кайткач, Наймушин Усть-Илимнан бер адым да читкә тайпылмаска дигән карарга килә. Усть-Илимдагы бөтен эшләр дә берничә финанслаусыз-нисез алып барылган бу көннәрдә Наймушин яңа бер тәгъбир уйлап чыгара: «Йорт салуның ние бар? Ә менә шул йортны законлаштыру — анысы мәсьәлә!»

1963 елның май аенда Братскида министр Непорожний җитәкчелегендә «Усть-Илим — яңача эш башы» дигән девиз астында киңәшмә үткәрелә. Мондагы яңалык, Усть-Илим, Богучан һәм бу тирәдәге башка су станцияләрен ардан энергия «хәзинәләре» дип карап, шул энергияне Советлар Союзының гомуми энергетика системасына кушудан гыйбарәт була.

Киңәшмәнең байтак карарлары ахырынача уйлап бетерелмичә кабул ителә. Усть-Илимга вакытлы автомобиль юлы салынса да ярар диелә. Падун поселогындагы менә дигән йортларны мич белән җылытырга күчермәкче, канализацияне ташламакчы булалар. Кыскасы, төзелеш тарихын кирегә таба боруга тиңләнерлек карарлар эшләнә.

Наймушин бер атна буена эндәшми йөри, объектлардан кайтып керми. Соңыннан ул бу хакта үзе: «Усть-Илимны финанслау чыганакларын эзләү белән маш-

АНАТОЛИЙ НАГНОЙНЫХ ◆ БРАТСК КАЬАРМАНЫ ◆

гуль булдым»,— дип сөйли. Министр басымы белән Усть-Илим су станциясен төзү идарәсен «таратып» торырга мәҗбүр булса да, Наймушин эшне тагын да киңәйтебрәк җибәрә. Ул бөтен җитәкчелекне үз кулына ала. Юан Борын янына барып кайта, анда палаткалар шәһәрчегенә тап булып, кәефе кырыла. Йорт сызымнары бармы, дип сорый ул. Бар, диләр: борыслардан ике катлы йортлар салмакчылар икән, тик әле кая салырга икәнен генә күрсәтмәгәннәр. «Хәзер без басып торган урынга сала башлагыз! — ди Наймушин һәм өстәп куя: — Берьюлы икене. Берсе төзелеш идарәсенә, икенчесе инженер-техник хезмәткәрләргә тулай торак булыр. Братск кешеләрен палаткаларга кертеп булмый». Иван Иванович урман заводы урынын да үзе күрсәтә. «Падундагы заводны монда күчерергә кирәк, Братскида икесе дә җитәр».

Аннары ул йөз җитмешенче чакрымда корылып килә торган Эдучанкага — Усть-Илимга сузылачак автомобиль юлының «башкаласында» да булып кайта. Юлчылардан кала анда электр тапшыргыч линияне сузачак кешеләр, механизаторлар, элемтәчеләр, энергетиклар, тәэминатчылар бүлеге дә килеп урнашкан була инде. Ул кайберәүләрнең үзләренә-үзләре йорт салып урнашуларын мактап бетерә алмый: «Нык кадрлар!» Аннары юл салуның схемасын тәфсилләп карарга тотына. Хуп күрә дә елмаеп: «Тик срокны икеләтә кыскартырга кирәк булачак»,— дип киңәш бирә. «Акча каян алабыз соң аңа, Иван Иванович?» «Сезнең эшегез — юл салу, ә минем эшем — акча юнәтү...»

Аның Усть-Илимга өстән кушылганча вакытлы юл түгел, ә «мәңгелек» юл суздырасы килә.

Наймушин Иркутскига — партия өлкә комитетының беренче секретаре Семен Николаевич Щетинин янына оча.

Алар озак кына сөйләшеп утырдылар, төзелешнең бөтен детальләрен ачыкладылар. Сүзен йомгаклап, Щетинин:

— Усть-Илим ГЭСы төзелеше идарәсе оештыр, Иван Иванович. Яңадан үзбелдеклелектә гаепләмәсеннәр өчен, без сиңа комиссия җибәрербез, моны Мәскәү дә белеп торыр. Мин министр белән сөйләшермен,— диде.

Усть-Илим идарәнең урнашу төбәгенә әйләнде. Братск ГЭСы төзелешенең бөтен подразделениеләре анда үз бригадаларын җибәрүне намус эше дип кабул иттеләр. 1965 ел башына палаткалар шәһәрчеге бетерелде. Бу хакта Наймушинга хәбәр иткәч, ул тыныч кына:

— Шулай итеп, Усть-Илим башланды дип санарга була,— диде.

## IV

1964 ел ахырына киләсе ел өчен төзелешкә акча күчерү юк дәрәҗәсендә булуы беленде. Һәм министрлык төзелеш идарәсен тарату турында яңа карар кабул итте. Ихтимал, бу көннәр Иван Ивановичның гомерендәге иң авырларыннан булгандыр. Ул көн саен Иркутск белән Мәскәүгә шалтырата башлады. Ләкин Наймушин белән обком секретаре Щетининның бөтен тырышлыгы җилгә оча барды: Мәскәүдә Себернең бу төбәгендә электр энергиясе болай да кирәгеннән артык дигән сүзләр куера. Тик бер елдан соң Братск алюминий заводы сафка басачагы һәм электр энергиясенә кытлык башланачагын беркем дә искәртергә уйлап карамый.

Наймушин аның саен үҗәтләнде. Ул биргән һәр дүрт боерыкның берсе Усть-Илим проблемасын хәл итүгә карый иде. Ул Братск ГЭСы төзелешенең һәр подразделениесенә Усть-Илимдагы эшне көчәйтергә кирәк дигән бурычны куя. Усть-Илимга өстәмә бригадалар чыгып китә. Наймушинның шәхси боерыгы белән туксан квартирлы торак йорт өчен панельләр озатыла. Һәм тиздән Наймушин Мәскәүдән министрның Усть-Илим ГЭСы төзү идарәсе оештыру турындагы боерыгын алып кайта.

Усть-Илим язмышын кемгә тапшырырга икән? Кешеләрне үзе дә бик яхшы сайлап ала белүенә карамастан, ул ярдәмчеләре белән шул хакта киңәшеп ка-

рый. Братскида төзү-монтаж идарәсе начальнигы булып эшләүче Герасименкога туктарга булалар. Һәм ул Усть-Илим ГЭСы төзелешенең баш инженеры итеп җибәрелә.

1965 елның икенче яртысында Братск ГЭСы төзелешенең барлык подразделениеләре Усть-Илим мәйданында эшли.

Наймушин Усть-Илимга юл сузу мәсьәләсе белән мәшгуль. «Усть-Илим юлын каты өсле итеп салуның файдалырак икәнен Мәскәүгә раслап күрсәтергә кирәк!» — ди ул. Ул юл туфрактан гына өелер һәм өстенә гравий гына җәелер дигән күрсәтмә дә була, аның вакытлыча гына икәнлеге кире каккысыз дип уйланыла. Бу эшнең очына чыгуны Наймушин Вольдейт белән шушы очеркның авторына тапшыра. Алар, күп исәпләүләрдән һәм фараз кылулардан соң, аңа Усть-Илим юлы тимер-бетон плитәләрдән салынырга тиеш дигән тәкъдим белән керәләр. Бер караганда, бик парадоксаль тәкъдим була бу. Ләкин алар аның дөреслеген исбатлап бирәләр. Гравий юлы бер тапкыр төзекләндереп чыгуны да исәпләсәң, 54 ярым миллион сумга төшә, асфальт-бетон юл 41,8 миллион сум чыгым сорый, ә тимер-бетон плитәләргә 51,4 миллион сум җитәчәк! Туфрактан өелгән гравий юл барысыннан да кыйммәткәрәк төшәсе булган икән! Наймушин шунда ук тимер-бетон эйберләре комбинатына шылтыратып ала: «Усть-Илимга тимер-бетон плитәләрдән салынган юл буенча кайчан барып җитәргә була?» Комбинат управляющие Александр Степанович Южаков — Наймушинның акияттәгедәй планнарын тормышка ашыруга булышкан искиткеч кешеләрнең бер вәкиле. Шул ук көнне Седанов төзү-монтаж идарәсе начальнигына юлга кирәкле плитәләрне әзерләүче завод урынын билгеләп куярга кушыла. «Кайчан хәбәр итим, Иван Иванович?», — дип сорый ул. «Заводны эшләтә башлагач», — дип җавап бирә Наймушин.

## V

1965 елның көзендә Наймушин Усть-Илим төзелешенә бетмәс-төкәнмәс дәртен бирә. Америка журналистлары аңа «су аюы» дигән кушамат тагалар. Мәскәүдә һәм Братскида чыннан да аны Усть-Илимга аю кебек ыргылып тора дип саныйлар. Ул исә 1962—1964 елларда ирешелми калганнарны куып җитәргә генә ашыга. Боларның бөтенесен ул 1967 елда Усть-Илим ГЭСының «тәпиен юар» өчен ягъни беренче буаны буып, казанлык казу һәм төп эшләргә керешү хакына эшли. Бу исә су станцияләре коруда беренче мәртәбә агым ысулы куллану дигән сүз: Усть-Илим буасына беренче бетон Братск ГЭСын эшләп тапшыргачы ук салыначак.

Юл трассасы кырмыска оясына охшап кала. Аның 250 чакрымының һәр карышындагы эшләр Наймушинның шәхси күрсәтмәләре нигезендә башкарыла: кышка кергәнче, ул юлдан Усть-Илимга беренче машиналар йөк ташырга тиеш була.

Ангараның Ершов бусагасы тирәсендә бик мөһим бер бурыч хәл ителеп ята: анда чуер төялгән баржалар озатыла. Тик сунын тирәнлеге өчтән бер өлешенә генә төялгән баржаларны үткәрергә мөмкинлек бирә. Суны күтәрү өчен бусаганың сул як тармагын буып алырга кирәк. Мондый бурычны моңа кадәр беркемнең дә һәм беркайда да хәл иткәне булмый. Тармакның бер өлешен шартлату юлы белән капларга дигән тәкъдим барлыкка килә. Дамбага йөз мең кубометр кыя ишү таләп ителә. Җитмәсә, Ангараның әченәрәк керә барган саен, су агызып алып китмәсен өчен, эре ташлар сорала. Гадәттә, моның ише эшкә айлар буе хәзерләнә торган булалар: Ангара кебек кырыс табигатьле елгага 720 метрлы дамба сузу — колак ишетмәгән кыюлык. Күрәш җиңү белән тәгәлләнә. Бусагадагы елга суы ярты метрга күтәрелә, уннарча мең сум акчаны янга калдырырга мөмкинлек туа.

1965 ел азагында Наймушин юлны тимер-бетон плитәләр белән каплау мәсьәләсенә чума. Бу проблема уңаеннан биниһая күпсанлы киңәшмәләр үткәрелә. Проектчыларның да, Братск һәм Усть-Илим ГЭСлары дирекцияләренең дә Наймушин фикере белән килешеп җитәселәре килми.

һәм, һәрвакыттагыча, төп җаваплылыкны Наймушин үз өстенә ала. Ул тимер-бетон плитәләр сала башларга дигән күрсәтмә бирә. Тиздән алары салына да башлый, тик икенче көнне үк министр урынбасарыннан Братск — Усть-Илим автомобиль юлына бетон салуны тыйган телеграмма килеп төшә. Телеграммалар өзлексез ява тора. Наймушин бетон плитәләрне өзлексез озата бирә. Инде өч катлап асфальт җәяргә кирәк дип тә карыйлар. Һәм Наймушин Алексей Николаевич Косыгин исеменә аңлатма җибәрә, министр аңа үзенең уңай карашын белдергән фикерен терки. Тиздән ул документка «Непорожний һәм Наймушин тәкъдимнәре белән килешергә» дигән резолюция төшә.

## VI

Наймушинны бөтен илдә беләләр иде. Моның бар сәбәпләрен дә санап бетерерлек түгел. Братскида һәм Усть-Илимда исә аны аеруча хөрмәтлиләр, яраталар. Наймушинны гомерләрендә бер мәртәбә дә күрмәгән дүрт яшь егет 1974 елда аның хөрмәтенә Братск ГЭСы плотинасына кадәр озын марофонга чыгып китәргә булалар. Аның шундагы каберенә яшьләр исеменнән чәчәк куяр өчен.

Стратег буларак, Наймушин ведомство кысасына һич сыймый. Братокига килгәч, ул үз бурычын Братск ГЭСын кору планын үтәп чыгуда гына түгел, ә беренче чиратта Себернең бу төбәген комплекслы һәм тиз көндә юлга җибәрүдә дә күрә. Усть-Илим эшләрен ул берничә ел буенча Братск ГЭСында янга калдырулар исәбенә алып бара. Аны Волжск ГЭСын җибәрү тантанасына кунак итеп чакыргач, дәүләт комиссиясе председателе бөтен төзелешләр башлыклары алдында аннан:

— Эшләрегез ничек бара, Иван Иванович? — дип сорый.

— Икелегә,— дип җавап бирә Наймушин.

— Моны ничек аңларга соң?

— Ике мәртәбә куәтлерәк, тизрәк, арзанрак!

Братск ГЭСы рекордлы вакыт эчендә төзелеп бетә: биш ел да өч айда! Һәм ул — илебездә смета бәһасеннән арзанракка төзелгән, үзен дәүләт комиссиясе кабул иткәнчегә хәтле үк тулысынча аклаган бердәнбер ГЭС.

Ә Усть-Илимда бу вакытка казанлык әзерләнеп бетә, буага бетон салына башлый, даими поселокның беренче йортларында өй туйлары үткәрелә. Шулай итеп, су станцияләре төзелешендә агым ысулы хәрәкәткә килә. Наймушин илне мөмкин кадәр тизрәк тагын да арзанрак электр энергиясе белән тәэмин итү өчен тырышты. Вакытны оту өчен Наймушин 1966 елда ике күпер салырга кирәк дигән бик мөһим бер фикергә килә. Проектчылар автомобиль һәм тимер юллары өчен күперне Братскидагы шикелле үк буа өстенә салуны теләгәннәр иде. «Без биш ел буе көтә алмыйбыз»,— дип, Иван Иванович фикерен тормышка ашыру мөмкинлеге ала. Ә Братск — Усть-Илимның икенче «цемент күперен» үз көче белән салырга карар кыла да автоидарә начальнигын чакырта.

— Усть-Илимда күпер саласы бар иде.

— Мин төзүче түгел ләбаса, Иван Иванович.

— Автомобильче икәнеңне белгәнгә күрә чакырдым.

— Мин нишли алам соң?

— Йөз КРАЗны цемент ташырга көйлә!

Ике ел ярым буена Усть-Илим Братск цементын «ашап» тора. Өзлексез рәвештә, теләсә нинди һава шартларында, көне-төне.

Усть-Илимда беренче агрегатларны җибәрергә уйлый гына башлаган бер вакытта яңа — Богучан станциясе тарихы башланып китә. Мәскәүлеләр белән очрашу урыны итеп Иван Иванович бары тик Богучанны гына билгели башлый. Ул Ленин премиясе белән бүләкләнә, аңа Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелә.

1966 елда Усть-Илим хакындагы Март карарын илебезнең Министрлар Советында тикшергән чагында, Наймушин гел никтер шаян төстә елмаеп утырган дип сөйлиләр. Кем белә, бәлки ул 1960 елның январенда Юан Борынга баруын

исенә төшергәндер? Алар ул чакны Кияүләр исемле бер авылдан ерак түгел бер кышлакта куналар. Бөтенесе йокыга китеп бетүгә карамастан, сукыр лампа янында ике кеше бик озаклап тормыш хакында гәп сугып утыра. Карт аучының үз алдында Братск ГЭСы төзелеше начальнигы утырганына һич кенә дә ышанасы килми. Бары тик иртән хушлашкан чагында гына ул карлыккан тавышы белән Наймушинга:

— Җиребез турында кайгыртудан арый күрмә, Иван Иванович, арый күрмә!— дип кала.

Ә ул арырга уйламый да. Фаҗигале бер очраклылыктан — вертолетлары ялгыш утыру аркасында — гомере өзелгәнчегә кадәр кайчандыр олы тормышка мәшһүр Толстойның «Сугыш һәм тынычлык» романын күчереп чыгу белән аяк атлаган татар егете, ә тормышының азагында легендар Иван Иванович Наймушин дигән дан казанган бу асыл зат безнең җиребез хакында кайгыртуыннан һич арымыйча Братск ГЭСы буасы белән янәшәдәге каберендә үлемсезлек дөньясында ята.

Ә. **ГАФФАР** тәрҗемәсе

## Укучының күңел дәфтәренә

**Якут мәкальләре һәм әйтемнәре**

*Зур елгада җил салкын, зур савытта юшкын күп*
*Боткаң пешсә, маен кызганма.*
*Буш капчык утырып торалмый.*
*Балта чапмаган чагында бүрәнә дә ял итә.*
*Бер сыерның тиресен ике кат тунамыйлар.*
*Якында елга барында әллә кайдан су ташый.*
*Дошманга зыян китергән һәр чара да файдалы.*
*Иртә тормасаң — көнең югалыр, ә яшьли укымый калсаң — бөтен гомерең әрәм.*

Ринат Мөхәммәдиев,
филология фәннәре кандидаты

# ШИГЪРИ ХӘРӘКӘТ ҺӘМ АНЫҢ КАЙБЕР ТЕНДЕНЦИЯЛӘРЕ

*1980 нче елгы поэзиябезгә бер караш*

Шагыйрь һәм шигырь сүзләренә элек-электән олы һәм тирән мәгънә йөкләтелгән. Борын-борыннан җыр иясе шигырьне тын да алмый тыңлау, аларны иҗат иткән шагыйрь исемен үзгә бер хөрмәт белән искә алу, акыл иясе һәм моң чишмәсе итеп тану гадәткә кергән. Әдәбият тарихына гына түгел, культурабыз тарихына, халкыбызның иҗтимагый аңы үсеше баскычларына күз салсак та без шагыйрь исеменең ни дәрәҗәдә мәртәбәле булып, татар поэзиясенең гомер-гомергә кешелекле, интернациональ рухлы һәм прогрессив көч булганлыгын күрербез. Күңелгә иң элек Кол Гали, Мөхәммәдъяр, Утыз Имәни, Кандалый һәм Акмуллалар калдырган үлмәс җырларның моңы яктылыгы төшә. Көр күңелле, азатлык сөючән, һәм сугышчан поэзиябезнең чишмә башы шулардан булганга. Шигъриятебездә яңа дәвер ачкан Тукай рухы исә бөтен поэзиябезгә — аның үткәненә, бүгенгесенә һәм киләчәгенә нур сибеп тора. Шуның яктылыгында Һ. Такташ, М. Җәлил, Ф. Кәрим һәм Х. Туфаннар йолдызлыгы балкый. Болар яңа сүз түгел, әлбәттә. Әмма бу исемнәрнең соңгы еллардагы шигъри хәрәкәткә турыдан-туры мөнәсәбәте бар. Чөнки шул вакыт аралыгында без, бүген дә шигъри сафта булган, җыр һәм шигырьнең илаһилыгын намусы һәм күңеле аклыгыдай саклый килгән олы шагыйрь Хәсән Туфанга 80 яшь тулу көнен бәйрәм иттек. Әле шушы ел башында гына булып узган Һ. Такташ һәм М. Җәлил юбилейларының бүгенге татар поэзиясенә йогынтысы шулай ук чиксез зур булды. Аларны киләр буыннарга олы гражданлык үрнәге булып торган тормыш һәм иҗат юлы бетмәс-төкәнмәс илһам чыганагы.

Такташ, Җәлил, Туфан... Сүз дә юк, югары критерийлар, гадәттән тыш югары! Әмма анализланыла торган шигъри әсәрләр арасында шундый критерийлар алдында да йөз кызартмаслыклары булуны тою күңелгә дәрт һәм көч өстәп тора.

Табигый ки, поэзиябездә эзләнү һәм ачышларга, яңа идея-эстетик кыйммәтләргә омтылыш бер генә көнгә дә тукталып тормый, өзлексез дәвам итә. һәм бу эзләнүләр һәр шагыйрьдә үзенчә, башка һичкемнекенә охшамаган юлдан бара. Ләкин шуның белән берга, шигъриятебезнең үсеш баскычларына күз салганда, билгеле бер вакыт аралыгында өстенлек иткән гомуми тенденцияләр дә аермачык булып күзгә ташлана. Әйтик, берара шигырьдә сюжетлылыкка зур әһәмият бирелгән булса, күпмедер вакыт үткәч бу бөтенләй икенче планга күчә, онытылу дәрәҗәсенә җитә язды. Аннан шигырьдә, шулай әйтергә ярәса, тематик бум башланган. Кулына каләм алган һәр шагыйрь шул чорда аеруча популяр булган һәм, әлбәттә, гомумән дә зур әһәмияткә ия темага гына мөрәҗәгать иткән сыман. Әйтерсең лә, шәхси тормыш, шәхси кичерешләр, хис, борчу һәм мәшәкатьләр булмаган да. Бәхәссез ки, бу тенденциянең шигъ-

риятебез үсешенә уңай йогынтысы зур булган. Әмма тора-бара чама тойгысының онытылып, әһәмиятле һәм җитди темаларга әдәби эшләнеше, сәнгатьчә камиллеге төрле дәрәҗәдә булган әсәрләр күпләп языла торгач, әдәби сүзнең кадере китү, файдалы эш коэффициенты кимү куркынычы абайлап алынган. Моны тоемлаучылар ашыгыч рәвештә форма өстендә эзләнүләргә ташланды, шигъри форманы активлаштыру һәм җанландыруга йөз тоттылар. Поэзиябезгә яңа бизәкләр өстәлде, арада сәеррәк, ятрак тоелган бизәкләрнең дә булуы кайберләрне сагайтып та алды. Әмма аермачык булып алтмышынчы еллар урталарында күзгә ташланган бу хәрәкәтне традицияләр белән хисаплашмау, яуланган биеклекләрдән баш тарту янсә мөгез чыгару дип санаучылар ялгышкан кебек, яшь шагыйрьләр татар поэзиясенә моңарчы күрелмәгән форма яңалыгы һәм эчтәлек тирәнлеге китерделәр дип шаккатучылар да хаталанды, ашыга төштеләр. Вакыт үтте — шау-шулар да тына төште. Уйлап баксаң, күп гасырлык бай үткәне булган шигърнятебездә беренди дә «революция» булып узмаган икән, ә нибарысы әдәбиятка, үз урынын дәгъва итеп, тагы бер буын сәләтле шагыйрьләр килгән. Аерма тик шунда — имин елларда үсеп, илдә материаль һәм мораль шартлар нык стабильләшеп өлгергән чорда шәхес буларак формалашкан буын икән бу. Ә яңа шартларның яңа характерлар тәрбияләве гаҗәп түгел.

Дөнья поэзиясе тарихында өйрәнерлек, үрнәк итеп алырлык сәхифәләрнең күп булуы табигый. Шуларга йөз белән борылу, традицияләргә яңача бер дикъкать белән карау сыйфат үзгәрешләре дә китермәде түгел. Роберт Әхмәтҗанов, Р. Харис, Р. Мингалимов иҗатлары шуңарга ачык дәлил. Әмма чираттагы бу мавыгуның да чиге бар икән. Форма өлкәсендәге мавыктыргыч экспериментлар ишәя төшкәч, рухланып китеп, моны үзмаксат итеп алучылар да табылды. Популярлашып килгән «Кыска шигырьләр»не генә искә алыйк. Дөрес, дүрт һәм башка сандагы юлдан торган әсәрләр борын-борын заманнарда да язылмаган түгел. Әмма моны бүген үзенчәлекле форма һәм хәтта шигъри жанр итеп тә тәкъдим итәргә омтылучылар табылды. Р. Фәйзуллинның кыска шигырьләре белән таныштык: бәхәссез, уңышлылары, мөстәкыйль шигырь булып яшәргә хаклылары байтак. Шигъри заготовка, язылачак әсәр өчен чимал булып кына торырлыклары да ким түгел. Шушы нәрсә кемнәргәдер охшап китте — «Кыска шигырьләр» дигән баш астында (белмим, нәрсә дигән сүздер ул рубрикамы, үлчәү берәмлегеме, әллә жанрмы, әллә тагы без белмәгән бөтенләй чит-ят бернәрсәме?..) матбугатта һәм бигрәк тә «Казан утлары»нда, кем әйтмешли, «яңа төр» әсәрләр басыла башлады. Авторлары Г. Афзал, Рәшит Әхмәтҗанов, Ф. Яруллин, В. Туктарова һ. б. Моңа кадәр шул ук Г. Афзал, З. Нури, Ш. Галиев, Г. Рәхим кебек юморсатира осталары әлегедәй әсәрләрен гадәтләнгәнчә «дүртьюллыклар» дип кенә атый иде, югыйсә.

Шулай да форма тирәсендәге шау-шулар да, үз чиратында, инде тына төште. Шигърнятебез барышында соңгы елларда күзгә ташланган тенденция — ул гражданлык активлыгына омтылышның арта баруы. Мәгълүм булганча, гражданлылык — поэзиянең генә түгел, гомумән, әдәбият һәм сәнгатьнең мәртәбәсен, сугышчанлыгын һәм, барыннан да бигрәк, аларның иҗтимагый тормыштагы урынын, йөзен билгеләүче сыйфат. Чын сәнгать әсәре, димәк, аңардан башка мөмкин түгел. Шигърияттә исә, хис һәм акыл көче бергә кристаллашкан үтә нәфис жанрда, гражданлылык әсәрнең һәм идея, һәм эстетик кыйммәтен билгеләүче төп критерийга әйләнә. Бәхәссез ки, форма оригинальлегенә омтылыш әдәбиятка алтмышынчы елларда килгән буынга гына хас күренеш булмаган кебек, гражданлылыкның да чын шигърияттән мәңге аерылгысызлыгы аңлашылса кирәк. Сюжетлылык һәм әһәмиятле темаларга даими игътибар аеруча кирәклеге дә көн кебек ачык. Ләкин шуңарга да карамастан, болар һәркайсы поэзиябезнең соңгы 3–4 дистә еллар эчендәге үсешенең аерым этапларын характерлап килгән үзенчәлекләр. Һәм шунысы кызыклы — бу һава алмашынулар, кагыйдә буларак, иҗат кыйбласын тапкан, шигъри хәрәкәттә үз урынын алган авторлар иҗатында түгел, ә иң элек үз-үзен эзләгән, гомум шигъри процесста үз урынын билгеләүгә ашыккан яшьләрдә чагылыш таба. Кемгәдер гаҗәп тә тоелырга мөмкин, ләкин факт — хәрәкәт төсмерләрен иң элек шигъри үрентеләр билгели икән.

Чын шигърият культларны яратмый — сюжет культын да, тема культын да, форма культын да, үз «мин»еңне өреп кабартуга кайтып калса, гражданлылык культын да кабул итә алмый шигърият. Шигърнятнең дисталәгән компонентлары гармониясенә

ирешкән шагыйрьләр үз арабызда[1]. Әйтик, шул ук Х. Туфан. Олы бәйрәме көннәрен дә ул гадәттәгечә тыйнак һәм сабыр каршы алды. «Лирика» дип исемләнгән җыйнак кына китап һәм газета-журнал сәхифәләрендә бирелгән җыр-шигырьләр төркеме. Шул юбилей көннәрендә искә алучылар булмый калмагандыр — Х. Туфан, китабына булсын, вакытлы матбугатка булсын, бары тик соң дәрәҗә шигъри камиллеккә ирешкән әсәрләрен генә тәкъдим итте. Югыйсә, ни китерсә дә басарлар иде кебек бит. Юк, ул алай булдыра алмый, шигърияткә изге иcеме белән дә, укучы зәвыгы белән дә шаяра алмый олы шагыйрь — матбугатка җиде кат иләк аша үткән әсәрләрен генә җибәрә. Һич икеләнми раслый алам, бу яктан ул безнең һәммәбезгә дә үрнәк булган фидакарь җан!

Х. Туфан шигырьләрен укый башлагач та калдырып киту кыен булган кебек, аның иҗаты хакында сүзне бүлеп тору да җиңел эш түгел. Шулай да, сүз уңаеннан файдаланып, өлгереп килгән бер мәсьәләгә тукталып узасы килә. Бүгенге совет поэзиясен даими өйрәнеп килгән танылган тәнкыйтьче А. А. Михайлов «Литературная газета»да дөнья күргән бер мәкаләсендә «Газета яки журналда басылган шигырьләре шагыйрьнең визит карточкасы булырга тиеш» дигән иде. Ә бездә исә моны бик күпләр, айһай, бик күпләр, бөтенләй искә дә алмыйдыр кебек. Башлап язучы һәм талант ягы чамалы шигырь чыгаручылар өчен матбугатта чыгу, укучы алдында исемен күрсәтеп алуның үзмаксат булуын аңларга да була. Ә чын мәгънәсендә шигъри талантка ия булып та матбугатка ни әлекте шуны тәкъдим иткән шагыйрьләрнең талымсызлыгы, кабаланып-кабаланып ашыгуы аңлашылмый. Кем куа аларны, әллә шигырь җыентыкларының калынлыгы һәм вакытлы матбугатта ешрак чыгу буенча безгә мәгълүм булмаган берәр конкурс игълан ителгәнме, дигән шик тә керә күңелгә. Вакытлы матбугатта шигырь исеме белән пешеп җитмәгән язмалар, кечкенә бер мәкалә яисә информация аша да укучыга җиткерү мөмкин булган мәгънәле һәм мәгънәсез, тегеннән-моннан рифмаланган сүзләр күбәйде. Әдәби сүзнең идея һәм эстетик җегәренә турыдан-туры суга торган мондый күренешләргә, мәгълүм булганча, партиябезнең XXVI съездында ясаган докладында иптәш Л. И. Брежнев та килешмәүчән булырга чакырды. Һәм бер тәнкыйтьчеләрне генә дә түгел, матбугат органнарын, иҗат оешмаларын һәм аларның партия оешмаларын. Безгә бу сүзләрнең мәгънәсе һәм ни дәрәҗәдә урынлы булуы хакында кайтып-кайтып уйланырга кирәк булыр иде.

Үзәк телевидение буенча чыгышында шагыйрь О. Сөләйманов, шигырь язарга омтылучыларның күплеге ул коточкыч бәла түгел, бомба ясаучыларның көннән-көн ишәя баруы сагайтырга тиеш безне, дигән иде.— Хак сүзләр! Әмма, шигырь, шагыйрь һәм талант сүзләренең вакыт-вакыт беренчел мәгънәләрен онытып җибәрү, елдан-ел ул сүзләрне файдалануда юмартлана баруыбызның да бер чиге булырга тиештер ләбаса. Юкса, финансист һәм экономистлар теленнән төшмәгән девальвация термины шигырь белгечләре телендә дә иң популяр сүзгә әйләнеп китүе ихтимал. Инде итәк очын җыя төшебрәк әйткәндә, яшерен-батырын түгел ич, профессиональлеккә дәгъва иткән шигырь чыгаручылар, гомумән, поэзиябезнең абруен төшерә, укучы зәвыгын зәгыйфьләндерә, үсеп килүче һәм туачак яшь талантларны әдәбиятка килү юлында адаштыра.

Шушы урында яңадан Х. Туфан иҗатына әйләнеп кайтуның минем өчен ни дәрәҗәдә рәхәтлеген аңласагыз икән. Әйе, Туфан поэзиясе эстетик җегәре, шигъри камиллеге белән күпләргә, бик күпләргә үрнәк булып тора. Бер үк вакытта шагыйрьнең нинди олы гуманист, интернационалист булуы, иҗатының башыннан бүгенгесенәчә халыкчанлык һәм партиялелек идеяләре белән ни дәрәҗәдә сугарылуы да сокландыра. Моңлы булса да Туфанның бөтен иҗат юлы сүлмәс оптимизм рухы — Ватанга, халыкка һәм кешеләргә мәхәббәт нуры белән өртелгән. Әйтик, бер тема — даһи Ленин темасына шагыйрьнең мөнәсәбәтен күз алдыннан уздырыйк. 1926 елда Ленин үлгәч, юксынып язган «Мә, партия, мине!» шигыре мондый юллар белән башланган:

Күңел — ярсу елга,
Күкрәгемдә — уйлар ташкыны,
Авыр, дуслар,
Бу йөрәк бит чуер таш түгел!

[1] Мәкалә Хәсән ага Туфан вафат булганга кадәр җыелган иде.

һәм шушы шигырь язылганнан соң ярты гасыр чамасы вакыт үткәч иҗат ителгән икенче бер әсәр үзенә җәлеп итә:

Җирдә яз... Таллар исе...
Һавада кошлар өне...
Кай елда иде икән
Гомернең шушы көне!..

«Ленин» дип беренче кат
Кем әйтте! Әни микән!
Апрельнең үземе соң,
Тургае әйтте микән!..

«Киләчәк көннән сиңа
Сәлам бу»,— дигән кебек,
Бу сүзне синме, кояш,
Китердең нурга төреп!..

Бер нәрсә көн кебек ачык, еллар үткән саен шагыйрьнең хис кайнарлыгы да үсә, арта гына барган. Ленин исеменең Җир, ана, яз, һәм туган як табигатедәй изге төшенчә булуын шулай шагыйранә әйтеп биргән олы шагыйрь Хәсән Туфан.

В. И. Ленинның тууына 110 ел тулу вакыйгасы татар шагыйрьләрен яңа иҗат җимешләренә дә рухландырмады түгел. Мисал өчен, «Казан утлары»нда Н. Арсланов, Ә. Маликов, С. Баттал, Г. Латыйп, Ш. Маннапов һәм башка авторларның шигырьләре дөнья күрде. Ә «Социалистик Татарстан» исә «Даһи Ленин — илһам чыганагы» дигән рубрика астында «Шигъри Сабантуй» уздырды. Әлбәттә, шигъри әсәрләрнең барысы да бер дәрәҗәдә камил иде, чын мгънәсендә иҗат җимешләре иде дисәң — дереслеккә хилафлык килер иде. Бу юлы да, гадәттәгечә, теманың әһәмиятле булуы — вакытлы матбугатка юл ача дип ышанган авторлар булмады түгел. Миңа исә, укучы буларак, Н. Арсланов, С. Сөләйманова, Роберт Әхмәтҗанов, Р. Миңнуллин, Рифгать Закиров һәм Ф. Сафин әсәрләре ныграк тәэсир итте. Дөрес, бу очракта «миңа ошыйошамый» бердәнбер критерий булмаска да мөмкин.

Ә инде «Шигъри Сабантуй»ның уртасына чыгып баскан Сибгат Хәким әсәрләренә, бигрәк тә «5924» дип исемләнгән шигырьгә аерым тукталырга кирәктер. Аңа битараф калу һич мөмкин түгел. Себер юлындагы 5924 нче номерлы багана... Даһи Ленин сөргендә булган җирләр... Шагыйрь шул багана тирәли әйләнә, уйларга бирелә. Уй-хыял чорыбызның һәм кешелекнең имән баганасы булган Ленин образына күчеш ясый, даһи юлбашчының масштаблы образы тудырыла. Гади һәм гадәти генә детальләрдән дә шундый олы һәм җитди гомумиләштерүләргә юл табу бу очракта шигъри осталык үрнәге буларак тәкъдим ителүгә лаек. Һәм бу үзенчәлек С. Хәкимнең бөтен иҗатын колачлап торган сыйфат үзенчәлеге булып та тора. Моны шагыйрьнең узган ел журналда басылган алты шигыре дә ачык дәлилли кебек. Шагыйрь күңеленнән очырылган алты күгәрченгә охшатыргамы аларны, шагыйрьнең хисләреннән шытып чыккан алты төрле чәчәккә тиңләргәме, әллә шагыйрьне гомере буе борчып йөргән мәсьәләләр, рухи халәтләрнең җанлы образы дип раслау дөресрәк булырмы?! Яңа өйләнешкән бәхетле парлар Ленин һәйкәленә чәчәкләр китергән; дәһшәтле сугыш хатирәләре күңелгә тынгылык бирми; тарих агышы һәм кеше гомере хакындагы уйларның очы-кырые юк — шул кадәре уйлар-хисләр дәрьясында шагыйрь.

Яз җитте, тагын да яз җитте,
Җир эреп, ага бозлар,
Китми нишлисең дигән күк
Иренеп ага бозлар.

. . . . . . . . . . . . . . .

Китәләр, бәхилләшәләр,
Бетми сөйләр сүзләре.

**Еракта, ләкин колакта**
**Бозларның гөжелдәве.**

Шигырьгә өстәп һични әйтергә урын калмаган, ә фикергә бетмәс-төкәнмәс киңлекләр ачыла.

Алга таба үтсәк, игътибарны Нури Арсланов шигырьләре җәлеп итәр. Үзләренең уйнаклап торган шигъри агышы, рух күтәренкелеге һәм проблемаларының җитдилеге белән җәлеп итә алар. Шигъри форма, яңадан-яңа образлар системасы, үзенчәлекле бизәк һәм нәкышлары белән Н. Арсланов поэзиябезнең борынгыдан килгән традицияләрен дәвам итә. Һәм шул күзлектән ул бүгенге көн татар шагыйрьләренең һәммәсеннән аерылып тора.

**Күз яшьләрем, таммасана,**
**Яңгырлар күпме яуса да**
**Диңгезләр тулганы юк.**
**Көннәре үтте язымның,**
**Шулай да күңел сазымның**
**Кыллары тынганы юк.**

Тынгысыз сазын ул шулай әле Г. Хайям робагыйларындагы мәңгелек яшьлек һәм мәхәббәт кылларына көйли, әле Н. Хикмәт сыман сынмас рухлы оптимист көрәшчегә әйләнә:

**Кеше, арын киртәләрдән,**
**Атомны кулга алчы! —**
**Саклап калчы шул бәладән**
**Җир шарын... ярылганчы.**

Һәм яңадан иптәш Л. И. Брежневның партия съезды трибунасыннан әйтелгән сүзләре искә төшә: «Хәрби темага турылыклы авторларның эшләре Ватанга мәхәббәт тәрбияли, сынауларда нык булырга өйрәтә». Әйе, тынычлык, иминлек өчен көрәш чорыбызның иң мөһим проблемасы булып кала бирә. Шуңа күрә, авыр сугышларны үз башларыннан уздырган буын вәкилләре — фронтовик шагыйрьләр иҗатына, без иң элек, хәрби-патриотик тәрбия чыганагы итеп карарга тиеш. Бөек Җиңүнең 35 еллыгында Татарстан китап нәшриятының Н. Дәүли, З. Нури, Х. Камалов, С. Баттал һәм М. Мазунов китапларын дөньяга чыгаруы бер дә очраклы түгел. Аларга С. Хәким, Ә. Маликов, М. Рафиков, Г. Нәбиуллин, М. Хәсәен кебек фронтовикларның вакытлы матбугат сәхифәләрендә чыгып килгән әсәрләре кушылгач, татар совет поэзиясенең бүген дә тынычлык өчен көрәштә төшеп калганнардан булмавы бик ачык булып һәм конкрет рәвештә күз алдына килеп баса. Дөрес, аерым очракларда, искә алынган авторларның бер ишесе шигъри камиллек һәм эстетик җегәр төшенчәләрен оныта төшеп, үсештән туктатлган хәлдә, калыпка салынган сөйләү, хикәяләү белән дә мавыкмыйлар түгел. Әмма шундый житешсезлекләре һәм тел ягыннан төгәлсезлекләре очраштыруга да карамастан, уртак темага мөнәсәбәтләрендә һәркайсының кабатланмас үз йөзе бар. Әйтик, Н. Дәүлигә лирик җылылык һәм дөньяның төрле почмакларында барган революцион хәрәкәткә игътибарлылык хас булса, Х. Камалов исә үзенең ихласлыгы белән укучының күңел түрендәге иң изге төшенчәләргә туры юл табу сәләтенә ия. З. Нуриның «Шигырь китапханәсе»ндә чыккан «Күңел яктысы» китабы арада тулылыгы белән аерылып тора һәм шагыйрь үткән юлның озын һәм катлаулы да, мактаулы һәм данлы да икәнлеге хакында сөйли. Бу җыентык, барыннан да элек, совет кешесенең интернациональ һәм патриотик рухын, тарихи оптимизмын, җорлыгы һәм киң күңеллелеген дәлилле күрсәтә.

Ватан өчен көрәш һәм җирдә иминлекне саклау темасы фронтовик шагыйрьләр өчен генә дип бүлеп куелган кишәрлек түгел, әлбәттә. Моны бөек Җиңүнең 35 еллыгы уңаена дөнья күргән бүтән шигырьләр дә раслап килә. Араларыннан Роберт Әхмәтҗановның «Ирләр юк» әсәре үзенең масштаблы уй-ниятә корылып, сәнгатьчә

тәэсир итү көченә ирешкән булуы белән аерылып тора («Казан утлары», 1980, 5 сан). Ә менә аның артыннан ук бирелгән Р. Гәрәй, Д. Сирай, Рәшит Гатауллин һәм Н. Әхмәдиев шигырьләре хакында алай дип әйтү мөмкин түгел. Мисал өчен, Р. Гәрәйне без авыл һәм туган як темасына тугрылыклы, хисләре нечкәлеге белән үзгә шагыйрь буларак белә идек. «Туган авылымның туксан батыры» бик тә шаблон яңгырашлы:

Туган авылымның туксан батыры
Исәннәрнең күңел түрендә.
— Уяу булыгыз — дип, ил улларын
Кисәтәләр алар бүген дә,

— барысы да хак сүзләр, урынлы сүзләр, ләкин яңача һәм шагыйранә әйтелмәгән.

Соңгы елларда бермә-бер активлаша төшеп иҗат иткән Д. Сирай да бу очракта традициягә кереп туйдыра башлаган сүзтезмәләрдән арына алмаган:

Күкрәкләрдә уч ялкыны күтәрелде,
Өермәдәй соңыннан Берлин
Урамына бәреп керде.
Һәм ул ялкын байрак булып
Балкып рейхстагка менде.

Шушы урында Гетеның «Шигырьләр менә дигән булырга тиешләр. Янсә аларны бөтенләй язмаска гына» дигән сүзләре урынлы яңгырар сыман. Яшь шагыйрә Н. Измайлова исә моны хәтердән чыгармаган. Аның «Унбер җәлилчегә» дигән шигыре дулкынландыргыч тойгы һәм шигъри детальләр берлегеннән гыйбарәт. «Ах, бу кояш бигрәк моңлы ядкарь сездән — исәннәргә»,— дигән мөрәҗәгать белән тәмамлана әсәр. Ә күңелне тыныч иртәләрнең, иминлектә үткән елларның кадере һәм җирдә яшәүнең мәгънәсе хакындагы уйлар биләп ала.

Җәлилчеләр... Еллар үткән саен ватанга һәм халыкка булган тугрылыклары калкурак тоела барган, намус һәм каһарманлыклары белән халкыбызның йөзе аклыгын бөтен Европага таныткан затлар. Әдәбиятыбызның төрле жанрларында иҗат итүче талант ияләренә мәңгелек илһам чыганагы алар. Үткән ел бу күзлектән аеруча уңдырышлы булды: Т. Миңнуллинның «Моңлы бер җыр» драмасы һәм Р. Харисның «Җәлилчеләр» циклы. Һәр икесе авыз тутырып сөйләшергә нигез булырлык әсәрләр — Р. Харис аз санлы юлларда һәр каһарманның гомерен, ватанга тугрылыклылыгын символлаштыра торган идея һәм эстетик җегәргә ия шигъри детальләр табуга ирешкән. Ә бу исә җәлилчеләрнең гомумиләштерелгән масштаблы образын тудыруда үтемле һәм кулай чара булып чыккан. Мисал өчен, җәлилчеләр исеменнән сөйләнелгән берничә монологтан өзекләр китерик:

Гайнан Кормаш:

...Ул — коммунист каны!
Утлы кан ул!
Кайсыгызга гына таммасын —
янгын чыга.
Менә сиңа тамды —
Черемисең, фашист, янасың.

Абдулла Алиш:

...Күзләремә минем төне буе
газап булып тулды ак тынлык.
Күзем көйде,
көек эчендә дә
пычратмадым сине, яктылык!..

Зиннәт Хәсәнов:

**...Ватанымның гимны!.. Кыйнадылар —**
**тәнгә сеңде кабер салкыны...**
**Чәчләремдә кәфен төсе түгел,**
**нәфрәтемнең ап-ак ялкыны.**

Әсәр композиция җәһәтеннән бербөтен һәм төзек, һәр батырның монологы гына түгел, кереш белән соңгы сүз дә ватан өчен яшәү һәм үлә белүнең иң зур батырлык икәнлеген бар тавышка яңгыратып тора. Ләкин кереш һәм соңгы сүзләрдә рефрен булып яңгыраган шундый юллар бар:

**Ватан өчен үлү — безнең бурыч!**
**Совет өчен үлү — батырлык!**

яисә:

**Ватан өчен яшәү — безнең бурыч!**
**Совет өчен яшәү — батырлык!**

Ватан һәм Совет төшенчәләрен аерып, хәтта күпмедер каршы кую белән килешеп булмый, безнең аңга алар бер дәрәҗәдәге изге нәрсә булып кереп калган. Җәлилчеләр дә бит Ватан һәм Совет төшенчәсен яшьли бер бөтен итеп кабул иткән, совет чынбарлыгында шәхес буларак формалашкан буын вәкилләре. Зур идея нагрузкасы йөкләтелгән бу юлларны үзгәртергә кирәк.

Инде килеп вакытлы матбугатта Татарстан АССР төзелүгә 60 ел тулу уңае белән дә байтак кына шигъри әсәрләр басылып чыгуын искә алу урынлы булыр. Арада хәтергә уелып калганнары да бар. Әйтик, М. Әгъләмовның:

**Шагыйрь дустым, сәяхәттән кайткач,**
**Әйткән иде, Татарстаным,**
**Картадагы синең сурәтеңнең**
**Чабып барган атка охшавын,**

— кебек юлларын искәрми калу мөмкин түгел. Ил белән бергә экономика өлкәсендә булсын, культурада булсын, ай үсәсен көн үскән республикабызны акияттәге канатлы атка охшату ни кадәрле матур һәм урынлы. Һәм бит, бу образ шагыйрь фантазиясендә генә дә тумаган, анык реаль җирлеге дә бар икән — Татарстан картасына карап та шуны моңарчы күрә, тоемлый гына алмаганбыз. М. Әгъләмовның әлегедәй әсәрләрен укыгач күңелгә килә торган рәнҗү катыш үкенечкә генә һаман да җирлек кала бирә: сәләтле бу шагыйрь әле һаман, гражданин буларак та үзен мобилизацияләп, җиң сызганып иҗат эшенә кереп чума алмый йөри.

Шигырь калыбына салынган буш сүзләр, кызганычка каршы, бу очракта да аз язылмады. Характерлы бер мисалга мөрәҗәгать итик:

**Син минем Татарстаным,**
**Үткәнем, килер ал таңым,**
**Намусым, вөҗданым, даным**
**Сөекле республикам...**

Ә. Рәшитовның дөрес һәм урынлы сүзләрдән торган бу язмасы алга таба да шундый ук рухта дәвам итә. «Килә — ява, килә — ява, нияләнде бер болыт» дигәндәй, әлеге дә баягы сезонлы юллар бит болар.

Әхлак мәсьәләләре партиянең XXVI съезды трибунасыннан үзгә бер әһәмияткә ия проблема буларак билгеләп узылды. Шушы уңайдан И. Юзеевның «Мәхәббәт китабы» җитди сөйләшүгә нигез. ...Мәхәббәт. Кешелекне һәм дөньяны тотып торган әлеге хис, тойгы хакында дөнья поэзиясе тарихында азмы әсәрләр язылган. Һәм бүген шул хакта китап кадәр китап язарга җөрьәт иткән шагыйрьнең кыюлыгына сокланырга мөмкин. И. Юзеев мәхәббәт хисен тар мәгънәсендә түгел, ә кешене кеше иткән һәм кешене, илне, дөньяны мәгънәле, ямьле иткән төшенчә буларак җырлый. Мәхәббәтнең аерым бер сурәсен хәтерләткән һәр бүлек тормышчанлыгы

һәм гыйбрәтле вакыйгага корылган шигъри сюжеты белән җәлеп итә... Язмышлар, мәхәббәт хисен илаһилык дәрәҗәсенә күтәргән язмышлар, мәхәббәттән мәхрүм калган кызганыч язмышлар — бары да бар монда. Нәтиҗәдә, мәхәббәт — яшьлек һәм сөю белән генә чикләнмичә, намус, ил һәм халык алдындагы бурыч, дуслык, туганлык, җыр һәм җир тоткасыннан гыйбарәт көч буларак күз алдына килеп баса. Бүгенге шартларда «Әминә Мусаны көткәндәй, көтегез!» кебек сүзләр ни дәрәҗәдә актуаль һәм урынлы яңгырый. Китапның соңгы юллары исә күңелгә тынгылык бирми, кайтып-кайтып уйлануларга чакыра:

Сөю хисен әгәр югалтмаса,
Җир суынмас мәңге, Җир яшәр!

Әхлак мәсьәләсенең шигъри хәрәкәтебездәге урынын, ни дәрәҗәдә уңышлы булса да, бер әсәр рамкаларында гына чикләп карау дөрес булмас иде. Бу хакта сүз барганда Роберт Әхмәтҗановның «Хәтер елгасы», Р. Гатауллинның «Чакыру», Рәшит Әхмәтҗановның «Җан яктысы» исемле яңа җыентыкларын, Г. Афзал, Ш. Галиевнең яңа әсәрләрен, Г. Латыйп, М. Шабаев, Ф. Яруллин, Г. Рәхим һәм Р. Миңнуллинның шигъри циклларын искә алмый мөмкин түгел. Мисал өчен Г. Рәхимнең «Табылдыклар өстәлендә» тукталыйк. Исеме алай ук зур шигъри яңгырашка ия булмаган бер шигырьдә кайбер поэма авторларын көнләштерерлек фикер һәм хис кайнарлыгы тупланган. Моңын югалтучы, телен югалтучылар өчен урын юк шагыйрьнең күңелендә, ә авыр минутларында ярдәмгә, киңәшкә, назга мохтаҗлар өчен исә ул шәрран ачык.

Соңгы елларда күләгәдәрәк калып килгән М. Шабаевның «Күзнең якты моңнары» дигән яңа циклы да игътибарга лаек. Чираттагы бер төркем урта кул әсәрләре янәшәсендә, аның «Өйрәт, Ибет!» шигыре тормышчанлыгы, гадилеге белән генә түгел, гыйбрәтле язмыш аша тасвирланган әхлакый тирәнлеге, чеметтерәп алырга сәләте белән дә үрнәк булырлык.

Чеметтерәп алу дигәннән, кай вакытта андый шигырьне бөтенләй көтмәгән җирдә очратасың. Менә мисалга Рифгать Закировтан берничә өзек:

...Озаттың бураннарда...
Бер үзеңә күпме аклык
Калдырдым урамнарда!

...Кояшлы, җилле җәйдә
Сиңа калсын дип, гөлләргә
Тимәдем бөтенләй дә.

...Инде озаттым үзем,
һәм син дә калдырып киттең
Бөтен сарысын көзнең...

Колач җитмәслек проблемалар да күтәрелмәгән, ә күңелгә тия, уйландыра торган шигырь.

Р. Закиров шигырьләре кайсыдыр ягы белән — ихласлыгы һәм җылылыгы беләнме — Рәшит Әхмәтҗановны хәтерләтә. «Җан яктысы» китабы Рәшитнең башлаган юлында дәвам итүе хакында сөйли. Аның җиңел агышлы әсәрләрен укыганда чынлап та күңелгә яктылык, нур үтеп кергәндәй була. Дөрес, җыентыкта әлеге яктылыктан мәхрүм калган шигырьләр дә юк түгел. Аның ихласлыгы шул дәрәҗәдә ки, әгәр шигырьләрен «ясый» башласа, моны укучысыннан ул аз гына да яшерә алмый — шигыренең яме, сүзенең тәме югала. Бу үзенчәлекле һәм ихлас шагыйрьнең хәтта ялгышып та үз-үзенә хыянәт итмәвен телисе иде.

Роберт Әхмәтҗановның «Хәтер елгасы» җыентыгы егерме биш еллык иҗат нәтиҗәсе. Бер дә икеләнмичә әйтергә мөмкин, кызыклы шагыйрьнең яхшы китабы дөнья күргән: фикерләре җитдилеге белән күңелне тартса, хисләре кайнарлыгы белән сокландыра. Әмма китапны укып чыккач, тагы бер нәрсә ачыклана — шагыйрь

кабатлана башлаган. Аның алдында «Быть или не быть?» дигән классик сорау тора. Аю булып аю да үз тәпиен бер кыштан артык суырып ятмый — безнең Роберт та шушы хакыйкатьне аңласын иде.

Рәдиф Гатауллинның да чагыштырмача тулы җыентыгын күрү насыйп булды. Анда шагыйрьнең уй һәм хисләре хәрәкәте, иҗат эволюциясе аермачык чагылыш тапкан. Мәхәббәт лирикасында ул кабатланмас ярсулыгы, романтика канатында очкан хисләр ташкыны белән үзгә урын алды. Үз-үзенә поэзиядә «мәхәббәтнең Мәҗнүн премиясе» бирер ялгышмады Р. Гатауллин. Тора-бара шагыйрь алдында яңа офыклар ачылды — яңа шигырьләр, Париж һәм Лондон цикллары язылды. Кыскасы, шагыйрь берөзлексез эзләнүдә, хәрәкәттә. Ләкин, моннан 10—15 ел элекке иҗаты белән чагыштырып караганда аның шигырьләре үзләренең кабатланмас сафлыгын, оригинальлеген югалта төштеләр кебек. Ни хикмәттер, ул я адрессыз абстракт фәлсәфәгә кереп чума, я конкрет шәхескә багышлап истәлекләр язарга ярата башлады. Әдәбият тирәли фәлсәфәләре дә ышаебрак китте кебек. Бу үзенчелекле талантның яңадан Эйфель башняларына янсә тагы да биегрәккә менүе нәтиҗәсендә язылган һәм бүгенге чынбарлыгыбызны киңрәк иңләгән әсәрләрен укыйсы килә. Янсә манараларына, башняларына кул селтәп, инде, ниһаять, җиргә төшәсе иде шагыйрьгә...

Язучы А Гыйләҗевның «Җомга көн, кич белән» повесте түбәндәге юллар белән башлана: «Вальпараиса, Галапогос, Титикака, Куала-Лумпур — шәп яңгырый торган исемнәр, беләм. Әмма минем өчен Аксыргәк авылы, Ташлыяр елгасы тагын да шәбрәк!» Рәдифкә әле бу юлларның мәгънәсе хакында ныклап торып уйланасы бар.

Равил Фәйзуллин укучыларга «Сәйдәш» поэмасын тәкъдим итте. Культурабыз тарихында иң хөрмәтле урыннарның берсен алып торган композиторыбыз образына мөрәҗәгать итү һәрьяклап хуплауга лаеклы. Сәйдәшне җырлап туймасак та аның үз образын җырга салганыбыз юк иде бит әле. Поэмада чын мәгънәсендә шигъри юллар, строфалар бар. «Я сәүдәгәр булсын, я мулла», «Хатыннар», «Сискәнү» дип исемләнгән бүлекләр тулы вариантында күңелләрне билләрлек яңгырашка ия иделәр. Әмма шуларга да карамастан, Р. Фәйзуллинның әлеге хезмәте тәгәлләнгән шигъри әсәр булып чыкмаган, дигән фикердә калырга туры килә. Ни өчен? Чөнки шагыйрь Сәйдәшнең тормыш һәм иҗат юлын җентекләп өйрәнүенә дә карамастан, аның рухи дөньясына, күңеленә, җыр һәм музыкаларындагы моң тирәнлегенә үтеп керә алмаган. Бу — бер. Икенчедән, вакыт-вакыт шагыйрь үзенең кайсы жанрда язуын да онытып җибәрә. Мисал өчен:

...Оренбурга — Салих Сәйдәшевка
Хәбәр килде беркөн Казаннан:
Дәүләт театры оешкан, ди,
шунда эшкә чакырып язганнар.
Дәүләт театры! Уен мени!
Уйлата да, кызыктыра да.
Труппалар, димәк, сукбайлыктан
чыгып, хәзер яңа юл яра!

— кебек юлларның шигъри әсәрдән түгеллеге кычкырып тора. Ә мондый прозаизмнар бар гына түгел, байтак күпләр. Р. Фәйзуллин Сәйдәш образына шигъри ачкыч таба алмаган, тупланган материаллар бәлки киләчәктә язылачак проза әсәре өчен җирлек булыр.

Бүгенге шигъриятебезне нечкә хисле һәм гүзәллеккә аеруча сизгер булган шагыйрәләребез иҗатыннан башка күз алдына китерү авыр булыр иде. Саҗидә Сөләйманованың арабыздан китүе шигырь сөючеләр өчен нинди зур югалту икәнлеген искәртеп тору да артык. Н. Измайлованың соңгы елларда басылган шигырьләре безнең барыбызны да куандырды. Л. Шакирҗанова, Ф. Гыйззәтуллина, Р. Хәлиуллина, В. Туктарова һәм С. Гәрәеваларның яңа шигырьләре дә ихласлыклары, табигыйлекләре белән күңелгә якын. Шагыйрәләребез исемлеге болар белән генә чикләнми, билгеле. Ә менә 1980 елда басылган шигырьләре уңаена, кызганычка каршы, җылы сүз әйтеп булмый, бары тик А. С. Пушкинның «Не тот поэт, кто рифмы плесть умеет» дигән сүзләрен хәтергә төшерергә туры килә.

Шигъриятебезнең мөһим бер тармагы — җыр текстлары хакында да бер авыз сүз әйтеп китү кирәктер. Х. Туфан, С. Хәким, И. Юзеев һәм Ш. Галиев кебек бу төр иҗатның да үз осталары байтак бездә. Гомумән, бездә һәр шагыйрьнең милли эстрадага, җыр сәнгате үсешенә билгеле бер өлеш кертергә омтылуы мәгълүм. Җыр текстлары язуны иҗатының төп юнәлеше итеп сайлаган авторлар да бар. Әйтик, Г. Зәйнашева, М. Мазунов һ. б. Ләкин соңгы елларда яшерен-батырын түгел, бу авторлар ничектер күләгәдәрәк кала бара. Һәм моның объектив сәбәпләре бар. Заман белән бергә җыр жанры да үсә, ә бу исә җыр текстларына да таләпләр күтәрелә бара дигән сүз. Эстрадабызда торган саен җитдирәк җырларның өстенлек итә баруына Р. Фәйзуллин, Г. Рәхимнәр буыны вәкилләре сизелерлек өлеш кертте. Ә инде алардан соң килүче Зөлфәт, Р. Миңнуллин, Ф. Сафин һәм М. Галиевларның җыр жанрына игътибары тагы да арта төште дисәк, шулай ук арттыру булмас. Һәркайсының халык теленнән төшми җырлана торган җырлары бар. Бу буынның да җырда, әгәр шулай әйтергә яраса, үз «солисты» ачыкланды — ул Разил Вәлиев. Радио һәм телевидениедә аның җырлары яңгырамаган көн сирәктер. Эш җырлары күплектә һәм аларның популярлыгында гына да түгел, барыннан да элек аның, җыр сәнгатебезнең үткәндәге традицияләренә игътибарлы булган хәлдә, заманчалыкка омтылып иҗат итүендә һәм тематик диапазоны киңлегендә. Әйтик, соңгы елда ул яшьлек һәм мәхәббәт шатлыкларын уртаклашу белән генә чикләнмичә, җаваплы һәм җитди темаларга да бердәй уңыш белән җыр язарга сәләтле икәнен күрсәтте.

**Сез кайсы халыктан!— дисәләр,**
**Батырлар исемен атадым.**
**Батырлар утларга керделәр,**
**Тик исән булсын, дип, Ватаным,**

— кебек юллар шул хакта сөйләмимени?! Тик Разилга бер нәрсә — җырлар саны белән артык мавыкмаска киңәш итү урынлы булыр.

КПСС Үзәк Комитетының «Иҗат яшьләре белән эшләү турында» махсус карар кабул итүе һәм әдәби алмаш язмышын даими кайгыртып килүе әдәбият-сәнгать дөньясына килүче яшь буынга — аерым алганда шагыйрьләргә — шифалы яңгыр сыман тәэсир итте. Сан ягыннан гына түгел, сыйфат ягыннан да соңгы елларда яшьләр өзлексез үсештә, хәрәкәттә. Бүгенге шигъриятебезне Зөлфәт, Р. Миңнуллин, Ф. Сафин, Н. Измайлова кебек профессиональ яктан җитлеккән, шәхес һәм гражданин буларак өлгергән шагыйрьләр иҗатыннан башка гына күз алдына китерсәк, аңарга нидер җитенкерәмәс иде. Дөрес, яшь шагыйрьләр дигән төшенчә бүген шактый абстракт яңгырый. Аларның санын берничә йөзгә җиткереп сөйләшүчеләр бар. Ике дистә белән генә чикләнергә мөмкиндер бәлки? Ә инде критерийларны тагы да үстерә төшкәндә, дүрт-биш санына тукталу да кыен булмас.

Инде яшьләр иҗаты дигән төшенчәне вакыт ягыннан да чикли төшеп, узган елгы әсәрләргә генә тукталсак, эшләр болайрак тора: Зөлфәт ел дәвамында әлкәннәр матбугатында бер генә шигырь дә чыгармаган. Әйе, бу шул ук, без иң элек искә алган Зөлфәт. Уйландыра торган факт бу. Эчендә шагыйрь җаны булса, ул үзе дә артык түзеп тора алмас!

Татарстан китап нәшриятында соңгы бер елда гына да дүрт яшь шагыйрьнең аерым җыентыклары дөнья күргән. Шуларның өчесе — Х. Әюпов, Р. Низамиев һәм Н. Әхмәдиев беренче китап авторлары Фәннур Сафин исә чираттагы җыентыгында тагы да үсә, табигый ки, олыгая төшкән. Шигырьләрендә күңелдән бәреп чыккан хисләр, ихлас хисләрнең гәүдәләнешен күрәсең. Шагыйрьнең үзе һәм яшьтәшләренең җәмгыятьтәге урыны хакындагы уйлары тормышчан һәм актуаль. Әмма бер нәрсә шикләнүгә урын калдыра — иртә профессиональләшү куркынычы янамыймы аңарга?! Вакыт-вакыт Фәннур сүзнең төмен тоймый башлаган төсле.

Харрас Әюпов исә беренче китабында урын алган шигырьләреннән сабыр һәм тыйнак автор буларак күз алдына килә. Шул ук вакытта телнең, шигъри сүзнең төмен, ассоциатив тирәнлеген, моңын тоя белә, ә бу исә шагыйрь өчен аз түгел. Әмма күп тә түгел! Харрас әлеге хисләр, тойгылары белән генә кызыклы, яшь шагыйрьнең уйфикерләре белән дә танышу теләге канәгатьләнелми кала. Бу очракта мәшһүр Шил-

ләрнең күңел илһамы гына җитми шагыйрьгә — зирәк акыл илһамы кирәк кебек сүзләрен хәтергә төшерү урынлы булыр иде. Һәм шушы уңайдан аңарга билгеле бер дәрәҗәдә үрнәк итеп Зиннур Мансуров иҗатын искә алырга мөмкин. «Социалистик Татарстан»да басылган «Идел төбендәге чишмә» циклы һәм «Казан утлары»нда чыккан шигырьләре бу яшь авторның фәлсәфи уйлануларга йөз тотуы, дөньяга һәм әйләнә-тирәлеккә үз мөнәсәбәтен ачыкларга даими омтылышы турында сөйли. Дөрес, үз чиратында, аның да вакыт-вакыт икенче чиккә ташланган чаклары була. Шигырьгә фикер һәм образларны чамасыз тыгызлап тутыру — үз-үзеңнән акыллырак булырга омтылу исә шигърияттә шулай ук мәртәбә санала алмый. Авторның «Бурыч» шигыре моның характерлы мисалы.

Рашат Низамиевнең «Йолдыз яңгыры», Нур Әхмәдиевның «Аһәң» җыентыклары иң элек һәр ике авторның да активлыкка, гражданлык активлыгына омтылышы белән күзгә ташлана. Рашат хисләрендә кайнаррак, ярсурак һәм Р. Гатауллин рухындагы романтик та бераз. Әмма әлегә бу сыйфат аның, уңышыннан бигрәк, уңышсыз әсәрләренә хас. Реаль тормышка якынрак, заман борчуларына аваздашрак шигырьләрендә ныграк ышандыра ул: мәсәлән «Соңгы төш», «Өмет», «Моң», «Чикләр турында» шигырьләр.

Әлбәттә, Нур Әхмәдиевның да изге теләк һәм омтылышлары игътибарга лаек. Әһәмиятле тема, актуальлеккә ия мәсьәләләргә ашкынып тора. Ләкин әлегә аның күпчелек шигырьләре кирәкле темага язылган кирәксез әсәрләр кебегрәк тәэсир калдыра. Шигъри табыш, бары үземнеке генә дип әйтерлек хис һәм фикерләр, кызганычка каршы, юк дәрәҗәсендә. Үз мин-мине тирәсендә сүз куерту һәм акланмаган фәлсәфәләр авторның булган өстенлекләрен дә юкка чыгарып, каплап киткән.

Беренче китаплары югарыда күзәтелгән иптәшләр, җыеп әйткәндә, төзек язалар, шома язалар, телләре-телгә йокмый. Сүзләре хак, хисләре табигый. Укучы ирексездән сикәлтәсез юлдан юырткан ат арбасында утырып барган агайга охшап кала. Һаман бер үк ритм — келтер-келтер, келтер-келтер... Ирексездән, күз йомыла башлый, черем итәсе килә. Ә ат һаман бер көйгә юырта бирә, һаман бер үк келтер-келтер, келтер-келтер... Сискәндереп, бер тарттырып та алмый, туктап та калмый. Һаман бер көй, бер үлчәм. Тәгәрмәч бер тирән чокырга да төшми ичмасам, хет югында, гөнаһ шомлыгы, ат сыртына кигәвен дә килеп кунмый,— дип офтанырга гына кала.

Соңгы вакытта тагы Хәйдәр һәм Э. Мостафин кебек яшьләрнең игътибарга лаек шигырьләр белән чыгыш ясавын искә алу урынлы булыр. Икесе дә сурәтләү чараларының оригинальлегенә омтыла, тел-бизәкләр белән эш итүдә зәвыклылар. Әмма шушы ук үзенчәлекләре үзмаксатка әйләнгән чакларда — матур гына картиналары да җансызлана. Ә бит җансыз матурлыкка, мәгънәсез сырлауларга караганда, ямьсез булса да җанлы чынбарлык яхшырак. Бу авторларның шигырьләрендә шәхес буларак пассивлык та күзгә ташлана.

Яшьләр иҗатындагы уңай һәм җитешсезлек саналырга тиешле кайбер тенденцияләр шулардан гыйбарәт. Ә инде гомумән алганда, шигъри алмашны характерлаган төп сыйфатлар — шигърияттә үз сүзеңне әйтүгә, гражданлылыкка һәм югары сәнгатьлелеккә омтылыш, хис һәм фикер гармониясенә йөз тотудан гыйбарәт. Бу исә лаеклы алмаш үсә дигән сүз.

Инде сүз ахырында янә съезд документларына, иптәш Л. И. Брежнев докладына мөрәҗәгать итсәк, поэзиябезнең алга таба үсешендә һәрчак күз уңында тотылырга тиешле түбәндәге тезислар җитди игътибар сорый: 1) Партия сәнгатебезнең идея юнәлешенә битараф булмады һәм була алмый; 2) сәнгатькә ихтирам, мәхәббәт художникның үз халкы алдында зур җаваплы булуын да күздә тота; 3) тонык, сәнгать ягыннан зәгыйфь әсәрләрнең теманың актуальлеге артына яшеренеп калмавына ирешү бик мөһим. Әсәрләрнең геройлары вак эшләр даирәсендә бикләнмәсен... 4) әйләнә-тирәбездәге бар нәрсәнең матур, зәвыклы булуы ни дәрәҗәдә мөһим икәнлеген аңлатып тору кирәкми.— Өстәп нидер әйтергә омтылу соралмый да, югары трибунадан әйтелгән бу җитди сүзләр әдәбиятыбыз, аерым алганда, шигъриятебезнең алга таба барышында төп девиз һәм маяк булырга тиеш.

Галия Хантимерова

# ТӨСЛӘР БАЛКЫШЫ

*Мәдинә Маликованың иҗат портретына штрихлар*

Мәдинә Маликованың иҗади йөзе хакында уйланганда Сильва Капутикянның мәгълүм сүзләре хәтергә килә. «Нилектән сәнгатьтә һәм әдәбиятта, бигрәк тә прозада, барлык чорларда хатын-кызлар аз булды икән?» дигән сорау куйган иде ул һәм бу хәлнең сәбәпләрен ачыкларга тырышкан иде. Табигать хатын-кызларга акылны да, йөрәк хисләрен дә ирләрдән ким бирмәгән бит югыйсә... Капутикян үзе куйган сорауга түбәндәгечә җавап биргән иде: күрәсең, нәселне дәвам итүче буларак һәм гасырлар буена бирелеп килгән үзенчәлекле тәрбия нәтиҗәсендә, хатын-кыз үзен тулысынча иҗат эшенә генә багышлый алмыйдыр. Ә сәнгатьтә һәм әдәбиятта исә бары тик бөтен барлыгыңны биреп эшләгәндә генә күзгә күренерлек нәтиҗәгә ирешеп була.



Чыннан да, сәнгатьтә һәм әдәбиятта, элек тә һәм хәзер дә, башлыча ир-егетләр хакимлек итә. Аларның көчле җырында хатын-кызларның йомшак тавышы чак кына ишетелеп китә, ул авазларны да күпчелек очракта шагыйрәләр бирә. Хәтта зур үсешкә ирешкән әдәбиятларның прозасында да хатын-кыз исемнәре берән-сәрән генә.

Мәдинә Маликованың иҗаты исә, безнеңчә, хатын-кыз прозаик булганы өчен генә түгел, ә бәлки җәмгыятьнең матди һәм рухи тормышы ашкынулы үзгәрешләр кичереп торган бу заманда, татар әдәбиятына үз өлешен кертеп, дөньяга карашыбызны киңәйтеп җибәргәнгә күрә дә аерым сөйләшүгә лаек.

«Юлдашлар» исемле беренче хикәяләр җыентыгында ук (1967 ел) М. Маликова үзен укучы алдына тирән әхлакый мәсьәләләр куя белүче җитди язучы итеп күрсәткән иде. Соңрак аның «Казан каласы — таш кала» исемле икенче җыентыгы дөнья күрде (1971 ел). М. Маликова — шәһәр темасын уңышлы рәвештә үзләштерүче аз санлы татар язучыларының берсе. Аның әсәрләрен укыганда, язучы иҗатында күтәрелгән тема һәм проблемаларның төрлелеге җәлеп итә. Язучы үзенең геройларын төрле өлкәләрдә һәм вакыйгаларда тасвирлап, яшәү рәвешенең, кеше мөмкинлекләренең, максатка ирешү юлларының күп төрле булуын күрсәтергә тырыша.

Соңгы вакытта дөнья күргән «Янартаулар яктысында» исемле повестенда ул, балык тоту траулеры капитаны Өмит Гасимов, аның хатыны актриса Казанская, атаклы Камчатка гейзерларын саклаучы Вадим Николаев кебек көчле ихтыярлы, гадәттән тыш якты күңелле, хыяллары белән ерак билгесезлекләргә омтылып яшәүче кешеләр үрнәгендә, рәссам Зуфирәнең күңеле канатланганын, тормышы мәгънәле, җаны омтылышлы булып киткәнен тасвирлый. Зуфирәгә кырык яшь инде, ләкин ул һаман да максатына ирешә алмаган, үз-үзен тапмаган, буяулар ярдәмендә дөньяның төсмерләре

муллыгын, шатлык-кайгыларны тасвирлап бирергә өйрәнеп җитмәгән әле. Капитан Гасимов белән очрашканга кадәр, Зуфирәнең гомере кысан гаилә тормышында, ресторанда аккордеон уйнап көн күрүче, вак җанлы һәм пешмәгән, вөҗданның һәм намусның, әхлакый җаваплылыкның ни икәнен дә белмәгән Эльвир белән бергә яшәп уза. Дөрес, өйләнешер алдыннан Зуфирәгә Эльвирның (исеме генә дә ни тора — ни ирләр, ни хатын-кызлар исеме түгел...) максатсыз кеше икәнлеген әйтәләр. Әмма Зуфирә — мавыгучан, хискә бирелүчән шәхес, акылы әйткәнгә ныклап колак сала алмый, тыштан ялтыравыгына алданып, музыка училищесын дә тәмамлый алмаган егет белән язмышын бәйли. Ире аркасында күп хурлыкка дучар була Зуфирә. Иренең сәеркәсе өенә барып, аңлашырга маташып йөрүе генә дә ни тора!

Зуфирә шул кадәр кимсетелгән һәм түбәнсетелгән ки, ул ялгызлыктан курка, кызын әтисеннән аерырга хакым юк, дип исәпли. Аның рухы шул кадәр көчсез ки, ул өендә ире белән сәеркәсе өстенә килеп кергәч тә, үз-үзен яклый алмый. Соңыннан Эльвир, бернинди вөҗдан газаплары да тоймыйча, кызын һәм акылга зәгыйфь әнкәсен хатыны кулында калдырып, Румиягә йортка керә.

Гадәттән тыш һөнәр иясе, чын ир-егет капитан Гасимов белән очрашканнан соң гына Зуфирәнең күңеле үсеп китә, үз-үзенә ихтирамы, ышанычы арта. «Кеше, сыер кебек, җылы абзарда гына яшәргә тиеш түгел. Ул үз кылганнарына, үз тормышына шәм яктысында, хәтта электр яктысында гына да карарга тиеш түгел. Ул үзенә яшен яктысында карарга тиеш бер заман. Менә шул чакта ул үзенең чын бәһасен белә алыр»,— ди Өмит Зуфирәгә һәм Камчатканы өйрәнгән кешеләрнең, Лаперуз, Беринг кебекләрнең батырлыгын мисалга китерә. Алар кешелекнең киләчәге, бәхете турында уйлаганнар, кырыс табигатьле якларга китеп, үзләрен авыр, әмма олы мәгънәгә ия булган язмышка дучар иткәннәр.

Зур идеяләргә хезмәт итү белән мавыгып яшәүче, якты хыяллы кешеләрнең — капитан Гасимовның, урманчы Вадим Николаевның, балыкчыларның һәм геологларның көнкүреше һәм фикерләү рәвеше Зуфирә каршында яңа дөнья ачкандай була. «Идеалыбыз — гармонияле рәвештә үскән кеше»,— дигән сүзләргә без ничектер күнегеп киттек, аларның олы мәгънәсе хакында һәрвакытта да тиешенчә уйланмыйбыз. Маликова үз повестенда бу гармониягә ирешүнең, бигрәк тә хатын-кыз өчен, никадәр авыр икәнлеген бик ачык күрсәтә. Зуфирә — яңа заманның яшьтән үк яңача тәрбия алган беренче буын вәкиле. Ул буынның әниләре иске кануннар нигезендә тәрбияләнгән иде; хатын-кыз иренең сүзеннән чыкмаска тиеш, кешегә күтәрелеп карамас дәрәҗәдә йомылган булырга тиеш, хисләрен һәм теләкләрен чикләргә тиеш, чөнки аның дөньяга килүенең төп максаты — бала табу. Гореф-гадәт, кеше күңеле тиз һәм кинәт үзгәрә алмый. Зуфирә күңелендә булган үзгәреш тә җиңел генә бирелми, моны Вадим Николаев бик яхшы аңлый: «Бирегә сезне Өмиткә, ягъни ир кешегә булган мәхәббәт кенә китермәгән, шулай бит? Лаперузларны, Берингларны белгесез юлларга дәшкән талпыну алып килгән сезне. Ни генә булмасын, мәхәббәттән уңмадым дип, сез аяктан егылып ятмассыз»— ди ул Зуфирәгә, һәм хаклы булып чыга. Әхлакый тетрәнү Зуфирәнең җанын яңарта. Ул Өмитнең тышкы кыяфәтен генә күргән, аны зәңгәр күзле, тынгысыз җанлы, мавыгучан һәм хыялый кеше дип кенә белгән, аның язмышының бөтен катлаулылыгын, элекке хатыны белән булган мөнәсәбәтләренең тетрәндергеч нечкәлекләрен аңламаган икән. Кинәт Зуфирәнең күзе ачылып киткәндәй була, ул, чын сәнгать әсәре тудыру өчен, кешеләр күңелендәге хисләр, омтылышлар көрәшен, әлеге көрәшнең кискенләгән һәм авырлыгын күрсәтү зарур икәнен, ә моның өчен шәхси мәшәкатьләреңнән, йомшак якларыңнан арынырга кирәклеген аңлый: Өмит белән бергә булу өмете өзелгәннән соң, ул үзе дә бик каршылыклы хисләр кичерә: бер яктан газапланса, икенче яктан, үзендә моңарчы булмаган азатлык хисе туганын тоя. Шушы мизгелдә Зуфирә җиңүнең иң зурысы — үзенең җан газапларыңны җиңүдә һәм алдыңа куйган изге максатыңа буйсынып яши белүдә икәнлегенә төшенә. Һәм бер көрешү өмет итеп аэродромга килгән капитан Гасимов белән очрашудан баш тарта. Үзеңне җиңү, ваклыклардан арыну, яшәешеңнең изге максатын табу — иҗади, ә кайчакта газаплы эзлән;, бу — киләчәк хакына барган аяусыз көрәштә бүгенгенең үткәнне җиңүе, дигән сүз.

Зуфирә шәхесенең яңаруы, аның әхлакый баюы олы җанлы, гадәттән тыш кырыс язмышлы кешеләр белән аралашу аша бирелгән. Вакыйгалар белән төрле кыйсса-

ларда гына ишеткән урыннарга — җир читенә, Камчаткага алып китәләр. Бер уйласаң, андый язмышлар укучы өчен кызыклы һәм файдалы микән, дигән сорау да туарга мөмкин. Файдалы икән шул! Тормышыбыз маяклары булган революционерлар, табигать серләрен ачучылар, яңа җирләргә беренче булып аяк баскан сәяхәтчеләр, космонавтлар безнең барыр юлларны яктыртып тормыйлармыни?

Ниһаять, нәрсә турында соң ул «Янартаулар яктысында» дигән повесть — мәхәббәт турындамы, яшәү рәвеше турындамы? Ул кеше турында, мәхәббәт турында — димәк, яшәү рәвеше турында. Язучы Юрий Бондарев шундый бер кызыклы күзәтү ясавы хакында сөйли: моннан кырык-илле еллар элек, «мәхәббәт» сүзе кешеләр телендә еш кулланылуы буенча икенче-өченче урында торган икән, ә хәзерге фәнни-техник революция заманы кешесенең сөйләмендә исә бу сүз «космос», «лазер» һ. б. сүзләрдән соң, тугызынчымы, унынчымы урынга чигенгән. Һәм менә Маликова үзенең геройлары Зуфирә, Гасимов, Вадим Николаевларның мәхәббәте мисалында ярату хисенең хыялый дөньяга гына алып китмәвен, ә бәлки, заман кешесенең әхлакый таянычына әверелеп, аның барча уй-хисләре, яшәү рәвеше, хезмәте, иҗаты белән аерылгысыз бәйләнештә икәнлеген исбатлый. Мәсьәләнең болай куелышы һәм художество чаралары белән ышандырырлык итеп чишелеше — авторның иҗади уңышы.

Яшәеш максатын эзләү темасы М. Маликованың тагын бер повестенда — «Казан каласы — таш кала»да киң яктыртыла. Бу әсәрдә дә геройларның үзләре сайлаган һөнәрләре буенча хезмәте, иҗади талпынуларын шәхси тормыш серләре белән табигый, аерылмас бәйләнештә истә калырлык итеп тасвирланган.

Повестьның герое Мәрьям, башта төзүче инженер, аннары архитектор, гүзәл биналардан торган, бакчаларга күмелгән «Бәхет каласы» төзү турында хыяллана. Хәзергә исә аңа типовой проектларны урынга бәйләү, ягъни нигезләр проектлау белән шөгыльләнергә туры килә. Ул моның вакытлы хәл икәнлеген, кешеләргә торак җитмәгәнлектән килеп чыкканлыгын яхшы аңлый. Шул ук типовой проектларга да ул ниндидер бер үзенчәлек кертергә тырыша: йортларның тышкы стеналарын төрле төстәге плиталар белән бизи, бер йортны икенчесенә балконнар белән тоташтыра һ. б. Мәрьям бөтен җаны-тәне белән кешеләргә яхшылык кылырга омтыла. Әмма аның яшьли сөйгән егете — рәссам Шәүкәт бөтенләй башка кеше. «Мин урта кул кеше булырга теләмим. Алай яшәүнең ни кызыгы бар? Мин сәнгатьтә үз сүземне әйтергә тиеш. Һәрхәлдә Антов дигән художникның үз Джокондасы булыр»,— ди ул көперенеп. Аның фикеренчә, Леонардо да Винчи заманнары күптән узган инде, «халык күбәйде хәзер, барын да күреп бетерә алмыйлар... Шунлыктан еш кына очракта, иң талантлылар түгел, ә бәлки үз әсәрләрен үзләре күрсәтә алганнар, аларның шөплегенә башкаларны да ышандыра белгәннәр өскә калкып чыга»... Шәүкәт талантлы рәссам, ләкин ул «чын сәнгать әсәрләре тудыру өчен, иң элек иҗат итәргә иркен булмаң, мул тормышың булырга тиеш», дип саный.

Авыр Мәрьямгә Шәүкәт янында. Моның сәбәбе егетнең дан эстәвендә. Һәм шул ук вакытта бар көчен биреп эшләргә теләмәвендә генә түгел, моның сәбәбе — хатын-кыздан өстенлек хисендә, Мәрьямнең иҗади эшкә сәләтле булуына ышанмауда да. «Бер өй эчендә ике иҗат кешесе артыграк булмас микән? — ди ул.— Бер казанга ике тәкә башы сыймый. Ике кеше ике якка тарткан гаиләдә нинди иминлек булсын... Уйлап кара әле, Мәрьям: әгәр дә син миңа таяныч була алсаң, мин сәнгатьтә икебез өчен дә эшләячәкмен. Ант итеп әйтәм!» — ди ул. Баштарак Мәрьям чыннан да үзен мәхәббәт хакына зур корбаннар бирергә сәләтле дип исәпли, ләкин тора-бара аларның дөньяга карашы капма-каршы икәнлеге ачыклана. Рәхәт тормыш артыннан куа торгач, Шәүкәтнең таланты әкренләп югала. «Миллион ел тырыша, баш вата торгач, атом бомбасы иҗат итте кешелек! Җир йөзендә тормышны юк итү чарасын! Я, уйлап кара, шуннан да искитәрлек, шуннан да куәтле берәр нәрсә тапканмы ул? Кешелекнең иң бөек ачышы — үзен-үзе юк итү чарасы»,— ди күңеле бушап калган Шәүкәт. Ләкин Мәрьямнең фикере бөтенләй башкача: ул кешелекнең иң бөек иҗат казанышы итеп Джоконданың елмаюын — җаннарны сафландыра, куандыра торган серле һәм тылсымлы кеше елмаюын саный. Яхшылык һәм матурлык хакына тудырылган әсәрләр үлемсез, аларны бернинди бомба да юк итә алмый.

Шәүкәт белән Мәрьямнең мөнәсәбәтләре катлаулы, авыр. Ниһаять, алар читләшә-

ләр. Мәрьям, кайгысыннан һәм ялгызлыгыннан котылу теләге белән, кияүгә чыга. Ләкин чын мәхәббәтнең көче шундый ки, Мәрьям Шәүкәтне оныта алмый, иреннән аерылырга мәҗбүр була. Берничә елдан соң Шәүкәтне тагын очраткач, ул мәгънәсез һәм максатсыз яшәргә хакы юклыгына төшенә. Дөрес, аның тормышы моңарчы да бөтенләй үк буш булмаган, ул бала тәрбияләгән, ләкин бер бала үстерү генә кешенең тормышын олы мәгънәгә ия итә алмый икән шул. Мәхәббәт — никадәр генә ачы, газаплы булмасын, барыбер игелекле хис, «чөнки бары тик мәхәббәт аша гына Мәрьям өчен йөрәк хисләренең, ашкынып талпынуларның мөкатдәс сере ачылды, бу ачышы булмаса, ул иҗатның татлы газабын, олы бәхетен дә татый алмаган булыр иде. Җан сызланулары көчле булуга карамастан, Мәрьям яңа микрорайонның проекты өстендә фидакарь рәвештә эшли, бу хезмәтендә аңа проект институтының иҗат уты белән янган башка кешеләре — архитектор Марат, «тормыш — көрәш ул» дигән ышаныч белән яшәүче конструктор Ирина Сергеевна ярдәм итәләр.

Маликованың «Казан каласы — таш кала» повесте совет интеллигенциясенең иҗади омтылышларын күрсәтү белән кызыклы. Бу әсәр, чын интеллигент, белемле мещаннан аермалы буларак, җәмгыятькә хезмәт итүдән башка үз тормышын күз алдына китерә алмый, дигән фикергә укучыны ышандыра. Хисләрнең үсешен, аларның сизелер-сизелмәс кенә үзгәрешен дә тасвирлауда һәм хатын-кыз күңелен аңлый белүдә язучының осталыгын аерым билгеләп үтәсе килә.

«Казан каласы — таш кала»ның уңай яклары күп, ләкин баш өлешен бераз кыскарткан тәкъдирдә ул тагын да отышлырак булыр иде. Әсәрнең өчтән берен укыганнан соң гына ул укучыны чын-чынлап мавыктырып алып китә. Повестьта геройлар күп, алар барысы да үз урыннарында, ә менә художник Газиз Лотфуллин образы вакыйгалар үсешенә әллә ни зур мәгънә бирми, әсәрнең идеясе ачылуга күп хезмәт күрсәтми. Ләкин шушы кытыршылыкларына карамастан, бу повесть язучының үсешендә бер баскыч булып тора.

Маликованың тормыш хәлләре төрлелеген аерым вакыйгалар аша гына түгел, ә бәлки гомуми агымда тасвирлый белүе бер үк иҗтимагый шартларда төрле язмышларны чагылдырганда да бик ачык күренә.

Әгәр дә Зуфирә белән Мәрьям образларын тасвирлаганда, аларның хатын-кыз булудан бигрәк, рухи байлык тудыручы кешеләр икәнлеге хакында сүз барса, «Гандәлифтән Зөһрәгә хат» хикәясендә хатын-кыз язмышы бөтенләй башкача борылышта күрсәтелә: бу инде азатлык һәм тигез хокуклык төшенчәләрен дөрес аңламау нәтиҗәсендә, балалары өчен бөтен җаваплылыкны үз җилкәсенә алып, аларның өтисен читләштерү аркасында бәхетсезлеккә дучар булган хатын-кыз. Моның авырлыгы Гандәлифнең үзеннән дә бигрәк, ике улы өстенә төшә. Үз вакытында кияүгә дә Гандәлиф яратып түгел, ә бәлки авылга ялга кайткан офицерның чибәрлегенә кызыгып кына чыккан була. Соңрак ул иренең кайчандыр башка берәүне яратканлыгын һәм аны оныта алмаганлыгын белә, көнләшүенә чыдый алмыйча, нәни баласын кулына алып, икенче балалары булачагын иренә әйтеп тә тормыйча, китеп бара. Төпле белем дә, ныклы һөнәр дә ала алмаган Гандәлиф ике баланы зур киенлек белән үстерә. Балаларына ул, әтиегез очучы иде, һәлак булды, ди. Андый очракларда шулай була бит ул: балалар әчтән кимсенеп, кыюсыз һәм гарьчән булып үсәләр, һәм болар барысы да әниләренең мин-минлеге, үз хокукларын һәм бурычын дөрес аңламавы аркасында килеп чыга. Гандәлифнең өлкән улы башта бәхетсез мәхәббәткә юлыга, аннары машина астына эләгеп, һәлак була — шул рәвешле, аның җилкәсенә өелгән әхлакый җаваплылыкның артык авырлыгы фаҗигагә китерә. Кызганычка каршы уңышлы сайланмаган хат формасы авторга Гандәлиф образын тиешенчә ачарга һәм куелган мәсьәләләрне ахырынача чишәргә мөмкинлек бирмәгән.

М. Маликованың детектив жанрына да мөрәҗәгать итүе аның иҗат мәйданы киң булуы хакында сөйли. «Августның бер төнендә» хикәясе, «Хөкем» һәм «Адашканга юл кайда?» повестьлары детективның барча кануннарына туры китереп язылганнар: вакыйгаларның тыгызлыгы, киеренлеге, көтелмәгән борылышлар укучыга әсәрне бер башлагач ташлап торырга ирек бирмиләр. Әлбәттә, әгәр дә автор шушы кагыйдәләр белән генә чикләнсә, аның бу әсәрләре бары тик мавыктыргыч хикәятләр генә булып калырлар, укып чыккач та онытылырлар иде. Бәхеткә каршы, Маликованың детектив жанрындагы әсәрләре дә социаль бурыч үтиләр. Автор, тормышының төрле

якларын күрсәткәндә, социаль каршылыкларны шомартмый, геройларның холкына дөрес психологик анализ бирә, аларның кылганнарында яхшылык һәм яманлык дәрәҗәсен күрсәтә, кешеләрнең үзара мөнәсәбәтен иҗтимагый һәм шәхси мохитта яшәеше белән тыгыз бәйләнештә бирә.

Язучының киеренке вакыйга белән мавыктыра белү сәләте әсәрдән әсәргә үсә бара. Әгәр дә «Августның бер төнендә» дигән хикәядә вакыйгалар тыгызланып киткәнче тасвирлауга бер-ике бит урын багышланган булса, «Хөкем» повесте исә беренче юлыннан ук мавыктырып алып китә.

«Адашканга юл кайда?» повестенда намусы саф, ләкин тәҗрибәсезлеге аркасында җинаятьчеләр арасына эләккән яшь кешеләргә нишләргә? — дигән сорау куела. «Тәҗрибәсезлек бәлагә тарыта»,— дигән Пушкин. Маликова повестенда бозык хатын Нателланың чибәрлегенә алданган яшь таксист Фидаил һәлак була, консерватория студенткасы Зөлфә бик зур күңел җәрәхәте ала. Әсәр бу жанрга хас традицион алымнан башлана: иртәнге якта Казан каласының буш урамында такси шоферының үле гәүдәсен табып алалар. Машина идәнендә әр-яңа егерме бишлек акча табыла. «Шофер кесәсеннән чыккан акча түгел бу... без акчаны кадерләп йөртә белмибез, тотабыз да йомарлыйбыз, һич булмаса бөклибез»,— ди Фидаилнең алмашчысы Нияз. Димәк, Фидаилне акчасын талау максаты белән үтермәгәннәр. Шушы урыннан җинаятьне төрлечә фаразлау башлана. Тикшерү нәтиҗәсендә, төрле кискен вакыйгалардан соң, үтерүченең Атлас икәнлеге, аңа исә чибәр Нателла һәм аның дусты Люсиның сөяркәсе Константин ярдәм иткәнлеге ачыклана.

Кемнәр соң алар — Нателла, Атлас, Константин-Котик? Нателла Казан учреждениеләренең берсендә секретарь-машинистка булып эшли. Ул җаваплы эштә эшләгән иренең мул хезмәт хакына иркен яшәргә өлгергән күнеккән, иреннән аерылгач исә үзе эшләп тапкан гына җитми. Нателланың якыннарыннан берәү — Риф аның хакында менә ничек сөйли: «Су төбендә бик матур чәчәккә охшаган тереклек ияләре бар. Актиния дип атала ул. Тик үзе чәчәк түгел, ерткыч хайван. Аның авызына эләккән балык эреп юкка чыга». «Кара сабаклы кызыл чәчәк»,— дип уйлый кара күлмәкле Нателланы күргәч таксист Нияз. Шул ук Риф Нателла тирәсендәге кешеләрне түбәндәгечә тасвирлый: «Әнә Люси — суда йөзгән медуза кебек. Төссез, файдасыз җан иясе. Бу медуза суда чәреп таркалган калдыклар белән туклана. Аны теләсәң тотып алырга, теләсәң тотып кыйнарга мөмкин — бернәрсә сизми ул. Ә аның Котигы оясындагы кысла шикелле. Ул да ялкау, ул да файдасыз, тик оясыннан кыскычларын чыгарып куйган, үткән-сүткән җан ияләрен эләктерергә генә тора». Ә Риф үзе кем соң? «Мин күл өстендә яткан төнбоек яфрагы кебек, барсын күрәм, беләм, ишетәм, ләкин ни дә булса эшләүне кирәк санамыйм. Нигә катышырга? Әйдә, барсын үз көенә, һәркемнең үз язмышы»,— ди ул. Тар карашлы, дөньяга битараф адәмнәрнең типик вәкиле бу. Ни хисабына көн итә соң ул? Кайда туры килсә шунда акча эшләп ала: көндезләрен җеназаларда уйный торган оркестр белән йөри, кичләрен рестораннарда уйный, бер инвалидның почмагында яши, Риф образында автор җинаятьчеләрнең үзләре кебек куркыныч булган битараф кешеләрне хөкем итә: Нателла тирәсендәге бәндәләрнең кара эшләрен белеп тора Риф, әмма дәшми, ул арада Фидаилне үтерәләр, Нияз да чак кына җинаятьченең мотоциклы астына эләкми кала.

Бездә җинаятьчелекнең иҗтимагый-политик нигезе күптән инде юкка чыгарылган, кешенең кеше хисабына яшәве бетерелгән, эшсезлек тә онытылган. Ләкин шуңа да карамастан, кайбер әхлакый тотрыксыз кешеләрнең күңелендә эшләмичә генә, башкалар хисабына рәхәт яшәргә омтылыш туа, тиешле тәрбия алмау, әчкече аталарның йогынтысы кайбер яшьләрне җинаять юлына этәрә. Маликова үзенең повестенда үтерүчегә әверелгән студент Атласның характеры үсешен күрсәтә. Аның балачагы нинди шартларда үткәнен тасвирлый. Йөк ташучы булып эшләгән атасы, Атласны ике яшьлек чагында ташлап, икенче хатынга өйләнә. Малай кечкенә, караңгы өйдә, кысан тормышта, әнисе карамагында үсә. Үзеннән бәхетлерәк малайлардан өзелеп көнләшә, эчтән генә үзен башкалардан өстен саный, чөнки ифрат чибәр була. Өстәвенә аңарда башка беркемдә булмаган сәләт бар. Мәсәлән, ул үз күзе белән бер генә күргән ачкычны ясап бирә белә. Дөресрәге, ачкычларның сурәтен ясый, ә Котик аларны заводта тимердән коя. Ачкыч ясатып урланган әйберләр Атласка үзе теләгәнчә иркен яшәргә мөмкинлек бирә. Тату-имин гаилә канаты астында үскән, бөтенләй идеал-

ларда тәрбияләнгән Зөлфәгә матур йөзле бу адәмнең кара эчле булуын күрү җиңел түгел.

Повесть яшьләргә адреслап язылган. Ә яшьлек ул — кешенең тормышта үз урынын эзләү чоры, шәхеснең иҗтимагый өлгереш кичергән вакыты. Язучы яшьләргә игелек теләп, кисәтү ясый: «Тыштан ялтырауга алданмагыз, кешеләрнең күңелен, җанын аңларга өйрәнегез, лаеклы дуслар таба белегез. Югыйсә ялгышу-адашулар өчен бик кыйммәт түләргә туры киләчәк»,— ди ул.

Детектив жанрда иҗади уңышларга ирешкәннән соң, Маликова киләчәктә дә бу теманы эшкәртүдән туктамас кебек тоелган иде. Ләкин алай булып чыкмады. Моннан соң ул традицион рухта язылган әсәрләр бастырып чыгарды. Аның «Егетлеккә бер адым» җыентыгы һәм алда сүз барган «Янартаулар яктысында» повесте шундыйлардан.

«Егетлеккә бер адым» повестенда әтиләре ташлап киткән яшүсмерләр язмышы, аталарның балалары өчен җәмгыять каршындагы җаваплылыгы турында сүз бара. «Язгы такыялар» повесте хатирәләр формасында язылган, анда өлкән яшьтәге Газзә үзенең авыр, әмма матур эшләргә бай яшьлеген искә ала. Утызынчы елларда ул актив комсомол булган, авылда колхоз оештыруда катнашкан, авыр сугыш елларында үзен аямый эшләгән. «Чәчәкләрне генә түгел, гомерем елларын да такыялар итеп үрдем,— ди Газзә үзе турында,— Ак, кызыл, сары, зәңгәр — төрле чәчәкләр булды...» Кызганычка каршы, бу повестьта коры сөйләп чыгуга күбрәк урын бирелгән.

М. Маликова җәмгыятебезнең төрле социаль катламнарына гына түгел, төрле яшьтәге укучыларга да мөрәҗәгать итә. Ул яшьләр өчен, балалар өчен дә күп яза. Мәсәлән, «Көндәшләр» хикәясе белән автор безне башка мохиткә — авылга алып китә. Давыт исемле яшүсмер малайның матурлыкны аңлый башлавы тасвирлана анда. Бу малай өчен колхозның яшь ат караучысы Заһир — егетлек һәм батырлык үрнәгенә, ә укытучы Әкълимә гүзәллек мисалына әвереләләр. Давытның күз алдында Заһир зур батырлык эшли: күрше авыл егете урлап киткән Әкълимәне коткару өчен, язгы ташу вакытында, кара төндә Агыйделне йөзеп чыга. Заһир Әкълиманең бөтенләй башканы сөйгәнен белә, аның үзенә карамасын да аңлый, ләкин кыз намусын саклап калу өчен тормышын куркыныч астына куя, чөнки аның өчен кеше намусыннан да кадерлерәк нәрсә дөньяда юк.

Язучы үз иҗатының нәкъ чәчәк аткан чагын кичерә. Ул шактый актив эшли, тормыш хәлләрен һәм кеше типларын хәтердә уелып калырлык итеп тасвирларга омтыла, әхлакый мәсьәләләрне кискен итеп куя белә,— моны игелекле активлык дип, язмышның кискен борылышларында кешеләргә ярдәм кулы сузу дип аңларга кирәк.

М. Маликованың язу стиленә бер үзенчәлек хас: ул гүяки якын кешесенә үз башыннан узганнарны сөйли, мохитны үзе күргәндәй тасвирлый. Ләкин бу шулай тоела гына. Аның әсәрләрендәге тормыш хәлләре аерым бер кеше башыннан узганнар гына түгел, алар гомумиләштерелгән. Бу әсәрләр сыгылмалы тел белән язылган, аларда вакыйгаларның киеренкелеге, заман сулышы ярыйсы ук оста бирелә. Кыскасы, шундый үсештәге Мәдинә Маликова иҗаты татар прозасын тема төрлелегенә һәм әхлакый проблемалы әсәрләргә баетуга шактый зур өлеш кертте һәм кертер әле.

# ТӘНКЫЙТЬ СҮЗЕ—КАДЕРЛЕ СҮЗ

Әдәби иҗат практикасын анализлауда тәнкыйтьнең юл күрсәтүчәнлек сыйфаты мәгълүм. Театр һәм драматургия тарихында Ф. Әмирхан, Г. Кәрам, Ф. Бурнаш, Г. Кутуй, Г. Кашшаф кебек әдипләрнең һәм тәнкыйтьчеләрнең үз вакытларында әйткән кадерле фикерләре, замандашлары иҗатына шифалы йогынты ясау белән бергә, әле хәзер дә әһәмиятләрен югалтмыйлар.

Театр һәм драматургия тарихын өйрәнеп, бүгенге сәхнәбезне даими күзәтеп баручы, замандаш драматурглар иҗатында матур яралгыларны кадерләп үстерергә омтылучы бүгенге тәнкыйтьчеләр турында уйланганда, беренчеләрдән булып А. Әхмәдуллин эшчәнлеге күңелебезгә килә. Шуңа күрә аның сәхнә әдәбияты проблемаларына мәкаләләре тупланган яңа китабы да зур кызыксыну уята.

Китап өч бүлектән тора: 1/ Бүгенге драматургия мәсьәләләре; 2/ Драматургия осталары; 3/Драма һәм сәхнә.

Исемнәреннән үк күренгәнчә, беренче бүлек мәкаләләре 60-70 нче еллар татар драматургиясенең актуаль проблемаларына карыйлар: «Драматургия, аның үсеш юнәлешләре», «Уңай герой», «1968 елда татар драматургиясе», «Уңышлар һәм кимчелекләр», «Дөреслек хакына», «Заман героен эзләү юлында», «Сәнгатьчә ачышлар», «Яңа казанышлар юлында», «Татар драматургиясенең хәзерге хәле»— болар татар драматургиясенең соңгы егерме елдагы үсеш тенденцияләрен нечкәләп өйрәнү нәтиҗәсе.

Тәҗрибәле тәнкыйтьче буларак, А. Әхмәдуллин бүгенге драматургия казанышларын классик мирастан аерылгысыз итеп карый. Моны икенче бүлеккә кергән мәкаләләр ачык раслый: «Татар драматургиясенә нигез салучы», «Аның сәнгатьчә ачышлары», «Бүген дә кыйммәтле мирас», «Драматург — новатор», «Г. Ибраһимов һәм татар драматургиясе», «Ул социаль бәрелешләрне чагылдырды», «Язучының гражданлык йөзе», «Драматургның үсү юлы», «Өч драматург турында»— бу күзәтүләрендә автор, классик әдәбият тарихындагы аерым аспектларны яктырту белән бергә, бүгенге татар драматургиясенең бай традицияләр җирлегендә яшәвен ача, казанышларны лаеклы дәвам итәргә, үстерергә өнди.

Мәсәлән, Т. Миңнуллин иҗатын анализлап, ул мондый фикер әйтә: «Үзенең язу манерасы һәм стиле белән Т. Миңнуллин... Кәрим Тинчуринга якын. Ләкин аның вакыйгаларны сиштыруда, психологик бизәкләрне нечкә салуда үз кулы, үз почеркы бар. К. Тинчуринның төп иҗат ялкыны иске тормышны фаш итүгә юнәлтелгән иде, шуңа күрә аңарда сатира көчле. Т. Миңнуллин исә йомшак юмор белән эш итә. Ул бүгенгенең уңай якләрын раслауның үтемле формаларын эзли. Аның соңгы әсәрләрендә киң кулланыла башлаган шартлылык алымнарын да шул юнәлештәге эзләнүләр нәтиҗәсе итеп карарга кирәк».

Китапның өченче бүлеге, нигездә, спектакльләргә язылган рецензияләрдән тора, алар драматургия һәм сәхнә тормышының агымдагы проблемаларына, конкрет мәсьәләләренә аеруча нечкәләп тукталу ягыннан аерылып торалар. «Яшь йөрәкләр» яңадан сәхнәдә, «Каюм Насыйри», «Читлектәге кош бәхетлеме?», «Чак-чак кына...». «Комсомол яшьлеге», «Өчәү юлга чыктык», «Канкай углы Бәхтияр», «Ак калфак», «Анага мәдхия», «Ташлама утны, Прометей!» рецензияләрендә тәнкыйтьче татар һәм башкорт театрларының, драматургиясенең уңышларына чын күңелдән сөенеп, оттырышларына ихлас көенеп, мөһим фикерләр әйтә. Авторның башкорт театры спектакльләре уңае белән романтик алымнарны, поэтик образлылыкны яклаган фикере аерым игътибарга лаек.

«Мәктәп сәхнәсе», «Халык талантлары» мәкаләләрендә үзешчәннәр иҗатына һәм балалар сәхнәсе репертуарына кагылышлы борчылу сүзләре дә әдипләр һәм театр җәмәгатьчелеген, тамашачыларны битараф калдырмаска тиеш.

Китапта игътибар үзәгендә торган проблемаларның берсе — заманның уңай герое мәсьәләсе. Ф. Хөсни кебек тәҗрибәле әдипләр фикерен куәтләп, А. Әхмәдуллин уңай идеалларны масштаблы уңай герой образы аша үткәрүне яклый. «Зур уңай геройны күрсәтү өчен аны зур тискәре типка каршы куярга кирәк» дигән концепцияне инкарь итеп, бу мәсьәләгә бөтенләй үзгә карашын автор Т. Миңнуллинның иҗат тәҗрибәсен анализлап дәлилли.

А. Әхмәдуллин мәкаләләрендә уңай герой мәсьәләсендә генә түгел, гомумән уңай башлангычка хөрмәт зур. Драматургиядә дә ул уңай якларын табарга, аларны игътибар үзәгенә куярга омтыла. «Чын кешелек сыйфатлары, безнең көннәр каһарманнарының асыл гүзәллекләре,— ди ул, естә генә ятмын, еш кына аларны көч

[1] А. Әхмәдуллин. Сәхнә әдәбияты һәм тормыш. Казан, 1980.

куеп таба һәм тиешенчә тасвирлый белергә кирәк».

Һәр мәкаләдә пьесаларның идея эчтәлегенә, теоретик моментларга сизгерлек күзгә ташлана. Моны классик мираска мөнәсәбәттә дә күрергә мөмкин. Әйтик, Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар» әсәрендәге «иман» символы сәхнәдә башка мәгънә ала икән, тәнкыйтьче моңа кабат-кабат игътибар юнәлтүдән тартынмый. Яшь драматурглар иҗатына карата әйтелгән мондый фикерләр бигрәк тә мөһим.

Тормышчанлык, автор позициясе («Алар өчәү иде»), идея сафлыгы, проблема-тема конкретлыгы, жанр аныклыгы, форма бетенлеге, стиль берлеге («Кырлай егете»), отышлы чыккан шартлы алымнар, романтик пафос, поэтик образлылык кебек мөһим мәсьәләләр турында төгәл мисалларга таянып фикер йөртелү китапның кыйммәтен аеруча күтәрә. Шул ук вакытта тәнкыйтьченең аерым мәсьәләләргә кагылышлы бәяләмәләрендә бәхәсле моментлар да юк түгел. Ә тулаем алганда, алар агымдагы иҗат практикасына карата вакытында каралган әйтелгән кирәкле сүз, гомумиләштерү, анализ булып ишетеләләр.

Мәкаләләрдән авторның тәнкыйть стилен дә ачык төсмерләргә була. А. Әхмәдуллин үз фикерен мөмкин кадәр гади итеп әйтергә омтыла. Ләкин бу гадилек — гадиләштерү, беркатлылык юлына басу түгел. Объектив анализларында автор итагатьле генә итеп үз киңәшен белдерүдән дә тартынмый. Аерым спектакльгә, артистлар осталыгына караган мәкаләләрендә дә А. Әхмәдуллин үзенә хас кешелеклелек һәм таләпчәнлек белән эш итә. Кыскасы, бу китап авторы «күсәк тоткан критик» түгел.

Әмма аны «алсу күзлек кигән тәнкыйтьче» дип тә әйтеп булмый. Н. Исәнбәт, Х. Вахит, А. Гыйләҗев, Т. Миңнуллин кебек танылган драматурглар иҗатларына карата әйтелгән принципиаль фикерләр моңа ачык дәлил.

Т. Миңнуллин иҗатына тәнкыйтьче күптәннән игътибар итеп килә. Әле 1968 елда ук ул болай язган иде: «Анализны «Миләүшәнең туган көне» исемле пьесасыннан башларга уйлыйм. Ни өчен? Чөнки ул, бердән, үткән елны сәхнәгә менгән әсәрләрнең кызыклыларыннан берсе. Аның белән олы драматургиябезгә үзенчәлекле һәм талантлы автор килде. Икенчедән, бу әсәрдә хәзерге драматургиядә бара торган, югарыда әйтеп узылган эзләнүләр чагыла». Талантын раслап өлгергән бу драматург иҗатына китаптагы 31 мәкаләнең алтысы (тулысынча яисә төп өлешендә) багышланган. Ихтимал, тәнкыйтьче игътибарын Т. Миңнуллин иҗатындагы яңа тенденцияләр, халыкчанлык, заманча фикер йөртә белү кебек үзенчәлекләр тартадыр.

Классик әдипләребез турындагы мәкаләләрдә А. Әхмәдуллин һәрбер драматургны татар сәхнә әдәбиятына керткән өлешенә, яңалыгына, карап характерлый. Мондый мәкаләләр арасында Г. Камал, һ. Такташ иҗат портретлары исә шактый тулы бирелүләре белән дә отышлы.

Җыйнап әйткәндә, бу китаптагы тәнкыйть сүзе — бүгенге театрыбыз һәм драматургиябез өчен тансык сүз.

**Р. ӘХМӘТҖАНОВ,**
филология фәннәре кандидаты,

**Н. ХАНЗАФАРОВ,**
филология фәннәре кандидаты.

# ЯШЬЛӘР ЮЛГА ЧЫГА

Заман таләбе әдәби әсәр тукымасына үз йогынтысын алып килә тора. Бүгенге укучыны табигатьнең гүзәл күренешләрен, персонажларның портретларын осталык белән сурәтләп бирү, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне кызыклы итеп күрсәтү осталыгы гына канәгатьләндереп җиткермәскә мөмкин. Бу, кайберәүләр уйлавынча, рациональлекнең лирикадан өстенлек алуы диган сүз түгел, бәлки тормышның үзендә фикерләү культурасының нык үсүе белән аңлатыла.

Марсель Галиевнең «Ул чакта» дип исемләнгән китабына кергән «Ак абагалар» повесте, барыннан да элек, әнә шул ягы белән үзенчәлекле. Бу әсәрдән искитмәле вакыйгалар тезмәсе эзләргә теләүчеләрнең өмете акланмаячак. Вакыйгалар алмашуы мәгънәсендәге динамика бирелә шактый салмак, аның каравы фикер динамикасы көчле генә бирелгән.

Хикәяләү архитектура бүлеге студенты Данияр исеменнән бара. Әле үзенең тормыштагы урынын гына түгел, мәхәббәтен дә төгәен билгели алмаган, эзләнүчән, тынгысыз җанлы егет алдына әледән-әле бер сорау калкып чыга: «Яшәү мәгънәсе нәрсәдә?»

Данияр, бу яшьтә бик күпләргә хас булганча, үзен башкалардан һичсүзсез сәләтлерәк, өстенрәк итеп хис итә. Янәсе, ул гына дөньяның бихисап төсмерләрен, төрлелегән комплексны кабул итә, бары ул гына кешеләр турында гадел хөкем чыгара ала.

Язучы әсәргә эпиграф итеп А. Сент-Экзюпериның «Яшәү ул — әкренләп туа бару» дигән сүзләрен алган. Ләкин уйлану лар процессында ул, үзе үк бу фикергә каршы килеп, «Вакыт чикләнгән. Яшәү ул — әкрен-әкрен үлә бару» дигән антитезисны ташлый. Дөресен әйткәндә, бу фикерләр арасында каршылык юк. Ул һәр шәхеснең яшәү мәгънәсен ничек аңлавына бәйләнгән. Кеше үз алдында якты бер перспектива күрмәсә, һәрнәрсәгә битараф караса, яшәү, чыннан да, әкрен-әкрен үлә бару булып әверелә. Киресенчә, кеше көн туган саен үзе өчен дөньяның яңа якларын ача бар-

са, якты максатларга омтылуда ихтыярлылыгын күрсәтсә, кешеләрне ярату кебек иң гуманлы хискә ия булса, йөрәгендә иҗат ялкыны үрләсә, ул хисләргә, белемгә, тәҗрибәгә байый барачак, һәркөнне кечкенә генә булса да ачыш ясый алачак.

Даниярны без икенчеләр исәбенә кертәбез. М. Галиевның герое тормышка актив мөнәсәбәттә. Дөрес, ул әле дөньяны күбрәк алсу төсләр белән күзаллый, практик тормыш ваклыкларының әһәмиятен бәяләп бетерә алмый. «Дөнья театрында бөек актерлар уйнар өчен сәхнәне иңендә тотучы меңнәрчә гадиләр кирәк» дигән фәлсәфә аның үз натурасына туры килә. Чөнки ул балачак дустын яки әтисен әнә шул «гадиләр» итеп атарга җөрьәт итмәсә дә, үзен «дөнья театрында уйнарлык» актер итеп сизә. Әмма тормыш моның дөреслеккә туры килеп бетмәвен күрсәтә. Бу мәгънәдә Даниярның урман каравылчысы Мирхәтим агай белән очрашып сөйләшүе гыйбрәтле. Әлегә кадәр Данияр кешеләрне үз идеалына туры килү-килмәү критерие белән бәяләгән, аларга үз асылын көчләп таккан, Мирхәтим агайның шат күңелле булуын да аңлап бетерә алмый ул. Имеш, урман каравылчысы кебек кечкенә кешедә нинди шатлык, нәрсәдән канәгатьләнү тойгысы була алсын. Мондый затлы хисләр бөекләр өчен генә хас дигән ышанычы аңа гади кешеләрнең бәхетен аңлауны кыенлаштыра. Баксаң, шул ук Мирхәтим агай шагыйрь җанлы кеше икән бит. «Урманны тыңлый, ишетә дә белергә кирәк, энем. Урман елый да, көлә дә белә ул... Урман белән сөйләшергә яратам мин. Яшерен-батырын түгел, «төшереп» алган көннәрдә каеннарны читләтеп үтәргә тырышам. Оялта, брат. Чын әгәр, чиста халык. Андый чакта лутчы иманлектә йөрүең. Иман ул каты халык, без мужикның хәлен аңлый!» Данияр бу сөйләшүдән бик гыйбрәтле нәтиҗә ясый. «Кечкенә шәхес дип уйлыйсың. Түбәнсетеп карыйсың. Ә аның эчендә гәүһәр ята. Табигый сәләт. Үз иҗаты. Андый кешеләр кычкырып, шапырынып йөрмиләр. Алар хәтта үзләрендә никадәр байлык ятканын да белми, сизми йөриләр. Ялгыш кына ачылып китәләр, һәм шунда ук онытalar да...» Эпизодик сөйләшүдән дә шундый сөземтә ясау Даниярның яши-яши туа баруын раслаучы бик матур мисал.

Сөйгәне Айрүзә белән аралары өзелүе дә Даниярның үзен артык югары бәяләвеннән килмиме икән. Хыялы белән сәнгать күкләрендә йөзгән егет өчен «гади генә авылда, гади генә бер өйдә тыныч кына яшәргә» омтылган, финанс-экономика институты студенты буларак, шигъриятне коры саннарда тоючы кызны тиң күрмәве гаҗәп түгел. Үзен «гадәти итеп түгел, мәңге үзгәрмәс җан итеп тойган» Данияр да диалектика законнарының көчен тоярга, кешеләрне аңлауда эволюция кичерергә мәҗбүр. Бу исә язучының тормыш хакыйкатенә ихтирам белән каравыннан килеп чыга. М. Галиев тормышны аерым шәхеснең күңел тирбәлешләре, интим хисләре аша сурәтләү осталыгын үзләштереп килә.

Китапка кергән «Ул чакта» исемле икенче повесть исә гадәти-традицион нигездә язылган. Автор мөстәкыйль тормышка әле яңа гына аяк басып килүче, күңел кояшы бары тик якты төсләр белән генә балкучы, кешеләрдә яхшы якларны гына күрергә күнеккән үсмер егет Сәйярның кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең үзе уйлаганнан шактый катлаулы булуын аңлаудан туган күңел каршылыкларын гади генә, абстракт уйланулар белән бизәмичә генә сөйли.

Сәйяр нечкә күңелле егет. Төсләр байлыгын сизгер аңлаучы рәссам. Унсигез яше дә тулмаган егетнең инануынча, дөнья — гүзәллек мохиты, анда икейөзлелек, тупаслык, хәйләкәрлек кебек тискәре якларга урын булмаска тиеш. Бу аның үз хыялында тудырган дөньясы. Ләкин чынбарлыкта матурлык гармониясенең бозылган очраклары да була икән. Тик бу диспропорцияне тоемлау унсигез яшьлек кеше өчен җиңел түгел. Ни өчен дигәндә, кайбер кешеләрдә зәгыйфь эчтәлек шактый камил формага яшеренгән була икән бит. Инженер Әхмәт Шәрәфиевне кара уйлы кеше дип беренче карашка кем әйтә алыр? Ул пөхтә итеп киенгән, галстук таккан. Һәрвакыт шат күңелле. Үзләренә һөҗүм иткән хулиганнарны акылга утыртуын күрү Сәйярның Шәрәфиевка карата булган уңай фикерен тагын да ныгытып куя.

Сәйяр гәүдәгә дә, әхлакка да элек-электән таза нәселдән. «Авыл анасы» Җиһан әбисе тәрбиясендә ул туры сүзле, төпле акыллы, уйлаганын яшермичә әйтә алучы, начар шаукымнарга бирешмәүчән табигатьле булып үскән. Әбисе гомер буе җир җимертеп эшләп, «яшәү дәртен җуймаган, хәрәкәтчән, һәрвакыт ни дә булса уйлап чыгарырга яратучан» булып калган, бу сыйфатлар Сәйярга да күчкән.

Кешенең нәрсәгә дә булса инануы нык булырга тиеш. Шул иман аңа һәртөрле очраклы агымнарга кушылып китмәү өчен, медицина теле белән әйткәндә, иммунитет ролен үтәячәк. Сәйярга да юлында «бәтен эшчәнлекнең төбендә акча ята», «бу дөньяда иркен яшәп калырга кирәк» дигән карашны тормыш девизы итеп алган Шәрәфиев кебекләр очрый. Баштарак аңа әле Шәрәфиев, әле туры сүзле Уразаев хаклы булып тоела, тик ул үзе әле кырт кисеп нәтиҗә ясарга гына ашыкмый. Шулай да сафлыкка сусаган егет күңеленә сәнгать белән фанатикларча илһамланган, Шәрәфиевлар күзлегеннән чыгып карaганда «яши белмәүче» Уразаевлар якынрак. Үзенә тартып торган менә шушы яктылык аңа, дөрес юлны табарга, тайпылмыйча алга барырга ярдәм итә.

Сәйярның эчке ихтыяҗларын, кыска гына итеп, матурлыкка омтылу дип атарга мөмкин. Бу бигрәк тә аның беренче мәхәббәтенә мөнәсәбәтендә күренә. Инде кияүгә чыгарга өлгергән Мәдинә Сәйярга яшь ягыннан да, үз-үзен тотышындагы артык иреклелеге буенча да тиң түгел, алар арасындагы мөнәсәбәтләрдә бу нәрсә ачык

күренә. Әз генә саксыз кагылганда да җәрәхәтләнергә торган нәфис күңелле Сәйяр өчен Мәдинәнең ирләр компаниясендә үзен «тәҗрибәле» хатыннарга хас булганча йогәнсезрәк тотуы һәм аның турында «дуслары»ның тупас сүзләрен ишетү бик авыр хисләр тудыра. Бу тойгылар армиядә узган ике ел дәвамында да егетнең йөрәген сызлатып тора. Ләкин кешеләрдә яхшылыкның өстенлек алуына ышанган күңелендә Мәдинәнең үз урынын бүтәннәргә бирми торуы да сизә. Армиядән кайткач булган очрашулары бер-бере өчен зарыккан ике күңелнең аңлашуы белән тәмамлануы логик яктан акланган табигый финал булып яңгырый.

Данияр, Сәйяр, Айрүзә, Динара, Мәдинә, Лениза һәм башка образлар — безнең көннәрдән турыдан-туры китап битләренә килеп кергән персонажлар: Аларның холык-фигыльләрендә, эш-хәрәкәтләрендә ясалмалылык юк, иң күркәм сыйфатлары — табигыйлек.

Киң карашлы, эрудицияле яшьләрнең кызыклы образларын, фальшь ясамыйча, табигый сурәтләү күбрәк М. Галиев кебек үзе дә шул буын вәкиле булган яшь әдипләр өлешенә төшә. Алар сәнгатьтә катлаулы эзләнүләр алып бара, төрле экспериментлар ясый, кайвакыт хәтта үз-үзләре белән табигый каршылыкларга да керәләр. М. Галиев та, сүз рәссамы буларак, әзер калыплар белән генә эш итәргә яратмый. «Ак абагалар», «Ул чакта» повестьларында бу авруча ачык күренә. Әсәрләрендә интеллектуаль-фәлсәфи юнәлеш өстенлек итү аның иҗатында үзенчәлекле як. Бу, бәлки, аның геройларының сәнгатькә, матурлык тудырырга омтылучы, хискә, моңга бай, тирән акыллы яшьләр булуыннан да киләдер.

«Ак абагалар» һәм «Ул чакта» повестьлары беренче карашка бер юнәлештә, бер сулыш белән язылган әсәрләр кебек тәэсир калдырса да, алар әчке хасиятләре ягыннан шактый аерылып тора. Беренчесендә фәлсәфи уйлану, күренешләргә абстракт бәя бирү өстенлек ала, хәтта вакыт-вакыт үзмаксатка да әверелеп китә. Икенче повесть та мондый башлангычтан мәхрүм түгел, тик инде ул төгәлрәк, үткенрәк, әсәрнең идеясен тирәнрәк ачуга хезмәт итүгә буйсындырыла. Беренче әсәрдә әле автор юк-юкта уйлап ук бетерелмәгән фикерләр дә әйтеп узгалый.

М. Галиев повестьларының тезелешстиль ягыннан да үз йөзе бар. Аларны укучы төрле кучешләргә бик сак булырга тиеш. Чөнки үткән белән бүгенге, реаль күренешләр белән уйланулар урыны-урыны белән шактый тыгыз берегеп китәләр. Язучы әдәбиятка үз почеркы, үз юнәлеше белән килә. Һәм аның индивидуаль йөзе инде хәзер үк ачык төсмерләнә. Бу үзенчәлек М. Галиевның алдагы иҗатында тагын да тулырак ачылыр дип өметләнергә кирәк.

**Фоат ГАЛИМУЛЛИН.**

Миркасыйм Госманов

# ЭЗЛӘР ДАСТАНГА ИЛТӘ

Бу әсәр фольклор фәнебездә шактыйдан бирле мәгълүм. Аның кыскача текстын беренче мәртәбә 1913 елны Казанда нәшер ителгән «Халык әдәбияты. Бәетләр» китабында Хуҗа Бәдигый бастырып чыгарган. Шуннан соң ул башка җыентыкларга да бәет үрнәге буларак кертелә килә. Х. Ярми тарафыннан тупланган «Бәетләр» китабында /1960 ел/ аның ике варианты китерелә. Моннан соң да «Хан кызы» әсәре фольклорчыларыбызның игътибарын җәлеп итә килде. Мисал рәвешендә Х. Ярми, И. Надиров, Ф. Урманчеев, М. Мәһдиев һәм Р. Мөхәммәтҗанов хезмәтләрен күрсәтергә мөмкин.

Егет белән кызның кара-каршы сөйләшүе, дәресрәге, «әйтеш» алымы белән иҗат ителгән бу әсәрнең әдәби-эстетик сыйфәты, эчтәлеге һәм социаль-иҗтимагый функциясе хакында фольклор белгечләребез моңарчы беркадәре яздылар инде. Әсәрнең мәгънәсен артык «социальләштереп» җибәрү, «хан кызы» дигән төшенчәне бик беркатлы аңлау рәвешендәге фаразларга карата да гадел тәнкыйть фикере әйтелде. (М. Мәһдиев, «Казан утлары», 1968, II нче сан).

Чыннан да, моңарчы мәгълүм текстлар, аларның эчтәлекләре буенча хөкем йөрткәндә, әсәрдә бернинди феодаль иерархия башында торган хан-падишаһ кына сурәтләнми, бәлки феодализм чорындагы гадәти патриархаль гаиләдән чыккан татар кызының күркәм сыйфатлары, тыйнак холкы, шул ук вакытта беркадәре хиссиэчке омтылышы да шигъри формада тасвир ителә. Әсәрнең нигезендә дә «хокук» мәсьәләсеннән бигрәк чоры өчен характерлы әхлак нормаларын тасвирлау булса кирәк. Шуның өстенә кыз белән егет мөнәсәбәтләренең күркәм һәм көлкелерәк ситуацияләре дә гәүдәләнгән дип әйтергә мөмкин.

Әсәр үзенең төзелеше, әдәби-сурәтләү алымнары белән бәетләрдән бөтенләй үзгә, төрки халыклардагы «әйтеш» жанрына якынрак. Моның шулай икәнлеген күрү өчен әсәрнең үзенә, аның иң тулы һәм сыйфатлы вариантына мөраҗәгать итик. Тәкъдим ителә торган текстка кадәр, мондый вариантларның экспедицияләр вакытында шактый күп /15—20 ләп дәфтәр/ табылуын да әйтергә кирәк. Мәсәлән, 1968 елны Буа районында табылган бер кульязмада /ул хәзер Н. И. Лобачевский исемендәге гыйльми китапханәдә саклана — Т. 2382 Алга таба саклау берәмлегенең саны гына күрсәтелә/ 28 юл теркәлеп калган. Чәчкап авылында табылган Бибизәһрә Мөхәммәтзакир кызы дәфтәрендә 20 юллык фрагмент бар /Т. 2374/. Ә Кайбычтагы Зариф Идрисов кульязмасында исә 32 юл теркәлгән /Т. 2384/. Тәтеш районындагы Кече Әтрәч авылыннан Шәйхелислам Зиннур улы китапчыгында 58 юллы текст /Т. 2364/, шул ук районның Олы Торма авылында яшәүче Бибинур Насыйбуллинаның җырлар дәфтәрендә /Т. 2362/ 46 юл сакланган...

Барлык вариантлар өчен дә уртак нәрсә — егет белән кызның ябык ишек аркылы «әйтешүе». Гомумән, алар арасында артык принципиаль аерма юк та кебек. Чөнки әсәрнең беренче өлешендә шул ук буй-сын, йөз-кыяфәтне мактау, икенче өлешендә исә, ата-ана, апа-сеңел һәм җиңгәләргә сылтап, егетне өйгә кертмәскә тырышу.

Ләкин төрле нөсхәләрне үзара чагыштырып карый башласаң, өлеге тасвирлауның, өлеге аклапулар һәм шунда ук аларны кире кагуларның үзенә күрә эчке

эзлеклелеге, хәтта закончалыгы бар икәнен беләсең. Мәсәлән, егет кызны теләсә ничек мактамый, бәлки иң элек буй-сынын, бармакларын тасвирлый, аннары чәчкә күчә, каш-күзне телгә ала, шуннан соң авыз һәм тешләрне мактый. Ягъни, зурдан, гомумидән кечкенәгә, конкретлыкка таба күчеш эзлеклелеге саклана. Шул юл белән кульминацион югарылыкка ирешелә, чөнки гүзәллек сыйфатын мактап сурәтләгәндә иң оста һәм иң үтемле чара иң вак әгъзаларның да күркәм сыйфатларын күрә белүгә кайтып кала. Бу рәвешле соклана алу сыйфаты бары чын чибәрлеккә табынучы гашыйк күзләргә генә хас. Анда гашыйк егет күзенең «сукырлыгыннан», дөресрәге, берьяклы гына күрә алуыннан бик нечкә, бик ягымлы итеп көлү дә сизелеп тора. Чөнки бөтен җире бердәй килешкән кыз тормышта бик сирәк очрак булса да, әкиятләрдәге «хан-падишаһларда» гына булыр. Менә ни өчен егетебез гадәти кыз баланы «хан кызы» дип олылый! Чөнки бу төшенчә русча «царевна»дан тыш, Н. Ф. Катанов дөрес тәрҗемә иткәнчә, «царь-девица»ны да белдерә. Аның чыннан да ил биләүче, дәүләт башында торучы хан кызы булмавын әсәрнең икенче өлешендәге детальләр — чәч тарагы, мунча, челтәрле чана, утын балтасы h. б. да күрсәтеп тора. Ниһаять, егет белән кыз үзләре дә авылда яшиләр.

Әсәрнең беренче өлешендә егетнең мактавы гомумидән конкретка күчсә, шул юл белән ул кызны чарасыз калдыруга ирешә язган булса, икенче өлештә дә ишек ачарга күнә төшкән кызыбыз сылтау-сәбәпләре эредән вакланауга таба йөз тота: башта ул атасыннан куркуын әйтә: аннары анасыннан, агасыннан, ниһаять... ялчыколыннан да курка булып чыга. Җыеп әйткәндә, «ачыла ишек» егет алдында, чөнки ул безнең әкиятләрдәге кебек тапкыр, үз дигәнен булдыручан, уңган, типик егет.

Ләкин чынбарлыкта түгел, ә яшьләр җыелып, уен-көлке ясап утырган җирдә ачыла өлеге ишек. Аңлашыла төшсен өчен, Шәйхелислам Зиннур улы дәфтәреннән алынган (Т. 2364) текстны тулысынча китерик. Кулъязма XIX гасырның икенче яртысында төзелгән.

### ИЛАҺИ МАТУР ХАН КЫЗЫ БӘЕТЕ

1. Һавадин очып йөргән кош дәгелме!
Егетнең җан сөйгәне кыз дәгелме!
2. Бер кич бардым кыз катына — кузәттеләр.
Уникe чукмар белән озаттылар.
3. Бар әйтеңез ярыма: кайгырмасын,
Сул кабыргам кыңгыр иде — төзәттеләр.
4. — Хан кызы, ач ишегең, бән керәем,
Сәнең буең зифа дирләр, бән күрәем.
5. — Бәнем буем зифасын сән нидәрсән!
Сазда үскән тал-чыбыклар күрмәймесән!!
6. — Хан кызы, ач ишегең, бән керәем,
Сәнең бармагың нечкә дирләр, бән күрәем.
7. — Бәнем бармакым нечкәсен сән нидәрсән!
Сазда үскән сары камыш күрмәймесән!!
8. — Хан кызы, ач ишегең, бән керәем.
Сәнең сачың кара дирләр, бән күрәем.
9. — Бәнем сачым карасын сән нидәрсән!
Асламчыда кара ефәк күрмәймесең!!
10. — Хан кызы, ач ишегең, бән керәем,
Сәнең кашың кара дирләр, бән күрәем.
11. — Бәнем кашым карасын сән нидәрсән!
Шәкертләрдә кара каләм күрмәймесән!!
12. — Хан кызы, ач ишегең, бән керәем,
Сәнең күзең кара дирләр, бән күрәем.
13. — Бәнем күзем карсын сән нидәрсән!!
Шәһәрләрдә кара түмә күрмәймесән!!

**14. — Хан кызы, ач ишегең, бән керәем,**
**Синең агызың кечкенә дирләр, бән күрәем.**
**15. — Бәнем агызым кечкенәсен сән нидәрсән!**
**Асламчыда алтын уймак күрмәймесән!!**
**16. — Хан кызы, ач ишегең, бән керәем,**
**Синең дешең вак дирләр, бән күрәем.**
**17.— Бәнем дәшем ваклыгын сән нидәрсән!**
**Базардагы йенҗү-мәрҗән күрмәймесән!!**
**18. — Тәнем егет, җаным егет, кермә, егет,**
**Бәнем атам усал, күрсә сүгәр.**
**19. — Атаңа алтын таяк бән бирәем,**
**Мәсҗет юлын күрсәтүбән йибәрәем!**
**20. — Тәнем егет, җаным егет, кермә егет,**
**Бәнем анам усал кеше, күрсә сүгәр.**
**21. — Анаңа алтын тарак бән бирәем,**
**Мунча юлын күрсәтүбән йибәрәем!**
**22. — Тәнем егет, җаным егет, кермә егет,**
**Бәнем агам усал кеше, күрсә сүгәр.**
**23. — Агаңны акбүз атка мендерәем,**
**Шәһәр юлын күрсәтүбән йибәрәем!**
**24. — Тәнем егет, җаным егет, кермә егет,**
**Бәнем җиңгәм усал кеше, күрсә сүгәр.**
**25. — Җиңгәңә чeлтәрле чана бән бирәем,**
**Атасының өенә йибәрәем!**
**26. — Тәнем егет, җаным егет, кермә егет,**
**Бәнем энем усал кеше, күрсә сүгәр.**
**27. — Энеңә матур кызый бән бирәем.**
**Шәһәр юлын күрсәтүбән йибәрәем.**
**28. — Тәнем егет, җаным егет, кермә егет,**
**Бәнем тәкәм усал хайван, күрсә сөзәр.**
**29. — Тәкәңә олуг кәҗә бән бирәем.**
**Абзар юлын күрсәтүбән йибәрәем.**

Әсәрнең гомум төзелешенә, композицион элеклелегенә игътибар итсәк, аның иң гулы, иң төзек һәм эзлекле үрнәк булуын күрәбез. Бу мәсьәләнең бер ягы. Икенчесе исә Шәйхелислам бабай текстының композицион тулылыгында. Моңарчы фәндә мәгълүм вариантларның барысы да, шулай ук кульязмаларның да бер өлеше, ишек янында «хан кызы»на мөрәҗәгать итүдән үк башланып китә. Яңа вариантларда да күренә. Мәсәлән, Олы Торма авылы кульязмасында (Т. 2362) җырның соңгы өлеше болайрак тәмамлана (вариант һәм вариацияләр ачыграк күренсен өчен озынрак өзек китерик).

**— ... Агаңа челтәрле чана бән бирәем,**
**Кала юлын күрсәтүбән йибәрәем!**
**— Җаным егет, тәнем егет, кермә, егет,**
**Бәнем җиңгәм яман кеше, күрсә сүгәр.**
**— Җиңгәңә тимер чиләк бән бирәем,**
**Су юлын күрсәтүбән йибәрәем!**
**— Җаным егет, тәнем егет, кермә, егет,**
**Бәнем сеңлем яман кеше, күрсә сүгәр.**
**— Сеңлеңә галим шәкерт бән бирәем,**
**Чарлак юлын күрсәтүбән йибәрәем!**
**— Җаным егет, тәнем егет, кермә егет,**
**Бәнем колым яман кеше, күрсә сүгәр.**
**— Колыңа авыр балта бән бирәем,**
**Урман юлын күрсәтүбән йибәрәем!**

**Бардым иде кыз күзләргә — күзәттеләр,**
**Уникe чукмар белән озаттылар.**

Бу варианттагы үзгәлекләр характерлы. Мәсәлән, беренче нөсхәдәге тәкә турындагы тупасрак строфа урынына кол һәм аңар бирeләчәк авыр балта белән күрсәтeләчәк урман юлы алынган. Күпчелек башка вариантларда да ул шулай. Шуңа күрә соңгы строфаны бары Шәйхелислам дәфтәренең үз хосусияты дип бәяләргә кирәк.

Тәкъдим ителгән варианттагы башлау өлешенең ят яки бердәнбер мисал булмавын раслый торган икенче факт та бар. Мәсәлән, Апаста табылган дефектлы дәфтәрдә (Т. 2358) әсәр, кайбер элементлары белән әле генә китерелгән өзекне кабатлаган хәлдә (сеңел — шәкерт, кол — урман), түбәндәгечә тәмамлана:

**Бардым иде кыз күзләргә — күзәттеләр,**
**Уникe чукмар белән озаттылар.**
**Бар әйтеңез шул җаныйга: кайгырмасын,**
**Сул кабыргам җантык иде — төзәттеләр.**

Һәр ике очракта да бу «өстәмә» җырлар әсәрнең башкарылу ысулы, хәтта аның иҗтимагый функциясе белән бәйләнгән булырга тиеш. Икенчерәк итеп әйткәндә, алар әсәрнең кайчан һәм ничек башкарылуын күрсәтә торган сценарий чаралары булып та хезмәт иткән.

Чыннан да, «Хан кызы» җырын кайда, кемнәр һәм ничек башкарганнар соң?

Бу сорауларга җавап итеп китерерлек язма документлар сакланмаган. Шәкерт дәфтәрләрендә коры тексттан гайре бернәрсә дә китерелми. Бу сорауларга җавап эзләгән чакта, җыр текстының үзенә һәм әле генә телгә алынган «өстәмә» материалга мөрәҗәгать итү юлы кала. Җыр исә (бигрәк тә башлау янсә йомгаклау булып хезмәт иткән, ягъни урын җәһәтеннән «тотрыклы» өлеше) аның яшьләр-кызлар һәм егетләр бергә җыелган урыннарда, ихтимал, аулак өйләрдә, коллектив рәвештә башкарылуына ишарә ясый. Мәсәлән, уен башланган чакта чая егетләрнең берсе:

**Һавадин очып йөргән кош дәгелме,**
**Егетнең җан сөйгәне кыз дәгелме...**

— дип башлап җибәрә дә, алдан килешенеп кую буенча, икенче берәү егет роленә кереп, «хан кызы»ннан ишек ачуны сорый, аны мактый башлый. Кызларның бер чаясы аңар җавап бирә. Күп очракта бу мактау һәм горурлану җырларын чыннан да үзара күңел куешып, ым кагышып йөри торган егет белән кыз башкарган булуы бик мөмкин. Чөнки мактау сүзләре, бераз күпертү булса да, гомумән, матур сүзләр. Әсәрнең бу өлешендә хәтта юмор-ирония дә сизелер-сизелмәс дәрәҗәдә генә. Әмма икенче өлештә, бигрәк тә 24 нче икеюллыктан башлап, юмор көчәя төшә. Ә уенда катнашкан яшьләрнең бу мизгелдәге теләк һәм шөгыльләре исә йөз күрешүдән, аулакта әңгәмә корудан, аңлашудан гыйбарәт. Соңгы такмаклар җырлангач, «уникe чукмар»ның телгә алынуы бик урынлы: егетнең таләпчәнлеге, кызны мактый белүе нәтиҗәсендә ишек ачыла һәм нәкъ шул мәлдә «кыз катына» баручыны күзәтеп торучыларың «уникe чукмар» егет башына ишелеп төшә. Ата, ана, ага, җиңгә, эне, (яки сеңел) һәм ко̄л — алты кеше, аларның һәрберсендә икешәр йодрык. Менә ни өчен уникe чукмар! Уен, күрәсең, әнә шулай шаярып «тукмак алышулар», җиңелчә мускул язып килешүләр белән очлангандыр.

Ләкин «Хан кызы»ның бөтен әһәмиятен, кыйммәтен шушы соңгы элементка — уникe чукмарга гына кайтарып калдырырга ярамый: аның чын әдәби көче, тыңлаучыны сихерли торган сыйфаты ул яшьләргә хас омтылышны гаҗәп романтик, чынбарлыкны исә, беркадәр шартлырак булса да, бик реалистик тасвирлавында.

Бу уенны, ихтимал, егетләр, ягъни шәкерт малайлар үзләре генә җыелган җирләрдә, мәсәлән, кышкы мәдрәсәләрнең торак бүлмәләрендә башкарганнардыр. Җырның кайбер вариантларында чак кына иреклерәк, (сеңелгә шәкерт бирeп, чарлак юлын күрсәтү кебек) сюжет сызыкларының очравы шуңа ишарә ясый. Кайбер нөс-

хәлләрдә эне-сеңелгә «мәдрәсә юлы» күрсәтелә, ягъни әдәп ягыннан тотнаклы хәл кылына.

Һәрхәлдә ничек кенә булмасын, без җыр версиясенең яшьләр җыелышкан кичәләрдә драматик күренеш — инсценировка рәвешендә башкарылуы, ягъни аның үзенә күрә коллектив йола җыры, дөресрәге, көйле халык сәхнәсе әсәре булуы дөреслеккә бик якын. Ахыр чиктә төрки халыклардагы әйтеш жанры үзе үк халык сәхнәсе репертуарының бер төре бит!

Дөрес, фәнни әдәбиятта «Хан кызы»н туйларда башкарыла торган йола җыры дип аңлату да бар[1]. Әмма тормышның иң мөһим вакыйгаларыннан берсе булган никахкавышу туенда үзара мөнәсәбәтләренә карата юнәлгән юмор-ирония белән кем генә шөгыльләнер икән? Туй йолаларының берсендә дә өйләнүче егеттән янсә кияүгә чыгучы кыздан көлү юк. Дөрес, туйларда кода-кодачалар, кыз-киленчәкләр — егетярәннар әйтешә, юмористик әрепләшү кебек элементлар булгалаган. Әмма болар өйләнүчеләр түгел, бәлки бәйрәм итүчеләр! Кияү белән кәләш, кагыйдә буларак, туй ритуалларын тыйнак, әдәпле һәм тантаналы рәвештә башкарганнар. Чын туй йоласы булган «Яр-яр» җырының кияү-кәләш исеменнән әйтелгән версияләрендә дә (аны өйләнүчеләр үзләре түгел, бәлки шулар булып уйнаучылар башкарган) туй итүче яшьләрдән көлүнең эзе дә юк. Яшьләргә төбәп әйтелгән теләк сүзләре җитди һәм ихлас. Җыеп әйткәндә, тышкы сыйфатларына гына карап, әсәрнең без таныша торган версиясен туй җыры дип әйтергә җитәрлек нигез юк. Борынгырак вариантларына, эчке табигатенә, иҗтимагый функциясенә караганда, аны уен җырларына кертү мәгъкульрәк.

Истәлекнең социаль тормыш документы буларак кыйммәтенә килсәк, анда һичшиксез, үз чорында хөкем сөргән әхлак-мораль нормалары чагылуын күрәбез. Әйе, иске татар тормышында кыз белән егетнең, ярәшелгәнгә кадәр, аулакта күрешүләре очрашулары тыелган. Ләкин әсәр бу тыюларның яшьләр тарафыннан бозыла килүен дә күрсәтә.

Әдәби эшләнеш күзлегеннән караганда да җыр эстетик әһәмияткә ия. Монда декларатив аһ-зарлар, ясалма-коры өзгәләнүләр юк. Егет хәтта кызга сәлам дип тә әйтми. Яшьләрнең бер-берләренә омтылышы гүзәллеккә соклану ясслыгында бирелә. Археологик мәгълүматлар һәм тел материаллары бу җырның нәкъ шушы калыпта (версиядә) татарлар яши торган төбәкләрнең көнбатышырак өлешендә формалашуын, шунда киң таралуын күрсәтә. Һәрхәлдә, Тау ягы районнарында ул активрак җырланган — күбрәк кучерелгән. Табышлар шуны раслый. Истәлекнең туу вакыты исә XIX йөзгә кадәргә дәвергә туры килә. Йорт хезмәтчесен крепостной йомышчы дигән мәгънәдәрәк булган «кол» сүзе белән атау аның крепостнойлык тезелеш хөкем сөргән чорда формалашып калуына ишарә ясый. (Татарларда крепостнойлар бетерелгән чорда кызның «коллы» гаиләдән итеп күрсәтелүе һич тә гаҗәп түгел — бу борынгылыкның әкиятләрчә чагылуы гына.)

Әмма әсәрнең үзәгенә — җырчы егет белән чибәр «хан кызы»ның әйтешүе сюжетына, шул сюжетның кайчан туууына килсәк, мәсьәлә бераз катлаулана төшә. Чөнки бу төп сюжет татарлардан шактый еракта яшәгән башка төрки халыкларда — хакасларда да очрый икән. Дөрес, аларда да бу әсәрнең кайбер версияләрен туй җырлары белән бутап йөргәннәр. Мәсәлән, Н. Ф. Катанов җыйган материалларны 1907 елны үзенең мәшһүр «Образцы народной литературы тюркских племен» дигән китабында бастырган В. В. Радлов (IX том, 289 нчы бит) уналты гына юлдан торган өзеккә «кияү һәм кәләш сөйләшүе» дип исем биргән. Хакасчада исә ир-кизи, ягъни ир кеше һәм кыз-кизи, ягъни кыз кеше дигән нейтраль атамалар кулланыла.

Катанов язып алган хакас җырының туй йоласы әсәре булмавын раслый торган көчле дәлил хакас фальклорының үзендә үк сакланып калганы. Ул — чәчмә юллар белән шигъри строфалар үрелеп бирелгән әкият сыманрак әсәр. Аны сугышка хәтле үк күренекле хакас әдибе Н. Г. Доможоков язып алган һәм 1941 елны Абаканда чыккан «Хакасский фольклор» китабында бастырган (123 нче — 124 нче битләр). Истәлек безнеңчә, берничә яктан әһәмиятле: анда туй йоласына хас галәмәтләр бөтенләй булмаганы кебек, ул үзенең структурасы белән Катанов-Радлов вариантларыннан та-

[1] Р. Мөхәммәтҗанов. Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты. Уфа, 1977. 57 бит.

рихи борынгылыгы ягыннан да аерыла. Егетнең исеме дә булуы (Начах), аның конкрет хан кызына өйләнергә теләве, ниһаять, типик борынгы төрки эпослардагы кебек, геройның тыңдаучысы «олы җырчы» эпитеты белән характерлануы да игътибарга лаек. Мәсәлән, аерым фрагментларны фарсыча тезеган «Шәҗәрәт әл-әтрәк»тә генә сакланып калган бер төркичә эпоста Олуг Җырчы телгә алына (бу өзекләрне В. Г. Тизенгаузен һәм В. В. Бартольд публикацияләреннән карарга мөмкин). Гомумән, әсәр мәхәббәт сюжетына корылган борынгы бер дастанның, аның да, ихтимал, «кечкенә эпослар» дип йөртелә торган төренең бер «сүтелеп» яңадан үрелгән, мәгәр әкият кыяфәтенәрәк китерелгән мисалы булырга охшый. Шуңа күрә дә, дөресен әйткәндә, аның очы очка ялганмый: сүз башында Начахка бирелгән югары бәя — характеристика әсәр ахырында акланмыйча кала. Андый сыйфатка ия җырчы егет, фольклор логикасы буенча, кызны буйсындырырга тиеш иде; шулай ук әлеге логика буенча, тәкәббер хан кызының да үзгәрүе таләп кылына. Кыскасы, бу килеш әсәрнең фәлсәфәсе, иҗтимагый функциясе бөтенләй ачылмый кала.

Хакасча әсәрнең табигатен шулай бераз ачыклый төшкәч, үзебезнең Идел буе версиясенә кабат кайта алабыз. Бер карауга боларның һәр икесе үз алдына мөстәкыйль әйберләр булса да, аларның кайбер уртак моментлары һәм таңгал дип әйтерлек детальләре дә бар икән. Мондый охшашлыклар, хәтта сурәтләү таңгаллекләре очраклы гына рәвештә барлыкка килмәгәндер. Аларның нигезендә ниндидер бер тамыры белән «уртак» сюжет, төгәлрәк әйткәндә, дастан-эпос сюжеты ятадыр.

Уртак чыганакны болай сюжетка гына кайтарып калдыруының сәбәбе шунда ки, татарча һәм хакасча «Хан кызларын» бер әсәрнең ике милли версиясе, яисә аларны соңгы дәвер мәдәни бәйләнешләренең җимешләре дип карарга ярамый. Чөнки бу ике халык соңгы сигез-тугыз, бәлки ун-унбиш гасыр дәвамында үзара бөтенләй башка шартларда яшәгәннәр һәм үзгәреп үскәннәр. Өстәвенә һәр ике халыкта да әсәр сюжеты үз юлы белән үскән: хакасларда ул шаян җыр яисә әкияткә таба борылыш ясаган (эпосның әкиятләшүе безнең татарларга да хас, мәсәлән, «Алпамыш» дастаны), татарларда исә уен җыры булып формалашкан. Ягъни жанр ягыннан бербересеннән бөтенләй диярлек ераклашкан.

Шулай итеп, югарыда китерелгән материаллардан күренгәнчә, без танышкан Идел буе «Хан кызы» әсәре бәет тә яисә туй йоласы җыры да булмаган кебек, гадәти генә уен җыры да түгел икән. Ул кайчандыр яшәгән бер мәхәббәт дастанының сүтелүе нәтиҗәсендә «сибелеп калган» детальләрдән соңрак икенче нигездә оешкан үзенә күрә «әр-яңа» әсәр. Димәк, хәзер безнең кулда «Хан кызы» сюжетының икенчел яшәеше.

Әгәр безнең фараз азмы-күпме дәрәҗәдә расланса, борынгы эпосларыбыз репертуарын ачыклауда тагы бер мөһим факт артыр иде. Әлеге сюжетның татарлардагы башка версияләре, шулай ук кардәш халыклардагы яңа үрнәкләре табылса, ихтимал урта гасырларда берничә тугандаш төрки кавемгә уртак булган «Хан кызы» дастанының төп сюжетын яңадан торгызырга да мөмкинлек туар иде.

# ОСТАЗ

Тамырлары гасырлар тирәнлегеннән үк килүче музыкабызның иң катлаулы һәм, кызганычка каршы, аз өйрәнелгән башкаручылык сәнгате киң мәйданга авыр юллар үтеп, тар гына сукмаклардан килеп чыкты. Камил Мотыйгый, Фәттах Латыйпов, Фатыйма Гомәрова, Газиз Әлмөхәммәтов, Солтан Габәши, Фәйзулла Туишев кебек беренче җырчыларыбыз һәм музыкантларыбызның иҗат эшчәнлеге моның ачык мисалы булып тора.

Иңнәренә гаять зур һәм җаваплы йөк күтәргән, беренче сукмакларны салган, үзләре белән сәләтле яшьләрне ияртеп, алар күңелендә якты киләчәккә өметләр

уяткан, дәрт, рух биргән җырчыларыбыз һәм музыкантларыбызның фидакарь хезмәте татар совет башкаручылык сәнгате үсешенә нигез булды. Чөнки алар үрнәгендә бер-бер артлы яшь җырчылар, музыкантлар сәхнәгә күтереләләр, дөньяга чыгалар. Ул талантларның иҗади язмышлары төрлечә булса да юллары-максатлары бер — җыр һәм музыка сәнгатен үстерү өчен үз-үзләрен аямыйча эшләү иде. Шулар арасында 12 яшьлек Каюм Байбуров та була.

1907 елда Ташкентның бер эшче гаиләсендә бишенче бала булып дөньяга килә Каюм. Биш яшендә әтисеннән ятим кала. Гаиләдә иң олысы булган унбиш яшьлек абыйсы кечкенә Каюм күңелендә скрипкада уйнауга мәхәббәт уята. Ул үзе скрипкада, мандолинада, гармунда һәм башка уен коралларында үзлегеннән өйрәнеп шактый оста уйнаган.

Соңыннан Каюм Абдулла улы үзенең бер автобиографик белешмәсендә шундый беренче «дәресләре» турында: «12 яшемдә күрше йортта яшәүче бер студент-һәвәскәр музыканттан дәресләр ала башладым. Бу дәрес минем хәтеремдә скрипкада ничек итеп уйнарга ярамый дигән дәрәҗәдә калган»,— дип яза.

Каюм үз максатына ирешү өчен төрле мөмкинлекләр эзли. Аның бәхетенә 1922 елда Ташкентка Петербург консерваториясенең атаклы профессоры Л. С. Ауэр шәкерте, талантлы һәм танылган скрипкачы А. Н. Берлин эшкә килә. Каюм аңардан скрипка буенча дәресләр ала башлый. Дәрес хакын түләү өчен төрле эшләр башкарып акча табарга туры килсә дә, яшүсмер егет А. Берлин «классында» укуына чиксез шатлана. Аның беренче мәртәбә төпле музыкаль белем ала башлавы нәкъ менә шушы чорга туры килә.

1923 елда А. Н. Берлин Мәскәүгә китә. Каюмның чиксез сәләтле, тырыш булуын күреп, киләчәктә яхшы скрипкачы булачагына нык ышанып, ул аңа музыка техникумында укырга киңәш бирә. Каюм Байбуров бу тәкъдимне шатланып кабул итә һәм остазы артыннан Мәскәүгә китә. Биредә ул бертуган Рубинштейннар исемендәге музыкаль техникумга, А. Н. Берлин классына укырга керә.

Техникумны бишле билгеләренә генә тәмамлап Каюм Байбуров Мәскәү дәүләт консерваториясенә, Л. С. Ауэрның икенче шәкерте, танылган скрипкачы Л. М. Цейтлин классына укырга керә. Консерваторияне уңышлы тәмамлагач, аңа консерваториядә аспирантурага калырга тәкъдим ителә. Аспирантура программасын да уңышлы үзләштереп, Каюм Байбуров югары белемле профессиональ музыкант булып җитлегә.

Уку елларында Каюм Байбуров исеме һәрвакыт макталып телгә алына. Ул иң алдынгы студентлардан санала. Аның тырышлыгы, әлгер булуы, белемгә омтылышы, әледән-әле ирешкән уңышлары күпләр өчен үрнәк була. Консерваториядә укыганда студентлар, аспирантлар кичәләрендә актив катнаша. Шул ук вакытта параллель рәвештә консерватория каршындагы музыка мәктәбендә һәм музыка училищесында укыта, җәмәгать эшләрендә актив катнаша, Мәскәүнең театр, музыка уку йортларында белем алучы татар-башкорт яшьләренең якын дусты, ярдәмчесе һәм киңәшчесе була. Мәскәү консерваториясенең Зур залында татар опера студиясе укучылары белән берлектә ясаган бер чыгышын тыңлагач, Фәтхи Бурнаш Каюм Байбуровның скрипкада татар композиторлары әсәрләрен башкаруына югары бәя бирә. Каюм Байбуров репертуарында татар композиторлары белән бергә рус, чит ил классикларының әсәрләре дә күп булуы, ягъни стильләр, чорлар төрлелеге, аның замандашларының әйтүенә караганда, күпләр өчен ирешә алмаслык үрнәк була. Мәсәлән, СССРның халык артисты, атаклы совет дирижеры Е. Э. Хайкин җитәкчелегендәге симфоник оркестрга кушылып скрипка өчен катлаулы әсәр дип саналган Брамс концертын зур уңыш белән башкарып чыгуы музыкантның искиткеч сәләтле, уйнау техникасының бик югары дәрәҗәдә булуы турында сөйли.

Никадәр генә оста башкаручы булмасын, Каюм Байбуров укытучылык хезмәтен һәрвакытта да беренче планга куя. Чөнки аның педагоглык сәләте зур була. Бу хакта Татарстанның атказанган артисткасы, халыкара конкурслар лауреаты, Мәскәү дәүләт консерваториясе доценты Зариус Шихморзаева: «Каюм Абдуллович 1973 нче елга кадәр укытты. Ул педагог буларак чын мәгънәсендә сихри көчкә ия иде»,— дип сөйли. К. Байбуров классында укып чыккан скрипкачылар Мәскәү, Ленинград театрларында, филармонияләрендә, шул исәптән СССР Зур театрының скрипкачылар ансамблендә, СССР Дәүләт симфоник оркестрында, Үзәк телевидение һәм Бөтенсоюз радиосының симфоник оркестрында һәм башка бик күп коллективларда уңышлы эшли. Ул укыткан күп кенә музыкантлар халыкара конкурсларда лауреат исемен яулап алды (мәсәлән, З. Шихморзаева, А. Киселев, А. Аренков, Я. Бородицкий, Ф. Дружинин һәм башкалар). «Каюм Абдуловичның педагог буларак тагын бер үзенчәлекле ягы турында әйтәсе килә,— дип искә алалар аның шәкертләре. — Скрипкада уйнау ысулларын дәрес үзләштермәүләре аркасында «өметсез» дип табылган студентларны аңа «төзәтергә» биргәч ул алардан беренче класслы музыкант «ясый» иде. Соңыннан шушы «өметсез» студентлар арасыннан да халыкара конкурслар лауреатлары килеп чыкты».

Каюм Байбуров эшчәнлеге белән Казан тамашачылары да яхшы таныш. Беренче




мәртәбә ул Казанга 1940 елда Татарстанның 15 еллыгын бәйрәм итү тантанасында катнашу өчен чакырыла. Ә 1941 елда К. Байбуров Мәскәүдә үткәреләчәк татар әдәбияты һәм сәнгате декадасына әзерлек эшләрендә ярдәм итү өчен РСФСР халык комиссарлары Советы каршындагы сәнгать эшләре комитеты тарафыннан тагын Казанга җибәрелә. «Мин Казанга килгәндә татар дәүләт опера һәм балет театры сәхнәсендә Н. Җиһановның «Алтынчәч» операсын куюга өстендә кызу темплар белән, рухланып эшлиләр иде. Миңа оркестрда концертмейстер булып эшләргә туры килде»,— дип искә ала ул көннәрне К. Байбуров. Сугыш башлангач, ул Казанда кала, театрда эшли, Казан музыка училищесында, 1 нче музыка мәктәбендә укыта башлый. Шуның белән бергә Казан радиостудиясендә һәм ансамбльләрдә уйный. Актив эшчәнлеге, хәрби частьләрдә, госпитальләрдә ясаган чыгышлары өчен культура работниклары профсоюзының Татарстан өлкә комитеты К. Байбуровны Почет грамотасы белән бүләкли.

1943 елда Мәскәү консерваториясе аны яңадан чакыртып ала. К. Байбуров музыка училищесында, Үзәк музыка мәктәбендә эшләвен дәвам иттерә.

Бу олы музыкант һәм педагог турында Зариус Шихмөрзаева истәлекләреннән тагын шундый юлларны китерик: «1941 елда безнең гаилә Казанга күчеп килгәч, мин 1 нче музыка мәктәбенә Каюм Абдуллович классына укырга кердем. Ул Казаннан киткәч, мин дә Мәскәүгә китеп Үзәк музыка мәктәбендә Байбуров классында белем алуымны дәвам иттем. Беренче көннәрдән үк ул минем укытучым-остазым булды, әтием кебек якын кешегә әверелде. Каюм Абдуллович искиткеч яхшы педагог, виртуоз скрипкачы, югары культуралы музыкант иде. Аның скрипкада уйнавын һәрвакыт сокланып һәм таң калып тыңладык. Гаҗәеп матур тавыш, саф интонация белән ачык һәм бик төгәл итеп уйный— аның уйнавына йөрәккә үтеп керерлек табигыйлык хас иде. Нинди генә сәләткә ия булуларына карамастан, ул үзенең укучылары алдына да нәкъ шундый таләпләрне куйды, үзеннән да яхшырак уйнарга өйрәтергә тырышты».

Каюм Байбуров гыйльми эшләр белән дә шөгыльләнә: методик әсбаплар яза, скрипкада уйнау өчен әерым әсәрләрне зур уңыш белән эшкәртә һ. б. Скрипкада уйнау өчен төзегән уку программалары, фәнни конференцияләрдә ясаган докладлары аның күпкырлы иҗат кешесе булуы турында сөйли.

Мәскәү дәүләт консерваториясе доценты РСФСРның атказанган культура работнигы Каюм Байбуров — Октябрь революциясе ярдәмендә махсус югары белем алган беренче татар скрипкачысы гына түгел, ул татар профессиональ башкаручылык сәнгатенә нигез салышкан музыкантларыбызның да берсе. Инде дөньядан киткән бу тирән эрудицияле, шәһрәтле музыкант һәм педагог исемен музыкаль җәмәгатьчелек, Мәскәү консерваториясе һәм башка музыкаль уку йортлары коллективлары һәрвакыт олы ихтирам белән телгә алалар.

**РАФАЭЛЬ ИЛЬЯСОВ.**

Самат Шакир

# КЫЗЫЛ ЧӘЧӘКЛӘР ҮСӘР...

Көчле җилдә наратлар шаулый. Күк йөзе болытлы. Күңелсез салкын көннәр. Немецлар белән каты бәрелештән соң ялга утырган сугышчылар туган-үскән якларын искә алалар, кардәш-туганнарыннан, дус-ишләрдән һәм кызлардан килгән хатларны укыйлар. Шундый чакларда күңел нечкәрүчән була. Кечкенә генә бер истәлек тә сине хисләндерә, сагышландыра.

Кичә генә бу урыннарны немец итекләре таптаган иде. Алар халыкка күпме бәла-каза, афәт, үлем китергәннәр. Әнә якында гына бер авыл күренә. Хәер, нинди авыл инде ул? Кайчандыр шау-гөр килеп торган урамнар урынында корымлы таш өемнәре һәм кисәүләр генә өелеп тора.

Сугышчыларның берсе шул күренешкә озак кына текәлеп тора да, йөрәге сыкрауга түзә алмый, теш арасыннан «их, егетләр!» дип куя.

Азербайҗан егете Ибраһимов аңа ягымлы карап сорау бирә:

— Әй, дус кеше, син Уралдан бит әле? — ди.— Бала вакытта минем Уралда булганым бар. Аның зур-зур морҗалы заводлары, таш кыялы таулары мине гаҗәпкә калдырган иде. Легендар Урал бит ул!

«Урал» дигән сүзне ишеткәч, аның дус кешесе тагын да җанлана төшә. Кесәсеннән таушалып беткән кечкенә блокнот чыгарып укый башлый:

Мин Уралда тудым, шунда үстем,
Елгасыннан барып су эчтем.
Бакчасыннан җимешләрен өздем,
Сандугачлар тавышын ишеттем.

Бу шигырь күңелләрне тагын да рухландырып җибәрә. Еракта калган нигезне, әти-әниләрне искә төшерә.

— Шәп соң синең бу шигырең,— ди Ибраһимов — миңа да берәр шигырь язып бир әле. Истәлегең итеп саклармын.

Дусты каскасын күтәребрәк куя һәм күзләрендә шатлык очкыннары балкытып:

— Мин кече яшьтән үк җыр, шигырь чыгарырга яратам. Менә бирадә дә шигырь язуым дәвам итәлә. Якын дуска иң яхшы теләкләремне язармын,— дип вәгъдә бирә.

Кара-кучкыл болытлар арасыннан фашист самолетлары күренә. Бер үк вакытта немец танклары да ата-ата безнең окопларга якынлаша башлый. Һәм безнекеләр дә һөҗүмгә күтәрелә. Металлга металл бәрелеп чыңлый. Дошман окоплары өстендә ут өермәсе уйный башлый... Көтмәгәндә сул яктан килеп чыккан немец танкысына каршы көмдер граната тотып шуыша. Тиздән көчле шартлау яңгырый, танкка дөрләп ут каба. Аннары ярсу атака. Үз сугышчыларын һөҗүмгә алып баручы Урал егете яраланып ава... Аннары яңадан аягына басып автоматтан ата-ата алга ыргыла. Дошман пулясы аны икенче мәртәбә яралый. Соңгы сулышын алганда:

— Уралыма хат языгыз, мине онытмасыннар. Илемә тугрылыклы булып үләм...— дип васыятен пышылдый...

Соңыннан аның гимнастерка кесәсеннән чыккан кечкенә фоторәсемгә карап сугышчылар уйга калалар. Кыр сумкасындагы дәфтәреннән һәм «Урал мәхәббәте» дигән китабыннан шигырьләрен укыганда сугышчыларның күзеннән яшь чыга. Соңгы саубуллашу сүзләрен Ибраһимов, башын түбән иеп, әйтә:

— Тыныч йокла, нечкә хисле баһадир дустым! Син миңа да шигырь язарга вәгъдә иткән идең... Боларны без кулдан-кулга йөртеп укырбыз.

Урал егете — яшь шагыйрь Макс Гатау иде ул.

М. Гатауның беренче шигыре 1933 елда басылып чыга. Шуннан соң ул көндәлек матбугат битләрендә әледән-әле катнашып килә. Аның иҗаты үз укучыларын таба.

Макс Гатау (Гайнетдин Зәйнетдин улы Гатауллин) 1913 елны Курган өлкәсенең Әлмән районы, Тозау авылында туа. Яшьтән ятим калып, ят кулларда йөреп үсә. Октябрь революциясе җиңгәч, балалар йортында тәрбияләнә, алдынгы укучыларның берсе була. Биредә аны пионерга кабул итәләр. Беренче мәртәбә кызыл галстук тагып туган авылына кунакка кайткач, авыл кулаклары, куштаннар бу кыю малайның артыннан көлеп калалар:

— Ай, ходаем, кем соң ул борынын чөеп йөри дисәм, Гайнук икән. Үләрсең килешенә, хи-хи-хи!..

«Гайнук» тә югалып калмый:

— Ыштан балакларын читек кунычыннан чыгарып кем куштанланып йөри дисәм, кулак Җамали икән,— дип, әче сүзләр белән тегенең авызын томалый.

Балалар йортында биш ел тәрбияләнгәннән соң ул яңадан туган авылына кайта. Хәзер Гайнетдин өстенә өр-яңа комсомол костюмы «юнгштурм» кигән, күкрәгендә «КИМ» значогы. Ул бу елларда авылда кулакларга каршы актив эш алып бара. Аннары, Чиләбе өлкәсендә авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлап, балалар йорты директоры булып эшли. Шул чорда шигырьләр яза башлый. «Ленин юлыннан» дигән стена газетасында аның дүрт кенә юллы беренче шигыре урнаштырыла. Озак та үтми, ул «Гармонь» дигән шигырь яза. Һәм анысы инде район газетасында ук басылып чыга. Шуннан башлап төннәр буе йокламыйча иҗат газабы кичерүләр... Билгеле, бөтенесе ал да гөл булып чыкмый... Коры юллар, яки берәр шагыйрьне кабатлаулар да була. Бер вакытны аңа редакциядән күңелсез җавап та килә. «Сез өзер сукмактан барасыз. Җиңел юл бу. Алай җиңел юл белән генә шагыйрь булып булмый. Шагыйрь булу өчен бик күп эзләнергә, бик күп укырга, тормышны өйрәнергә кирәк». Иҗат газабы белән янган төннәрдә бөтен язганнарын утка ыргытып, шигырь язудан туктарга исәпләгән чаклары да була егетнең, ләкин хыялый дәртле йөрәк һаман үзенекен итә, чигенмәскә, әйтелмәгән фикерләрне йөрәккә уелырлык итеп язарга өнди. Яшь шагыйрь Казан белән элемтә тота башлый. Тиздән аңа шатлыклы хәбәр килә: иң яхшы дигән шигырьләрен өлкә газетасында басарга булганнар!

Макс Гатау Казан дәүләт педагогия институтында читтән торып укыган елларда институтның әдәби түгәрәге бик яхшы эшләгән. Анда Баян Гыйззәт, Нур Гайсин, Мөхәммәт Әхмәтгалиев, Исмәгыйль Шәфиев, Таһир Сәйфиләр актив катнашканнар. Муса Җәлил, Нур Баян, Шәриф Камал һәм Ибраһим Газины чакырып институтта әдәби кичәләр үткәрелгән. Яшьләрнең шигырьләре түгәрәкнең стена газетасына урнаштырыла.

Макс Гатау шагыйрь Әхмәт Юныс белән дус була, алар бергәләп төзелешләргә баралар, яңа язган әсәрләрен бер-берсенә укыйлар, киңәшләшәләр. Макс Гатауның беренче китабының редакторы да Әхмәт Юныс була.

М. Гатау халык иҗатын кызыксынып өйрәнә. Ул тарихи урыннарда йөри, картлардан һәм карчыклардан борынгы истәлекләр, әкиятләр, бәетләр сөйләтеп һәм аларны бик җентекләп язып ала. Шулай ук музыканы да бик яраткан ул, үзе дә борынгы татар халык көйләрен яхшы җырлаган.

Уралның бай табигате, рудага бай таулары, яңа заводлары һәм домналары яшь шагыйрьне шигырьләр язарга рухландырган. Аның 1939 елны басылып чыккан «Урал мәхәббәте» дигән беренче китабына 18 шигырь һәм өч җыр тупланган. Исеменнән үк күренеп торганча, җыентыкның үзәгендә — Уралдагы төзелешләр турында язылган шигырьләр бәйләме.

**Меналмадык без бу тауларга,**
**Эчалмадык чишмә суларын,**
**Канатсызлар булып яшәдек без,**
**Төрмәсендә авыр елларның.**

**Мин хәтерлим Урал даласында**
**Яңгыраган курай моңнарын.**
**Истә әле күз яшьләрен түгеп**
**Ташлар ваткан эшче уллары.**

Менә шундый аһ-зарлар эчендә яшәгән халыклар кан эчүче патшаны һәм аның министрларын бәреп төшерәләр, ирекле, шатлыклы тормыш төзиләр. Яшь шагыйрь яңа Уралга һәм андагы эшчеләргә дан җырлый:

**Җил улаган Магнит кырларында**
**Гөрли хәзер биек домналар.**
**Чорыбызның батыр кешеләре**
**Җырлый-җырлый металл коялар.**

1938 елны язылган һәм «Азат хатын» журналында басылган поэма характерындагы «Урал истәлеге» шигыре форма үзенчәлеге белән аерылып тора. Яшьләр шаугәр килеп көймәдә йөзәләр. Яр буенда үскән агачлар яфракларын җилпеп, башларын иеп озатып кала. Нинди матур кич! Һәркем бу гүзәл күренешкә соклана. Ә менә Нәҗия, ни өчендер, бик боек. Нәрсә уйлый соң ул?

**Шат Нәҗия нишләп кинәт тынды!**
**Дулкыннардан алмый күзләрен.**
**Күзлиме ул әллә ай нурында**
**Су төбендә балык йөзгәнен!**

**Хәзер генә көмеш сәгатен ул**
**Төшердеме әллә кулыннан!**
**Түгел, түгел!**
**Менә ул уйлады**
**Әтисенең кабере турында.,**

Нәҗиянең әтисен Колчак бандитлары кулга алганнар һәм унбиш кызылармеец белән бергә кораллы сак астында атарга алып киткәннәр. Нәҗиянең әнисе Зифа үлемгә хөкем ителүчеләр сафында иң алдан атлап баручы ирен тәрәзә аркылы күрә һәм коштай атылып аның янына йөгерә.

— Хәйдәр, бәгърем! — дип кочып алырга да өлгерми, аны кораллы сакчылар кочагыннан өстерәп алып, урам ташына ыргыталар. Ләкин ана каушап калмый. Ул ачулы һәм ярсулы хәлдә: «Көпә-көндез кеше суючылар!» дип сакчының битенә төкерә. Ак бандитлар тоткыннарны халык алдында аталар. Бу канлы фаҗига нәни Нәҗияне тетрәтә... Менә хәзер инде ул зур үскән. Студент иптәшләре белән көймәдә йөрергә чыккан һәм әнә шул еракта калган авыр елларның кайгылы күренешләре аның күз алдына килә. Су өстенә зәңгәр күктән якты ай нурлары коела. Ә яшьләр җырлый-җырлый, бүгенге шат тормыш бирүчеләрне искә алып, көмеш кебек дулкыннар арасыннан берсен-берсе куышып узалар.

Совет Армиясенә алыну иң зур бәхет! Яшьләр бу көнне түземсезлек белән көтеп ала. Менә шушы турыда М. Гатау «Нык саклармын илем чикләрен» дигән шигырь яза. Анда мондый юллар бар:

**Әнкәем дә сөенеп каршы алды,**
**Күз нурыдай күргән баласын.**
**Һәм әйтте ул:**
**— Бик зур бәхет, улым!**
**Кызыл Армиягә барасың!**

Авылның табигате, аның эшчән кешеләре турында да яшь шагыйрь дулкынланып яза. Менә шат күңелле, кара күзле, озын чәчле колхозчы кыз Гөлшат. Ул эштән соң ял итәргә клубка килгән. Ул зур һәм якты зал уртасында иптәшләре белән бии, уйный-көлә, бәхетле яшьлеге өчен куана.

Ике гомер — ике яшьлек. М. Гатау моны «Ике яшьлек турында» дигән шигырендә сүзләр белән тулы сурәтли. Яшьлеге авыр заманнарда үткән Галим бабай бакчадагы гөлләргә карап уйга калган. Шат яшьләр аның янынннан сөйләшә-сөйләшә узалар. Ә Галим бабай кулы белән көрәктәй сакалын сыпырып, үткәннәрне — шушы ирекле тормышны яулап алу өчен көрәштә батырларча һәлак булган кешеләр турында уйлый.

М. Гатауның язган шигырьләре байтак булып, ул аларның күбесен матбугатта чыгармаган. Шундыйлардан Павлик Морозов турындагы поэмасы, татар әдәбиятында кыю пионер турында беренче поэмадан өзек, 1940 елны «Пионер каләме» журналында басылган. Анда шагыйрь табигать күренешләрен шактый оста тасвирлый.

Иртәнге җил исеп зәңгәр күлнең
Өсләрендә дулкын уйната.
Һәм төн була, менә ул күл тына,
Күңелләрдә хисләр уята.

Павлик Морозовның кулаклар тарафыннан ерткычларча үтерелүен тетрәнеп укыйсың. Канлы җинаятьчеләрне атарга хөкем итәләр. Яшь батырга һәйкәл салына. Пионерлар аны искә алып һәр яз саен чәчәк бәйләмнәре куялар.

М. Гатауның «Тау ташкыннары» исемле икенче җыентыгы да басылып чыгу өчен әзерләнгән булган, ләкин сугыш башланып китү аркасында чыкмый кала. «Павлик Морозов»та шунда кертелгән була. Кызганычка каршы, аның кулъязмасы сакланмаган. Яшь шагыйрь рус поэзиясеннән һәм Тукайдан, Такташтан бик күп өйрәнгән. Ул үз әсәрләренә таләпчән булган, шигырьләрен кабат-кабат эшләгән.

1938 елда язган «Посттагы уйлар» дигән шигырендә ул изге чигебезне бозып дошманнар сугыш ачсалар, аларга отпор бирeләчәген катгый белдерә:

Әгәр чиктә туплар яңгырасалар,
Ул илләрнең чиген буйларбыз.
Аямабыз — дошман каян чыкса,
Үз җирендә тотып кыйнарбыз!

Фашистларга каршы изге көрәш башлангач, М. Гатау да кулына корал алып алгы сафка басты. Батырлыгын һәм сәләтен күреп, сугыш кырында аңа кече командир дәрәҗәсе бирәләр.

1941 елның 20 ноябрендә Калинин өлкәсе, Гаврилово авылы янында барган каты сугышларның берсендә солдат һәм шагыйрь Макс Гатау һәлак була. Аның куен кесәсеннән табылган блокнотыннан көрәштәшләре түбәндәге сүзләрне укыйлар:

«Мин Уралым, Ватаным өчен сугыштым. Ә кем белә, бәлки мин үләрмен... Ләкин безнең кайнар каннарыбыз түгелгән урында кызыл чәчәкләр үсәр. Безнең кайнар йөрәкләребез суынмас...»

Риф Мөхәммәтҗанов

# КОЯШ БЕЛӘН АЙ МИКӘН...

Халкыбызның авыз иҗатында туй поэзиясе зур урын алып тора. Жанр составы ягыннан бу мирас шактый катлаулы һәм үзенчәлекле. Башкортстанның Ык буе регионында безгә, мәсәлән, туй циклы поэзиясенә караган дистәдән артык жанр белән очрашырга туры килде.

Шулардан аеруча игътибарга лаеклы түбәндәге жанрларны күрсәтергә мөмкин: 1. **Җырлар** (гадәти туй җырлары). 2. **Сыктаулар,** ягъни кыз елатулар. Башкортларда сеңләүләр, каракалпакларда сыңсулар һ. б. 3. **Таңкучатлар.** Таң әтәчләре кычкырганда, ярәшелгән кызның ахирәтләре белән берлектә хушлашу, үпкә белдерү җырлары. 4. **Шәмчыраклар** — кияү егетләренең кыз йортына кияүне алып килгәндәге җырлары. Гадәттә кияү ике яктан факеллар яндырып барган егетләр уртасында килә. Таңкучатлар нигездә керәшеннәрдә очраса, шәмчыраклар мишәрләрдә, шулай ук типтәр кебек этник төркемнәр арасында очрый. 5. **Самаклар** — яучы такмазалары. 6. **Яр-ярлар.** Күп кенә төрки халыкларда очрый: каракалпакларда — **хау-жар,** үзбәкләрдә — **яр-яр,** казакъларда — жар-жар, ногайларда — **хей-жәр,** һ. б. 7. **Баглаулар** — күпчелек урыннарда бирнә җырлары исемендә билгеле, башкорт халкының **йыусаларына** да якын тора. 8.**Типсоүләр** — кияү егетләренең килен төшергән вакыттагы юл җырлары. Пенза мишәрләре **вәдәкләр** дип атый. 9. **Арбаулар.** Кияүгә кияү арбаулар, киленгә килен арбаулар әйтелә. Борынгы магиячелеккә бәйле иҗат. 10. **Әйтешләр.** Шулай ук төрки халыкларының күбесендә очрый: казакъларда — **айтыс,** кыргызларда — **айтыш** һ. б. Кара-каршы әйтешүгә корылган бу иҗат туй циклында зур гына урын тота: кияү егетләре белән кыз ахирәтләре, кодалар белән җиңгәләр һ. б. арасында бара. 11. **Бит ачулар.** — яңа төшкән киленгә киңәш-теләк; кияү, каената, каенана, каениш, каенсеңле һ. б. алдында киленгә үзен ничек тотарга тиешлеге хакында традицион шигъри күрсәтмә. 12. **Кияү ябулар** — зөфаф кичендәге җиңгә сүзләре. Болардан тыш **мактаулар, хурлаулар, баталар** һ. б. шуның кебек поэтик төрләрне күрсәтергә булыр иде. Бу гаҗәеп бай материал борынгы туй йолаларын, шулай ук халык җырларының эчтәлеген, табигатен, шигърият белән йолалар арасындагы бәйләнешләрне өйрәнүдә кыйммәтле чыганак була ала.

Татар халкының туй поэзиясе борынгы кыз урлауларга һәм сату-алу никахына (яучылауга) корылган йолаларны да күз алдында бастырырга ярдәм итә. Мәсәлән, борынгы яучылау формулаларында сакланып калган берничә символик образга мөрәҗәгать итик:

Синдә дә бар аклы куй,
Миндә дә бар аклы куй.
Куйны куйга кушыек,
Безнең җакка җушыек.

Аклы куй биредә яшь кыз белән яшь егет образларын символлаштыра. Бу образлар халык ышанулары, магиячелек белән бәйле. Янәсе, усал, явыз көчләр сүзнең ни турында барганын белмәсәләр зыян итә алмый калалар: укларын аклы куйларга юнәлтәләр. Яучы килеп киткәннән соң, кызны ярәшү хакында да җиңгә болай дип хәбәр итә торган була: «без куй башы еттек әле». Кыз шуннан соң гына үзенең ярәшелгәнлеген белән. Яулап алу мәгънәсе яучы сүзенең дә төбендә ята. Ул үзен көчле итеп күрсәтергә тырыша:

Каеш баулы лачыным бар,
Былбылыңа килгәнмен.
Син тимер булсаң, мин — күмер,
Эретергә килгәнмен.

Былбыл — яшь кыз, каеш баулы лачын — шул былбылга күзе төшкән егет, кызның ата-анасы тимер булса да карышудан мәгънә юк: яучы барыбер күңелләрен эретәчәк. Шулай ук туй поэзиясендә еш кына очрый торган «аягы бәйләнгән тутый кош», «тозакка төшкән былбыл яки кәккүк», «шоңкар яки бөркет тырнагына эләккән бүдәнә, күгәрчен», һ. б. шундый символлар бары тик борынгы йолачылык (бу очракта кыз урлау, кызны яулап алу) нигезендә генә аңлатырга мөмкин.

Сату-алу никахына корылган туй йолаларыннан калган образлар да аз очрамый. Шул ук яучы самагында, мәсәлән, «Сездә товар, бездә сәүдәгәр», яки: «Сездә ак мал, бездә купец» кебек гыйбарәләр очрый.

Товар, ак мал — яшь кыз, сәүдәгәр яки купец — егет икәнлеге яхшы аңлашыла. Кайбер очракта исә поэтик образны белми торып, җырның чын мәгънәсен аңлавы авыр. Мәсәлән, таңкучаттан бер өзек алыйк:

**Әтекәем киткән сунарга,**
**Төлке аяккаен тунарга.**
**Тор, әтекәй, тор күрешә килдем,**
**Бер сумлык тәңкә сорарга.**

Кыз бу җырны никах иртәсендә, таң әтәчләре кычкырганда әтисе йоклап яткан тәрәзә каршысына килеп җырлый. Йола буенча, бу вакытта ата кеше тәрәзә ачып кызына тәңкә бирергә тиеш. Әгәр шулай аның күңелен күрмәсә, сатылган кызның жаны тынмый, соңыннан өрәккә әйләнеп, үч алуы да ихтимал дип уйланылган. Әлеге җырда әнә шул йола чагылыш таба. Дөресрәге, биредә йола үзгәрү яки төшеп калу аркасында аерым традицион элементларның поэтик образлар сыйфатында гына яшәүгә күчүе күренә. Мәсәлән, безнең кулда Башкортстанның Бакалы районында язып алынган ике кияү ябу җыры саклана. Сүз уңаенда шуны да әйтеп китик: кияү ябу йоласы билгеле булса да, аңа мөнәсәбәтле сүзләр хәзергәчә беркайда да очраганы юк иде. Шуларның берсендә болай диелә:

**Кыз күрми — бил чишелми,**
**Су күрми — итек чишелми,**
**Кыз келәте ишелми,**
**Юкка коймак тишелми.**

**Алаша кибәннән өрекмәс,**
**Кыз кияүдән курыкмас,**
**Икәү булып ятыгыз,**
**Өчәү булып басыгыз!**

Бу сүзләр — феодализм чорындагы татар крестьянына хас этик һәм эстетик идеалларының үзенчәлекле көзгесе дияргә мөмкин. Чынлап та, йола буенча кыз куенына керер алдыннан кияү тун өстеннән кара билбау буып алган, аның очын бик нык яшереп, чуалтып ураган. Кыз шуны тиз генә чишә алмаса, иң зур хурлык саналган. Аяк салдыру, егетнең аягын юу шулай ук кызга йөкләтелгән. Кияү ябу сүзләрендә, күрәсең, шуларга ишарә ясала. «Юкка коймак тишелми» диюдә дә кияү коймагы белән бәйле, бер мәгънә ята. Зөфаф төненнән соң, иртә таңда, мунча кереп чыккач, кияү егетләре кыз келәтенә җыела. Төп йортның килене булса — килен (җиңгә) исеменнән, җиткән кызлары булса, шул кыз исеменнән ишек аша коймак бирелә. Әгәр кәләш үзен гыйффәтсез тоткан булса, кияү әлеге коймакны нәкъ уртасына пәке кадап чыгарган, нәтиҗәдә туй таркалган, кызның язмышы еш кына бик аяныч тәмамланган. Димәк, йола үзе онытылганнан соң да әле ритуал элементлары шигъри детальләр рәвешендә яшәвен дәвам итә.

Туй поэзиясендә, батыр, кыю егет образы еш кына идеаллаштырып бирелә. Дөрес, кайвакыт аңа ачы сүзләр дә ишетергә туры килә:

**Безнең кияүнең капкасы.**
**Нарат икән аркасы.**
**Нарат булмый ни булсын,**
**Талап җыйган акчасы.**

Кәләш еш кына үтә чибәр, уңган итеп тасвирлана. Ул әнкәсенең берданбере, бакчадагы гөлгә, болында үскән хуш исле чәчәк һ. б. шундый образларга тиңләнә, «ханкызы» дип зурлана.

Бу үзенчәлек әйтешләрдә дә саклана. Туй драмасы вакытында, кияү егетләре ишек бавын сатып алганнан соң, ишек аркылы кияү белән кәләшнең әйтешләре башланган.

Мондый әйтешләр, йоланың төп мәгънәсе югала төшкәч, бары поэтик туй уенына, шаяруга әйләнә. Шәмчыраклар һәм типсәүләр кебек поэтик текстлар да шул юк хәлгә юлыга. Ярмәкәй районы, Усман-Ташлы авылында Дәүләтгәрәй Гәрәевтән язып алынган типсәүнең бер өзегенә игътибар итик:

**Ил асылы — егеттә, бум-бум.**
**Ир асылы — кибиттә, бум-бум.**
**Бөтен дөнья таң калсын, бум-бум.**
**Җыр-типсәүдәр таралсын, бум-бум!**
**Шоңкар кошның кулына, бум-бум,**
**Былбыл кунган юлында, бум-бум.**
**Кояш белән ай микән, бум-бум,**
**Күз чагыла нурына, бум-бум.**

Биредә поэтик образлар үстерелә, бер строфадан икенче строфага җәелдерелә. Кыз — ил асылы, егет — ир асылы, икесе дә кибиттә (ягъни кибиткәдә) бара. Кияү егетләре аларга җыр-типсәү җырлый, ахырда ике яшь күңел кояш белән айга охшатыла. Шул рәвешчә, шигъри образлар, лирик төзелеш, лирик аһәң-көй типсәүләрне йола тематикасы белән генә чикләми, бәлки күпмедер дәрәҗәдә ирекле, мөстәкыйль яшәешлегә әверелдерә.

Ә менә сыктаулар кәләшнең бөтен эчке дөньясын, аның ачы, аянычлы язмышын, өметләрен һәм шикләрен, психологик кичерешләрен барча тулылыгы белән ачып сала. Гомумән, сыктауларда чынбарлык, кем сыктауга карап, төрлечә бирелә. Мәсәлән бер очракта кияү йорты сарайга тиңләнә, икенче карасаң, ул бөкресе чыккан тавык кетәгә диелә. Бу яктан бигрәк тә кызның ата йортыннан киткәндәге сыктаулары характерлы. Яшь хатын үзенең мал урынына сатылганына көенә, ире йортындагы киләчәк тормыш өчен кайгыра. Аны барыннан да элек каенанасы борчый:

**Чылтыр да чылтыр чын чынаяк,**
**Чылтыратмый ничек юармын.**
**Каенанага ярау авыр диләр,**
**Каенанама ничек ярармын!!.**

Өстәвенә, ул инде каенанасы белән таныш, күңелендә начар фикер дә туган:

**Арьякта да саз башы,**
**Бирьякта да саз башы.**
**Шунда торган бианамның**
**Аждаһа тел, таз башы.**

Шуңа күрә үзен алдап-кодалап йөргән яучыга кызның нәфрәте аерата көчле:

**Алда киткән аткаемның**
**Эшлиясе яшел чук.**
**Яучы булган Гарифҗанны,**
**Ходаем, берүк яшен сук,**

— дип аны каргый, әтисенә дә өлеш чыгара:

**Ата кәккүк баласын,**
**Атма, әткәй, алам дип.**
**Әткәй үзең ятка саттың,**
**Әйтмә миңа «балам» дип.**

Сыктауларда да күрәсең, таныш образлар, йола белән бәйле мотивлар урын ала: каенана еш кына кире сыйфатларга төрелә, ата-анага үпкә, шелтә яңгырый.

Бит ачу һәм яр-яр йолаларына бәйле иҗат та символик образларга бай. Кызның толымын икегә ярып үрү, шул вакытта яр-яр әйтү — бу инде кияүгә бирелү символы. Ярәшелгәннән соң кыз бөркәнчек яки яулык ябынып йөрергә тиеш. Яулык бөркәндерү — шулай ук кияүгә бирелүне аңлаткан. Символик образ сыйфатында ул кызның сыктауларына да үтеп керә:

**Атыңа печән сал, җиңгә,**
**Авызлыгын ал, җиңгә.**
**Башыма яулык япканчы,**
**Татлы җаным ал, җиңгә.**

Әлеге сыктауларның мәгънәсен аңлау өчен турыдан-туры йола ритуалларына мөрәҗәгать итәргә туры килә. Бу бөркәнчекне яки яулыкны бары тик кияүнең энесе (каениш) кенә ача, салдыра ала торган була. Соңрак туган туй поэзиясендә мондый символик образлар йолачылыктан аерылып чыга, шартлы яки гиперболик төс ала.

Кыскасы, туй йоласы поэзиясенең барлык жанрлары да бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә туа һәм үсеш кичерә, йоладан һәм практик кулланылыштан аерылгысыз рәвештә яши. Соңгы үсеш баскычында туй поэзиясе беренчел яшәеш чикләреннән чыга, халыкның классик җырлары дәрәҗәсенә күтәрелә һәм гаҗәп үзенчәлекле рухи байлыгыбызга әверелә. Йолачылыкка бәйле рәвештә туган образлар да үзләренең төп мәгънәсен югалтып, мөстәкыйль шигъри символлар рәвешендә яши башлый.

## Мансур Шиһапов

# ҖАНЛЫ КУРЧАКЛАР

ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ
ТАРИХИ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

*Әгәр дә җансыз курчаклар миллионлаган тамашачыны җылыта, бөтен дөнья сәнгатенә төшкән йөкне күтәрә алмаган булса, мин курчак сәнгате белән шөгыльләнмәгән булыр идем.*

С. Образцов, ССРның халык артисты

Театр сәнгатенең, Г. Тукай сүзләре белән әйткәндә, «халыкка дәрсе гыйбрәттер» булуы һәм аның халыкны, яшь буынны идея-эстетик тәрбияләүдәге мөмкинлекләре Совет дәүләтенең беренче көннәреннән үк югары бәяләнде. Шул җөмләдән балалар өчен дә профессиональ театрлар оештырыла башлый һәм алар, сәнгатьне педагогиягә якынайтып, мәктәп белән бергәләп балаларга үзенчәлекле тәрбия бирергә керешәләр.

Курчак театры бала күңелендә бөреләнеп килгән үз-үзен аңлыйсы, үз-үзен раслыйсы килү тойгысына тиешле юнәлеш бирә. Балачак, Л. Толстой язганча, кеше аңында җуелмас эз, хис буразнасы сызып калдыра, шуңа күрә курчак театры баланың күңеле ни дәрәҗәдә үсенә ярдәм итәргә, «бөтен кешелекне төзәтергә, кешеләрнең ялгышлыкларын һәм бәхетсезлекләрен бетерергә... үз-үзен төзәтергә, бөтен яхшылыкларны кабул итәргә» омтылган хыялларына җавап һәм юнәлеш бирергә тиеш.

Хәзер Советлар Союзындагы 50 миллионнан артык балага йөздән артык курчак театры хезмәт күрсәтә. Алар арасында Казан курчак театры да күренекле урыннарның берсен биләп тора.

Элеккеге Россиядә курчак уены сәнгатенә аерым театр булып яшәү хокукы бирелми. Курчак тамашалары базар мәйданнарында, ярминкәләрдә генә күрсәтелә. Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң сәнгатьнең бу төренә формасы һәм эчтәлеге белән камилләшү өчен яңа, әлегәчә күрелмәгән мөмкинлекләр бирелә. 1918 нче елда Совет Россиясенең кайбер шәһәрләрендә курчак театры коллективлары барлыкка килә. Бу эш аеруча Мәскәүдә һәм Петроградта тиз җанланып китә. Курчак театрлары спектакльләре халыкны, бигрәк тә балаларны, яңа рәвеше, яңа эчтәлеге белән җәлеп итә. Революция идеяләрен, көннең, заманның мөһим проблемаларын эченә алган махсус пьесалар языла башлый. Сәхнәдә инде «Петрушка»лар гына түгел, ә заманча рухлы халык әкиятләрендәге геройлар гәүдәләнә, реаль вакыйгаларны, хәтта конкрет шәхес образларын чагылдырган спектакльләр уйнала.

Безнең илебездә курчак театры сәнгатен иң югары баскычка күтәрүче кеше — хәзерге Мәскәү дәүләт үзәк курчак театрының художество җитәкчесе, СССРның халык артисты Сергей Владимирович Образцов. Ул үзенең хезмәт һәм иҗат юлын курчакларны зур осталык, иң мөһиме — сәнгатьчә югары дәрәҗәдә хәрәкәткә китерүче, аларга йөрәк җылысын биргән артист буларак башлап җибәрә, тиз арада балаларның яраткан дустына әйләнә. Ул курчак театрының техник һәм сәнгать ягыннан искиткеч зур, яңа мөмкинлекләрен ача, курчак театры сәхнәсенең маҗаралы һәм кызыклы вакыйгаларны теләгәнчә тасвирларга сәләтле булуын раслый. С. Образцов тәҗрибәсе һәм алымнары үрнәк рәвешендә илебезнең күп милләтле курчак театрлары арасында тарала, ихтирам казана.

Татарстанда курчак театры партиябезнең һәм халкыбызның ихтыяры белән ил буенча җәелдерелгән культура революциясенең бер җимеше буларак барлыкка килде. 1926 елның сентябрендә партиянең Татарстан өлкә комитеты Казанда Үзәк пионерлар клубы оештыру турында карар кабул итте. Казан шәһәр Советы Гостинодворская урамындагы бер йортны (хәзерге Профсоюз урамындагы Мәгариф хезмәткәрләре йорты) пионерлар клубы итеп билгели. Рәссамнар аны тиешенчә бизи һәм Октябрь революциясенең X еллыгын бәйрәм иткән көннәрдә тантаналы төстә Үзәк пионерлар клубы ачыла. Ул тиз арада пионерлар, балалар һәм өлкәннәрнең яраткан урынына әверелә. Клубның беренче директоры В. Дьяков республиканың культура һәм сәнгать эшлеклеләре белән тыгыз элемтә урнаштыра. Клубта җыр, бию, драма түгәрәкләре оештырыла. Казан театр техникумы укытучылары, Татар дәүләт академия театры артистлары пионерларының иң якын дусларына әверелә.

Үзәк пионерлар клубы ачылуның беренче елларында ук үзешчән курчак театры оеша. Клубта эшләгән М. Л. Маяская үзешчән курчак театрының художество җитәкчесе итеп алына һәм зур омтылышлар белән эшкә керешә. 1932 елның 17 августында Үзәк пионерлар клубы каршындагы үзешчән түгәрәк членнары «Юлдан язган Петрушка» («Петрушка — беспризорник») дигән спектакль күрсәтәләр. Үзешчән курчак театры һәм аның куйган спектакльләре пионерлар һәм укучы балалар арасында бик тиз абруй казанырга өлгерә. Озакламый үзешчән коллектив җирлегендә Казан курчак театры оештырыла.

Яңа ялган курчак театрының эшен юлга салучы, аны чын мәгънәсендә профессиональ югарылыкка этәрүче кеше — талантлы артист һәм режиссер С. М. Мерзляков була. Ул «Өч дус», «Йөгерек-сикерек» дигән пьесалар яза һәм үзе үк сәхнәгә куя.

Яшь театр алдына яңа проблема килеп баса: милли группа оештырырга кирәклеге төп бурычларның берсе югарылыгында телгә алына башлый. Яшь татар тамашачылары театры артистларыннан Мәрьям Хисамова, Фуат Таһиров, Рәкыя Хәбибуллина, Сара Вәлиуллина, Вәли Гаффаров, Хәят Сабитова курчак театрына эшкә күчерелә һәм алар зур күтәренкелек белән курчак сәнгатен үзләштерүгә керешә.

Шул рәвешчә, 1934 елга кадәр Үзәк пионерлар клубы каршында Яшь тамашачылар театры, рус курчак театры һәм татар эстрада курчак театры финанс ягыннан да бергә, ярдәмләшеп яшәделәр. Соңрак курчак театры аерым оешма булып аерылып чыга. Аның рус һәм татар труппалары һәркайсы үзенә аерым спектакльләр куя башлый.

Театр коллективы укучыларны А. С. Пушкин, А. П. Чехов, Л. Н. Толстой, Г. Тукай кебек классик язучыларның балалар өчен язылган әсәрләре белән таныштыруга зур көч куя. Бу бөек язучыларның тирән гуманизм белән сугарылган, халыкчан әсәрләре курчаклар теле белән яшь тамашачыларга җиткерелә. Сугышка кадәрге елларда курчак

театры Г. Тукайның үлмәс әсәрләрен башка театрлар арасында беренчеләрдән булып сәхнәгә чыгара. Артистлардан Р. Хәбибуллина һәм Ф. Таһиров Г. Тукайның «Кәҗә белән сарык» әсәрен сәхнәләштерәләр. Ул биредә татарча әсәр нигезендә эшләнгән беренче татар спектакле булды. Яшь драматург Зәйни Шаһиморатов театрга Г. Тукайның үлемсез «Шүрәле»сен сәхнәләштереп тапшыра. «Шүрәле» курчак театры сәхнәсендә озак еллар дәвамында уңышлы барганның соңында тагын да зуррак сәхнәләргә күтәрелде.

Театрның татар труппасы өчен русчадан «Өч дус», А. П. Чеховның «Каштанка»сы, С. Образцовның «Зур Иван» әсәрләре тәрҗемә ителә. Язучы Халик Садрый «Әкият» дигән пьеса язып тапшыра. Болар барысы да сәхнәдә кую өчен зур тәҗрибә сорый торган әсәрләр. Һәм театрның бу әсәрләрне сәхнәгә куярга алынуы эзләнүчән, югары сәнгать осталыгына ирешкән иҗат коллективы тупланганлыгы турында сөйли.

Театрның техник җиһазлары да арта бара. Яктырту эшләре җайга салына, тавыш аппаратлары булдырыла. Баянчы А. Осипов, театрга эшкә килеп, спектакльләрнең музыка бизәлешенә күп көч сала. С. И. Брен җитәкчелегендәге квартет оештырылу спектакльләрнең сыйфатын яңа бер баскычка күтәрә. Квартетта виолончельче Х. Әбүбәкеров, пианистка А. Иваченко, скрипкачы С. Брен уйный. Театрның иҗат составына яңа көчләр — юморист У. Медведев, Казан театр техникумын тәмамлаган Г. Бакиров, А. Ибраһимов, Г. Минкиннар килеп кушыла.

Театрдагы мондый иҗат уңышлары, репертуарның баюы, артистларның осталыгы күтәрелү коллективка чын иҗат шатлыгы китерә. Театр 1937 елда Бөтенроссия смотрында катнашу хокукын яулый һәм үзенең иң яхшы спектакльләрен Мәскәү тамашачыларына күрсәтә.

1938 елда Ленинградта эшче яшьләр театры режиссерлары хәзерли торган курсларны тәмамлаган Сәлах Хөсни курчак театрына эшкә килә һәм, художество җитәкчесе буларак, репертуар сайлау мәсьәләсенә таләпчәнлекне тагын да арттыра, курчакларны йөртү техникасын камилләштерүдә эшли, С. Образцов театрындагы яңалыкларны Казан курчак театрына да кертергә омтыла. Ул — Казан курчак театры сәхнәсендә иң катлаулы төзелештәге курчак белән эш итүне башлап җибәргән режиссер.

Бөек Ватан сугышына кадәр курчак театры барлыгы 64 исемдәге пьесаны сәхнәләштерә: татар труппасы — 26, рус труппасы — 38 спектакль чыгара. Театрның бу еллардагы эшчәнлегенә бәя биреп, татар совет язучысы А. Алиш: «Театр коллективы, нигездә, таза, нык, үсәргә омтылучан, үз эшенә нык бирелгән коллектив. Артистлык осталыгын күтәрүче, курчак йөртү техникасын нык үзләштерүче үрнәк көчләр күтәрелеп үсеп киләләр», — дип яза («Кызыл Татарстан», 1939 ел, 21 февраль.)

Татар дәүләт курчак театрының нигез ташлары авыр шартларда һәм беренче артистларның, режиссерларның фидакарь хезмәте нәтиҗәсендә салынды. Халыкка хезмәт итү, дереслек өчен көрәш, яхшылыкның явызлыкны җиңүе кебек матур һәм якты фикерләр яшь тамашачыларны сәхнә белән нык тоташтырды.

Бөек Ватан сугышы алдыннан театрның директоры итеп А. Ф. Дэнина билгеләнә. Ул театрның стационар группасы өчен тиешле шартлар булдыруга күп көч сарыф итә. Курчаклар ясау мастерское ачыла, реконструкторлар чакыртыла. Казан дәүләт курчак театры илебездә танылган балалар театрлары сафына чыга. Ул үзенең соңгы репертуары белән ил күләмендә үткәреләчәк балалар театрлары смотрында катнашырга тиеш була. Ләкин, Бөек Ватан сугышы башлану сәбәпле, бу смотр үткәрелми кала.

1941 елның 22 нче июнь көнен курчак театры труппасы элеккеге Ворошилов районында каршылый. Гитлер Германиясенең совет иленә каршы хыянәтчел төстә сугыш башлау хәбәре артистларны тирәнтен тетрәндерә. Труппа, бу хәбәрне алу белән, Казанга кайтып китә. Һәркем туган илне, социалистик Ватанның бәйсезлеген саклап калу өчен фронтка китү теләгән белдерә. Театрның автомашинасы фронт өчен тапшырыла. Артистлардан У. Медведев, Г. Баканов, Н. Хәлфиев сугышның беренче көннәреннән үк фронтка китә. Һәм батырларча һәлак булалар. Ф. Таһиров, Н. Сиражетдинов сугыштан каты яраланып кайталар.

Сугыш башланган көннәрдә үк үзен көрәш сафларында дип санаган совет театр сәнгате сафында Казан курчак театры да бар иде. Шомлы һәм дәһшәтле еллар булуга да карамастан, театр үз эшен ташламады, иҗади эзләнгән дәвам иттерде. Авыл сәхнәләрендә, һөнәр училищеларында, мәктәпләрдә, госпитальләрдә спектакльләр куеп, өлкәннәрне дә, балаларны да бер теләккә әйдәде яисә берәзга гына булса да сугыш дәһшәтен онытырып торырга ярдәм итте.

Сугыш елларында патриотик тема совет сәнгатенең төп темасына әверелде. Курчак театры да үз чаралары һәм мөмкинлекләре белән яшь буынны туган илне яратырга, аңа тугры хезмәт итәргә, гаделлеккә өндәде, дошманнарга нәфрәт белән карарга чакырды. Бу төр сәнгать өчен әкиятләр төп иҗат нигезе булганлыктан, репертуарга халык әкиятләрендәге явыз һәм кара көчләргә каршы көрәшүче халык геройлары, уңай образларны пропагандалаган пьесалар кертелә.

А. Преображенскийның яшь тамашачыларны патриотик һәм интернациональ рухта тәрбияләүче «Нәфрәт» чәчәкләре», (К. Нәҗми тәрҗемәсе), Ш. Зәйнинең «Кечкенә партизаннар», «Сугышчан Петрушка» дигән әсәрләре сугыш елларында аеруча уңышлы һәм күп уйнала. С. Образцовның «Немец генералы дуңгыз баласы белән ничек көрәште» дигән пьесасы нигезендә эшләнгән спектакльдә фашизмның явыз ниятләре балаларны да, өлкәннәрне дә нәфрәтләндерерлек, шул ук вакытта ачы мәсхәрә белән чагыла.

Авыр сугыш елларында театрның татар труппасы куйган «Чуртан кушканча» (А. Тархановская), «Әкият» (Х. Садрый), С. Хәсни әсәрләре сәхнәдән төшми уйнала. С. Хәснинең «Алпамша», «Камыр батыр», «Хәйләкәр Таҗи» пьесаларына нигезләнеп сәхнәләштерелгән спектакльләрдәге Аждаһа, Дию пәрие кебек образлар усаллык, явызлык, ерткычлыкка нәфрәт уята. Бу спектакльләр турыдан-туры сугыш вакыйгаларын чагылдырмасалар да, артистлар үзләренең иҗади осталыклары белән сугыш елларына хас үзенчәлекле хисләр бирүгә ирештеләр.

1943 енық 14 декабрендә курчак театры үзенең 10 еллыгын билгеләп үтә. Бу көнгә театр махсус рәвештә «Чуртан кушканча» дигән спектакль хәзерли. Театрның репертуарын баетуга зур өлеш керткән драматург Әнәс Камал юбилей спектакле уңае белән «Җансыз курчакларга җан бирүче, үз күңелендәге тойгыларны шул курчаклар аша тамашачыга җиткерә алучы, балаларны тәрбияләүдә яңа форма тапкан җитез осталарның зур хезмәтләренә сокланмый мөмкин түгел»,— дип язып чыга («Совет әдәбияты», 1943 ел, 12 сан).

Театр бу юбилейга үз йөзен һәм тамашачысын тапкан, бай репертуар булдырган, җитлеккән иҗат коллективы буларак килә. Аның эшендә А. Ключарев, Җ. Фәйзи, М. Мозаффаров кебек танылган композиторлар, Ш. Зәйни, Х. Садрый, З. Шаһиморатов кебек язучылар катнаша. Театрда Троицкий һәм Ошустович кебек тәҗрибәле рәссамнар эшли. Театрның художество эшләре җитәкчесе, режиссер Сәлах Хәсни, драматурглар һәм артистлар белән бергә, репертуарны

заман таләпләреннән чыгып язылган пьесалар белән баетуда күп эшли.

Театрның авыр сугыш елларындагы эшчәнлеге тылдагы батырлыкка тиң. Коллектив һәр елны республикабыз шәһәрләре һәм авылларында 100 мең балага культура хезмәте күрсәтә. Артистлар ягылмаган салкын клубларда уйный, гастрольләргә йөргәндә транспорт булмый. Декорацияләр төялгән арбаларны авылдан авылга артистлар кайчакны үзләре тартып, җәяү йөри. Театр ветераны Вәли Гаффаров ул еллар хакында үзенең истәлекләрендә болай дип яза: «Авылларда клублар салкын. Ягарга утын юк. Без курчакларны уйнатканда туңган кулларыбызны, бармакларыбызны сулышыбыз белән җылыттык. Бияләй киеп уйнап булмый, чөнки курчакларны хәрәкәтләндерергә бармаклар кирәк бит. Декорацияләрне үгез җигелгән арбаларга төяп ташыдык, үзебез җәяү йөрдек»...

Ниһаять, җиңү. 1945 елның 9 май көне. Урамнарда халык ташкыны. Һәркайда музыка, шатлыклы җыр. Бу көн һәркемнең күңелендә онытылмаслык хатирә булып уелып калган. ТАССРның халык артисты Фуат Таһиров күңелендә бу көн менә ничек саклана: «Җиңү бәйрәме көнне машинага сәхнә кордык та Бауман урамына юнәлдек. Урамдагы халыкның иге-чиге юк. Филармониянең машина әрҗәсенә менеп баскан артистлары күренә. Фәйзи Биккинин кечкенә гармуннарын сайрата. Шул вакытта без — В. Гаффаров, С. Вәлиуллина, Б. Рычков, Р. Хәбибуллина, В. Третьякова — утырган машина да Бауман урамына килеп керә. Безнең машинада — дар агачлары. Аларга Гитлер, Геббельс, Ганс һәм башка фашистларның карачкылары асып куелган. Халык аларны каргый башлады, кайберләре, таш һәм балчык ыргытырга кереште. Алар хәтта курчаклар артында артистлар басып торганын да онытты».

Сугыштан соңгы елларда курчак театры балаларда хезмәтне ярату, авырлыкларны җиңә белү, ихтыяр көчен чыныктыру, тәртипле булу, өлкәннәргә хөрмәт белән карау, итагатьлелек, интернациональ рух тәрбияләү бурычларын игътибар үзәгендә тота. «Кечкенә партизаннар», «Партизаннар урманы әкияте» спектакльләрендә яшь патриотларның немец-фашист илбасарларына каршы героик көрәше күрсәтелә. Театрның репертуарын яңартуга яңа авторлар һәм композиторлар тартыла. 1951 нче елда драматург Әнәс Камал «Курчак театры» дигән җыентыгының чираттагы санын бастырып чыгара. Бу җыентыкка Х. Садрыйның «Камал бабай әкияте», Г. Гарьянов һәм Н. Никитинаның «Куан-ки», Г. Шамуковның «Уңган кыз», К. Иенейдерның «Сармишко җыры», Е. Шварцның «Югалган вакыт», Ф. Таһиров һәм Р. Хәбибуллинаның «Дуслар» дигән пьесалары тупланган иде. Театр шушы әсәрләрне үз репертуарына кертә. Болардан тыш, 60 нчы елларга кадәр театр сәхнәсендә «Хәйләкәр Таҗи», (С. Хәсни), «Хуҗа Насретдин» (Н. Исәнбәт), «Буратино» (А. Толстой), «Чапаев бөркете» (И. Ермаков), «Галәветдиннең тылсымлы лампасы» (Н. Гернет), «Бәхет җыры» (Н. Дәүли), һинд әкиятләре нигезендә эшләнгән «Чакыру» (А. Иолавайский) спектакльләре куелып сугыштан соңгы елларда репертуарның төп өлешен тәшкил иттеләр. Репертуарның байлыгы һәм төрлелеге, беренчедән, Н. Дәүли, Г. Шамуков, Д. Аппакова, Н. Исәнбәт кебек язучыларның курчак театры драматургиясенә килүләре белән аңлатыла. Кешедә бар нәрсә бала чактан башлана. Безнең әдипләребез балалар өчен язуның гаять җаваплы бурыч икәнлеген истә тотып иҗат итә башладылар. Яшь буынга идея-сәнгать тәҗрибәсе бирүдә балачак — кабатланмас чор. Күз уңына баланың җанын, күңелен тәрбияләү мәсьәләсе килеп баса. Шул ук вакытта бу чор балалар драматургиясенә, бигрәк тә курчак театрына багышлап язылган әсәрләргә заман балалары һәм

үсмерләрнең кызыклы, киеренке тормышын нечкә, тирән чагылдыру җитешми.

Театрның репертуары хакында матбугатта тәнкыйть фикерләре дә әйтелә. Пьесаларның зур өлеше әкиятләрдән эшләнгән инсценировкалар була, бер үк характерлы уңай геройлар еш кабатлана. Артистларның кайбер спектакльләрдә, бер үк тавыш белән ике-өч геройны сурәтләве, кайбер очракта образлардагы шәхси үзенчәлек сайлыгы да искәртелә. Бу фикерләр театрның яшь артистларына күбрәк кагыла иде. Ә, нигездә, театрның төп иҗат төшен тәшкил иткән Ф. Таһиров, Б. Рычков, В. Гаффаров, М. Хисамова, М. Язвина, С. Вәлиуллина кебек талантлы артистлар балалар психологиясен тирәнтен белгән хәлдә, аларның рухи ихтыяҗларына туры килердәй итеп уйнауларын дәвам итәләр. Алар театрның үз йөзенә, традициясенә нигез салды, аны яшь буын артистларына тапшырды.

Спектакльләрнең идея-художество эчтәлеген яшь тамашачыларга җиткерүдә музыкага булган игътибар сугыштан соңгы елларда яңа баскычка күтәрелде. Композиторлар М. Юдин, Д. Говорухин, Ш. Мәҗитов музыка язды. Музыкантлардан А. Эвченко, А. Осипов, Ә. Низаметдинов хезмәтләре театр тарихында якты эз калдырды.

1955 елны театрга директор итеп билгеләнгән А. П. Юсупов театрның стационар бинасын булдыру өчен күп көч куя. Һәм, ниһаять, Казан курчак театры Луковская урамындагы кинотеатр бинасына күчә. Биредә бер үк вакытта спектакльләр дә, кинофильмнар да күрсәтелә. Ә 1958 елны бу бина тулысынча курчак театрына тапшырыла. Һәм театр, 1958—59 еллар сезонын «Буратино» спектакле белән инде үз бинасында ачып җибәрә. Театрның техник цехлары ачыла, режиссерлар, актерлар, репетиция бүлмәләре булдырыла. Тулы канлы чын сәнгать әсәрләре иҗат итү өчен бөтен шартлар барлыкка килә.

Бүгенге татар дәүләт курчак театрының профессиональ югарылыкка ирешүендә бу вакыйга, әлбәттә, зур роль уйнады. 1938 елны ук Бөтенсоюз мәйданына күтәрелгән театр 1964 елда «Баранкин, кеше бул» һәм «Алтын чәкән» спектакльләре белән Бөтенсоюз курчак театрлары смотрында катнашу бәхетенә ирешә, анда зур бәя ала.

1967 елда Казан театр училищесында курчак театры артистлары бүлеге ачылды. 1970 елда аның беренче чыгарылышы булды. Коллективка махсус белемле, театр сәнгатенә чын күңелдән гашыйк булган яшь талант ияләре өстәлде. Алар, өлкән буын артистларының матур һәм бай традициясен дәвам итеп, театрның иҗат йөзенә үз бизәкләрен кертәләр. Училищены уңышлы тәмамлаган иң сәләтле яшьләр Ленинград дәүләт театр, музыка, киноматография институтына укырга җибәрелде. Хәзер труппада В. Ильина, И. Катаева, И. Зиннуров кебек театр тарихында иң беренчеләрдән булып махсус югары белем алган яшьләр эшли. Шул институтта укып кайткан И. Зиннуров — хәзер театрның баш режиссеры. Театр чын мәгънәсендә яшәрү чорын кичерә. Хәзер иҗат труппасының күпчелек өлешен яшьләр тәшкил итә.

Театрга сәләтле яшь актерлар белән бергә И. Москалев, И. Зиннуров, Р. Батуллин кебек режиссерлар килде. Э. Гельмс, Л. Насыйров, Х. Скальдина, А. Тубская, Л. Сперанская, Л. Шахматова, Т. Хуҗиәхмәтов кебек рәссамнар курчак образлары иҗат итәләр. С. Садыйкова, Ф. Әхмәтов, М. Яруллин, Р. Бикбулатов, Т. Розанова, Р. Хәсәнов, И. Якупов кебек композиторлар спектакльләргә матур көйләр язалар.

1968 елның ахырында икенче татар группасы оештырылу театр белән авыл тамашачылары арасындагы элемтәне тагын да ныгытты. Милли республика шартларында бу хәл театр тарихында әһәмиятле вакыйга булды. Ул милли балалар драматургиясе үсешенә дә уңай йогынты ясады.

Иҗат труппасының үсеше театрның авыл җирендәге яшь тамаша-

чылар белән аралашуына сизелерлек уңай йогынты ясады. Хәзер театр ел саен 1400 спектакль күрсәтә. Бу — һәр көнне 3—4 спектакль дигән сүз. Спектакльләрдә елына 300 мең тамашачы була. Аларның яртысы — авыл тамашачылары. Театрның гастроль маршрутлары республика чикләрен узып Киев, Пермь, Куйбышев, Свердловск, Киров, Ульяновск, Астрахань, Горький, Саратов өлкәләре, Чувашия, Башкортстан, Мари, Мордовия, Удмурт, Дагыстан автономияле республикалары буйлап сузылды. Бу — татар дәүләт курчак театрының чын-чынлап бөтенсоюз мәйданына чыгуы турында сөйли. Репертуарга классик әсәрләр белән беррәттән рус, татар һәм башка халыклар драматургиясенең балалар өчен язылган иң яхшы, югары художестволы оригиналь әсәрләре кертелә. А. Гайдар, С. Маршак, Антуан де Сент-Экзюпери, Н. Хикмәт, И. Шток, Г. Андерсен, Р. Рельян, Е. Геловецкий кебек төрле милләт авторларының күренүе театрның «интернациональ курчак театры» исеменә тугры булып яшәп килүен раслый. Игъланнарда Н. Исәнбәт, Н. Дәүли, Н. Фәттах, Т. Миңнуллин, Р. Батуллин, Ә. Маликов исемнәренең торган саен ешрак очравы татар курчак театры драматургиясенең дә җанлануын күрсәтә торган куанычлы хәл.

Хәзер татар дәүләт курчак театры сәхнәсендә төрле милләт вәкилләренең 20 дән артык пьесасы даими уйнала.

Курчак театры — балалар театры гына түгел. Курчак сәнгате — зур проблемалар, социаль мәсьәләләрне күтәреп чыга алырдай җитди сәнгать. Моның шулай икәнен Мәскәү, Ленинград, Горький, Каунас, Свердловск, Львов, Магнитогорск һ. б. шәһәрләрдәге курчак театрлары күптән исбат итте. Бу исемлеккә икеләнмичә Татар дәүләт курчак театрын да кертергә мөмкин. Ул тапкырлык, лирика, реалистик сатира белән сугарылган халык авыз иҗаты әсәрләреннән Н. Хикмәтнең «Сукыр патша», И. Штокның «Илаһи комедия», Антуан де Сент-Экзюпериның «Бәләкәй принц» кебек фәлсәфи һәм социаль проблемалар күтәргән пьесаларын сәхнәләштерде. Болар курчак театры сәнгате чараларына авыр бирелүче, идея-художество дәрәҗәсе югары булган җитди әсәрләр. Аларны курчак театры сәхнәсендә куюю иҗади кыюлык таләп итә.

Бүгенге заман курчак театрының бер үзенчәлеге — үзенә генә хас сәхнә йөзе табарга омтылудан һәм үзенә генә хас сәхнә теле булдырудан гыйбарәт. Ул хәзер күбесенчә режиссер фикеренә таянып һәм аңа буйсынып эш итә, үзгәреп тора, традицияләренә тугры калган хәлдә, шәхси йөзен булдыру юлларын эзләнә.

Казан курчак театрының бу өлкәдәге мәгълүм уңышлары соңгы елларда аерата күзгә күренеп тора. Ул илебездә алдынгы урыннарның берсенә чыкты. Театрның баш режиссеры булып эшләгән Р. Батуллин спектакльләрнең төрлелеге турында гына түгел, бәлки форма төрлелеге турында да күп кайгырта башлаган иде. Бу эшне хәзерге вакытта баш режиссер И. Зиннуров уңышлы дәвам итә. Курчак театрының традицион һәм яңа формалары проблемасын бүгенге «курчакларыбыз» иҗади аңлыйлар. Билгеле, кайбер чакларда бу проблема очраклы төсмердә генә хәл ителә яисә үзмаксат итеп кулланыла. Ханнар, дию пәрие, байлар яки еланнар, мескен ярлылар шуларны яклаучы нинди дә булса батыр малай яисә кыз — болар еш кына кабатлануга китерә торган образлар һәм аларны нинди генә яңа рәвешләрдә, формаларда яңартырга тырышсаң да, спектакльләр игезәкләргә охшап калучан була. Ә менә соңгы берничә спектакльдә «кара бүлмә» дигән бер алым кулланылды. Карага киенгән актерлар ирекле рәвештә сәхнәдә йөри, курчакла, йөртә, алар кара пәрдә һәм кара сәхнә җирлегендә күренмиләр дә диярлек. Алар курчаклар белән ябышкандай, бер «җан» булып йөриләр. Тагын шунысы да бик әһәмиятле: курчак театрын традицион төстә кул һәм бармаклар белән идарә ителә торган

кечкенә манекеннар дип күз алдына китергән тамашачылар хәзер инде артистлар белән бер үк буйдагы, хәтта зуррак та булган курчаклар белән очраша.

Моның кебек тәҗрибәләргә Казан курчак театры артистлары формаль карамаулары белән оталар. Тышкы матурлыкка гына омтылу юк диярлек. Бигрәк тә милли материалга таянып эш итүнең нәтиҗәле икәнлеге күренә. Ә бу табигыйлеккә, димәк сәнгатьчәлеккә китерә. Сәнгатьчәлек булган җирдә тәҗрибәләр ясавы иркенрәк. Бу нисбәттән Н. Дәүли пьесасы нигезендә куелган спектакль аерылып тора. «Кара бүлмә» алымы. Режиссерның стилизациягә омтылышы күренеп тора. Ә стилизация үзе нәфислеккә, «тамашалыкка», телнең халыкчанлыгына китерә. Бу спектакльнең нәни тамашачыга нәрсә әйтергә теләгәне, нинди максатны күз алдында тотканы, ягъни эстетикасы беренче карауга ук күренеп тора. Хәрәкәтләр төгәл, пөхтә, сүз гади, үтемле. Декорациясе дә матур, истә кала торган итеп ясалган. «Кара бүлмә» алымы курчакларны беренче планга чыгарып, портрет сыман итеп күрсәтергә мөмкинлек биргән.

Иҗат алымнарының күбәюе, яхшы спектакльләр иҗат итү аралашу чикләрен дә киңәйтеп җибәрде. Казан курчак театрының иҗат вәкилләре Азия илләрендәге курчак театрларының халыкара фестивалендә катнашты. Театрның баш режиссеры Илдус Зиннуров курчак театрларының Америка Кушма Штатларында үткәрелгән бөтендөнья форумында катнашты. Милли театрларның шул рәвешчә үзара бәйләнешы театрларга үзенә генә хас стиль, шәхси иҗади йөз булдыруга ярдәм итә. Шул җөмләдән Казан курчак театрына да. Ә аның бөтенсоюз мәйданында торып иҗат итүе офыкларының киләчәктә тагын да киңрәк ачылачагы турында сөйләп тора.

# ДАВЫЛ КАРДӘШЕ

Башбирмәс, ялкынлы йөрәкле кешеләр! Шушылай дип әйтүгә, бөркетләр кебек курку белмәс кыю йөрәклеләр күз алдына килеп баса. Алар башкалар бәхете һәм гаделлек өчен көрәш утына керәләр, кирәк икән, шуның хакына гомерләрен дә фида кылалар. Габидулла Әскәр улы Башировның да ерак бабасы куркусыз йөрәклеләр токымыннан булган.




*Якутскида патша самодержавиесенә каршы көрәшкән каһарманнар истәлегенә куелган мемориал*

Иксез-чиксез калмык далаларына Емельян Пугачевның ирекка чакырган авазы килеп ишетелүгә үк, ул үзенең соңгы атын иярли дә көрәш таңына карап юл ала. Тояк тавышыннан дала тынлыгы чәлпәрәмә килә. Татар, калмык һәм башкорт егетләре Пугачевка ярдәмгә ашыга.

Емельян Пугачев җитәкчелегендәге крестьяннар восстаниесе җиңелүгә дучар булса да, бу хәрәкәт, дәһшәтле яшен сыман, ил тарихында якты эз калдырды. Халык күтәрелеше патша тәхетен нигезе-ние белән дер селкетеп куйды.

Ул чагында изге ирек көрәшә кырында күпләр ятып калды, ә исән калганнары җәзага тартылды, каторга-сөргеннәргә озатылды. Габидулланың ерак бабасы Сәимгәрәйне дә Себергә сөрәләр. Ул Ерак Көнчыгышка каторгага, таш чыгару-вату эшенә озатыла. Пугачевның көрәштәше әнә шулай итеп үз туган туфрагыннан мәңгелеккә аерылып китә. Ләкин Сәимгәрәй хакында изге хатирә керләнмичә, саф килеш буыннан-буынга күчә-күчә бүгенге көннәргә кадәр килеп ирешкән!

Сәимгәрәйнең көрәшче җанлы рухы балаларының балаларына да күчә, алар йөрәгендә сүнмәс ялкын булып кабына. Пугачев чорында Сәимгәрәй йөрәгендә кабынган очкыннар революция елларында Габидулла йөрәгенә дә төшә. Көрәш утының дәвамчанлыгы бу!

Хәер, Габидулланың дәү әтисе Исламны гына алыйк. Аңарда да шул ук бунтарьлык рухы ташып тора. Яңа Каргалы авылында крестьяннар ачлыктан үлем хәленә җитәләр. Аларның ачы тормышына Ислам тыныч күз белән карый алмый. Көннәрдән бер көнне ул Ахун бай амбарындагы йозакны каерып вата да крестьяннарга иген өләшә. 1870 елда өяз суды аны Якутия җиренә мәңгелек сөргенгә җибәрү турында хөкем карары чыгара.

Ислам Бәширов революциягә кадәр күп еллар элек Якутскида дөнья куя. Шул елларның истәлеге булып, бу каладагы татар зиратында аның кабер ташы гына сакланып калган. Хәзерге вакытта ул зиратта патша самодержавиесенә каршы күтәрелгән өчен туып үскән җирләреннән сөрелгән каһарманнар истәлегенә мемориал куелган. Мемориалга язылган исемнәр арасында Казан, Уфа һәм Сембер губернасыннан сөрелгән күпләгән татар улларының исемнәрен очратасың.

*
* *

Габидулла үзенең ыруы турындагы риваятьләрне кечкенәдән үк ишетеп үсә. Әтисе Әскәр абзый Бәширов пристаньда йөк ташучы булып эшли. Әнисе Мәликә апа шәһәрнең хәлле кешеләренә ялланып, аларның керләрен уа, өйләрен акшарлый. Ата белән ана бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр җигелеп эшләсәләр дә, сигез җан иясеннән торган ишле гаиләгә очын-очка ялгап кына яшәргә туры килә... Габидулла гаиләдә беренче бала була, ул XX гасыр башында туа. Бербер артлы дөньяга энеләре Хәйрулла, Әхмәди һәм башкалар килә.

Үсмер малай әтисе авызыннан еш кына туган җирләре Агыйдел буйларыннан бу кырыс якларга килеп чыгуларының тарихын ишеткәли. Күршеләрендә яшәүче рус политик тоткыннарының шушы хактагы сүзләре дә аның күңелендә патша властена карата нәфрәт хисе уята. Акрынлап ул, ундүрт яшьлек малай, аларның үз кешесенә әверелеп китә, өлкәннәрнең яшерен йомышларын үти, алар киңәшмә үткәргәндә сакта тора, городовой яки полицейский күренүгә, тиз арада хәбәр сала. Көндезләрен ул мәктәпкә йөри.

Тора-бара Габидулланың тормышка карата үз карашы да бөреләнеп китә. Ул берәүләрнең көне-төне эшләп тә ачлы-туклы яшәүләренең, ә икенчеләренең кыл да селкетмичә рәхәтлектә типтереп гомер итүләренең сәбәбен яхшы кузаллый башлый. Үсмер егет үз киләчәгенең көрәштән торачагын сизә, шуңа әзерләнә.

Аның тормышында онытылмас бәхетле көн килә. Ул адашы Габидулла Төхфәтуллин белән бергә Е. М. Ярославский җитәкчелек иткән яшерен революцион түгәрәккә керә. Яшь көрәшче Февраль революциясен шатланып каршылый. Ә Октябрь революциясе аны бөтенләе белән үз кочагына бөтереп ала. Габидулла большевиклар партиясе сафына баса.

Нык холыклы, калын гәүдәле бу егет үз яшеннән өлкәнрәк булып күренә. Нур чәчеп торган дәртле, үткен карашы гаять зур ихтыяр көченә ия булуы турында сөйләп тора. Аның бу сыйфатлары соңыннан көрәш һәм эшчәнлек елларында бөтен тулылыгы белән ачыла.

Революция давылы Ерак Көнчыгышка да килеп җитә. Габидулла Бәширов Ридзинский җитәкләгән партизаннар отрядына язылып, Якутскины алуда, анда Совет власте урнаштыруда катнаша. Аннары ул интернациональ дружина оештыруда башлап йөри. Бу дружинаның нигезен татарлар, якутлар, кореялеләр һәм кыргызлар тәшкил итә. Аңа сыналган карт большевик Мәхмүт Зөбәйдуллин җитәкчелек итә, ә Габидулла Бәширов анда комиссар була.

Контрреволюцион өлкә советы Якутскида эшче депутатлары Советы башкарма комитеты членнарының күпчелеген кулга алып бетерә. Хәл кискенләшә, көрәш кыенлаша. Большевикларга хезмәт халкы белән аралашу өчен яшерен газета чыгару юлы гына кала. Тиздән «Бюллетень» дигән шундый газета тарала башлый. Бу басманың төп оештыручысы — Габидулла Бәширов. Аңа Г. А. Тәхфәтуллин белән А. С. Царственный ярдәм итәләр. Бу вакытта Бәширов белән Царственный Якутск типографиясендә эшлиләр. Алар төрле юл белән типографиядән кирәк булганның бөтенесен алып чыгалар. Тырышлык бушка китми — «Бюллетень» даими чыгып тора. Ул халыкка совет власте турындагы бөтен дөреслекне җиткерә бара.

Габидулла Әскәрович «Бюллетень»ны чыгару белән генә чикләнеп калмый, бу эшкә һәм тагын листовкалар таратуга хатыны Мария Әхмәтовнаны һәм энесе Хәйрулланы да тарта. Хәйрулла соңыннан Якутиядә гражданнар сугышы вакытында И. Я. Строга җитәкчелегендәге атлы разведкада йөри, Якутскины Колчак гаскәреннән азат итүдә катнаша. Шул сугышларда күрсәткән батырлыгы өчен аны М. И. Калинин исемле сәгать белән бүләкли.

Кече энесе Әхмәди дә абыйсы юлыннан китә. Совет власте елларында югары партия белеме ала, бик күп җаваплы урыннарда эшли. Соңгы вакытта партия өлкә комитеты каршында лекторлар группасын җитәкли. Әхмәди Бәширов бүген дә исән әле, ул Казанда яши.

Контрреволюцион өлкә советы «Бюллетень»нең эзенә төшә. Кыю большевик Габидулла Бәшировны кулга алалар. Ләкин ул беренче җай чыгу белән тоткынлыктан качып чыга да, шул ук кичне хатын-кыз күлмәге киеп, хатыны белән бергә подвалдан типографиянең исән калган җиһазларын коткарып кала. Берничә көннән соң «Бюллетень»нең яңа саны дөнья күрә. Типографияне дусты һәм адашы Габидулла Тәхфәтуллин өенә урнаштыралар. Газета шәһәрдәге һәм тирә-юньдәге хезмәт халкын контрреволюциягә каршы көрәшкә оештыруда әлегә бердәнбер, әмма нәтиҗәле коралга әверелә.

Якутскины колчакчылар яулап алгач, хәл тагын да начарая, Бәшировка яшеренеп яшәү икеләтә-өчләтә авырлаша. Шуңа да карамастан, ул йөк ташучылар союзына җитәкчелек итә. Бу эштә аңа әтисе гаять зур булышлык күрсәтә. Габидулла Әскәровичны полиция ялчылары ничек тә кулга алырга җай эзлиләр. Инде тоттылар дигәндә генә кыю большевик аларны тагын эздән яздыра. Ниһаять, ул Намск районындагы туганнары Икдисановларда яшеренеп торырга карар кыла. Урман аркылы җәяүләп шунда китә. Юлны чокырлы урыннардан сайлый. Югыйсә, полиция кулына эләгүеңне көт тә тор. Кинәт Габидулла этләр өргән тавыш ишетеп ала. Җитмәсә, алда ачыклык, ә аннан арырак — сазлы күл. Озак уйлап тормастан, күл суына чума да авызына камыш көпшәсе кабып ята. Полиция патруле берни сизмичә узып китә. Өч көн үтте дигәндә, тәмам алҗып-талып, ул Намскига килеп төшә. Әмма биредә дә тыныч түгел. Бөтен җирне полицейскийлар айкап йөри. Шунлыктан туганнары Габидулланы тайгага — аучылар өенә озатып куялар.

Шушыннан торып, ул йөк ташучылар союзы һәм аерым большевиклар белән элемтә тота. Ләкин вакыйгалар үзгәннән читтә торып большевистик эштә чын-чынлап катнашу мөмкин булмый. Дуслары, печән астына яшереп аны яңадан шәһәргә алып кайталар. Бу вакытта Бәшировлар гаиләсе мәктәп бинасында тора, әнисе җыештыручы булып эшли. Габидулланың властьтан качып, мәктәптә яшеренеп ятуы турындагы сүз директорга барып җитә һәм ул Мәликә апага эштән китәргә яки улын моннан чыгарып җибәрергә тәкъдим итә. Әнисенә нинди куркыныч янавын сизеп, Габидулла беркемгә әйтмичә төнлә башка урынга — йөк ташучылар янына күчә.

Ниһаять, 1919 елның җәендә акгвардиячеләр Габидулланың эзенә төшәләр. Ул кулга алына, башка большевиклар белән бергә пароходка төяп, аны Киринск шәһәренә озаталар. Юлда барганда ул эчем авырта дип сакчыдан бәдрәфкә керергә рөхсәт сорый. Елга куе караңгылыкка чумган. «Качу өчен иң уңай чак!» — дип уйлый Габидулла эченнән генә һәм бәдрәф тәрәзәсен каерып ача да суга сикерә. Бераздан ул урманга кереп югала. Берничә көнен урманда үткәрә.

Бәхет аңа тагын елмая. Ул, пристаньга килеп, Якутскига баручы бер пароходка йөк ташучы булып урнаша. Шәһәргә кайтуга, большевик дуслары белән элемтәсен яңартып җибәрә. Алар аркылы Киринск шәһәреннән ерак түгел Крылов җитәкчелегендәге партизаннар отряды хәрәкәт итүен ишетеп белә. Озак уйлаганнан соң Габидулла шушы отрядка барып кушылырга карар кыла. Соңыннан бу отряд «Ленадагы иреклеләрнең икенче Совет полкы» дип аталып йөртелә. Бәширов шәһәрдә Совет власте урнаштырылганчыга кадәр партизаннар отрядында йөри.

1920 елда Якутскига кайткач, аны, партиянең курку белмәс батыр солдатын, Иркутск шәһәренә контрреволюция калдыкларына каршы көрәшүнең гадәттән тыш комиссиясен җитәкләргә билгелиләр. Аңа бу вакытта үзенең дошманнары белән күп мәртәбәләр күзгә-күз очрашырга туры килә, ул үзен аяусыз көрәшче итеп таныта.

Партия эше кыюлык өстенә тирән белем дә таләп итә. Ул Свердловскида кыска сроклы курсларда укый. Якутскига кайткач, партиянең шәһәр комитеты секретаре булып эшли.

Ә 1928 елның июленнән ул — ВКП(б)ның өлкә контроль комиссиясе председателе. Аның бу бик җаваплы урынга сайлануы һич очраклы түгел. Партия эшенә тирән бирелгәнлек, намуслылык, тапшырылган эш өчен җаваплылык — большевик Г. Ә. Бәшировка хас бу сыйфатлар аның һәр эшендә чагылып тора.

Утызынчы елларда Якутиянең төньяк районнарында хәл катлауланып китә: контрреволюция калдыклары һәм кулаклар ачыктан-ачык эш йөртә башлыйлар. Халык дошманнарын үтәдән-үтә күрү тәҗрибәсе булган Бәширов Верхояние һәм Анадырда контрреволюционерларны һәм бандитларны юк итү буенча хөкүмәт комиссиясе председателе итеп билгеләнә. Сыналган большевик Габидулла Әскәрович бу җаваплы бурычны уңышлы үтәп чыга, партиягә хас саклык һәм зирәклек күрсәтә.

Әлбәттә, үтә кырыс котып чигенә барып җитүе җиңелдән булмый. 60 ар градуска җиткән салкыннарда һәм күз ачкысыз бураннарда алар, боланнар һәм этләр җигеп, куркыныч янаган урынга ашыгалар. Шуны да әйтик, хөкүмәт делегациясе үзе белән бернинди дә коралфәлән алмый. Аларга тыныч бер бурыч куела — балык тотучылар артеле оештыру. Бу эштә һичбер мәҗбүр итү, көчләү булмаска тиеш. Ә кулакларны куу мәсьәләсен хамначитлар (төп җирле халык), аучылар һәм балыкчылар үзләре хәл итә. Ярлылар үзләренең элекке изүчеләренә каршы көрәш дружинасы оештыралар.

Ләкин бөтенесе дә җиңел генә бармый. Байлар, кулаклар каршылык күрсәтәләр һәм хөкүмәт комиссиясен, беренче чиратта Г. Ә. Бәшировны ничек тә юк итәргә чамалыйлар. Алар яшерен рәвештә корал туплыйлар. Моны очраклы рәвештә балыкчылар артеле сизеп ала, күзәтү оештыра. Ә бер төнне совет власте дошманнары җыелган юртага һөҗүм итеп, аларны коралсызландыралар.

Габидулла Әскәрович һәрвакыт партия һәм халыкның күз алдында. Аны барысы да яхшы белә һәм тирәнтен ышана. Шуңа күрә дә бу большевикка һәр эшне һич икеләнмичә ышанып тапшыралар. Ул нинди генә эшкә тотынмасын, аны чын күңелдән, намус белән үтәп чыга.

Хәер, бүтәнчә булуы мөмкин дә түгел. Ул үзе дә түбәннән — эшче гаиләсеннән күтәрелгән кеше, шуңа да хезмәт ияләренең уе һәм эшләре аның йөрәгенә якын. Ул һәрчак аларның тугры дусты һәм киңәшчесе булып кала.

1931 елда Верхоянидән кайткач, Бәширов үзенең элекке эшен дәвам итә. Ә бер елдан соң ул Мәскәүдә Промакадемиядә белем ала. Аннары Якутия АССР Халык Комиссариаты Советы председателе урынбасары буларак, Г. Ә. Бәширов бөтен күңел җылысын биреп, җиң сызганып республика каршында торган гаять җаваплы бурычларны үти.

Ватаныбызга фашист илбасарлары ябырып кергәч, Габидулла Әскәрович кулына корал алып, ил азатлыгын яклап көрәшүчеләр сафына баса. Ул, бронетранспортер командиры буларак, коралдашлары белән авыр сугыш юлы узып, Польша һәм Германия территорияләрендә барган каты, канкойгыч сугышларда катнаша.

Туган шәһәре Якутскига җиңүче булып кайтып җитә ул! Аның күкрәген Кызыл Йолдыз, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары һәм бик күп медальләр бизи.

Сугыштан соң Габидулла Әскәрович ун ел дәвамында ЯАССР статистика идарәсе белән җитәкчелек итә. Кайда гына эшләмәсен, ул хезмәт ияләренең олы ихтирамын һәм мәхәббәтен казана. Партиянең тугры улы Советларның XV Бөтенроссия, VI Бөтенсоюз съездларында делегат булып катнаша. ЯАССР Үзәк башкарма комитеты члены итеп сайлана.

Габидулла Бәширов гомеренең соңгы сулышына кадәр үзен партия эшенә, хезмәт халкы бәхете өчен көрәшкә багышлады. Ул 1963 елда безнең арадан китеп барды. Быел аңа 80 яшь тулган булыр иде. Без ялкынлы большевик Г. Ә. Бәширов исемен тирән ихтирам белән искә алабыз.

**Нигъмәт ИКСАНОВ.**

## ӘДИП МАЛИКОВКА 60 ЯШЬ

# ОЗЫН ЮЛЛАР, ЕРАК ЕЛЛАР АРАСЫ



— Шәһәр газетасын укыдыңмы, Горький клубында яшь язучылар түгәрәге оештырыла икән.

— Әйе, Казаннан корреспондент Маликов килгән. Бик җитди күренә, оештырыр да...

— Булмас. Кая инде безнең Әлмәткә язучылар!..

1955 елның көзендә халык арасында менә шундый сүзләр йөри иде. Шагыйрь Әдип Маликовның тормыш һәм иҗат юлын, барыннан да бигрәк, Әлмәт шәһәре, нефть яклары белән башлап җибәрү бик урынлы. Чөнки ул гомеренең иң матур чакларын, иҗатының иң бәрәкәтле елларын биредә уздырды. Ул монда яшьләр газетасының үз хәбәрчесе булып эшләде, балалар үстерде, әдәби түгәрәк оештырды, нефтьчеләр, төзүчеләр турында беренче шигырьләрен, поэмаларын язды. Ниһаять, ул биредә читтән торып, Мәскәүдәге Максим Горький исемендәге Әдәбият институтын тәмамлады, СССР Язучылар союзы члены булды. Әдип Маликовның иң яхшы иҗади казанышлары, табышлары республикабызның нефть яклары, аның данлы кешеләре белән бәйле.

Әлмәткә килүенең беренче көннәреннән үк Әдип Маликов бу якларга гына хас кайнап торган тормыш агымына кушыла. Вахта машиналарына утырып, нефтьчеләр белән ерак буровойларга, промыселларга чыгып китә, салына башлаган катлы-катлы йортларның түбәләренә менә, көн саен дистәләгән эшчеләр белән очраша — булачак әсәрләре өчен яңа темалар, образлар, сүзләр эзли.

Без, түгәрәккә җыелган бер төркем яшьләр, юка гына гәүдәле, чандыр йөзле Әдипнең ул вакыттагы тырышлыгына, тынгысызлыгына, һәм энергиясенә сокланып, һич тә күзгә-башка ташланмый торган гап-гади нәрсәләрдән дә шигъри детальләр, тылсымлы образлар таба алуына гаҗәпләнеп бетә алмый идек.

Яшь язучы дип аталса да, шагыйрь Әдип Маликовның исеме, аның тормыш һәм иҗат юлы безгә яхшы таныш иде. Дөньяны күп күргән, «җир читенә аяк салындырып утырган». Башкортстанның Яңавыл районы Югары Чат авылында укытучы семьясында туган бу егет беренче шигырьләрен газета-журналларда сугышка кадәр үк бастырган. Бөек Ватан сугышында, разведка отделениесе командиры булып, Көньяк Сахалинны япон самурайларыннан азат итүдә катнашкан. Аның «Атаудагы хисләр» дигән беренче поэмасы да Ерак Көнчыгышта, сугышның кайнар эзләре өстендә язылган һәм 1945 елда «Совет әдәбияты» журналында чыккан. Армиядән демобилизацияләнеп кайту белән үк яшь шагыйрь Татарстан радиосында әдәби-драматик тапшырулар редакторы булып эшли, аннан яшьләр газетасының хәбәрчесе булып китә.

Әлмәткә килгәндә Әдип Маликовның газета-журналларда басылып чыккан дистәләгән шигырьләре, герой-шагыйрь Муса Җәлилнең Минзәләдә хәрби училищеда укыган вакытларын чагылдырган «Кайнар эзләр» исемле зур гына очеркы бар иде. Без, яшь язучылар, Әлмәткә бөтенләйгә торырга, эшләргә, иҗат итәргә дип килгән шагыйрьне шатланып, бертавыштан үзебезнең остазыбыз итеп кабул иттек.

Ул көннәрдә без әле барыбыз да шигырь язабыз. Һәммәбез дә яшьләр. Дәрт — бар, дәрман — юк дигәндәй, шигырьләребез дә абына-сөртенә, чатан-потан атлый. Ә остазыбыз, елмаюын яшерергә тырышып, зур түземлелек белән безне тыңлый, күзәтә, сыный. Вакыт-вакыт борчылып, баш түбәсенә таба тирән уелып кергән сирәк чәчләрен сыпырып ала...

Мин әле дә сокланып искә төшерәм: шул түгәрәктә утырган бер төркем яшьләрнең язучы булып китүләре өчен Әдип Маликовның никадәр сабырлыгы, таләпчәнлеге, акыллы киңәшләре кирәк булган!

Белүебезчә, остаз дигәнебез үзе дә шигырьләрен бик ансат кына язмый, туктаусыз эзләнә, өйрәнә, зур иҗат газаплары кичерә икән. Кайчакларда ул бөтенләй күздән югалып тора, өеннән чыкмый яза. Шулай бер вакыт, ул озак кына күренми торганнан соң, түгәрәк утырышына җыелдык.

— Минем бит әле бер нәрсә бар, шуны сезгә укып карыйм әле,— дигән булды, гадәтенчә, йөзенә тегенди-мондый билгеләр чыгармыйча.

Ул безгә үзенең әле яңа гына «табадан төшкән» «Ташчы» поэмасын укып китте:

**Бар иде ди Чупай тау,**
**Бөркет ял иткән куныл.**
**Эзләмәгез, тапмассыз,**
**Күчте ул шәһәр булып.**

Ташчылар бригадиры Касыймовка багышланган иде бу поэма. Түгәрәк членнары әсәрне хуплап, йотылып тыңладылар. Миңа — ул вакытта Мәхмүт ага Касыймов белән бер төзелеш идарәсендә, бер участокта эшләгән кешегә — бу поэма аеруча хуш килде. Шунда бинимаһая житез, тәбәнәк буйлы, кара тут йөзле, һәркемне яратып, үз итеп дәшә торган бригадирны күз алдына китердем. Кара син, шигырь юллары белән легендарь геройларны гына түгел, Касыймов кебек гап-гади эш кешесен дә менә нинди зур итеп, бөек итеп күрсәтеп була икән!

Әдип Маликовның «Гайшә апа», «Фәрданә», «Салкын алан», «Чигүле яулык» кебек поэмалары геройлары да үзебезгә таныш кешеләр арасыннан иде.

**Яшь этәч диярсең — корнетын**
**Кычкыртып җибәрсә Харитон.**
**Зыңгылдый тәрәзә — ялгышып,**
**Тон биреп куйганда баритон.**

Маликов, хәтта, кечкенә генә шигырьләрен дә, ничектер, ансат кына, тирә-юньнән конкрет җирлектән таба белә. Менә бу «Беренче оркестр» дигән шигырендә, мәсәлән, Әлмәт шәһәренең тууын, үсүен ул символик рәвештә шунда беренче оркестр оешу, яңа музыка туу белән тиңләп күрсәтә.

Бу елларда Ә. Маликов эшләде, бик күп шигырьләр, поэмалар иҗат итте. Һәм алар барысы да хезмәт кешесенә зур ихтирам һәм мәхәббәт белән сугарылган иде.

«Гайшә апа» поэмасында кешеләр өчен җанын бирергә әзер торган, киң күңелле ике милләт вәкиле — татар хатыны Гайшә апа белән рус хатыны Евдокия Ниловна образлары бирелә. Гайшә апа газ мичкәләрен ягучы кочегар булып эшли — үзенең күңеленнән алып та, хезмәте белән дә кешеләргә җылы өләшә.

Гайшә апа кайчандыр хәрби хезмәттәге ире белән чик буенда яшәгән, сугышны шунда каршылаган. Эвакуацияләнгәндә бомбага эләгеп үзенең бердәнбер улы Илгизен җуйган. Ләкин илебездә киң күңелле кешеләр аз түгел. Горький шәһәрендә Евдокия Ниловна аның Илгизен табып, үзенә ул итеп ала. Хәзер бу ике хатын, икесе ике җирдә яшәсәләр дә, бер-берсен онытмыйлар. Алар арасында дуслык җепләре өзелми, хат алышып торалар. Алай гына да түгел, Гайшә апаның улы тирән

җир астыннан чыгара торган газ Евдокия Ниловна яшәгән шәһәргә торба буйлап бара. Димәк, әле алар һаман да бер-берсенә яшәү җылысы биреп торалар. Шушы гади генә сюжетка корылган кечкенә поэмада ничаклы дуслык хисе, кешелеклелек, кечле образлар ята! Поэма 1959 елда журналда басылып чыгу белән авторны котлап, Сибгат ага Хәким хат яза: «Әдип дус! «Гайшә апа»ны укыдым, җыйнак, җылы, җырлы. Гайшә апаның язмышы да, бүгенгесе дә бар. Иң әйбәте — бербөтен хис кала, кайчандыр үзе әшегән, җаны туңган апаның кешеләрне шушылай җылытуы әйбәт. Ул җылының кадерен беләдер. Синең шигырьләрдән хәзерге Әлмәт сизелеп тора».

Гомумән, Әдип Маликов үзе дә остазларыннан бик уңды бугай. Аның иҗаты белән бик күп язучылар, шул исәптән Сибгат Хәким, Габдрахман Әпсәләмов, Фатих Хөсни, Мирсәй Әмир, Гали Хуҗиев, Мөхәммәт Садри кебек танылган шагыйрьләр һәм прозаиклар кызыксынып тора. Алар хатлар язалар, матбугат битләрендә чыгышлар ясыйлар, еш кына Әлмәткә килеп чыгалар, шагыйрь белән очрашып, аңа үзләренең фикерләрен әйтәләр, киңәшләрен бирәләр.

«Хөрмәтле Әдип туган! Яшьлек утравы» ошады миңа. Кереш алдыннан бирелгән кыска, ләкин төгәл һәм дөрес фикерләргә кушылган хәлдә, аларга өстәп, мин әле аны «намуслы китап» дип тә атар идем. Аның һәр юлыннан, һәр эпизодыннан, персонажларның хәрәкәтләреннән, башкарган эшләреннән намуслылык хисе бөркелеп тора. Ай, ясалма хисле купшы китаплар туйдырды, кызганычка каршы, бар бит алар да. Минемчә, бу китап татар әдәбиятында үзенә бер төрле хуш ис, кырыс җил бөркеп торучы «утрау» булып калыр, аңарга аяк баскан кешеләр башка бер җирдә дә таба алмаган яңа рәхәтлек табарлар. Ә бит бу һәрбер сәнгать әсәреннән сорала торган төп таләпләрнең берсе. Фатих Хөсни».

«Хөрмәтле Әдип туган!

«Яшьлек утравы»н мин журналда басылгач ук укып чыгып, бик яраткан идем. Әдәби әсәрдә мин факт дөреслегенә караганда әдәби дөреслекне беренче урынга куям. Юк исә бездә бит, аеруча очерклар жанрында, бик матур факт дөреслегенә нигезләнгән булып та, әдәби яктан ышандырмый торган әсәрләр була. Кызганычка каршы, андый әсәрләр еш кына очрый. Бу яктан синең прозаң бөтенләй яхшы якка аерылып тора. Синең прозаңда документаль дөреслек әдәби дөреслек дәрәҗәсенә күтәрелә. Бу инде һәр прозаикка да насыйп булмый торган бәхет. Мирсәй Әмир».

Менә шулай итеп, олы язучылар шагыйрьнең һәр әсәре белән кызыксынып, һәр даим аңа дәрт өстәп, илһам биреп торалар.

Әдип Маликовның иҗади үсешенә Әлмәткә Казаннан язучы Гариф Ахуновның күченеп килүе аеруча зур йогынты ясады. Гарифның яхшы прозаик булуы өстенә, сизгер тәнкыйтьче дә икәне безгә мәгълүм. Аның Әлмәткә килеп яши башлавы безнең барыбыз өчен дә зур бәхет иде. Әдипнең язылган һәр поэмасы, шигырьләре әдәби берләшмә утырышына кадәр Гариф белән икәүдән-икәү генә, кара-каршы утырып яхшы гына тикшерелгәнен беләидек. Әдип исә, мондый әңгәмәләрдән соң, үзенә генә хас сабырлык белән озак уйланып йөри, әсәрен кат-кат төзәтә, шуннан соң гына берләшмә утырышында яшь каләмдәшләре алдында укый.

1958 елда, әдәби берләшмә белән җитәкләүне Гариф Ахуновка тапшырып, шулай ук газета хәбәрчесе вазыйфасыннан да азат булып профессиональ эшкә күчкәч, Ә. Маликовның иҗат офыклары тагын да киңәя. Барыннан да бигрәк, тормышны өйрәнү өчен ерак араларга йөрү мөмкинлекләре туа. Юл — Ә. Маликовның хасияте, аның әдәби ризыгы, шатлык-куанычлары.

**Яратам матур яз айларын,**
**Һавада тургай сайравын.**
**Кырларга чыксам, шатлыгым арта —**
**Илтегез еракка, юлларым, юлларым!**

— дип тикмәгә генә җырламады ул.

Шушы елларда үзенең яшьлек эзләре, солдат каны сеңеп калган Сахалинга ике тапкыр барып кайту, Себер нефтен үзләштерергә киткән якташларыбыз сукмакларыннан Лена буйлап әйләнү, күп мәртәбәләр туган җире Башкортстанда булу ша-

гыйрьнең колачын зурайта, иҗат сулышын тирәнәйтә. Татарстан китап нәшриятында бер-бер артлы «Шигырьләр һәм поэмалар» (1964, 1967, 1971 еллар), «Таңбатыр», «Туган як моңнары», «Беренче оркестр», «Су ташучы аю», «Без кояшны юлда каршылыйбыз», «Кембригә юл», «Яшьлек утравым» китаплары чыгу рус телендә Мәскәүдә һәм Казанда басылган берничә әсәре, аның, һичшиксез, ул еллардагы тынгысыз хезмәте җимешләре.

Юл тәэсирләре белән язылган шигырьләрендә Ә. Маликов дуслыкның көчен, иң авыр чакларда да аның кешегә ярдәмгә килүен ышандырырлык итеп сурәтли. Бу, бигрәк тә, туган җирләреннән, сөйгән ярларыннан аерылып еракта яшәүче якташларыбыз мисалларында ачык чагыла. Авторны аеруча тетрәткәне — әлбәттә, аның яшьлек истәлекләре, солдат булып узган юллар. «Унбер каска», «Җир читенә очсам да», «Атауга соңгы сүз», «Чайка Пойтан» кебек шигырьләрендә Әдип — солдат әле һаман да походта, тынычлык сагында, Ватан-ананың тугрылыклы улы.

Ә. Маликов әсәрләрендә төп урынны хезмәт романтикасы алып тора. Аның геройлары — бораулаучылар, операторлар, төзүчеләр. Сүз дә юк, татар поэзиясенә нефтьчеләр образын беренчеләрдән булып Ә. Маликов алып килде.

Шунысы куанычлы: шагыйрь иҗади яктан әсәрдән-әсәргә үсә бара, поэмаларның сюжет-композицияләре дә, психологик нигезләре дә бөтенәя, ныгый. Шагыйрьнең уңышлары белән шатланган С. Хәким үзенең бер рецензиясендә: «Фәрданә» исемле поэма миндә тагын да яхшырак фикер калдырды. Монысында нефть эзләүче разведчик Сәйранның мәхәббәте ниндидер романтика белән өретелгән.» — дип язды. Хәсән Туфан, Әнвәр Давыдов, Хисам Камалов, Рәшит Гәрәйләр дә Әдип Маликовның бу елларда язылган шигырьләрен һәм поэмаларын мактап телгә алдылар.

Поэзиядә генә түгел, үзенең каләм иясе икәнен Әдип Маликов проза жанрында да күрсәтә килә. Аның төрле елларда язылган «Су ташучы аю», «Без кояшны юлда каршылыйбыз», «Кембригә юл» исемле китаплары һәм күп кенә очерклары шул хакта сөйли.

Мин үзем шагыйрьләрнең прозасын яратып укыйм. Алар фикерләрен тыгызрак итеп, образлы итеп әйтә беләләр. Аларның чәчмә әсәрләрендә, ничектер, эчке моң, лирика, аһәң булучан. Бу — Әдип Маликовта да шулай.

Аның 1973 елда күләмле проза әсәре — «Яшьлек утравым» повесте басылып чыкты. Монда герой — автор үзе. Ул чынбарлык бизмәнен дөрес тигезләгән яшь солдат Әхнәфне, чирләшкә булуына да карамастан, азатлык хакына, киләчәк буыннарга тынычлык алып килү хакына тешләрен кысып түзәргә, чыдарга мәҗбүр иткән. Әсәрнең бөтен тозы, орлыгы да шунда, минемчә.

Ә. Маликовның поэзиясе турында да, прозасы хакында да уйланырлык нәрсәләр күп. Ул кырык ел гомерен әдәбиятка багышлады, аны яңа тема, яңа образлар белән баетуда үзеннән зур өлеш кертте. Аның шигырьләре, поэмалары һәм проза әсәрләре җентекләп тикшерелүгә, өйрәнүгә, ниһаять, үз бәяләрен алуга лаек.

Менә, гомерләр! Әле күптәнме соң, Әлмәтнең караңгы кезендә беренче әдәбият түгәрәге оештырды, үзенең шәкертләре алдында җилкенә-җилкенә бу төбәктә язылган беренче шигырьләрен, беренче поэмаларын укыды. Әле күптәнме соң ул Әлмәттә яңа квартира алды, дуслары белән шушында өй туйлары уздырды, тормыш иптәше Саҗидә Сөләйманова белән, шатлана-шатлана, яңа туган улын күтәреп кайтты... Карыйсың, чирек гасыр узган, кешегә инде алтмыш яшь... Гомер кыска шул — аның һәр сәгате, һәр минуты үлчәнгән.

Такташның: «Ә авыл һаман катык ашый...» дигәне сыман, без дә әйтә алабыз: ә Әлмәт һаман шулай яшь. Әлмәттәге әдәби хәрәкәт элеккегечә үк хәрәкәт итә. Ай саен диярлек шәһәрнең үзеннән, Лениногорскидан, Азнакайдан, Баулыдан, Сарманнан, Мөслимнән һәм башка нефть районнарының башка төбәкләреннән җыелган яшь язучылар, шау-гөр килеп үзләренең яңа әсәрләрен тикшерәләр, киләчәккә планнар коралар, бәхәсләшәләр... Кыш уртасы җитү белән Әлмәт язучылары оешмасында ел йомгаклары буенча җыелыш уздырыла, ә өч ел үтүгә оешманың отчет-сайлау көне җитә....

Оешма кечкенә түгел — дистәдән артык профессиональ язучыны, иллеләп яшь каләмнәрне туплаган. Бу — илебезнең күп кенә өлкәләрендәге язучылардан артыграк. Әлбәттә, хикмәт санда түгел, эшнең нәтиҗәсендә. Без моңа шаһит итеп, Әлмәт

язучылары тарафыннан егерме биш ел эчендә иҗат ителгән 170 тән артык китапны күрсәтә алабыз. Оешмада төрле жанрларда эшләүче, әдәби алымнары белән генә түгел, гадәтләре, холык-фигыльләре, белән дә төрле язучылар бар. Җитәкче кешедән мондый шартларда, иҗат әһелләренә карата югары таләпчәнлек белән бергә, үтә сизгерлек тә, яхшы иҗади атмосфера тудыру да сорала. Оешманың җаваплы секретаре Татарстанның атказанган культура работнигы, Әлмәт шәһәр Советы депутаты шагыйрь Әдип Маликов инде бу вазыйфаны ун ел буе уңышлы үти килә.

«Алтмыш яшь — шагыйрьне яшьлеге»,— дип шаяртырга яратабыз. Бәлки ул шулайдыр да. Шагыйрьләр картайсалар да аларның язганнары картаймый, әдәбият картаймый. Минемчә, алтмыш яшь ул кисәтә кебек: «Чебешләрне санау вакыты җитте. Син тормышыңда ниләр әйтеп бетерә алмадың, әле соң түгел, әйтергә ашык!» — ди сыман.

**Шамил БИКЧУРИН.**

# ИБРАҺИМ САЛАХОВКА 70 ЯШЬ

Ибраһим Салахов — Казагыстанда туып-үскән каләмдәшләребезнең берсе. Ибраһим белән мин бала чакта ук, гаиләбез Күкчәтау шәһәренә күчеп баргач, таныштым. Шәһәрнең җидееллык татар мәктәбендә бишенче класстан башлап бергә укыдык.

Ибраһим Салахов бала чактан ук әдәбият белән кызыксына, үзе дә шигырьләр, хикәяләр язарга ярата икән. Минем белән дә ул фәкать сәнгать, әдәбият сөюче булганга күрә дуслашып китте дисәм ялгыш булмас. Чөнки без икебез ике төрле холык-фигыльле үсмерләр идек: ул һәр вакыт җитди, акыл белән эш итәргә ярата, ә мин исә шаян табигатьле идем.

«Ак юл», «Сөембикә», «Аң» журналларын кат-кат актару-укулар, алардагы шигырьләрне күчереп алулар, классик сәнгать әсәрләре күчермәләренә карап сокланулар, үзебезне дә әлеге бөек рәссамнарга һәм язучыларга беркадәр мөнәсәбәтле дип хис итүләр...— ахрысы безнең араны әнә шулар якынайтты булса кирәк.

Тыныч, айлы төннәрдә Күкчәтау урамнарында мандолина уйнап йөрүләр, сөйгән кызларга мәхәббәт хатлары язып, аларны бер билгеле урында — таудагы таш асларына куеп калдырулар һәм шуннан ук җавап алулар... болар барысы да гади әйберләрне әкияттәге кебек бизәп, гадәттән тыш итеп күрер өчен кирәк булгандыр, күрәсең.

Без Ибраһим белән Күкчәтаудан ерак түгел Мола-чокы дигән урынга барырга ярата идек. Анда гаҗәеп манзара: ай-далада офыкка барып тоташкан тигезлектән кинәт калкып күтәрелгән таш кыялар һәйкәл сыман басып торалар. Ак болытлы зәңгәр күктә канат какмыйча гына, сөзелеп очып йөргән тилгәннәр тавышы тирәяктагы тынлыкка ниндидер серле бер моң бирә. Без кыяга күтәреләбез. Анда берберебезгә үзебез язган шигырьләрне укыйбыз: мактыйбыз, тәнкыйтьтә итәбез, ничек тә һәр вакыт уртак тел таба торган идек. Менә мин кыя ташына төрле буяулар белән рәсем ясый башлыйм. Ибраһим, бик зур игътибар белән, һәр хәрәкәтемне күзәтә. Бу вакытта ул соклануын яшерми. Без әнә шулай: ул — миңа, мин аңа сокланып үстек. Икебез дә төзәлмәслек романтиклар идек шул.

Көз җитеп, укулар башлану белән җидееллык татар мәктәбе шәһәр халкының мәдәният йортына әйләнә. Монда инде Ибраһим җиң сызганып җәмәгать эшләренә чума. Ул — учкомда, ул — комсомолда, ул — безнең әдәби түгәрәкнең кульязма журналы редакторы, ул — төрле кичәләрнең оештыру эшләрендә иң актив җитәкчеләрдән берсе...

Мәктәптә кичәләр бик еш оештырыла: анда традицион бәйрәмнәрдән тыш язучыларыбызның юбилейлары үткәрелә, аларның әсәрләреннән инсценировкалар, әзекләр башкарыла, мондый кичәләрдә мәктәп халык белән шыгрым тулы була иде.

Көнбатыш әдәбиятына безне беренче булып җитәкләп килгән укытучыбыз Габдрахман ага Яхинның гаять хөрмәтле хезмәте турында да бу уңай белән искә алып үтү бик урынлы булыр. Ул безне, мәктәп программасыннан тыш, Шекспир, Шиллер, Байрон, Гейне, Пушкин, Толстой һәм башка бөек исемнәр белән танышу шәрәфенә ирештерде. Ул үзе дә яшертен генә, тыйнак кына яза торган кеше иде. Аның «Урман кызы» драмасы шул вакытларда Казан, Татарстан сәхнәләрендә куелып та йөрде һәм, ялгышмасам театрыбыз тарихына да кереп калды шикелле. Ибраһим белән без Габдрахман абзыйның игелекле йогынтысы тәэсирендә яшибез, аны остазыбыз итеп хөрмәтләп яд итәбез.

Күкчәтау еллары үткәч — ягъни, андагы мәктәпне тәмамлап, без Ибраһим белән Казанга килдек. Ул педагогия, ә мин сәнгать техникумына укырга кердек. Казанда Ибраһим Салаховның иҗади активлыгы артканнан артты. Ул төрле редакцияләрдә эшли башлады һәм бер-бер артлы әсәрләр бастыра килде. Элек «Ярату» исемле сәхнә әсәре дөнья күрде. Аннан «Дуэль» повесте. һәм «Сакта» (1973 ел) дигән шигырьләр җыентыгы басылып чыкты. Казан педагогия институтында укыганда Ибраһим Салахов «Мәхәббәт һәм өмет» исемле повестен тәмамлады.

Төрле сәбәпләр аркасында язучылык хезмәте тоткарланып торганнан соң, Ибраһим Салахов 1957 елда «Дала дулкыннары» дигән яңа шигырьләр китабын укучыларга тәкъдим итте. Ә аннары чирәм җир каһарманнарын сурәтләгән «Күкчәтау далаларында» романы дөнья күрде. Соңрак ул «Мәхәббәт картаямы?» повестен язды. Ул элек «Казан утлары» журналында басылды, аннары аерым китап булып чыкты.

Югарыда саналганнардан тыш, Ибраһим Салаховның күп кенә хикәяләре, легендалары, бигрәк тә казакъ халкы тормышыннан алып язылган әсәрләре, татар газета-журналлары белән бер рәттән, Казагыстанда чыга торган газеталарда бер-бер артлы басыла киләләр. Соңгы елларда язучы Ибраһим Салахов үзенең күптәнге хыялына — «Имәннәр тамыр җәйгәндә» исемле тарихи трилогиясен язып тәмамлауга ирешә.

Миңа соңгы елларда, Күкчәтауга кайткан чакларымда, һәрвакыт күңелле күренешләрнең шаһиты булырга туры килә. Без урамнан барганда юлыгучылар, бигрәк тә казакълар:

— Әссәламегаләйкум, акын ага! — дип Ибраһимны сәламлиләр. Көнчыгыштагыча катлаулы һәм озак итеп хәл-әхвәл сорашып, чиксез изге теләкләрен белдергәннән соң: «Сезнең чыгармаларыгызны (ягъни әсәрләрегезне) укып барабыз, рәхмәт, телегезгә чичәнлек, күңелегезгә хаклык иңсен!» — дип калалар. Тормыш-көнкүреш, гаилә мәсьәләләре буенча төрле гаризалар җәһәтеннән дә, хәзер инде белемле кешеләр җитәрлек булуга да карамастан, аңа керәләр. Ибраһимның кеше сүзен кире какмавы, кулыннан килгән ярдәмен кичектермичә, авырсынмыйча күрсәтергә әзер торуы да, әлбәттә, гади кешеләр күңелен үзенә җәлеп итәдер. Бу — язучыга хас сыйфатларның иң гүзәле, иң мөһиме.

Ибраһим Салаховка җитмеш яшь тулды. Без аның барча чордашлары, кордашлары, күп санлы укучылары исеменнән, каләмдәш дустыбызга чын күңелдән сәламәтлек, күңел күрлеге, иҗат уңышлары телибез. Үзе «Мәхәббәт картаямы?» дигәндәй, кешеләргә, тормышка, кадерле иҗат эшенә мәхәббәте бер дә картаймасын!

Нури **АРСЛАНОВ.**

# КОНСТАНТИН ЛЕБЕДЕВКА 60 ЯШЬ

Укучыларга үзенең ике әсәре — «Сынау көннәре»[1] һәм «Кешеләр һәм дәрәҗәләр»[2] исемле романнары белән билгеле. Бу романнарның беренчесе, исеменнән үк аңлашылып торганча, халкыбыз иңенә төшкән дәһшәтле сынау — Бөек Ватан сугышы көннәрендә совет интеллигенциясенең тормышын һәм хезмәтен сурәтләүгә багышланган. «Кешеләр һәм дәрәҗәләр» романының төп геройлары — медицина институты укытучылары һәм студентлары. Аларның катлаулы язмышларын, үзенчәлекле үзара мөнәсәбәтләрен тасвирлау аша язучы мөһим әхлак мәсьәләләрен күтәрә, совет кешесенең мораль-этик хокуклары җәмгыятьтә тоткан урын-дәрәҗәләргә бәйле рәвештә үзгәрергә тиеш түгел, дигән фикерне раслый. «Кешеләр һәм дәрәҗәләр» әсәрендә шулай ук югары уку йортлары алдында торган бик әһәмиятле проблемаларның берсе — яңа фәнни алмаш тәрбияләү мәсьәләсе дә үзәккә куела. Әлеге роман, «Знамя» журналында басылганнан соң, аерым китап булып Мәскәүдә басылып чыкты.

Константин Лебедев — күп санлы хикәяләр һәм галимнәр турында кызыклы очерклар авторы. Аның барлык әсәрләрен тормыш чынбарлыгына актив мөнәсәбәт, зур гомумиләштерү осталыгы һәм үзенчәлекле язу стиле берләштерә.

Язучының иҗатында шәхси биографиясе дә зур роль уйный. Ул асылда үзе яхшы белгән тормыш материалына таяна, геройлары йөзендә замандашларыбызның кабатланмас чалымнарын гәүдәләндерергә омтыла.

Константин Васильевич Лебедев тумышы белән күрше Чувашстан республикасыннан булса да, язмыш аны 1940 елларда ук Казан каласы белән бәйли. Нәкъ шул чорда ул Казан дәүләт медицина институтының дәвалау факультеты студенты булу бәхетенә ирешә. Дөрес, Лебедев башта Мәскәүдәге элемтә инженерлары институтында укый башлаган була, ләкин акфиннәр белән башланган сугыш аңа бу уку йортын тәмамлап чыгарга комачаулый. Канлы бәрелешләрнең берсендә яшь егет каты яралана...

Казан медицина институтында белем алып чыккач, К. Лебедев Эчке эшләр министрлыгы гаскәрләрендә врач булып хезмәт итә, институтта укыту һәм фәнни-тикшеренү эшчәнлеге белән шөгыльләнә, медицина фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗәгә ирешә. Язучының әдәби иҗат өлкәсендәге уңышлары да шул елларга туры килә.

[1] Дни испытаний. Роман. 2 нче төзәтелгән басмасы. Казан. 1962

[2] Люди и степени. Роман. М., «Советский писатель», 1968.

# РӨСТӘМ ЯХИНГА 60 ЯШЬ



Ул кичне консерваториянең актлар залында кеше аеруча күп иде. Җанлы сөйләшүдән, инструментларны әзерләүдән туган күпсанлы авазлар кичәгә бәйрәм рухы өсти, музыка белән очрашуга омтылышны торган саен көчәйтә. Ниһаять, залда урнашкан тантаналы тынлыкны бүлеп: «РСФСРның һәм ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Рөстәм Хаҗиевич Яхинның авторлык концертын башлыйбыз...» — дигән сүзләр яңгырады.

Бу талантлы композиторның исеме 40 нчы еллар уртасында ук музыка сөючеләрнең игътибарын үзенә җәлеп итте. Аның Г. Тукай һәм Ә. Ерикәй сүзләренә язган «Кем белер кадереңне» һәм «Тургай» исемле беренче романслары, фортепьяно һәм скрипка өчен сонаталары үзенчәлекле яңа композитор туып килүе турында сөйлиләр иде. Нечкә лиризм белән сугарылган, дәртле, күтәренке хисләр белән өретелгән көйләре тиз арада меңнәрчә тамашачылар күңелен яулап алды.

Р. Яхинның башкару эшчәнлеге, пианинода уйнау осталыгы да аның иҗатына үзенчәлекле төсмер өстәде. Ул илебез буйлап гастрольләрдә йөрү бәхетенә ирешкән беренче татар профессиональ пианистларыннан берсе булды.

Композитор, нигездә, фортепьяно һәм җыр музыкасы иҗат итә. Аның фортепьяно миниатюраларындагы төзеклек, музыкаль тел сафлыгы, гармониялелек һәм нәфислек илебезнең иң күренекле башкаручыларын да үзенә карата. Ә фортепьяно өчен язылган концерты пианистларның концерт репертуарында аерым урын алып тора. Республикабыздан читтә татар музыка сәнгатенә багышлап үткәрелгән иң җаваплы концертларның барысында да диярлек Яхинның бу әсәре яңгырамый калмый. Милли моң белән сугарылган бу концерт Мәскәүдә һәм Каракалпакстандагы татар әдәбияты һәм сәнгате көннәрендә дә, Татар дәүләт филармониясенең симфоник оркестры гастрольләре вакытында да йөз меңнәрчә тамашачыларның ихтирамын казанды.

Композиторның җырлары да халык тарафыннан яратып кабул ителде. Җыр өлкәсендәге осталыгын ул беренче адымнарыннан ук күрсәтте. Аның җырларын камера әсәрләрен башкаручылар да, танылган эстрада җырчылары да, үзешчәннәр дә яратып башкара. Р. Яхинның җыр иҗаты өлкәсендәге иң зур әсәрләреннән К. Даян сүзләренә язылган «Урал» кантатасы һәм М. Җәлил сүзләренә язылган «Моабит дәфтәреннән» вокаль циклы санала.

Композитор безнең музыкада беренчеләрдән булып хәзерге заман татар романсларын иҗат итте. Р. Яхинның бу жанр музыкасы аеруча ягымлы, һәркемнең йөрәгенә үтеп керерлек. Андагы хисләр һәркем өчен гади һәм аңлаешлы. Романс жанрына ул музыка училищесында укыган елларында ук мөрәҗәгать иткән иде. «Кем белер кадереңне», мәсәлән, үзенең искиткеч моңы һәм гадилеге, фикер төгәллеге белән аерылып тора. Бу әсәр композитор иҗатында иң якты сәхифәләрнең берсе булып калды.

Р. Яхинның җыр иҗатындагы табышлары башка жанрларда эшләгәндә дә чагыла. Мәсәлән, дәртле, дулкынландыргыч күтәренкелек белән сугарылган «Күңелемдә яз», «Күңелем өзгәләнгән минутларда» кебек романслардагы музыкаль үзенчәлек-

лар — фортепьяно өчен язылган концертның беренче кисәгендә, «Онытa алмыйм» романсындагы лирик кичерешләр — «Шигъри картина», «Поэма», «Элегия» кебек фортепьяно өчен һәм инструменталь пьесаларда. «Үзең аңла», «Сине көтәм» кебек романслары исә халык иҗаты аһәңнәренә бик бай.

Композитор җыр текстларын бик күп шагыйрьләр иҗатыннан ала. Анда татар поэзиясе классигы Г. Тукай, герой-шагыйрь М. Җәлил шигырьләрен дә күрәбез. Ул хәзерге заман шагыйрьләре әсәрләренә дә еш мөрәҗәгать итә. Бигрәк тә М. Ногман, З. Нури, М. Хөсәен, Х. Камалов һәм башка авторларның сүзләренә күп романслар язды.

Р. Яхин әсәрләрендә якты, матур шигъри дөнья ачыла. Ул көчле лирик хисләр белән бизәлгән. Романслардагы төп тема — ярату, мәхәббәт темасы. Ә аларның эчтәлеген исә лирик геройның саф һәм тирән кичерешләре, мәхәббәте белән очрашу теләге, аерылышу, кавышулар, сагыну хисләре тәшкил итә. Бу хисләрнең һәммәсе үзенчә ачыла, аларда моңарчы ишетелмәгән төсмерләр, үзенчәлекле нәфис музыкаль авазлар бик күп. Аның эмоциональ яктан катлаулы, нечкә хисле геройларында романтик композиторлар иҗатына хас төсмерләр дә шактый. Әмма романтик композиторларның әсәрләрендә төп каһарманның эчке кичерешләре, хыяллары билгесезлеккә омтылса, Р. Яхин романсларының герое заман сулышын тоеп, көр күңел белән яши.

Композиторның иҗаты һаман үсештә. Аны кызыксындырган темалар көннән-көн киңәя бара. Әсәрләренә гражданлык белән сугарылган фәлсәфи темалар үтеп керә. Муса Җәлил сүзләренә язылган «Яулык» романсында, мәсәлән, Ватанын саклап көрәшүче патриот сугышчы гына түгел, ә шагыйрь дә, җырчы да булган каһарман кичерешләре гәүдәләнә.

Гражданлык рухындагы романслар эчтәлеге белән фәлсәфи-лирик планда язылган әсәрләргә бик охшаш. Шагыйрь образы, мәсәлән, аның тормышта тоткан роле, иҗатының әһәмияте турындагы фәлсәфи уйланулар белән үрелеп бара һәм бу хәл әсәрне вокаль монолог жанрына якынлаштыра. Шуңа күрә дә Р. Яхин Тукай иҗатына еш мөрәҗәгать итә. Аны шагыйрьнең лирик уйланулары, фәлсәфи монологы җәлеп итә. Лирик-интим эчтәлекле романсларда бер генә хис-кичереш үстерелсә, фәлсәфи-лирик романсларда — мәсәлән, Г. Тукай сүзләренә язылган «Күңел йолдызы» романсында — сагышлы кичерешләргә өметле-оптимистик уйлар каршы куела. Алдынгы карашлы шагыйрьне кара көчләр эзәрлекли, ләкин ул аларга бирешми, үзендә көрәшерлек, җиңәрлек көч таба.

Р. Яхин иҗатының фәлсәфи һәм гражданлык күтәренкелеге лирик нигездә үсеп чыкты. Бу бәйләнеш аның гражданлык лирикасына үзенчәлекле юнәлеш бирә, фәлсәфи теманың шигъри яңгырашына ирешергә мөмкинлек тудыра. Көчле кичерешләр дулкынындагы лирик герой үзенә хас сыйфатларны югалтмый, ләкин ул инде дөньяны тирәнтенрәк аңлый, тормышта актив хәрәкәт юлын сайлый.

Р. Яхинның уңышы тагын шунда, ул романс жанрын күнегелгән кысалардан киңрәк мәйданга алып чыкты. Шуңа күрә аның җырларын профессиональ артистлар гына түгел, үзешчәннәр дә яратып башкара. Күп кенә җырлары исә бөтенләй халыкчалашып китте. Ул беренчеләрдән булып халкыбызның озын көйләрендә милли романс яралгыларын күреп алды. Романсларның интонацион төзелешендә дә халык җырларына якынлык сизелә. Ул интонацияләр еш кына тирән шигъри кичерешләрне үстереп җибәрүче башлангыч булып тора. Шул ук вакытта композитор романс көйләренең лирик төзелешенә күтәренке эмоциональлек, тизлек, тойгылар ачыклыгы өстәде. Аның романсларына фольклор әсәрләре генә түгел, ә башка музыка әсәрләре дә уңай йогынты ясады. Р. Яхинның моңлы стилендә мәсәлән, рус композиторлары Чайковский, Рахманинов романсларыннан килгән традицияләр дә үзенчәлекле милли яңгыраш тапты. Аның романсларына хас интонацион төзелештә бүгенге көн авазы, заманча фикер куәте нык сизелә. Бу бигрәк тә гражданлык рухындагы романсларга хас. Шундый интонацияне Яхин шагыйрь Муса Җәлил сүзләренә язылган «Җырларым» романс-монологында аеруча уңышлы кулланды.

Инде күптән үз тавышын, үзенчәлекле стилен тапкан талантлы композитор иҗатына таләпчәнлекне бүген дә киметми, ирешелгәннәр белән канәгатьләнеп калмый.

Аның соңгы елларда иҗат ителгән әсәрләре музыка сәнгатебезне яңа образлар, кабатланмас сурәтләү чаралары белән баетты. Бу бигрәк тә «Туган илем» һәм Р. Харис сүзләренә язылган «Кояшлы яңгыр» исемле вокаль циклларда ачык чагылыш тапты. Рөстәм Яхин безне киләчәктә яңадан-яңа әсәрләре белән сөендерер әле.

Гүзәл **ВАЙДА-СӘЙДӘШЕВА.**

## Укучының күңел дәфтәренә

**Әрмән мәкальләре һәм әйтемнәре**

*Юлга юлдашсыз чыкма.*
*Хезмәттән башка эш юк.*
*Йомырка урлый белүче атны да урлый ала.*
*Пеләш зат дәвалый белсә — үз башын чәчле итсен.*
*Теш ул безгә бик кирәк, ә авыртса суырабыз.*
*Теш казап тамак туймый.*
*Тасма тел тик торалмый.*
*Сине куып су акмаса, су артыннан үзең чап.*
*Томанлы көн — бүрегә шатлык.*
*Тату яшәү, тыныч тору — барча яхшылыкка әнкә.*
*Ерак туганың булганчы, яхшы күрше белән тор.*
*Дөя үз өркәчен күрми.*
*Язын бәрән, көзен чебеш яхшы.*
*Авызыңны ачканчы ук, күзләреңне ача бел.*
*Һәркем караган вакыт беркемгә дә карамый.*
*Су янында агач тизрәк үсә, ләкин тизрәк картая да.*
*Чит илгә киткән чагында андагыдай бүрек ки.*
*Бүредән курыксаң — сарык асрама.*
*Диңгезләр кичкән кеше елга суында батмый.*
*Аты юк, ә дага эзли.*
*Кечкенә кешеләргә дә бик зур төшләр кергәли.*
*Тәүге йомыркасын күреп тавык үзе дә көлә.*
*Аска үзем утырмыйм, ә өстәрәк урын юк.*
*Бер башмакка ике аяк тыга.*
*Җәяүле җайдактан көлә.*
*Өскә төкерсәм — кашым, аска төкерсәм — сакал.*
*Бала елан тотыйм дисәң, башта олысын үтер.*
*Әбәт үткәч ботка бәя булмый.*
*Югалса, чәч бөртегең дә баудай булып күренә.*
*Балык әле суда йөзә, ә таба утка куелган.*
*Үзен үстереп чыгарган йомырканы яратмый.*
*Карга күзенә күренсә, бөртек шытып чыгалмый.*
*Авыздагы сүз — синеке, авыздан чыкса — ят сүз.*
*Гадел кеше кыл булса да өзелмәс, бүрәнәдән юан ялганчы да — сынмыйча калмаячак.*
*Әгәр каенана икәнсең — тик бер күзең белән күр дә бер колак белән ишет.*

## Нури Арсланов

### Юмарт дуслар

И юмарт та минем дуслар:
Сыйлыйлар исерткәнче,
Ис-акылларым киткәнче,
(Акчаларым беткәнче!)
Таякларым югалганчы,
Хәтерләр чуалганчы,
Өчәр ай җикмәслек итеп
«Атларым» туарганчы.

Туарылдым, туарылдым,—
Җигәрләр әле тагын,
Җиңелмәм дип тәүбә кылдым,—
Җиңәрләр әле тагын...

Иске җыру бар шул хакта:
«Карурманнан чыккан чакта
Атлар төшми елгага.
И-и-и, дус-иш кирәк дөньяда...»

## Гәрәй Рәхим

### Битараф бәндәгә

Бик кирәк чагында
Йөрәгем таш минем.
Дошманга бер суксам,
Һичшиксез үтерә.

Йөрәгем — тере су.
Дусларга өләшсәм,
Терелтеп җибәрә
Һәм мең кат үстерә.

Ә менә син, бәндә,
Ни дошман түгелсең,
Ни бер дус түгелсең.
Йөрәкне бирсәм син — үсмисең.
Ә суксам — үлмисең.

## Фаил Шәфигуллин

# ЧИРАТ

Ашыкмагыз, җәмәгать, хәзер барысын да чираты белән сөйлим. Искәрдегезме? Мин сүзләрне чират белән әйттем. Ә чират белән әйтмәсәм нәрсә булыр иде? Мәгънәсе калмас иде сүзләрнең. Хәер, чират булмаса, тормышның мәгънәсе булыр иде микән? Булмас иде, мөгаен.

Мисал өчен менә сезне генә алыйк. Сез монда кергән чагында чират белән кердегез. Һәммәгез дә түгел, билгеле. Әнә, урта рәттә утырган ике ханым икесе бергә кереп кысылдылар ишек кысасына һәм бер-берсенә тирә-юньдәге кешеләрнең колак яфраклары кызарырлык сүзләр әйттеләр.

Әле бүген монда килергә чыккач, автобус тукталышындагы халыкны чиратка тезәргә тырышып караган идем. Тезелүен тезелде халык, әмма ләкин автобусы килмәде. Баксаң, автобусларны чиратка саласы бар икән әле башта. Юри искәреп тордым: маршрутта йөри торган автобусларга караганда, маңгайларына «По заказу» яисә «Обед», яисә «В парк» дигән язу элеп, чиратсыз элдерә торган автобуслар күбрәк икән ләбаса шәһәрдә.

Быел безне яңа микрорайонга күчерделәр. Менә кайда ул гүр тынлыгы, менә кайда ул первобытный тормыш. Өйрәнелгән гадәт буенча таң тишегеннән торасың чиратка басыйм дип — бер үзеңә бер туалет! Ишек төбендә ник бер адәм заты тыпырдап торсын! Юынырга чират алыйм, дип юынгыч янына киләсең — берәү дә юк. Газ плитәсе янына киләсең чират алыйм дип — берәү дә юк, ник шунда дүрт комфоркага дүрт кәстрүл куеп аш пешермисең!

Иртән ашап-эчкәндә, әниләр өстендә утыргандай, дерт-мерт итеп, әле бу тәрәзәгә, әле теге тәрәзәгә карыйсың, кайсы кибет янына җыелыр икән чират, дисең. Юк, җыелмый чират. Буш ындыр табагына кергәндәй, керәләр дә чыгалар кешеләр кибеткә, керәләр дә чыгалар...

Бүген дә урамда шундый күңелсез хәлдер инде, дип, тәрәзәгә күз салган идем, җәмәгать — әнкәйкәчкенәем — чират! Юк дисәң дә бар икән ул ходай, бер ачылмаса да бер ачыла икән ул күк капусы. Туктале, ялгыш күрмимме? Ялгыш түгел. Теп-тере чират! Походка чыккан гаскәр кеби бормаланып-бормаланып тезелеп киткән, мин сиңа әйтим. Ашыгудан тешләремне дә кияргә онытып, күлмәк-ыштаннан гына йөгереп чыктым урамга, килгән хутка чиратка бастым, килгән хутка ике кеше белән чәкәләшеп алдым.

Төш җитәрәк сатучылары да күренде. Сатучылар күренгәч, артымдагы күзлекле карчыктан:

— Ни саталар икән, белмисезме? — дип сорадым.

— Бомарше, — дип иреннәрен бөрештерде күзлекле карчык.

Еректан тартма кебек күренгән иде, килеп җитәрәк кенә шәйләдем: китап икән, шуны, бомарше, диләр икән.

Ничек кирәк алай, этешә-төртешә, ызгыша-талаша, өч бомарше сатып алдым да яңадан чират койрыгына барып бастым. Бәхетсезлеккә каршы, мин икенче кат барып җиткәнче бомарше бетте, бомарше беткәч, чират та таралды.

Шулай аптырабрак торганда, чатка күзем төште. Чират бит, билләһи, тагын чират! Бер ачылса ачыла икән ул бәхет! Каушавымнан бомаршеларымны төшереп җибәрә яздым.

Урам аша атылып чыксам, чират белән билет сатып яталар. Калтыраплар гына төштем инде. «Кая, — мин әйтәм, — кем актык? Ничәшәрне бирәләр?»

Күңелле генә чират торып, ике-өч кеше белән чәкәләшеп, дигәндәй, Харлампиев концертына җиде билет эләктердем.

Кайтыйм инде, дип чаттан борылуым булды,— әнкәйкәчкенәем — тагын чират! Йөгереп бардым. «Кая? — мин әйтәм.— Кем? Нәрсә?» Харлампиев концертына алган билетларны кассага кире тапшыра икән халык. Мин дә мөгезле түгел, кеше тапшырганда нишләп авыз ачып калыйм, дип фараз кылдым да чират уртасына бәреп кердем. Арттагыларның «чиратсыз керде, нахал!» дигән гыйбарәләрен тыңлый-тыңлый, «чиратсыз кермәсәм, чиратыгызның яме булыр идеме соң?!» дип эчемнән генә пырдымсыз халык белән бәхәсләшә-бәхәсләшә, тәрәзә янына барып җиттем, билетларның җидесен дә саттым.

Нәфес котырып җитте. Инде нишләргә? Туктале, бәлкем үземә башлап йөрергә, үземә инициатива күрсәтергә кирәктер. Һаман-һаман әзергә-бәзер, кеше җыйган чираттан файдаланып яшәргә ярамас. Азрак оят белергә кирәк.

Шулай уйлый-уйлый хуҗалык кибетенең йозаклы ишегенә барып сөялдем. Озакламый, минем артка тавышсыз-тынсыз гына шадра йөзле бер ир-ат килеп басты, аннары күрше подъезддан берьюлы берничә карчык чыкты, чират, минуты-сәгате белән үсеп, күзләремне иркәли башлады. Иренмәсәң була шул, миңеке бит бу, мин җыйган чират, дип куанып торганда, чират койрыгыннан әзмәвердәй бер адәм аерылып ишек төбенә килде, йорт түбәсенә тияр-тимәс очып үткән аэроплан тавышлары чыгарып гөрелдәде:

— Нәрсә сатачаклар? Белеп бастыгызмы? Кем әйтте?

Бәладән баш-аяк. Чират өчен җан атып йөрүеңне аңламас — тәпәләп ташлар.

Әзмәвернең карбыз зурлыгы йодрыкларына карап алдым да, күңелле генә дулкынланган чиратка кул болгап, автобус тукталышына юнәлдем.

Аэроплан дигәннән, аэропортка барып карыйм әле. Анда көне-төне чират өзелми, дигәннәр иде.

# КОРТ ЧАККЫРЫ

Кеше күрәчәген күрми гүргә керми, дигәндәй, шулай җәйге матур көннәрнең берендә, колхоз кладовщигы булып эшләгән чорымда, гөнаһ шомлыгына каршы, бер дә кирәкмәгәнгә дисәм, дөрес булып бетмәс, яшь бухгалтер Нәкыянең нурлы йөзен күреп чыгыйм дип, колхоз идарәсенә төшәсе иттем. Барып керсәм бухгатлерия ягына — эт тә юк. Өстәлләрдә исәп-хисап кәгазьләре генә чәчелеп ята. Ә-ә, мич буенда бер адәм утыра икән (әллә бу да Нәкыяны күрергә килгән инде). Күзлекле, сөзәк маңгайлы, кәтүк борынлы. Аягына кигәне итек тә, ботинка да түгел, өстенә кигәне кәчтүн дә, велвет та түгел. Үзе бик спай, бик кәяз. Каз каурыена охшаган тарагы белән сирәк чәчләрен сыпыра — пеләшен томаларга тырыша. (Һи, күрмәгән ди Нәкыя синең ише таш маңгайларны!)

— Кая олагып беткәннәр бу корт чаккырлары, — дидем мин әлеге адәмнең өс-башын, төс-кыяфәтен, кыланышларын бер кат күздән кичереп чыккач.

Якты маңгай миңа табарак борылды, тимер кысалы күзлек пыялалары ялт-йолт итеп минем йөзне ялмап алды. Бүлмә машина белән ашлык иләгәндәге шикелле шылтырау авазлары белән тулды.

— Бухгалтер-рларның бар-рысын да р-рәис чакыр-рып алды.
— Корт чаккыры икән.
— Кемне чактыр-расыз кор-ртка?!
— Безнең авылда шулай корт чаккыры, дип сөйләшәләр инде.
— Кем сөйләшә шулай дип?
— Умартачы Мифтах...
— Умарталык та бар мыни әле сезнең колхозда?
— Бар.
— Умар-ртасы булгач, балы да бар-рдыр инде аның? — диде күзлекле һәм, үзе сизепме, сизмичәме, иреннәрен ялап куйды.
— Бар, ник булмасын, балы да бар! — дип гайрәт чәчтем мин,— бал келәтендә мөлдерәмә тулы җиде тәпәнебез утыра.
Бал келәтендә ике генә тәпән утыра, югыйсә. Аның да берсе төпкә төшеп килә. Ябык чыраен арыш үрентесе сыман төссез төк баскан күзлекле кешегә сер бирмәс өчен шулай тырышам мин. Әле анысы гына җитмәде, бүлтәеп торган кесәмә сугып, ачкычларымны чылтыраттым.
— Менә, абзыкаем, бал келәтенең ачкычлары да үзебезнең кесәдә.
Күзлек пыялалары сәер ялтырады.
— Кладовщик булып эшлисез, димәк?
— Ә сез үзегез кем?
— Р-ревизор.
Өстәлгә таянган кулларым балавыз кебек йомшарды, борын яфракларым юешләнде, чәч төпләрем әллә нишләп, кымырҗып тора башлады.
— Иптәш р-р-ревизор, — дип сүзгә керештем мин, тик шунда ук тотлыгып калдым.
— Әле сез үр-ртәшә дә беләсез икән,— диде ревизор һәм ач бүре баласыдай ябык, килбәтсез портфеленә үрелде, — исәп-хисап эшләрен тәгәлләгәч, бар-рып чыгар-рбыз тәпәннәр-регезне кар-рарга. Ур-рынныгызда булыгыз!
Корт чаккыры! Нәрсә көтәм, нишләп торам? Гибадулла абый яисә Нәкыя килеп кергәнче, ычкынырга, таярга кирәк моннан.
Бал келәтен әллә ачкыч белән ачтым, әллә әфсен белән — анысын хәтерләмим, уйларым икенче тәпән турында, дөресрәге, икенче тәпәндәге бал турында иде.
Корт чаккыры! Документларга ике тәпән бал, дип теркәлгән бит анда. Ә монда... Әх, корт чаккыры, тәмле тамак! Син генә яратасың балны! Кладовщик Нурсәеттән башка кеше яратмый ди аны. Менә хәзер нишләргә инде, ничек җавап бирергә?
Тәпән төбендәге балга таяк тыгып карадым. Таякка бер карыш тирәсе гәрәбәдәй сары бал сыланып чыкты. Алай, сыекланган икән бу. Сыекланыр шул, ник сыекланмасын — әнә нинди эссе көн. Әгәр көн тагын да эсселәнебрәк китсә... Әйе, көн тагын да эсселәнебрәк китсә, бөтенләй сыеклана инде бу бал, суга әйләнә...
Озын-озак уйланып тормадым, бал өстенә ике чиләк җылымса су куйдым. Тула язды тәпән. Әмма бал бик нык сыекланды. Җитмәсә, суы балдан аерылып өскә җыела башлады. Тулмаса тулмас — азрагын түгәргә кирәк. Тәпәнне кыйшайтып чиләккә балны су агызганда, идән дә юешләнеп өлгергән икән — шул юешкә басуым булды — ике аягым берьюлы таеп китмәсенме. Тәпәнем бер якка гөрселдәп барып төште, үзем икенче якка.
Бөтен келәт идәненә ялтыравыклы сыекча җыелды. Суы сеңгәч, тайгак идәнем җилем белән майлагандай үзгәреп китте. Аяк белән бассам — аяк ябыша, уч белән таянсам — учым...
Ул арада ачык ишектән келәт эченә бал кортлары кереп тулды. Саранча көтүе мени! Маңгаема да килеп бәреләләр, учларыма ябышып та безелдиләр.

Нәкъ шул чагында бусагада ике шәүлә пәйда булды. Уң яктагысында күзлек пыялалары ялтырый — бусы баягы ревизор, сулдагысы киндер кепкадан — анысы колхоз рәисе Гибадулла абый.

— Менә ул!— дип, ике генә авыз сүз әйтте ревизор һәм, кулларын бутый-бутый, урамга чыгып йөгерде.

Аның:

— Кар-равыл, кор-ртка чактыр-рды, — дип сөрән салуы келәт ихатасының теге ягыннан ишетелде.

Гибадулла абыйның да хәлләре мөшкел иде, ахры. Ул кәчтүнен башыннан ук бөркәнеп бобигы эченә кереп ауды, шоферына:

— Куала!— дип кычкырды.

Машина кузгалып киткәч, баллы эзләр калдыра-калдыра, баллы бармакларымны суыра-суыра келәттән чыктым.

Мине дә кортлар сарган иде, әле маңгаема, әле яңакларыма, әле борыныма выжлап килеп бәрелүләренә караганда, мине дә чагалар иде бугай алар. Ләкин, ни гаҗәптер, авыртуны сизми идем мин...

..................

## Укучының күңел дәфтәренә

**Үзбәк мәкальләре һәм әйтемнәре**

*Сандугачка чәчәк якын, кешегә — туган ил.*
*Туган-үскән үз йортың — ят сарайдан мең артык.*
*Бер корабта йөзүчеләр уртак җанлы булалар.*
*Бер кылычка ике кын кирәкми.*
*Кеше көзгесе — кеше.*
*Ачык ишекне дә шакып кер.*
*Арык колын ат булыр, начар юлдаш ят булыр.*
*Хаклык кылычтан үткен.*
*Кыек утырган чакта да туры сүз генә сөйлә.*
*Дөянең бөкресе яхшы, сүзнең турысы кирәк.*
*Кыюлардан үлем дә курка.*
*Дәү дөягә зур ялма кирәк.*
*Фәннәр күп, ә гомер кыска — иң кирәк фәнне өйрән.*
*Әгәр чын галим икәнсең — бөтен дөнья синеке.*
*Наданның күзе сукыр.*
*Бүрегеңне сал дигәч, бер тиңтәк муен өзгән.*
*Берәү казыган арыкның суын бик күпләр эчә.*
*Яманнарны иярткәнче, үзең яхшыга ияр.*
*Яхшы атка бер камчы, яман атка мең камчы.*
*Ясалма булган изгелек яшерен гөнаһтан яман.*
*Эт улаганны бүре тыңламый, бүре уласа — хода саңгырау.*
*Миңа атым ошамый, ә атыма иярем.*
*Үз тегермәнеңнең ташын үзең әйләндерә бел.*
*Пычкы кебек була бел — тарткан якка кис тә кис.*
*Мин тыгылмаган казанда, начар ашлар пешсеннәр.*
*Акча бар җирдә тигезлек булмый.*
*Тик дөяңне тышаулагач «аллага ышанам» дип әйт.*
*Тавыкны бер ашыйсың, йомырканы күп тапкыр.*
*Кан белән кан юылмый.*
*Түзем ишек ачтыра.*

..................

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ИҖАТ ИНТЕЛЛИГЕНЦИЯСЕ УКУЫ

КПСС өлкә комитеты каршындагы иҗат интеллигенциясе активы семинарының чираттагы дәресе булды. Анда идеология работникларының Бөтенсоюз семинар-киңәшмәсе йомгаклары турында КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев сөйләде. Ул КПССның Совет җәмгыятендәге, тынычлык өчен көрәштәге, бөтендөнья социализм системасын үстерүдәге, халыкара коммунистик һәм милли азатлык хәрәкәтендәге роле, хәзерге шартларда идеология көрәше, унберенче бишьеллыкта илебезнең социаль-экономик үсеше турындагы мәсьәләләргә тукталды, әдәбият-сәнгать әһелләре һәм матбугат хезмәткәрләре алдындагы бурычларга аеруча басым ясады.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

Чираттагы партия җыелышында коммунист язучы Мөхәммәт Мәһдиевнең иҗат отчеты тыңланды.

М. Мәһдиев үзенең планнары, тормыш һәм әдәбият турында уйлануылары белән уртаклашты. Аның иҗаты турында чыгыш ясаган С. Хәким, Ә. Еники, Р. Фәйзуллин, А. Әхмәдуллин иптәшләр әдип иҗатындагы үзенчәлекле якларны билгеләп үттеләр, үзләренең тәкъдимнәрен һәм теләкләрен белдерделәр.

## ӘДӘБИЯТ ПРОБЛЕМАЛАРЫ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

«Казан утлары» журналының түгәрәк өстәле янында КПССның XXVI съезды карарлары яктылыгында татар әдәбияты алдында торган бурычлар турында зур сөйләшү үткәрелде. Анда Г. Бәширов, Н. Арсланов, Ә. Еники, С. Хәким, З. Нури, Г. Ахунов, В. Нуруллин, Т. Миңнуллин, Р. Мостафин һәм башка әдипләр катнашты.

Сөйләшү материаллары журналның быелгы унынчы санында урнаштырылачак.

## ХӨКҮМӘТ ДЕЛЕГАЦИЯСЕ СОСТАВЫНДА

ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов СССР Верховный Советы делегациясе составында Нигериягә барды. Нигерия Федератив Республикасы Милли җыелышы чакыруы буенча оештырылган әлеге рәсми визит вакытында халыкара проблемалар һәм Совет — Нигерия элемтәләрен тагын да ныгыту мәсьәләләре турында киң фикер алышу уздырылды. Нигерия ягыннан бу сөйләшүдә күренекле хөкүмәт эшлеклеләре, Милли җыелыш лидерлары һәм депутатлары катнашты.

Соңыннан безнең делегация ил буйлап сәяхәттә булды, аерым алганда, Квара һәм Венди штатларын, Совет — Нигерия хезмәттәшлегенең мөһим объекты — Көнбатыш Африкадагы беренче металлургия комбинатын карады.

## ЧИТ ҖИРЛӘРДӘ ЙӨРЕП ГЫЙБРӘТ АЛ...

РСФСР язучыларының бер төркеме Испаниядә туристик сәяхәттә булып кайтты. Бу группа составында татар язучылары Аяз Гыйләҗев белән Марсель Галиев тә бар иде. Алар Атлантик океан һәм Урта диңгез яры буендагы Кадис, Малага, Севилья, Гранада һәм Мадрид, Толедо шәһәрләрендә булдылар, күп санлы музейларын һәм тарихи истәлекле урыннарын карадылар. Гранада шәһәрендә язучылар белән, Мадридта Испания-Совет дуслыгы җәмгыяте членнары белән очрашулар. Испаниянең бөек шагыйре Гарсиа Лорка туган Фуэнте-Вакерос авылын күрү язучыларда зур тәэсир калдырды.

Язучы Әхәт Гаффар СССР Журналистлар союзы делегациясе составында Португалия буйлап сәяхәттә йөрде. Бу делегация илнең Лиссабон, Коимбри, Эвера, Браганса, Фатима һәм башка — барысы унбишләп шәһәрендә булды. Португалия коммунистлар партиясенең үзәк газетасы «Аванте» редакциясендә кунаклар белән кызыклы очрашу оештырылды. Делегациянe шулай ук Лиссабондагы һәм башка шәһәрләрдәге Португалия — СССР дуслыгы җәмгыятьләре кабул итте.

Бер төркем РСФСР язучылары белән бергә Җәвад Тәрҗеманов һәм Мәдинә Маликова Франциягә сәяхәт ясады. Алар анда Париж, Шартр, Тур, Бурж һ. б. шәһәрләрдә булып, Бальзак, Жорж Санд, Роден музейлары һәм башка истәлекле урыннар белән таныштылар. «Европа» журналы редакциясендә танылган язучы Пьер Гамарра белән очраштылар.

## ТУГАН ТЕЛ ҺӘМ ӘДӘБИЯТНЫ УКЫТУ ТУРЫНДА

Татарстан АССР Мәгариф министрлыгы каршындагы укыту-методик Советы президиумында мәктәпләрдә татар теле һәм

әдәбиятын укыту мәсьәләләре каралды. Президиум утырышын Татарстан мәгариф министры Р. А. Низамов алып барды. Анда татар теле һәм әдәбияты дәреслекләре авторлары, Казан дәүләт университеты, Казан, Алабуга дәүләт педагогия институты галимнәре, РСФСР Мәгариф министрлыгының Татарстан филиалы фәнни хезмәткәрләре, Татарстан укытучылар белемен күтәрү институты методистлары, укытучылар катнашты.

Президиум утырышында профессор М. З. Зәкиев, фән кандидатлары А. Г. Әхмәдуллин, Г. М. Әдһәмова, Б. М. Мифтахов, М. Х. Хәсәнова, А. Х. Нуриева, И. Г. Исмәгыйлова һ. б. иптәшләр дәреслекләрнең, туган тел һәм әдәбиятны укытуның сыйфатын яхшыртуга караган эшлекле тәкъдимнәр белән чыгыш ясадылар. Республика мәктәпләрендә татар теле һәм әдәбияты фәннәрен укытуны яхшырту турында карар кабул ителде.

## ДРАМАТУРГЛАР КИҢӘШӘ

Күптән түгел СССР Культура министрлыгы һәм Бөтенроссия театр җәмгыяте драматургларның тәрҗемәчеләр белән берләштерелгән Бөтенсоюз семинарын уздырды. Анда Татарстаннан драматург Ризван Хәмид катнашты. Семинарда аның «Иске йорт кешеләре» исемле сатирик комедиясе укып тикшерелде һәм уңай бәя алды. Ул илебез театрларында куюо өчен тәкъдим ителәчәк.

Дубултыда драматургларның Бөтенроссия семинары булып узган иде. Анда Татарстаннан Диас Вәлиев һәм Ризван Хәмид катнашты.

## МУЗЫКА БӘЙРӘМЕНДӘ ҚАТНАШТЫЛАР

ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе композитор Ренат Еникеев, җырчы Миңгол Галиев һәм скрипкачы Шамил Монасыйпов Уфада үткәрелгән Совет музыкасы бәйрәмендә катнаштылар. Анда илебезнең күренекле композиторлары әсәрләре белән бергә Р. Еникеевның «Кокушкино ягы» (С. Хәким сүзләре), «Синең эзләр» (Роберт Әхмәтҗанов сүзләре), «Тигез атлыйк» (Ф. Сафин сүзләре) дигән җырлары, скрипка һәм фортепиано өчен язган әсәрләре яңгырады. Кунаклар Нефтекамск, Янаул хезмәтчәннәре белән очрашуларда катнаштылар, Башкортстан телевидениесе аша чыгыш ясадылар.

## ӘЛМӘТ ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНДА

Татарстан Язучылар союзының Әлмәт бүлеге һәм «Әлмәт» әдәбият берләшмәсе членнарының гомуми җыелышында партиябезнең XXVI съезды карарлары яктылыгында язучылар алдында торган бурычлар турында сөйләшү булды. Җыелышта бүлекнең җаваплы секретаре Ә. Маликов, язучылар К. Булатова, Г. Афзал, Ю. Әминов, Ф. Гыйльметдинов чыгыш ясады.

Әлмәт шәһәренең Техника йортында әдәби-музыкаль кичә үткәрелде. Кичәне халык депутатларының Әлмәт шәһәр Советы башкарма комитеты председатель урынбасары Фәрит Мөхәммәтшин ачты. Татар поэзиясенең үткәне һәм бүгенгесе турында шагыйрь Ә. Маликов сөйләде. ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Г. Афзал, Э. Мөэминова, К. Булатова, Ә. Маликов, яшь шагыйрьләр һәм «Әлмәт» әдәбият берләшмәсе членнары Венера Туктарова, Котдус Батыров, Фәһимә Галиева, Илдар Хөснетдинов, Нурсибә Габдрахманова, Гөлгенә Маликова, Зилә Ногманова үзләренең шигырьләрен укыдылар.

Татарстанның халык артисткасы Зәкия Туишева шагыйрә Сажидә Сөләйманова һәм башкорт шагыйре Әнгам Атнабаев әсәрләрен башкарды.

Кичәнең икенче өлешендә Ф. Яруллин исемендәге музыка училищесының халык уен кораллары оркестры, шәһәр һәм район үзешчәннәре катнашында зур концерт булды.

Фойеда язучыларның автографлары белән китап сәүдәсе оештырылды.

Әлмәт нефтьчеләренең Техника йортында ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты шагыйрь Гамил Афзалга 60 яшь тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә булды.

Кичәне кереш сүз белән Әлмәт язучылар оешмасының җаваплы секретаре шагыйрь Әдип Маликов ачты.

Юбилярны Әлмәт шәһәр партия комитеты секретаре Маргарита Михайловна Петрова, Татарстан нефтьчеләре исеменнән «Татнефть» берләшмәсенең генеральный директоры урынбасары Үзбәк Саттаров котлады. Ү. Саттаров шагыйрьгә берләшмә һәм Татарстан нефтьчеләре профсоюзы өлкә комитетының Почет грамотасын тапшырды. Татарстан Язучылар союзы исеменнән шагыйрь Рөстәм Мингалимов, Чаллы язучылар оешмасы җитәкчесе шагыйрь Разил Вәлиев, Лениногорск нефтьчеләре һәм әдәбиятчылары исеменнән язучы Шамил Бикчурин, Азнакай нефтьчеләре исеменнән Нур Әхмәдиев һ. б. котлау сүзләре әйттеләр. Партиянең Сарман райкомы пропаганда бүлеге мөдире Дамир Гарифуллин, ВЛКСМның Әлмәт шәһәр комитеты секретаре Галина Былинкина, Әлмәт татар дәүләт драма театры директоры Марат Атнагулов, Татарстан нефтьчеләре профсоюзы өлкә комитеты вәкиле Йосыф Нәфиков шулай ук җылы котлау сүзләре белән чыгыш ясадылар. Гамил Афзал җавап сүзе итеп яңа шигырен укыды.

Кичәнең икенче өлешендә шагыйрь Г. Афзал сүзләренә язылган җырлар, аның шигырьләре яңгырады. Концертта РСФСРның халык артисты, ТАССРның Г. Тукай

исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Айрат Арсланов, Татарстанның халык артистлары Зәкия Туишева, Рамазан Ихсанов, Әлмәт драма театры артисты Зәкәрия Гыйлемов һәм үзешчән сәнгать осталары катнашты.

Фойеда язучыларның автографлары белән китап сәүдәсе оештырылды.

## ЧАЛЛЫ ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНДА

Кама буенда автомобиль гиганты корылу бу регионның экономик йөзен үзгәртү белән бергә, кешеләрнең рухи дөньясында да зур йогынты ясады. КамАЗда үзенчәлекле бер цех — әдәбият цехы да төзелде. Заводларның каркаслары яңа корылып килгән чакта ук әлеге «цех» үзенең әдәби продукциясен бирә башлаган иде инде. КамАЗ көннән-көн зуррак колач алды, аның проблемалары катлауланә, колачы зурая барды. Көн тәртибенә менә шул масштабларга тиң әсәрләр язу бурычы куелды. Чаллы язучылар оешмасының гомуми җыелышында сүз, нигездә, шул бурычлар турында барды. Оешманың җаваплы секретаре шагыйрь һәм прозаик Разил Вәлиев әдәби берләшмәләрне җанландыру, өметле авторлар белән индивидуаль эш алып бару, укучылар белән тыгыз элемтәдә тору, КамАЗ проблемаларына тирәнрәк үтеп керү мәсьәләләренә тукталды. Чыгыш ясаучылардан Э. Касыймов Р. Хисмәтуллин һ. б. язучыларның активлыгын күтәрү юллары турында фикерләре белән уртаклаштылар.

Яңа шәһәрдәге китапханәнең уку залында язучы Эдуард Касыймов әсәрләре буенча укучылар конференциясе уздырылды. Конференциядә чыгыш ясаган завод эшчеләре, китап сөючеләр, яшь язучылар әдип иҗатының КамАЗ проблемаларына багышланган булуына басым ясап сөйләделәр.

Соңыннан Э. Касыймов сорауларга җаваплар бирде.

Туган якны өйрәнү музееның «Кызыклы очрашулар клубы» үзенең чираттагы утырышын Чаллы язучылары иҗатына багышлаган иде. Язучылар оешмасының җаваплы секретаре Разил Вәлиев, яшь язучылар М. Сафин, В. Мартынов, Н. Дмитриева, Р. Заһретдинова, М. Волостнов КамАЗ проблемаларының бүгенге әдәбиятта чагылышы турында сөйләделәр, үз әсәрләрен укыдылар.

Яңа шәһәрдәге 54 нче эшчеләр тулай торагында булып узган кичә «Җирдә кеше булу җиңел түгел» дип аталган иде. Анда чыгыш ясаган язучылар Р. Вәлиев, А. Сычев, В. Атнагулов, Н. Чигвинцев, М. Сафин яңа кеше формалашуында әдәбиятның тоткан роле турында сөйләделәр. Эшчеләр үз тормышларыннан мисаллар китерделәр, әдәбият һәм тормыш арасындагы бәйләнеш мәсьәләләре белән кызыксындылар.

## БОРЫНГЫ БОЛГАР ТУФРАГЫНДА

Ел саен диярлек Түбән Кама эшче-иҗат яшьләренең борынгы Болгарга сәфәре күркәм бер традициягә әверелде. Ул «Кама таңнары» әдәби берләшмәсе (җитәкчесе Рахмай Хисмәтуллин) тарафыннан оештырыла.

Быел яшьлек шәһәренең яшь язучылары, үзешчән артистлары, туган як тарихын өйрәнүчеләр, «Әллүки» балалар театрының нәни артистлары — барлыгы 140 лап кеше Болгар ядкарьләре янында язучы Нурихан Фәттах, Казан тел, әдәбият һәм тарих институтының өлкән гыйльми хезмәткәре археолог Равил Фәхретдинов белән очраштылар. Кунакларны КПССның Куйбышев райкомы секретаре С. Низаметдинова каршы алды.

## ШАГЫЙРЬНЕҢ ТУГАН ЯКЛАРЫНДА

Минзәлә районының Күзкәй авыл Культура йортында шагыйрь Рәшит Гәрәйгә 50 яшь тулу уңаеннан зур әдәби бәйрәм үткәрелде. Районның партия, совет оешмалары җитәкчеләре, хезмәт иярләре вәкилләре, педагогия училищесы һәм Минзәлә татар дәүләт драма театры коллективлары юбиляр якташлары кайнар котладылар, аңа яңа иҗат уңышлары теләделәр. Кичәдә Рәшит Гәрәйнең төрле елларда язылган шигырьләре, аның сүзләренә иҗат ителгән җырлар яңгырады.

Шагыйрьнең иҗат бәйрәмендә Казаннан килгән каләмдәшләре Габдулла Шәрәфи, Мәхмүт Хөсәен, Фәннур Сафин, Татарстан Язучылар союзының Чаллы бүлегеннән Разил Вәлиев, Нәҗип Мадьяров, Газиз Кашапов, Хәниф Хөснуллин, шулай ук җырчы Рафаэль Ильясов һәм яшь композитор Риф Гатауллин катнашты.

## АРТИСТ ЮБИЛЕЕ

Габдулла Кариев туган төбәктә, Октябрь районының Күлбай Мораса авылында, татар профессиональ театр сәнгатенең беренче бразналарын сызган артистның 95 еллыгына багышланган кичә үткәрелде. Аны «Алга» колхозының партком секретаре Ә. Насыйбуллин ачты. Сәнгать фәннәре кандидаты Хәсән Гобәйдуллин, СССРның халык артисты Габдулла Шамуков Г. Кариевның татар сәхнәсе тарихында тоткан урыны турында сөйләделәр. 1908 елда граммофон тәлинкәсенә язып алынган яшь Кариев тавышын якташлары аеруча дулкынланып тыңладылар.

## ЯЗУЧЫ ИСЕМЕ БЕЛӘН

Якташлары, танылган татар совет язучысы Габдрахман Әпсәләмов исемен мәңгеләштерү нияте белән, Мордва АССРның Иске Аллагол авылы колхозчылары үзләренең гомуми җыелышларында колхозга

эдип исемен биру турында бертавыштан карар кабул иттеләр.

Хезмәт иялəре депутатларының район Советы башкарма комитеты әлеге елның «Трудовик» колхозын алга таба Г. Әпсәләмов исемендәге колхоз дип атарга диген карарын раслады.

## ХЕЗМӘТЛӘРЕН ХӨРМӘТЛӘП

СССР Верховный Советы Президиумы Указы белән, совет әдәбияты өлкәсендәге хезмәтләре өчен һәм юбилейлары уңаеннан шагыйрь Гамил Афзал, тәнкыйтьче һәм әдәбият белгече Рафаэль Мостафин «Почет билгесе» ордены белән бүләкләнделәр.

Филология фәне өлкәсендәге хезмәтләре өчен СССР фәннәр академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты өлкән хезмәткәре, филология фәннәре докторы, профессор Гали Мөхәммәтгалиевич Халитовка РСФСР Верховный Советы Президиумы Указы белән, «РСФСРның атказанган фән эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет культурасы өлкәсендәге хезмәтләре өчен язучы Геннадий Александрович Паушкинга, РСФСР Верховный Советы Президиумы Указы белән, «РСФСРның атказанган культура работнигы» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе артисты Айрат Арслановка, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисткасы Рәшидә Җиһаншинага, М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры солисты Ренат Ибраһимовка, РСФСР Верховный Советы Президиумы Указы белән, «РСФСРның халык артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

## АРАЛ ДУЛКЫННАРЫ

Каракалпакстан әдәбияты һәм сәнгате көннәре уңае белән Татарстан китап нәшриятында «Арал дулкыннары» исемле китап басылды. Бу җыентыкта классиклардан башлап яшь язучыларга кадәр булган каракалпак прозасы һәм поэзиясе вәкилләре сүз ала. Полиграфик яктан югары сыйфатлы итеп эшләнгән әлеге басманы төзүче, кереш сүз һәм белешмәләрне язучы — Лирон Хәмидуллин. «Без СССР халыкларының әдәбиятларының аралашып, бер-беренә булышып, ярдәмләшеп яшәвен күрәбез,— дип яза ул.— Укучы кулына керәчәк бу китап та шуның бер матур күренеше».


## ГАСТРОЛЬЛӘР ҖӘЕ


Июнь аенда Ленинград дәүләт академия комедия театры гастрольләре булды. Кунаклар В. Маяковский пьесасы буенча эшләнгән «Мунча», С. Ласкин пьесасы буенча «Акселератлар» һ. б. спектакльләрне күрсәттеләр. Ленинград театры гастрольләре башкалабыз тамашачыларында зур кызыксыну уятты.

# Ватаным

Рәшит **АБДУЛЛИН** музыкасы

Разил **ВӘЛИЕВ** сүзләре






Инде мин ничәнче мәртәбә
Гасырлар китабын актардым.
Күпме яу, сугышлар аркылы
Син җиңеп чыккансың, Ватаным.

Кушымта:

Сез кайсы халыктан? — дисәләр,
Батырлар исемен атадым.
Батырлар утларга керделәр,
Тик исән булсын, дип, Ватаным.

Илемнең хуҗасы булганга,
Мин җиргә нык басып атладым.
Кешеләр күтәрде Ватанны,
Кешене күтәрде Ватаным.

Кушымта.

Мин күрдем, төннәрне таратып,
Дөньяда алсу таң атканын.
Яктыра, аллана җир йөзе...
Таң булып нур сибә Ватаным.

Кушымта.

## ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАР!

Билгеле булганча, сентябрь аенда вакытлы матбугатка, шул исәптән «Казан утлары» журналына да, 1982 ел өчен язылу башлана. Укучыларның барысы да яхшы белгәнлектән, бу хакта кабат искә төшереп тормасак та ярар иде. Әмма, кызганычка каршы, һәр елны, эш узганнан соң, журналга языла алмый калган иптәшләрдән дәгъвалы хатлар яварга тотына. Шунлыктан язылу шартлары белән алдан ук таныштырып куюны кирәк таптык.

«Казан утлары» Бөтенсоюз каталогына кертелгән, журналның күрсәткеч саны, ягъни индексы — 73210. Димәк, аңа Советлар Союзының теләсә кайсы шәһәр яки авылында язылырга мөмкин. Бу эшне почта бүлеге һәм «Союзпечать» агентлыгы хезмәткәрләре башкаралар.

Язылуда төрле аңлашылмаулар чыкмасын өчен, аның чарасына алдан керешү яхшы.

Инде журналга язылган укучыны нинди шатлыклар көткәнен дә әйтеп үтик. 1982 ел — «Казан утлары» журналы тарихында аерылып торачак, чөнки шушы елның май аенда аның чыга башлавына 60 ел тула. Бу — әдәбиятыбыз һәм, гомумән, республикабыз культурасы үсеше тарихында зур вакыйга. Татарстан язучылары бу тантанага багышлап иң яхшы әсәрләрен тәкъдим итәрләр, әлбәттә. Редакциядә аннан тыш та шактый мул кульязмалар тупланды. Алар арасында укучыларга яхшы таныш өлкән әдипләрнең проза әсәрләре дә, шигъри көлтәләр дә, яшьләр иҗатыннан күркәм үрнәкләр дә бар.

Укучылар хәтерлиләрдер: үткән ел журналның аерым бер санында илнең башка өлкәләрендә яшәүче якташларыбыз иҗатына багышланган сәхифәләр бирелгән иде. Бу традиция алда да дәвам иттереләчәк, якташлар иҗатына да, аларның хезмәттәге батырлыкларын чагылдырган язмаларга да игътибар зур булачак.

Очерклар бүлеге укучыларны Татарстанның промышленносте, авыл хуҗалыгы һәм культурасындагы яңалыклары, мөһим мәсьәләләре, шул өлкәләрнең уңганнары белән таныштырып торачак.

Тәнкыйть мәкаләләрен язуга әдәбиятыбызның иң сәләтле белгечләре тартылачак.

Җыр яратучылар республика композиторларының яңа әсәрләре белән танышып барачаклар.

Кыскасы, журналның 1982 елда чыгачак һәр саны укучыга бай мәгълүмат, зур рухи байлык китерер. Шулардан мәхрүм булып калмас өчен, журналга язылу чарасын алдан кайгыртырга киңәш бирәбез.

Редакция үзе исә подписка белән шөгыльләнми. Бу эштә килеп чыккан низагълар хакында редакциягә хатлар язу урынсыз.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ